# Казан утлары

12

ДЕКАБРЬ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

12
ДЕКАБРЬ
1974

## Бу санда

Д. ЗӨБӘЕРОВА. Кыр чәчәге. Повесть . . . . 3
Р. ГӘРӘЙ. Васыятен дә әйтеп калдырмаган. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Х. ХӘЙРУЛЛИН. Ургыл. Роман . . . . . . . . 47
Ш. АНАК. Тыйнак табын. Шигырьләр . . . . . 92

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Г. РАМАЗАНОВ. Райнис. Шигырьләр . . . . . 94
Б. ИСХАКОВ. Тукай. Шигырьләр . . . . . . . 96

ШӘЙХИ МАННУРГА 70 ЯШЬ

З. РӘМИЕВ. «Яшь алмыйм шул мин янмыйча» . . 98
Ш. МАННУР. Гомер белән гомер арасы. Поэма . 100

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 109
Ш. САДЫЙКОВ. Председатель . . . . . . . . 111
Л. ИХСАНОВА. Сәрвәрнең туган көне . . . . 120
Г. ШӘЙХИЕВ. Буа каһарманнары . . . . . . . 124

СӘНГАТЬ

Ш. РАХМАНКУЛОВ. Заһид Хәбибуллин . . . . 135

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ф. ИБРАҺИМОВА. «Тәрбиятел этфаль» һәм «Ак юл» журналларында балалар әдәбияты . . . . 145

ӘДӘБИ КОНСУЛЬТАЦИЯ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Сурәтле фикер . . . . . . 152

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. ШӘРӘФЕТДИНОВ. Арадан бер һәйкәл . . . 158
И. ВӘЛИТОВ. «Эпик жанрлар» . . . . . . . . 161
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Китап укыганда . . . . . . . 163

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**И. АБДУЛЛИН. Киң колачлы галим** . . . . . . **166**

**Р. ШИРИЯЗДАНОВ. Атаклы гармунчы-музыкант** . **167**

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Ш. ГАЛИЕВ. Курыкма, тимим!** Шигырьләр . . . **169**

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Киндзюлис килә дә әйтә...** Мәзәкләр . . . . . **175**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . **181**

**1974 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр** . **185**



Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.



Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/IX-1974 ел. Басарга кул куелды 11/X-1974 ел. ПФ 09130. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн. изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87.000 экз. Заказ Ю-233, Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.



© «Казан утлары». 1974 ел.

Диләрә Зөбәерова

# КЫР ЧӘЧӘГЕ

ПОВЕСТЬ

Тәнәфес вакытын туры китереп, укытучы Ләйсәнне телефонга чакырдылар. Районнан шалтыраталар икән. Аның иртәнге якларда ук мәгариф бүлегенә килеп чыгарга тиешлеген әйттеләр.

Чакыру житди яңгырады. Сәбәбен-нисен тикшереп тормастан, кыз ашыгып юлга җыенды.

Апрель урталары булса да, көн суык. Төньяктан авышкан әче салкын инде март башларында ук сыза башлаган карны яңадан чиратты. Ташу төшүен көткән яшьләр табигатькә хәтта үпкәләрен белдерә башладылар.

— Юкка чапаланасыз,— диде аларга гомер иткән картлар,— язгы бозга ястык калынлыгы булса да ышанма, көннәре шундый аның. Бүген болай, иртәгә тегеләй, сына да куя.

Һәм шулай булды да. Кичке зәһәр суыкны куып, көпшәкләнгән карларны ялмаштырып, җылы җил чыкты. Ләйсәнне утыртып киткән автомобиль районга җитәрәк шып туктады.

Алда җәйге чәлләрдә тараеп кала торган инеш иңкүлеге җәйрәп ята. Кырык яктан агып төшкән гөрләвекләр аны олы күлгә әверелдергән. Аркылы салынган күперчек уртада кыйшайган көймә сыман тирбәлеп тора. Моңа кадәр шул күпер астында мыштым гына агып яткан исемсез-нисез инеш бүген, гүя үзенең кемлеген күрсәтергә җыенгандай, боз өстенә калкып чыккан да олы юлны буган. Янәсе, күрәсезме, ул нинди кодрәтле: тели икән әллә кемнәрне дә юлдан туктатыр. Ләйсән бу минутларда әнә шул инешне хәтерләткән берәүне исенә төшерде. Мондый кәпрәюләр шундый көйсез килгән язда гына була торган кысыр шапырыну ул.

— Булмый, — диде шофер Кәшиф абый, сәгатенә карап. — Егерме биш чакрымны биш сәгатьләп килсәк, бу араны биш тәүлексез дә узып булмас. Борылмый булмый.

— Ә мин барып карыйм әле, — диде Ләйсән калын кашларын җыерган шоферга, — көтәләр бит, монда чаклы килгәч инде.

— Кая ашкынасың? — диде янәшәдә калын портфелен кочаклап утырган авыл Советы хисапчысы,— төнлә су саркый төшәр, иртәгә иртәрәк кыймылдарбыз.

Кыз барыбер сүзен сүз итте. Әйләнә-тулгана, бата-чума мәгариф бүлегенә барып кергәндә, инде эш сәгате тәмамланып килә иде.

— Менә үзе дә килде, — диде Габбасов, каршында утырган ят кешене Ләйсән белән таныштырып, — иптәш Мөслимова дигәнебез шушы була инде.

Бик пөхтә киенгән бу озын буйлы кунак министрлыктан килгән вәкил булып чыкты. Кунакка Ләйсәннең татар кызларына хас чандыр гәүдәсе, коңгырт чәчләре, кершәнгә буялмаган пакь йөзе, шомырттай кара күзләре гаҗәп сөйкемле булып күренде.

Баштарак Казан кешесеннән уңайсызланса да, соңга таба аның каш астыннан гына сынап утыруына ачуы килеп, Ләйсән кыюланып китте.

— Менә, — диде ул, урта яшьләрне узып баручы мөдирнең кабаклары сәлперәя башлаган күзләренә карап, — сез чакырдыгыз, мин килдем. Шуннан?

— Күреп торам, — диде мөдир, Ләйсәнгә каршысына утырырга ишарәләп, — сезнең белән сөйләшәсе бик җитди сүз бар, сеңел, ягъни иптәш Мөслимова. Баштук гафу үтенәм юл өзек чакта чакырып алуыбыз өчен!..

— Гафу, гафу!..

— Язгы ташудан да курыкмый юлга чыккан мондый кыю кыз, шаять, безнең ышанычны аклар, — диде мөдир, Ләйсән белән сөйләшкән җиреннән вәкилгә борылып.

Вәкил, анысы бик дөрес, тик менә үзе ни әйтер, димәкче иде, тыелып калды. Мәсьәләне хәл итүне кызның үз ирегенә куярга ярамас. Шуңа күрә, кыска гына паузадан соң, дөрес, дөрес дип мөдирнең сүзен генә куәтләп алды.

Мөдир сүзне озакка сузмый гына мәсьәләнең асылын әйтергә ашыкты.

— Безгә инспектор кирәк. Бик кирәк. Ашыгыч кирәк! — диде ул, янадан Ләйсәнгә текәлеп.

Ләйсән көлемсерәп куйды:

— Тиешле кешесе табылмагангамы әллә?

— Нәкъ тиешле кешесе табыла кебек. Инспектор өчен кирәк булган һәр ике нәрсәгә дә ия сез: дипломыгыз бар, тәҗрибәгез җитәрлек.

— Нәрсә әйтергә теләгәнегез аңлашылды, — диде Ләйсән, — димәк, хәзер мин уйларга, уйланырга һәм иртәгә иртән шуның нәтиҗәсен сезгә кереп әйтергә тиешмен.

Мөдир белән вәкил елмаешып куйдылар. Кызның тапкырлыгы ошады аларга.

Башланган сүз Ләйсән чыгып киткәч тә дәвам итте.

— Кандидатурага тел тидерә торган түгел, әйбәт күренә, — диде вәкил, — тик...— «Тик»тән соңын әйтеп бетермичә сүзне икенчегә борды, эш стажын сорады.

— Җиденче елын укыта. Институтны читтән торып тәмамлады. Менә икенче ел инде укыту бүлеге мөдире булып эшли, — диде Габбасов.

— Алары әйбәт икән икәнен дә, тик бер тоткарлык бар бит әле. Кыз сылу күренә. Аңа кызыгып йөрүчеләр берәү генә түгелдер. Сайлар мөмкинлеге бар дигән сүз. Кыскасы, кияүгә чыгар чагы җиткән аның. Балалы хатыннарга инспектор булуы кыен. Бер айданмы, бер елданмы, икенче кандидатура эзли башларга туры килмәсен, дияем.

Габбасов министрлыктан килгән инспекторның бик җитди бу фикеренә җиңел генә җавап та бирде:

— Ирләр алдында бик эре кылана ди ул. Андыйлар кияүгә ашыкмыйлар...

Ләйсән мәгариф бүлегеннән уйланып чыкты. Бу хезмәтнең вазифалары аңа азмы-күпме таныш иде инде. Инспектор, нәкъ язучы Чехов әйткәнчә, һәр яктан да гүзәл кеше булырга тиеш.

Ул — үрнәк кеше. Бусы — теләсә кайсы укытучы яттан белә торган

билгеле кагыйдә. Инспектор иң әйбәт укытучы дигән сүз ул. Монысын Сәфәр абый әйтте.

Пенсионер укытучы Сәфәр Батыршин Ләйсәннең элекке остазы, кыз аның белән һаман да аралаша, киңәшә. Менә бүген дә мәгариф бүлегеннән чыккач ук аларга китте. Сәфәр ага Ләйсәннәргә тел-әдәбият укытты. Ләйсәннең дә әдәбиятчы булып китүенә аның тәэсире тими калмагандыр. Үтә яратып тыңлый иде шул ул аның дәресләрен.

Сәфәр ага Казан педагогия институтында укыган. Шул чакта әдәби җомгаларга йөргән, атаклы язучыларның күбесен күреп белгән. Хәтта үзләреннән кул куйдырып алган китаплары да байтак. Үз-үзен тотышы да, кием-салымы да гаҗәп гади шул абыйның. Аның алмаш-тилмәш кия торган буй-буй күлмәкләре бар. Шуларның якасын күк галстук белән буа да иңенә күгелҗем пинжәк сала. Сугыштан кайткан көнне үк үзенең дары исе сеңгән хәрби киемнәрен мичкә дөнгечләп тутырган да ут төрткән дип сөйлиләр... «Нигә әрәм итәсең кием-салымны?» дигән сорауларына «Күз алдымда тормасын, яңадан киясе булмасын», — дип җавап биргән, имеш. Дөрестер, чөнки аның мәктәптә бер генә мәртәбә дә яшел гимнастеркадан, галәфи чалбардан күренгәне булмады. Менә шундый үзенчәлекле кеше ул Сәфәр абый. Ул вакытның кадерен белә. Кырык биш минутның бер генә секундын да әрәм иттерми. Класс ишегеннән җәһәт кенә килеп керә дә өстәлгә узышлый ук исәнләшергә, кабатлыйсы дәресне искә төшерергә өлгерә. Исемлек барлап тормый, буш парталарга күзе төшсә, бер ара табып, журналга билге төртеп куя. «Кем килмәгән, ни өчен килмәгән?» кебек сорауларын укытучылар бүлмәсенә чыккач класс җитәкчесенә бирә.

Сәфәр абый Ләйсәннәр мәктәбенә мәгариф бүлеге аппаратыннан күчте. Ул озак еллар буе инспектор булып эшләгән. Шуңадыр, күрәсең, укытучыларның яше-карты аны зурлыйлар. Әле генә институт тәмамлап кайткан Дилбәр апа бигрәк мохтаҗ аның ярдәменә. Балалар шаулый башладымы, дәрес уртасы дип тормый, килеп ишек кага да аны чакырып чыгара. Менә стена аркылы ишетелгән гүләү тынып кала. Сәфәр абый «сабакларын» укыта тегеләрнең... Озак та үтми, ул берни булмагандай яңадан класска кереп, ишекле-түрле йөреп яңа дәрес аңлата башлый. Шундый чакларда ул Ләйсәнгә тумыштан укытучы булып туган, тырнак очына кер кундырмас, пакь җанлы кеше булып тоела һәм аңа охшарга теләп хыяллана иде. Хәер, мәктәп елларында күңеленә якты нур сызучылары аз булмады Ләйсәннең. Үзе укытучы булып эшли башлагач күңеле нечкәргән бер көнне көндәлек дәфтәренә үрелде. Әмма тыелып калды, кайчандыр кайсыдыр әдипнең: «Мин көндәлекләр алып бармыйм, йөрәк аша үткән вакыйгалар болай да хәтердә кала. Ә кирәкмәстәйләре, орлык җилләткәндә очкан кибәк кебек, барыбер онытылып бетә» дигән юлларын искә төшерде һәм дәфтәрен читкә этәрде, язып куясы уйларын хәтеренә сеңдерде.

Сәфәр абыйсының: «Соң син, иптәш укытучы, укытучы галиҗәнабләрне чын күңелдән ихтирам итәсеңме?» дигән сүзенә ул әнә шул күңелләндәгеп әйтеп бирде.

— Укытучым! Мәктәп елларында илаһи бер зат булып тоела идең син миңа! Кыңгырау чыңын мин синең аваз итеп ишетәм. Класска сәгатендә-минутында керергә тиешлегенә төшенеп түгел, сине рәнҗетмәс өчен керә идем. Кайбер дәресләрне дә акыл белән аңлап түгел, синең алда кызармас, сине ачуландырмас өчен хәзерли идем. Баксаң, әчке тәртип кагыйдәләрен генә искә төшертеп, гел әйбәт булырга, күп итеп гыйлем җыярга, ялгышмаска өндәп торучы рәсми вәкил генә түгел, гади бер табигый кеше икәнсең. Җаның да, йөрәгең дә олы. Син әти дә, син абый да, син сабый да була аласың икән...

— Лэкин шуны онытма, иптэш житэкче, энэ шул хөрмэтле укытучыны куркытырга, оялтырга хакың юк синең. Ул син уйлаган сабый түгел, олы кеше. Ул синең, нэкъ бая әйткэнеңчэ, җаның, йөрэгең барлыгын тойсын. Артык үз дэ итмэсен, санласын, дэрэжэңне күрсен, зурласын, — диде Сэфэр абыйсы, Лэйсэннең киңэш сорап ялварган күзлэренэ карап, — шул сыйфатларга ия була алсаң, ризалаш!

Кыз уйга калды. Ул остазының гадэтен яхшы белэ. Мондый житди сорауга чэчрэп җавап биргэнне яратмый. Лэйсэн бу минутларда, үзенең киләчәк язмышыннан бигрэк, Сэфэр абыйсы турында уйланды, шундый акыллы киңэшчең булу зур бэхет бит ул.

Аштан соң Суфия апа бизэкле касэлэргэ салып җимеш суы китерде.

— Сизденме җиңгэңнең табиплыгын? — диде Сэфэр абыйсы, сөйкемле карчыгының сыен хуплап. — Мондый житди сөйлэшүлэрдэн соң ул мине хуш исле куе чэйдэн мэхрүм итэ. Йокысы качмасын, дию инде.

Суфия апа кунакка моңсу гына карап алды. Лэйсэннең күңелендэ шик яралды. Абыйсының суырылып ябыгуына күрешкэч үк игътибар иткэн иде инде ул. Сэламэтлек какшау билгесе түгелме соң болар?

Суфия апа — поляк кызы. Сэфэр абыйсы аны сугыштан алып кайткан бердэнбер трофеем син минем дип шаярта. Мондый чакта Суфия апа да авыз ачып калмый:

— Трофей бушка төшэ ул, э син мине катынлыкка ялварып, ялынып алдың.

— И карчык, анысы мактанма инде, — ди карты елмаеп, — уртак сэбэплэр аркасында кавыштык. Мине телең белэн алдасаң, мэрхүмэ энине динең белэн шаккатырдың.

Монысын шулай аңларга кирэк: Сэфэр абыйның энисе, килен белэн күрешкэч үк, үпкэлэп, улына борылып: «И улым, нэселдэ-нэсэптэ юк эшлэрне мэйтэрден, хатының мэржүшкэ түгелме соң?» — дигэн. Суфия апа мөселман поляк кызы икэн. Ул аңа мэкамь белэн бер дога укып жибэргэн. Шуннан соң гына гайрэтле кайнана тэүбэ-эстэгъфируллаcына килгэн. Бу имеш-мимеш түгел, Сэфэр абыйның үз авызыннан ишетелгэн кызыкларның берсе иде... Иде дияргэ генэ калды шул инде...

Лэйсэннең зирэк акыллы остазы белэн соңгы очрашуы иде бу. Язгы ташулар тынып, ерганаклар корый башлаган көнне район газетасында некролог басылып чыкты. Кара белэн каймаланган җыйнак кына хэбэрдэ Сэфэр абыйсының озакка сузылган каты авырудан соң вафат булуы турында әйтелгэн иде. Озакка сузылган дигэн юллар Лэйсэнне тетрэтеп жибэрде. Шул тикле дэ ихтыяр көче булыр икэн кешедэ. Ул бит авыруыннан беркайчан да зарланмады. Эчтэн генэ сызып йөргэн икэн.

Кайгыдан каңгырап калган Суфия апаның үтенечен кире кагу мөмкин түгел иде. Лэйсэн үзенэ аерым фатир алганчы, аның янына күчеп килде. Шулай итеп, ялгыз калган Суфия апа, кайчандыр үзенең кадерле картын көткэндэй, кызның мэктэплэрдэн арып кайтып керүен көтэ башлады. Э яңа инспектор авылларга еш йөри иде.

Мэктэпкэ кунаклар килеп төште. Тэнэфескэ агылучы балалар, тар коридорның ике ягына сыенып, аларга юл бирделэр.

— Күрдегезме? — диде арада калкурак күренгэн бер чая малай, янындагыларга телен чатлатып, — апалар-абыйлар утка басалар икэн бүген, тикшерергэ килгэннэр ич, теге озын абый башлыклары аларның.

— Рэхим итэсез! — диде директор, урыныннан торып, мэгариф бүлегеннэн килеп төшкэн иптэшлэргэ. — Хэбэрегезне алдык, көттек. Чишенегез.

Мөдир Габбасов пыяла шкафны көзге итеп төзэтенэ башлаган инспекторга да, бөгелеп туфлиларын алмаштырып маташкан методистка

да гаҗәпсенеп карап алды. Ләйсән бу карашны бик йөгерек укыды: «Кайсы сер тотмасыгыз житкерде боларга киләсебезне?» дигән сүз иде бу. Директор чыгып китүгә, Ләйсән моңа җавап та биреп өлгерде:

— Укытучылар газетасында укыдым, фронталь тикшерүләр алдан хәбәр итәлергә тиеш!

Мөдир кинаяле елмайды:

— Әзергә-бәзер генә килеп төшү күңеллерәк, әлбәттә.

Ләйсәннең җавабы бу юлы да хәзер иде:

— Бер тәүлек эчендә иң хәйләкәр укытучы да безнең күзне буарлык эш башкара алмый.

Мөдир Ләйсәннең туры әйтә торган гадәтен ишетеп белә. Сүз куертып маташу килешмәс, диде ул эченнән генә. Шул арада яшь инспектор үзенең тәкәллефләнә белүен дә күрсәтергә өлгерде. Алдан әзерләнгән план буенча, тикшерү комиссиясе стенадагы дәрес расписаниеләрен өйрәнә иде. Яшь инспектор бу мәктәптә татарча һәм русча тел-әдәбият дәресләренең укытылышын тикшерәчәк.

— Мин хәзер бишенче «а» классына керергә, аннары унынчы класста татар әдәбияты дәресендә катнашырга тиеш,— диде ул янәшәсендәге иптәшләренә.

Бу фәнне алып баручы юантык укытучы журналлар шүрлегендә актарына иде. Инспекторның әлеге сүзен ишетүгә сискәнеп китте һәм ыспай гына атлап ишеккә юнәлде.

— Сәкинә апа, — диде Ләйсән, үз кешегә эндәшкәндәй аны туктатып, — рөхсәт итсәгез, мин сезнең дәресегездә утырырга телим.

— Булмый, җаным, — диде Сәкинә апасы, тавышларын уйнаклатып,— сочинение яздыртам мин бүген алардан. Балалар каушарлар.

Астыртын мөдир бу күренешнең дә шаһите иде. Мыек аслап кына шуны уйлап алды: яшь инспекторның кече күңеллелегеннән ничек оста файдалана...

Ул арада кыңгырау да шалтырады. Икенче дәресне сайлар вакыт узган иде инде. Нәүмизләнгән Ләйсән урталыкта аптырап калды. Нәкъ вакытында мөдире аңа ярдәмгә ашыкты:

— Кыек атып туры китердек, — диде ул, журналын кочаклап чыгып баручы Сәкинә Галимованы туктатып, — укучыларның иҗади фикер йөртүләре белән дә кызыксынабыз без, иптәш Галимова. — Аннан соң инспекторга борылды: — Мин сезнең бу дәрескә катнашуыгызны үтенәм, — диде.

— Бә-ә-әй,— диде укытучы җөмләсен көйгә салып,— кирәгез со-о-ң!..

Дәресне башлап җибәргәндә класста ризасызлык аңлаткан «ыһлау»лар купты. Бая гына коридорда тикшерүчеләр килүен хәбәр иткән теге калкурак малай шушы классныкы икән:

— Апа-а-а, сочинение дәфтәрләрен алып килергә кушмаганыегыз би-и-ит, нигә алай итә-ә-сез инде-е-е...

«Укучыларын да нәкъ үзе кебек көйләп сөйләшергә өйрәткән икән бу»,— дип уйлады Ләйсән.

Укытучы бу юлы да югалып калмады:

— Сезнең иҗади фикер йөртүегез белән кызыксынам, — диде ул, мөдирнең әлеге сүзләрен кабатлап, — аннан со-о-ң, язмаларыгызның аерым кәгазьдә булуы шарт. Районга алып китүләре мөмки-ин. — Ә үзе күз кырые белән генә арткы партага сыенган инспекторга карап алды.

Сәкинә Галимова, сизгәнегезчә, йокымсырый торганнардан түгел. Җитәкче эше кешеләрнең нәсел-нәсәбенә чаклы тикшеренеп, аның турында хәбәрдар булып яши. Яңа инспекторның телче-әдәбиятчы икәнен белде инде ул. Шуңа күрә аны үз дәресләренә якын җибәрәсе килмәгән иде. Чөнки ул бу фәнне бик үк белеп, яратып укытмый.

Галимова башлангычтан җидееллыкка күтәрелде. Башка фәннәргә теше үтмәслеген сизеп, тел-әдәбиятка алынды. Хәйләле-юмалый торгач,

укытучыларның шул чордагы ике генә еллык «мини институтын да» ермачлап чыкты һәм дипломлы әдәбиятчылар исемлегенә керде. Ә аннан соң сессияләргә йөрергә тиешле вакытын хуҗалыгын аякка бастыруга сарыф итте. Шактый гомер иткән мәктәп йортына кул селтәп, дүртпочмаклы гына булса да үз өен торгызды. Танасы бозаулады, берсе саулык, берсе тәкә булсын дип бәрәннәр сатып алды, кош-корт үрчетте. Йорт-җире көйләнгәч, өсте-башы бөтәйгәч, җиде кат үлчәп дигәндәй, һәр ягын уйлап, киңәшеп кенә акыл утырткан бер сабыр кеше белән гаилә корып җибәрде. Ә тормышның җитенкерәмәгән вак-төяк якларына пошмый башлады. Эштәге аягүрә генә әйтелгән тәнкыйть-мазарны ишетмәмешкә салыша, җитдирәкләреннән я теле белән җайлап, я табыны белән майлап котыла килә. Инспектор дигәннәренә дә исе китми башлады. Киләләр, кисәтәләр, китәләр, ә ул һаман үзенчә, үз җае, үз көе белән генә ватылмый-таушалмый эшли бирә. Аларның тел төбендә һаман бер сүз:

— Искечә укытасың, китаплар укымыйсың, иҗади эшләмисең, әдәбиятка мәхәббәт уятмыйсың, мәктәптә бер шигырь язучың да юк, кыскасы, киләчәктә эшеңдә борылыш ясамасаң, чара күрүебез мөмкин,— диләр. Ә аның тел очында һаман шул шомарып беткән әзер җаваплар:

— Без тәҗрибә белән алдырабыз, яңачалап әнә яшьләр укытсы-ы-н. Такмак әйтүче, декламация чыгаручы малайлар тумаганга да мин гаепле түге-е-ел. Такташтыр, Туфандыр ишеләр, җанкисәкләре-е-ем, мондый гына мәктәпләрдә аунап ятмый алар. Чара-мазар белән янаулардан да бик тиз генә өркә торган кеше түгел бу апагыз, беләсегез килсә-ә-ә. Тора-салып кешене эштән куулар күптән бетте инде алар! Мәктәптән чыгарып ташларлык ни эшләгән әле мин ул кадәр! Я, әйтегез! Әйтегез! Эчеп-исереп йөрим-ме-е? Юк! Прогул ясап, бот күтәреп өйдә ятам-м-ы-ы? Юк!! Ул тарафлардан местком каршында да, дирекция алдында да йөзем акмы? Ак!.. Я, бу яшь кенә нәрсә мине тикшермәк булып нәрсә кыра ала инде?

Ул, алдында ачылып яткан китапны укыганга салышып, әнә шуларны уйлап утыра иде, янына «яшь нәрсә» килеп баскач сискәнеп китте:

— Мин катнашкан дәрес планыгыз белән таныштырыгызчы, иптәш Галимова.

«Әй-әй-әй,— дип уйлады ул күңеленнән,— фамилиялап дәшә башлады бу яшь нәмәстәкәй хәзер миңа, юньлегә түгелдер... Юмаланып алмый булмас».

— План дигәннән, Ләйсән матурым, сезнең белән бер утырып киңәшәсе барые бит әле ул хакта, — диде яшькелт күзләрен ача-йома, — язма эшләр үткәргәндә дәфтәр тотырып план язуның кирәге юктыр дип уйлыйм мин үземә калса. Менә сез ничегрәк уйлыйсыз микән бу хакта, диюем.

Үзе ашыккан кыяфәт белән, җиңен терсәгенә кадәр тартып, сәгатенә карап алды.

— Барысын да аңлашырбыз,— диде инспектор әлеге соравыннан чигенергә теләмичә, — башта план дәфтәрегез белән танышыйк.

Нәкъ Ләйсән уйлаганча булды да чыкты. Галиәсгар Камал иҗатына багышланган дәреснең сочинениегә әверелүенә инспектор иптәш Мөслимова үзе «сәбәпче» икән...

Берничә минуттан Ләйсән рус әдәбияты дәресендә утыра иде.

Класс тып-тын. Балалар, юка күкрәкләрен парта кырыена терәп, укытучыга төбәлгәннәр.

Укытучы Гөлсинә Рахмаевна әле икенче елын гына укыта. Яшьлеге йөзендә уйный. Бит очлары яна. Мәрмәрдәй ак кулында акбуры дерелди. Өстенә шәмәхә йон костюм кигән. Аякларында кашлы туфлилар. Тактага, каушау билгеседер инде, авышканрак хәрефләр белән

дәреснең темасы язылды: «Поэзия М. Ю. Лермонтова». Стенага шагыйрьнең рәсеме эленде. Күпертмә погонлы офицер шагыйрьнең әсир иткеч сөйкемле йөземе, әллә анын күңелгә Тукай шигырьләре белән бергә ингән әсәрләре йогынты ясадымы, укытучы кыз үзе дә кыюланды: тавышы көчәйде, хәрәкәтләре кимеде. Партага ябышкандай булып тып-тын утырган балалар иркенәйделәр. Укытучы кыз, нәфис гәүдәсе белән класс каршына басып, «Шагыйрьнең үлеменә» дигән шигырьне яттан укыды.

Һәлак булды шагыйрь, намус колы
Ялалардан әрнеп егылды...

«Укытучы булып, әдәбият укытучысы булып туган бу кыз», дип язып куйды Ләйсән алдында яткан дәфтәргә. Аннан соң ул, сөенеп, як-ягында утырган балаларга карап алды:

Сабыйларның канатланыр чагы
Мәктәпләрдә укыр чак булыр...

— дигәнме шагыйрь? Шулай дигән Тукай. Тукай, Такташ әсәрләре белән теле ачылган балалар әкренләп рус поэзиясенә дә сукмак салалар. Ике милләт әдәбиятын-сәнгатен бергә өйрәнү кешенең дөньяга карашын киңәйтә, фикерләү офыкларын иркенәйтә. Ләйсән бу турыда күптән уйлана. Хәтта Сәфәр абыйсы белән шушы хакта бәхәс ачып кызып киткән чакларында Суфия апа гына арага кереп татуландырган иде бер үзләрен.

— Нәрсә син, — диде аңа абыйсы, бер кочак патефон табалары күтәреп кайткач,— тагын шул колак барабаннарын имгәткеч «буги-буги»лар белән аза кубасыңмы?

— Таба алган кадәр аларын да алып кайттым, — диде кыз, юка иреннәрен очлайтып, — «Карурман»нар моңайткан күңелне «буги-буги»лар да юаткалый.

— Шул такмакларга бастырам дип кушаяклап сикерергә дә өйрәндек, дисең инде, ә?

— Унган кеше барысын да булдыра ала, дисез ич үзегез.

Сәфәр абый арык куллары белән чуар түбәтәен кымшатып куйды, аннан соң шәкертенең тозсызрак сүз ычкындырганын искәртеп, тамагын кырды:

— Нәрсә?! Чү, талпынып кына күккә ашам дигәндә, башың түшәмгә тиеп мәтәлеп төшмә!

Ләйсән абыйсыннан да уздырмакчы. Кызыл чүпрәк күргән күркәдәй кызарып, кабарып китте.

— Яшьләргә везде дорога, картларга везде почет! Бер чатлы сукмаклар гына тар безгә!..

Ул алай артык өркеми иде абыйсыннан. Анын көмеш таба кебек «ыһ» иткәнче кыза, «уһ» дигәнче суына икәнен белә. Тик бу дуамал гадәтне Суфия апа гына өнәп бетерми. «Үзенә-үзе хуҗа булмаган кеше белән яшәү — ярсу айгырны йөгәнсез тоту белән бер», ди ул. Аларның һәр икесен авызлыклау өчен көч-куәт кирәк...

Ярый ла, янында шундый куәтле кешең булса...

Бу сүзләр Ләйсәнне дә уйланырга мәҗбүр итә. Аны да холкы-фигыле белән Сәфәр абыйсына охшаганнар диләр бит әле. Ярый ла, Сәфәр абый янында шундый куәткә ия булган кеше бар. Ә Ләйсән ялгыз. Әнә шундый сабыр, көчле рухлы кешене очрата алмаганга ялгыз Ләйсән. Әти-әниләре анын Ташкентта яшәделәр һәм ул аларны шунда җирләште. Ят телдә башлангыч классны тәмамлау белән, ул Татарстанга кайтты. Туган телендә укыйсы, туган ягында канат ярасы килде анын. Менә шул гомердән бирле ул анда калган агасы белән ике-өч елга бер генә күрешеп яши. Арада хатлар йөри, хатларда сагынычлы сәламнәр, инсафлы булырга кушкан киңәшләр килә. Ләйсән андый үгетләргә алай

бик мохтаҗ түгел түгелен. Аңа сөте белән кергән тәүфыйк дигән күркәм сыйфаты аның башкалар белән бүлешергә дә җитә. Тик менә анда җанны җылыта, ташны эретә торган йомшак күңеллелек житенкерәми. Кичерә, күтәрә белми. Фасоннан төшеп калган бер мәкаль бар. Күлкегә санап әйткәндә, кеше сиңа таш белән кизәнсә, син аның алдына аш куй дигәнрәк мәгънәне аңлата ул. Төптәнрәк уйласаң, теләсә кем алдына тез чүгәргә, ә аннан соң зәһәррәк үч алу өчен бер уңай көтеп, яшерен позициягә посарга кушкан мәкерле мәкаль бу. Юк, юк, таш белән атканнарны гына түгел, кыек-мыек ычкынган сүзләрне дә уйлап-чамалап кына гафу итә Ләйсән сеңелегез. Дөресен әйткәндә, ир-ат холкы анда. Ачуын чыгарсаң, әйтәсен шунда ук йөзеңә бәреп әйтә дә йөрәген баса, артында елап-рәнҗеп йөрми. Кеше көен көйлим дип бөгелми-сыгылмый, кирәк икән иплэп кенә үз көеңә дә бора белә.

Мәрхүм Сәфәр абый үзе дә шәкертенә сабырлык тели, сабыр төбендә сары алтын барын онытмаска куша иде. Ул үз холкының кайнарлыгын белә һәм аны тумыштан килгән хаста дип аңлата. Алар нәсел-нәсәпләре белән гаскәри кешеләр булганнар. Аның кирәкле кәгазьләр тартмасында бабаларыннан калган шәҗәрә бар. Шәҗәрә — нәсел агачы дигән сүз. Саргаеп беткән, таушалган кәгазьгә агач рәсеме ясалган. Шуның тырпайган ботак очларына, бөҗрага алынып, кеше исемнәре язылган. Алар Сәфәр аганың бабалары, туган-тумачалары икән. Шәҗәрә Гази бабайдан башланган. Гази — гарәпчә — гаскәри кеше.

— Исеме җисеменә туры килгән аның,— дия иде Сәфәр абый.— Петр патшалык иткәндә, Төньяк сугышына катнашкан ул. Ә менә бу ботактагы Байчура бабай Пугач батырны яклап Каңкай полкында сугышкан. Ә шуннан чыккан ботак — аның улы Мостафа бабай буладыр. Ул инде беренче Ватан сугышы солдаты. Бородино кырында ятып калган. Менә бу сул яктагы ботак төрекләрнең иманын укытканда яраланып, доктор Пироговтан дәваланган Шакир бабакай була. Бу кырыйдагысы — әткәйнең агасы Һидиятулла, ул да исңәгән дары исен. Япон сугышына катнашкан. Аның хатка өстәп язган бер җыруын әткәй гел такмаклый иде:

Аягымны яралады
Маньчжурия ташлары.
Илгә җанын фида кыла
Газиз солдат башлары.

Ә менә бу очтарак торган ботак Сәфәр аганың үзе инде. Мин дә сәфәрләр кылдым шул. Иделдән Одерга барып җиттем. Шулай, кызым, сугыш дигән афәтнең, еллар узса да, учагы сүнде, ярасы төзәлде, димә. Әле аның буыннардан-буынга кан белән күчә торган хастасы кала. Каны коелган кешенең холкы кырысрак була, диләр. Безнең нәселнең каны күп коелган.

Дөрестер бу...

*

* *

— Уфф, — дип пошыргаланды Ләйсән, өстендәге юрганың бер якка сыдырып, — инде уйлана торгач, әллә кайларга тәгәрәдем. Йокы дигәннең әсәре дә юк. Бу ниткән бөркү бүлмә булды соң әле?.. Моржалары шартлаганчы якмасалар...

Аннан соң үзенең тупаслыгыннан оялып, шыпырт кына, инде ничәнче тапкырдыр, уң ягына борылып ятты. Караңгыга иялэнгән күзләр кичтән үзенә җәлеп иткән китап шкафын эзләп тапты. Шүрлекләрдә мал шактый. Татарның Дәрдмәнденнән алып чукча Рытхэугә хәтле менеп кунаклаган. Дәрдмәнд диделәрме, Ләйсән мәрхүмә әнисен, ваем-

сыз сабый чагын сагына. Шәфәкъ баткан кичке моңсулыкта әнисенең Дәрдмәнд шигырьләрен көйләп йоклатканын хәтерли:

Асыл ташым, кыйгач кашым
Йоклаек икәү,
Йокла, иркә, йокла, бәбкә,
Бәллү-бәллү, бәү,
Бәллү, бәәәүүү...

*
* *

Инспектор әлеге Ядрәк мәктәбеннән алган тәэсирләреннән айнырга өлгермәде, аны икенче сәфәргә ашыктырдылар.

— Мөслимова,— диде мөдир Ләйсәнгә, иптәшләп-фәләнләп тормый гына, — әнә тегендәге шкафтан Каенсу мәктәбе укытучылары делосын ал. Анда Жанна Миңнегайнетдинова белән Кифая Мөлековаларның анкеталары, гаризалары һәм шуңа охшаган барлык нәрсәләр белән таныш та менә бу жалобаны укып чык. — Ул инспекторга зәңгәр конверт сузды. — Фикерләрең туплангач миңа кер, иртәгә үк шул якка чыгып керергә туры килмәгәе.

Әллә яшь инспекторны канатландырмак булыпмы, әллә инде күңелендәген ычкындыруы иде, ул тагын шуны да өстәде:

— Сынау вакытын уздың, мәктәпләрне күргәләдең, яңа эштә чирканчык алу шул була.

Ләйсән пыяла өлге капланган өстәлгә мөдир кабинетыннан алып чыккан папкаларны куйды, алдына әлеге хатны җәеп салды. Дәгъваның башын йөгертеп кенә укый башлаган иде, тора-бара ак маңгае җыерыла төште, керфекләре озынаеп ачулы җөмләләргә кадалды.

«...Җәмилә белән Кифая дигән укытучыларыгыз авылның ямен җибәреп яталар. Мәктәп өен кеше атлап кермәслек шайтан почмагы иттеләр. Стеналары тулы сурәт, идәннәрендә эт тиреләре ауный. Базар көнне иртәдән кичкә чаклы патефон әйләндерәләр. Аннан чыккан яшелле-зәңгәрле тавышка чыдар әмәл юк. Заграничный көй бугай. Үзләре дә чәлдер-чөлдер әллә нинди телдә сөйләшәләр. Менә сиңа камсамуллар... Өс-башларын күрсәгез иде әле, чуар чалбар кияләр. Яннарына ир-атлар да кергәли сыман. Шушы азып-тузып беткән нәрсәләргә ничек итеп үзеңнең газиз балаларыңны тапшырмак кирәк. Уффф!..»

Кыз хәрефләрен ватып-сындырып куелган имзаларга үртәлеп карап торды да янындагы папкага үрелде. Тышына Миңнегайнетдинова Жанна Җиһангәрәевна дип язылган шәхси делога текәлде. Кызга егерме дүрт яшь. Әле беренче елын гына укыта икән. Хәрби хезмәткәр гаиләсендә туган. Төрле җирдә яшәп төрле мәктәп тәрбиясен алган. Мәскәү педагогия институтының чит телләр факультетын тәмамлаган. Малайларча боргалап язылган автобиография... Шук кызга охшый.

Икенче папканы да ачты Ләйсән. Кифая Мөлекованың биографиясе нибары ике-өч җөмләдән тора. Авылда туган, калада укыган. Тарих укыта...

*
* *

Каенсуга килеп төшү белән, инспектор туп-туры мәктәпкә юнәлде. Директор Ләйсәнне тыңлаганда күзләрен йомгалап, кулларын уып утырды. Ул арык гәүдәле, артык хәрәкәтчән, нервлары шактый какшаганга охшый.

— Һе, һе, — дип кабатлады директор, бармаклары белән өстәлне барабанлап,— Җәмилә белән Кифая диген, һе, һе, фасонын-нием китерә беләләр инде алар белүен. Нишлисең, яшь чаклары бит. Һе... язып җибәрүчесен әйтер идем, дөнья күрмәгән кеше галәмәте бу.

Директорның хатка булган мөнәсәбәте ачыкланмады: кызларны якларга теләве — «өйдән чүп чыгармавымы»? әллә, ул фараз иткәнчә, яшьләрнең артык заманча кылануы кемнәргәдер ошамыймы?

Шулайрак икән шул, моңа дәлилләр эзлисе булмады. Үзләре очрап тордылар.

Авыл уртасындагы такта түбәле иске йортка укучылар озата барды аны. Китапханәдән кайтулары, ахры, култык асларында таушалган калын китаплар. Романнарга урелгәннәр. Берсе чуклы башлык урынына брошка кадаган беретка киеп алган. Өлкән класста укый болар.

— Укытучы Җәмилә апаларыгыз кайда тора? — диюгә, дәррәү җавап бирделәр:

— Түбән очта гына!

— Озатып куйыйкмы, апа?

— Күреп торам, укытучы апаларыгызны зурлыйсыз икән.

— Бәй, яратмый ни. Җәмилә апа — класс җитәкчебез ич ул.

Сипкелле кызның сүзен чалбарлы костюм кигәне җөпләде:

— Җәмилә апамы? Җәмилә апа белән Кифая апа безнең классны, каникулда колхоз печәнен җилләтеп алган акчабызга үзләренекен өстәп, Ленинградка алып барып кайттылар. Безнең ул эрмитажларны, ул Ленин басып торган броневикларны тиз генә күрәсебез юк иде әле.

— Күп нәрсәләргә өйрәндек без алардан. Мандолина уйныйбыз, танцы түгәрәгенә йөрдек...

— Алар безгә кызыклы китаплар биреп торалар...

Яшькелт пәрдәләрен җилфердәткән ачык тәрәзәдән таныш моң агыла. Юа торгач юкарып беткән сөян баскычта салып калдырган аяк киемнәре тора. Ләйсән үзалдына гына елмаеп куйды: «Спартак» фабрикасы чыгарган туфлинең каешын өзеп, җиз чылбыр такканнар. Башкаларныкына охшамасын, янәсе. Ләйсән өйгә узгач иңбашын сикертеп куйды: «Керегез!» дигән яңгыравык тавыш кайдан килде соң? Соравына җавап эзләп, як-ягына каранды: тыштан мескенрәк күренгән бу өйнең эче, ачык тәрәзәдән яңгыраган моң кебек, күңелне хушландырып җибәрде. Стеналарында — Африка урманнарын тасвирлаган рәсемнәр. Журнал битләреннән кисеп алынган киноактерлар елмая. Ишек катында — тәбәнәк тахта. Өстендә җәймәсе төсле яшькелт мендәр ята. Киштәләрдә — китаплар. Өч аяклы җәенке өстәлчектә магнитофон әйләнә. Аның катында торшер... Чү, нәрсә соң бу? Әйе, әйе, баздан үсеп чыккан диярсең, идәнне тишеп агач ботагы утырткannaр да фонарьлар асканнар. Аяк астында йонлач келәм ята.

Ләйсән юка иреннәрен ерып торганда, кече яктан чакырган тавышның иясе килеп чыкты. Сары чәчләрен турыга ачып тараткан бу кыз стенадан карап торган кайсыдыр актрисаны хәтерләтте. Күпмедер аптырашып-елмаешып торгач, Ләйсән аңа кул сузды:

— Ялгыз өйгә бәреп кергәч, угры дип уйлый күрмәгез, мин — кунак. Исемем — Ләйсән.

Йомарлак май кебек ак тезләрен каплар-капламас чуар күлмәкле кыз, шуны гына көткәндәй, аның йомшак бармакларын эләктереп алды:

— Мине Җәмилә диләр...

Озак көттермәде, хаттагы «чуар чалбарлысы» — Кифая да кайтты. Кызлар, кунакны үз тиңнәре итеп, теләгән кадәр чыркылдаштылар: берберсен уртәшә-уртәшә, кече якта чәй кайнаттылар, башланган конфет кабы ачылды, ипи телделәр, парлары чыгып торган бәләкәй чуен белән бәрәңге дә утырды өстәлгә.

Ә магнитофон һаман әйләнә, хисләрне кытыклагыч музыка агыла то-

ра. Шул чак Ләйсән, үзенең ник килгәнен һәм кемлеген онытып, кызлар дөньясына чумды. Монда күңелле, рәхәт иде. Тамак ялгангач та, алар ниндидер житди сөйләшүләрдән читтә кала бирделәр. Инспекторның бирегә ни өчен килүе белән дә кызыксынмадылар, чөнки, ни әйтсәң дә, алар күңелләре белән тиңдәшләр иде. Ләйсән чөйдәге гитарага үрелде. Кылларын чирткәләгәч, кызларга ымлады:

— Жырлыйбызмы?

— Жырлыйбыз!

> Торма, егет, мине көтеп
> Тәрәз төбендә.
> Башка егет, башка өмет
> Күңел түремдә... Лә-лә,
> Минем күңелемдә...

Шуңа җавап биргәндәй, ишек яңагындагы кыңгырау төймәсенә төрттеләр: Җәмилә урыныннан сикереп торды һәм сораулы карашларын кызларга текәде.

— Кара әле,— диде Ләйсән, кыз чыгып киткәч Кифаяга,— чын исеме ничек аның? Рәсми кәгазьләргә Жанна языла, ә үзенә Җәмилә дидертә.

— Җәмиләме? Әтисе кушкан исемнән баш тартып, үз-үзенә кушкан интернациональ исем ул Җәмилә.

Дөньяның Татарстаны, Урта Азиясе, Африкасы Җәмиләләр белән тулган ич.

— Синең егетең бармы, Кифая?

Кызның зәңгәр күзләре тоныгаеп калды. Ләйсән, кирәкмәс сүз башлавын тоеп, китап киштәсенә борылды.

Җәмилә тиз әйләнеп кайтты.

— Иртәләдең, — диде аңа Ләйсән елмаеп.

— Әй, без шундый өй кошлары ла, иеме, Кифая?

— Шулай шул.

— Клубка да йөрмисезме?

— Ни бар анда?

— Менә сиңа — мә! Кино карарга, биергә, ял итәргә.

— Кеше «көлдерепме?»

Ләйсәннең маңгае җыерылып, кашлары бүртте:

— Көлдереп?

Кеше моң-зарлы чагында олыгаеп күренә, кызларның да яшьлек ялкыны капкан нурлы күзләре сүрелгәндәй булды. Инспектор чынлап та аларның күңелләрен күләгәли торган борчу барын тойды. Җайлап кына уртаклашырга иде шуны. Ул моңа җирлек хәзерләде! Йомшак башмакларын салып тахтага янтайды.

— Үземә калса да, әллә кая китә алганым юк, киносын да рецензиясен укымыйча караганым юк, башкасына да өлгерә алган кадәр генә. Вакыт җитмәве үзәккә үтә лә.

— Райүзәктә яшисез, ичмасам, анда ни кылансаң — шул килешә. Ә монда...

— Ә укучыларыгыз үзегез өчен үлеп торалар.

— Әбиләренә генә ярап булмый.

— Шулай шул, — диде Җәмилә, дустының сүзенә мәгънә өстәп. — Күлмәкнең озынын кисәк, «карчыкка әйләнәбез», кыскасы «оятыбызны качыра». Чәчне дә үзебезчә йөртер хәл юк, «тузган баш» диләр. Сөрмә тартырга да хакыбыз юк инде менә. Итегебезгә кадәр катышалар. Озын кунычлысын кисәң, «торна аяклар» булабыз, ботинкаларыбызны мулла кәлүшенә охшаталар. Шулай итеп, клубка киеп чыгар өс-башыбыз юк безнең.

— Башка яшьләр ничегрәк киенәләр соң?

— Монда яшьләр озак торамыни?

— Торганнары?

— Безнеңчә киенә, янәсе, бездән күрмәкче киенә. Үз башыма бәла алып, «Ничек киенсәң килешә» дигән лекция укыган идем, ник укыганыма үкенеп үлә яздым, иеме, Кифая?

— Әйе шул!

Бу авылда кызлар кызлар белән генә танцевать итәләр икән. Болар егетләрне дә биергә өйрәтмәкче булганнар да «ирдәүкә» исеме алганнар. Шуларга җавап итеп «дуслык, иптәшлек» турында лекция сөйләгәннәр икән, «мәхәббәт инструкторлары» дип атаганнар үзләрен.

— Кемнәр үрти соң сезне?

— Ханжалар. Мондый иске карашлы кешеләре бар авыл бөтен Татарстанда берәү генәдер.

Ләйсән иренен тешләп куйды: искелек белән яңалык арасында барган көрәшнең бер мизгеле инде бу... Шушы темага район газетасына бер мәкалә язып карар гамы әллә, чынлап та?!

*

* *

Эш сәгате тәмамланган иде инде. Ләйсән пальтосын төймәләп торганда телефон шалтырады. Трубканы Әкбәрова алды:

— Юк, китмәде әле.

Ләйсән, кабаланып, аның кулындагы трубкага сузылды.

— Тартып алмасаң булмый идеме?

Телефоннан металлдай чыңлаган тавыш ишетелде:

— Нәрсә сез анда? Үзара низагъларыгызны куегыз. Менә нәрсә, Ләйсән Гәрәевна, мин әле моннан — райкомнан шалтыратам. Алан мәктәбен тикшерәсебез бар бит. Иртәнге алтыда аппаратта булыгыз.

Кисәктән шалтыраган телефон, Әкбәрованың төкселеге, мөдирнең кырыслыгы — барысы берьюлы кызның кәефен кырды. Җитмәсә, кайдан шалтыратуын әйт әле син аның. Безне ничек әрләгәнен анда тыңлап торучы булмаса ярар иде. Авылга барасын да сәгате килеп җиткәч кенә әйтүен кара тагын. Теге вакыттагы кебек, директорларына хәбәр итеп куймасын, янәсе.

Бу Ләйсәннең үзенә күрә башлыгыннан зарланып алуы иде.

Габбасов хезмәткәрләренә әтиләренең исемен кушып дәшә. Ә Ләйсән исә өлкәннәргә апа, абый дисә, яшьләрне, яшьтәшләрен исемнәре белән атый. Арада апа, абый дияргә дә, исемнәре белән дәшәргә дә кыймый торган иптәшләр очрый. Аларны фамилияләре белән йөртә. Шундыйларның берсе Хәнифә Сәлимовнага Әкбәрова дип кенә мөрәҗәгать итә ул.

Әкбәрова — методист. Үзен бик кадерләп һәм кадерләтеп яшәргә ярата торган хатын. Искерсә дә төсе уңмый торган затлы товар кебек инде олыгаеп килсә дә — әле ул матур.

— Яшь чагында тагын да чибәр иде әле бу зәһәр,— диләр аның турында сүз чыкканда кайберәүләр. Алдында әйтергә базмыйлар. Әкбәровада кисәктән кинаялэп туры әйтә һәм шуның белән кешеләр алдында синең дәрәҗәңне бер мыскалга төшереп куя торган «көч» бар. Сүзен ул теш арасыннан сайлап кына чыгара, чамалап кылана. Әмма кешеләрдә була торган кимчелекләрне бик сизгер эләктерә һәм артларында гайбәтләренә керешә. Ләкин ул гайбәт дигәнең аның тарафыннан шундый оста эшкәртелеп тарала ки, күпләр ирексездән кешеләргә Әкбәрова яккан бәя белән килешәләр. Үзе беркем белән дә каракаршы дуэльгә чыкмас, ягъни ызгышмас. Әмма, авыл картлары әйтмешли, күчәрең аңа орына икән, сак бул. Мондый төр кешеләр ачуын китергән бәндәсеннән астыртын үч алмый калмый. Менә шуңа күрә дә бирелдәге хезмәткәрләрнең берсе дә, хәтта мөдир үзе дә Әкбәрова белән сүз көрәштерергә, аңа «орынырга» теләми. Ә Ләйсәнгә нәрсә: «Минем

Әкбәрова алдында әкбәр укыйсым юк,— дип кенә җибәрә ул, аның алдында бик ачылмаска, аннан сагаерга кушкан иптәшләргә.— Үзен белсен. Кемне нинди ысул белән үзенә якынайтырга, яки этәрергә кирәк булган «шәхес методикасыннан» башка нәрсәсе юк. Педагогик методикасы сай, мәктәпләргә чыкмый, укытучыларга ярдәм итми».

Әкбәрова үзенә инспектор Мөслимова биргән мондый бәяне үткерлеге беләнме ишетеп-тоеп тора.

Коллегасы булган икенче инспектор Галимә апаның үз мәшәкате үзенә җиткән, аның беркемдә дә эше юк. Ул аппаратта сирәк була, еш авырый. Айлар буе больницада ята, санаторийларга йөри. Табигате беләнме, сырхаулык басканга мы — йомык кеше ул. Көн саен туа торган кыңгыраусыз яңалыкларга колак торгызмый, теш үтмәстәй эшкә тыкшынмый.

Ләйсән меткабинет мөдире Маһибә Фәйрушина белән әйбәт мөнәсәбәттә. Ләкин аның бер ягы бар: синең турыңда күпчелек нинди фикердә — ул шуңа кушыла. Ләйсән Маһибәнең мондый холык-фигылен тормышны белмәүдән, авырлык күрмәүдән килә дип карый. Ул — район советы башкарма комитеты председателе кызы. Җылы ояда үскән. Нужасыз укыган. Ире сабыр. Эше мөстәкыйль.

Мөдир Габбасовның үзенә килсәң, беркем алдында да ачылмыйябылмый, бераз мин-минлеге дә бар, коеп куйган администратор. Үзен тотышы шәп. Бәреләп сугыла белми. Тагын, директорлар кубызына биемәсә дә, алар белән дус яшәүне хуп күрә. Ләйсән хисапчы Мәсгуть абыйсын аеруча ихтирам итә. Аз сүзле, акыллы кеше ул. Үзенең олы яшьтә икәнен искәрткәндәй, Ләйсәнгә «кызым» дип дәшә.

*
* *

Мөдир белән инспектор Аланга килеп кергәндә, авылның уянып аякка баскан җанлы чагы иде. Берсе бара, берсе кайта дигәндәй, халык — хәрәкәттә. Директор Газизов кунакларны гаҗәпсенеп каршылады:

— Ай-ай-ай, иртәләгәнсез!

Уртача буйлы бу директорны Ләйсән еш күргәли. Бик үк әшнәләр булмасалар да, алар мөдир белән үз кешедәй аңлашалар. Алар — райүзәккә якын. Мәктәбе яңа. Коллектив көчле. Контроль җитәрлек. Шуңа күрә Казаннан килеп төшүчеләр дә, үткән-сүткән дә шушы мәктәпкә кагыла, куст киңәшмәләре монда үтә.

Башлангыч класслар яңа программаны ничек кабул итәләр? Инспекторның бүгенге бурычы — тагын бер кат шуны тикшерү, сорашу, фикер алышу. Ул тоташ биш сәгать буенча дәресләрдә утырды.

Фәтхия Кадыйрова икенче елын гына эшләсә дә, батыраеп җиткән, күзеңә туп-туры карый, кыю сөйләшә. Ул быел өченче классларны укыта.

Өченче класс балалары сабый түгел инде, үсмерләнә башлыйлар. Җаваплы класс — өченче класс. Аларның артык калын уку китаплары белән танышкач, уйланып утырганы бар Ләйсәннең. Йөз егермеләп авторны берләштергән бу дәреслек «Туган ил» дип атала. Ай-һай, тугыз яшьлек сабыйлар өчен тозлырак түгелме? Ул бу фикерен дәреслекне төзүче авторларга да язып җибәрде. Озак та үтмәде, рәсми конверт белән машинкада басылган җавап килеп төште:

— Укытып карыйк, киләчәк нәрсә күрсәтер, нәтиҗәсен бергәләп хәл итәрбез...— дигәннәр.

Икенче ел инде «укытып карау» дәвам итә. Укытучылар сүзенә караганда, балалар китапны авырсынмый кабул итәләр. Мәктәпләрдә булган саен инспектор үзе дә моңа инана бара.

Лэйсэн Фэтхия белэн дэрескэ кереп китте. Ул, гадэттэ, класс ишеген ачу белэн тотышны үзгэртэ. Балаларның үзенэ төбэлеп карауларын күрмэмешкэ салышып, арткы партага сыена. Дэфтэрен кыштырдатмый гына ача. Калэмен тотып утырмый. Дэрес барышында чыккан кызыктан авызын ермый, эче пошса, маңгаен җыермый, тыныч кына тыңлап утыра. Дэрестэге уңай яки кире якларны мөмкин кадэр хэтерендэ сакларга тырыша.

Соңгы кыңгырау шалтырап, балалар өйлэренэ таралгач, инспектор белэн укытучы буш класста калдылар. Баштарак үзен бик иркен тоткан Фэтхия Лэйсэн белэн икэүдэн-икэү калгач тартынып куйды, күзлэре юашланды. Кулына калэм алды, дэфтэр ачты — инспекторның искэрмэлэрен язып барачак.

Укытучы халкының яшьрэклэренэ дэ һэм өлкэнрэклэренэ дэ хас уртак бер гадэт бар: аларның инспектордан уңай яклары турында да ишетэселэре, ягъни бераз гына макталасылары да килэ. Тэнкыйть мэсьэлэсендэ шул: кеше-кара юкта гына иплэбрэк тэнкыйтьлэгэнне яраталар алар. Лэйсэн аны үзенчэ аңлый. Институт эскэмиясеннэн генэ күтэрелгэн яшьлэрдэ эле һэртөрле кисэтүлэргэ-шелтэлэргэ каршы, табипларча эйтсэк, иммунитет тумаган. Эмер тоны белэн сөйлэшкэнне, шелтэле кисэтүне авыр кабул итэлэр. Э өлкэнрэклэргэ исэ тэҗрибэлэренэ таянып масаю хас. Туры эйткэн — туганына ярамагандай, дөреслекне күзлэренэ тутырып карап эйткэнне дорфалыкка саныйлар.

Шулай итеп, ниһаять, Лэйсэн дэ кемнең нindирэк кылларын ничегрэк тирбэтергэ кирэгенэ төшенэ башлады.

Менэ бүген дэ ул башта Фэтхиянең уңай якларын телгэ алды:

— Сэлэтле укытучы сез. Дэреслэргэ хэзерлекле йөрисез. Классны кулыгызда тота белэсез, шулай да...

Кыска гына паузадан соң, каршында утыручының сораулы күзлэренэ текэлде:

— Балаларны кырык биш минут буена гаскэри формада «смирно»га гына тотарга да ярамый. Иркенрэк хис итеп, хэрэкэтлэнебрэк утырсалар да зыян юк. Буыннары йомшак, тиз арыйлар алар. Аннан соң, шуны да эйтик, укытучының урынлы-урынсыз кырыслыгы сабыйны куркыта, алай гына да түгел, рэнҗетэ. Алар күңеленең өрфиядэй нечкэ һэм сизгер чагы. Кеше дигэнең, үзең белэсең, бик катлаулы җан. Берэүлэрен җитдилек белэн тыңлатсаң, икенчелэре җан азыгы булган яхшы сүзгэ мохтаҗ. Тиз җэрэхэтлэнэ торган йөрэк тупас сүздэн генэ түгел, ачулы караштан да кулэгэ артына поса. Гөлнэзирэң тактага дэртлэнеп чыкты. Ялгышмасам, кайбер укучыларга авыр тоелган катлаулы мисалны чатлатып чишеп бирэчэк иде ул. Кызның кулына акбур алуы булды, шунда сез аңа нинди кисэтү ясадыгыз?

— Такта янында дөрес басып торырга куштым бугай.

— Э менэ шуны ничек итеп эйттегез?

— ?

— «Тактага сыртыңны куйма», дидегез аңа, Фэтхия, укучыгыз шунда ук коелып инде... Кешедэ арка бар, җилкэ бар, э сырт...

Инспекторның исем белэн үз итеп дэшүе каушый башлаган укытучының кэефен күтэребрэк җибэрде. Менэ хэзер аның белэн күзгэ-күз карашып, кыюланыбрак сөйлэшергэ дэ була инде.

— Сез соңгы дэрестэ гади сүзлэр белэн генэ укучыларны рэссам Шишкин иҗаты белэн таныштырдыгыз. Күргэзмэ эсбаплар алып кергэнсез. «Башаклар өлгерде» картинасын тээсирлэнеп карады балалар. Эмма... ялгышмасам, сез Алабуга кызы түгелме эле?

— Ийе!

— Э менэ шул моменттан файдаланып, атаклы художникның каладашыгыз икэнен эйтсэгез, «Башаклар өлгерде» картинасында туган як

басуларыгыз тасвирлануын сөйләсәгез һәм тагын да китереп шәһәрдәге Шишкин музеенда булгалаганыгызны да өстәсәгез, нинди шәп буласы иде, ә!

*
* *

Башлангыч класслар өч кенә еллыкка калдылар бит. Дүртенче класс яңача укыту белән йөзгә-йөз очраша. Бу күренешне ун яшьлекләр ничек күтәрәләр? Бу сорауга җавапны Алан урта мәктәбе дә бирергә тиеш. Икенче көнне инспектор алар арасында утырды, дүртенчеләр генә димәссең, эре сөякле, буйлы хәзерге балалар. Өс-башлары күркәм. Кызлар кашемир күлмәк өстеннән атлас алъяпкыч япканнар. Ир балалар өстендә йон костюмнар, өстәл аслары күн портфельләр белән тулган. Кара капкачлы авыш парталарга алмашка җайлы өстәлләр куелган. Кара такта да хәзер кара түгел, яшькелт такта. Җылы төсләр балаларның күзен саклый, диләр врачлар.

Укытучы Гарипова үзе тәмамлаган шушы татар мәктәбендә рус теле укыта. Кичә мәсәлче Крыловның «Квартет»ын өйрәнгәннәр икән.

Ул, уртанчы рәттә утыручы чандыр малайны бастырып, шул мәсәлне укытты.

Авыр сүзләрне дөресләргә теләп берничә кул калыкты.

— «Он» дигәнне дөрес әйтмәде. Русча «О» татарчадагы «О» кебек түгел, урманда ишетелгән аваз шикелле «ао» булып яңгырый.

— Дөрес. Тагын нинди ялгыш ясалды әле?

— «Давать» сүзен «давайт» дип укырга кирәкми...

Журналда мәсәлне укыган малай фамилиясе янына өчле билгесе төшсә, инспектор дәфтәренә дүртле тамды. «Кырысрак таләп итә, түбәнрәк бәя куя» дигән юллар язылды.

Икенче дәрес икенче катта — стеналарыннан Колумб, Магеллан, Гагарин рәсемнәре карап торган география кабинетында узды. Яраталар икән балалар бу фәнне. Укытучының сөйләвенә караганда, бирегә күтәреләсе көнне бәйрәмчә киенеп киләләр алар. Бүген дә кызлар чәчләрен төрле тасмалар белән үргәннәр, малайлар пинҗәк төймәләрен ялтыратканнар...

Фәне дә кызыклы. Укытучылары да үзенә җәлеп итә торган. Мактаулы укытучы шул Әминә Вәлитова. Кыз чагы райкомолда үткән аның. Андыйлар картая белмиләр. Әнә күзләре нинди тере. Инде кырык бишне узып барса да, очып кына йөри. Өсте-башы яшьләрчә: чәче кыска, күлмәге гәүдәсенә сыланып тора. Әминә инспектор белән кайберәүләр кебек ятсынып, каушап түгел, дус кызыдай күреп, кул кысып күрешә. Нәрсә ди чех педагогы Каменский: «Укытучы мәгърифәтче генә түгел, психолог та булырга, артист рәвешенә дә керергә тиеш»,— диме? Әминә — Амос абзый таләбенә дә җавап бирә торган укытучы.

— Әйдә, киттек,— ди ул, инспекторны култыклап,— мыскал тәлинкәңне тигезлә, кай ягым җиңәр, яманымы, яхшысымы? Язмыш бүгенгә синең кулыңда.

Узган дәрес әйбәт йомгакланды. Менә ул класс каршына соргылт төстәге ят глобус тотып басты.

— Бу нәрсә, укучылар?

— Ай шары!

Бу хорга инспектор янында утырган почык борынлы кызның да нечкә тавышы кушылды:

— Ай шары!

Ләйсән, елмаюдан тыелу өчен, иреннәрен бөрештереп куйды.

— Карагыз әле,— диде укытучы, балаларга Айның экватор өлешендәге калкулыгын күрсәтеп,— менә монда көянтәле кызга охшаган

шәүлә бар. Халык шуңа таянып моңсу әкият иҗат иткән. Я, кемнең ишеткәне бар шуны?

Беләләр икән. Кәтүк хәтле генә кара чәчле малай алмалы чиләкләрен асып суга төшкән ятимә кызның баш очындагы тулган айга карап елый-елый үзенә тартып алуын ялварган әкиятне сөйләп тә чыкты.

Ә чынлап карасаң, ятимә кызга охшаган бу шәүлә Аязлык диңгезе уртасындагы кратерлар икән. Монысын укытучы үзе аңлатты. Балалар Айның картасын беренче Совет галимнәре төшереп алуын да белеп торалар. Шулар өстенә бүгенге Айга кагылышлы башка мәгълүматлар да өстәлде. Алар Ай өстендә абына-абына йөреп кайткан Америка астронавтларын телевизордан карап торганнар.

Бишектән төшкәннән алып таякка таянганына хәтле алар хуплап сөйли торган егерменче гасыр галәмәтләре инде бу. Кеше галәмгә юл салган елны туганнар бүген кулларында ай шарын уйната. Ә тагын ун елдан, егерме елдан аларга алмашка кемнәр килер? Яңа укучылар! Менә ни өчен программалар үзгәртелә! Ләйсән шул турыда да уйлап утырды.

*

* *

Педсоветта сүз Алан сигезьеллык мәктәбендә уку-укыту эшләренең яңача куелуы турында барды.

Тикшерү йомгакларыннан коллектив канәгать калды. Директор да, җыелыштан чыккач, иркен сулап куйды. Күңеле күтәренке чакта сүз куертасы килде аның.

— Педсоветларны кыска тота башладык бит, әйбәт бу. Бар иде заманында бишәр сәгать өзлексез бәхәсләшеп утырган чаклар... Бер елны, мин сиңа әйтим, теге инде — Аргасык районында эшләгәндә, РОНО мөдире бер взвод диярлек кеше белән килеп төште. Күрше мәктәп директорларын җыйган, инспекторын иярткән һәм тагын әллә кемнәрен алып килгән. Биш көн буена мәктәпнең астын өскә китерделәр. Үзләренең дә, укытучыларның да күзләренә йокы кермәде. Соңгы көнне педсовет җыйдык. Төш авышкач башланган җыелыштан чөгендердәй кызарышып төнлә таралдык. Ник шунда берәребез «әйбәт эшлисең» дигән җылы сүз ишетсен дә, ник беребезгә генә булса да юньле киңәш бирүче булсын. Ә шелтә дигәнен җәлләмәделәр: ике кешегә катысы, берсенә йомшаграгы чәпәлде. Беренче елымны гына укытсам да, мин дә коры калмадым: кисәтеп киттеләр...

Директорның сүзен өзәргә туры килде. Чөнки математика укытучысы Гыйльмеҗиһан Ләйсәнне, төркемнән аерып, юл өстендәге өйләренә алып кереп китте. Ә мөдир, гадәттәгечә, бу юлы да директорларга туктаган иде, алар сөйләшә-сөйләшә алга атладылар.

*

* *

Йокыга гына китеп барган Ләйсәнне тәрәзә чиртеп уяттылар. Башта ул үзенең кайда, кемнәрдә икәнен абайламый торды. Исенә килгәч, җәймәсен генә бөркәнеп, хуҗалар йоклаган бүлмә ишегенә килде:

— Гыйльмеҗиһан апа, тәрәзә төбендә кеше бар.

Үзе ялт итеп урынына кире кереп ятты. Ләкин аңа барыбер тиз генә йоклап китәргә ирек бирмәделәр. Төнге кунак — мөдир Габбасов булып чыкты. Аңа яңа урын җәеп, ах-вах килеп йөргән арада ярты төн узган иде инде.

Нишләп РОНО мөдире директор фатирына сыймаган? Нигә аны төн уртасында чыгарып җибәргәннәр? Өендә ни булганын күршеңнән

сора дигәндәй, инспектор бу сорауларга тулы җавапны аппаратка кайткач кына Әкбәрова авызыннан ишетте. Эш болай булган.

Директор хәзергә бер генә бүлмәле йортта тора. Салына башлаган дүрт бүлмәлесе әле өлгермәгән. Менә шул котыйчыктай кечкенә өендә аның эштән кайтуын көтеп утыра торган иркә хатыны бар. Эшләми ул. Өйдә генә тору ямансудыр, кунак-мазар килеп чыктымы, ачылып китә, өс-башын алмаштыра, бизәнеп ала. Менә шул сәбәпләр аркасында ир дигәне кунак-мазар белән бик мавыкмый — көнчелеге килә булса кирәк. Шулай да ул хатын-кыз алдында үзен вәкарьле тота торган Габбасовны, җитмәсә тагы, үзенең башлыгы да бит, күпсенми, гел иярттеп кайта.

Кунак килүгә, гадәттәгечә, пилмән бөгелгән, мичтә бәлеш була. Табын уртасында шешә дә сыйгандыр, ансыз булмастыр. Хатыны изүсез, җиңсез күлмәген кигән, кершән сөртенгән. Мич каршында пешеренеп йөргәндә хуҗабикә болай да чибәрләнеп китә: бите, түше алсуллана. Кыскасы, сыйдан сыгылып торган табыны да, бизәнгән-төзәнгән хатыны да — барысы да әлләл-лә икән. Алдан әйткәнебезчә, мондый табыннарны, мондый хатыннарны күргәләгән ир уртасының боларга бик исе китмәгән китүен, тик хуҗа кеше генә, гадәттәгечә, «тешем сызлый» хәйләсе белән, чыраен сыткалап алгалаган. Табын җыелган, урын җәелгән. Ут сүнгәч кенә, чәе-мәе артыграк йотылгангамы, кунакның тагын бер тышны әйләнеп керәсе килгән. Бераздан аның артыннан хуҗа да чыгып киткән. Икесе ике төрле йомыш куып болын кадәр ишегалдында аймыл булышканнар. Кунак исә, хуҗасының тышта калганын шәйләмичә, келәсен элә кергән. Хуҗа дигәнебез, абзар-кураларны әйләнеп, малын-туарын барлап дигәндәй, шактый вакыттан соң инде керим дип ишегенә төртсә — аптыраш... Башта иләп кенә шакый — ачмыйлар. Әллә «шайтан вәсвәсәсе кереп» бикләнгәннәрме болар?! Күңелен шом баскан ир инде ишекне дөмбердәтә үк башлый. Кунак, хуҗалар ачар дип — ул аларның икесен дә өйдә дип белә — хатын исә, ир кеше торсын дип, бер-берсенә салынышып ятканда, инде кыйшайган иске ишек башындагы тимер-томырлар коела башлый. Икәүләп сикерешеп торсалар, ни күрсеннәр: ачуыннан ярсыган ир ишекне иңенә салып кергән.

Иртәгесен акыл утырткан ирләр бер-берсен аңлашканнар аңлашуын да, әмма шул җирлектә туган имеш-мимешләр телдән телгә йогып үрчи биргән. Дөрес булса, хак булса, директорның яшь хатыны белән борчагы пешмәгән Габбасов барыбер үзенекен иткән. Җиде төн уртасы дип тормаган, инспектор кыз кунаклаган фатирга киткән. Кыз ягындагы тәрәзәгә бер генә чирткән, ишеге дә ачылган. Мәсьәләнең асылына тиз төшенгән хуҗа хатын аптырап калмаган, икесенә бер бүлмәгә үз кулы белән урын да җәеп биргән. Гыйльмеҗиһанның эше хутта ди, хәзер мөдир дә, инспектор да аның кулында: «Күр дә тор, орденын ук ала алмаса да, медален тагып куяр әле».

Ләйсән юлдашы мөдир башыннан узган бу хәлләрне баштарак ышаныргa-ышанмаска белми авызын ачып тыңласа да, гайбәтнең үзенә кагылган өлешен ишеткәч, бүлмәне яңгыратып көлеп җибәрде. Ләкин икенче көнне уеннан уймак чыкты:

— Бик күп сөйләшә башладыгыз, Ләйсән Гәрәевна,— диде аңа Габбасов, каш астыннан гына карап,— бүгеннән алып аппаратка мәктәпләрдән гайбәт ташуыгызны ташлагыз.

Өстенә ауган бу нахактан телсез калган Ләйсәннең йөзенә күк тимгелләр типте.

— Минме? — диде ул, кулын күкрәгенә куеп.— Минме сөйләгән?..

— Ярар, аңлашылды,— диде мөдир, инспекторны кызып китүдән туктатып.— Кара әле, ничек кызардыгыз. Ояла белгән кешедә өмет бар. Димәк, моннан соң мондый хәлләр кабатланмас, дип ышаныйк.

*
* *

Лэйсэн эштэн үзгэреп кайтты. Аның һәр хәрәкәтендә, кыйланмышында артык олысымаклану сизелә. Башка чакта ул өйгә кайткач ук кешелеккә кия торган киемен үзе теккән җиңсез халатына алыштыра иде. Яшел борчак төшкән бу кыска күлмәк аны кызчык итә. Шуның өстенә, эштә ирләр катында оялып-тартынып утырган кыз Суфия апасы янында иркенәеп китә. Ялан тәпиенә үкчәсез чүәген элә дә кухняны айкап чыга. Тәмле аш исен сизгән борын яфраклары бөрешә, иркә күзләрен ача-кыса, апасыннан үзен җәлләткән була:

— Бу минутта дөньяда миннән дә ач кеше юк, ипекәемдер, менә.

— Ризык белән ант итмә,— ди аңа Суфия апасы ачуланып, аннан соң, кәефен җибәрмәгәем дип, аркасыннан чәбәкләп ала.— Кылтайма тагын. Укытучылар җитәкчесе, имеш, син нарасыйның үзен җитәкләп балалар бакчасына озатасы бар.

Ә бүген үзгә Лэйсэн. Юл костюмнарын салгач та, халатына үрелмәде, кеше-кара кергәндә кия торган җиңле күлмәген эзләп тапты. Бер дә төчеләнмичә, апасының хәлен сорашты. Ашыкмый гына табын хәзерләште, сөйләшми генә ашады. Телевизор катында да озак утырмады, «Соңгы хәбәрләр» сүнү белән эш өстәленә күчте.

Суфия апа, кичке йорт эшләре белән гадәттәгечә бер кат мыштырдап алгач, игътибарын кызга юнәлтте.

— Апам,— диде Лэйсэн, яңадан җитдиләнеп,— хәзер генә төшенә башладым...— Ниһаять, ул күңелендәген бушаткандай булды. Сулкылдап сулыш алды да сүзен дәвам иттерде:— Бик-бик җаваплы эшкә тотынганмын бит мин, әй. Утыр әле, уйлашыйк бергә,— диде аннан соң, урындыгын апасына сузып, үзе өстәл башына терәлгән диван почмагына күчте. Суфия апасы, Лэйсэннең бер генә җөмләлек кысыр хәсрәтен тыңлагач, үзенекен әйтте:

— Бик күп укыйсың, кызкай. Азрак ял ит, танса-мансасына бар. Теге егеткә хат яз.

— Кайсы?

— Кушнарат укытучысына, теге предложение ясап маташкан...

Лэйсэн көлемсерәп куйды.

— Көлмә дә, нитмә дә. Мине синең киләчәгең борчый.

Лэйсэн кашын җыерып язу өстәле янына узды. Суфия апасы тезеп куйган яңа журналларны актарган булып, аңа бирәсе җавапны үзүзенә бирде:

— Тансага... Булмый. Тансага чабар яшь узып бара. Теге Кушнарат егетенәме? Булмый, сүз кушкан бер егеткә борылып карый башласаң, дәрәҗәңнең кайларга тәгәрәгәнен шәйләүчеләр табылыр. Әле болай да...

*
* *

Лэйсэн эшкә иртәләп килүчән... Бүлмәдәшләре күренгәләгәнче, киеме элгечтә булыр, үзе көзге каршында төзәтенгәләгәч, алдына кирәкле кәгазьләрен җәеп эшкә утырыр. Бүген дә шулай, иплэп кенә кабинет ишеген ачкан иде, сискәнеп китте, күңеленә килгәнен теле белән әйтә алмый аптырап калды.

— Ай, бу Сезме, ни, Сабирҗан абый? Хәерле иртә, алайса!

— Исәнмесез, Мөслимова,— диде яндагы буш өстәл артына утырган кунак, кашларын җәя төшеп.— Көтмәгәндә килеп төштек бу юлы.

— Ник хәбәр итмәдегез соң? Каршылаган булыр идек.

Кунакның елмайганда чагыла торган платин теше ялтырап китте.

— Без синең белән чакырып кына алына, зурлап каршылана торган кунаклар гына түгел шул, сеңелкәш.

Ләйсән юка иреннәрен бөреп, сул кашын кыйгайтты:

— Дөрес сүзгә җавап юк.

Сабирҗан Гайнуллин — Мәгариф министрлыгы инспекторы. Ләйсән аның белән РОНОга чакырылган көнне — язгы ташу өстендә — мөдир кабинетында танышкан иде.

Шул елны ук алар хезмәттәш булып киттеләр. Ике-өч ай саен очрашып торалар. Менә бу юлы да бик вакытлы килде әле ул.

Быелгы бәйрәм түгәрәк санлы, Сәфәр ага әйтмешли, мөбарәк санлы бәйрәм. Аны каршылау хәзерлеге күптән башланды. Октябрь каһарманнары сафына бастырасы үтә яхшы укытучылары бар.

Менә ул икенче көнне үк Гайнуллин алдына сөлге буе исемлек китереп салды.

— Карагыз һәм сайлагыз. Берсеннән-берсе әйбәт кешеләребез болар: укытучы булып туганнар, укытучылыкка укыганнар, укытучы булганнар. Барысы да шул изге юлда: эш дигәндә — җаннары фида.

Исемлек инспекторлар күзеннән үткәч, райком, профком бюроларында тикшерелгәч, иләктән-иләккә сөзелгәндәй, шактый кыскарды.

— Сабирҗан абый,— диде Ләйсән, кабинетта икәве генә калгач, аңа ялварулы күзләрен текәп,— чын кеше итеп баш ия торган бер кешем бар. Шуны исемлектән тәгәрәткәннәр.

Гайнуллинга кызның чаялана гына түгел, назлана белүе дә ошады.

— Беләм мин ул укытучыны. Әйбәт, бүләккә лаеклы. Әмма барысын да берьюлы зурлап булмый, бүләкне өләшмиләр бит...

Кызның сөмсере коела башлаган иде, Гайнуллин аның җилкәсенә аталарча сакланып кына кулын салды, ә кыз тартынып куйды.

— Яшьрәк чакта мин дә сезнең кебек чәчрәп чыгучан, сүземне сүз итү өчен яна торган кеше идем. Олыгая төшкәч, басылдым. Кирәкми, дөрләргә ярамый. «Йөрәкне йөгәнләргә кирәк»,— ди берәү, канатлы йөрәкләр күгәрчен кебек очып чыгарга торалар. Очырмагыз әле сез аны.

Кышкы айларда йокымсырап яткан буран март башларында шаулап уянды, карын-ниен берьюлы тузгытып дуларга тотынды. Атналык командировкага гына килгән министрлык вәкиле юл өзеклегенә, һавалар болганып, очышлар тукталып торуга артык хафаланмады. Укыту бүлеге мөдирләрен җыеп сөйләшкәч, алдына мәктәпләр исемлеге алып салды, каләмен тамгалы графага төртте:

— Безгә бу мәктәпкә барып кайтырга кирәк булыр...

*

* *

Илле алтынчы размерлы толып эченә чумган Ләйсән үрәчәле чананың түренә чумәште.

— Төньяк котыпка юл тоттык,— диде шундый ук толыплы Казан инспекторы, дилбегәне кагып.— Хәерле юлга!

Мөдир, бераз соңгарак калып чыксагыз да ярыйсы иде, юл бераз языла төшсен иде, дисә дә, алар ашыктылар.

— Үзебез сапкан юллардан атлыйк әле!

Табигатьнең дә үз холкы холык. Төн буена сызгырган җил таң алдыннан басылып, көн җылынып китте. Ай буе сарайда солы ашап яткан бахбай да сәфәрне тансыклаган, ахры, тигезрәк урыннардан юырта, көрт салган төшләрдә абынмаска тырышып гайрәтләнеп атлый. Ләйсән исә, толып эченнән башын калкытып, ак юрганлы иркен басуларны хозурланып карап бара.

— Шәһәрләрдә мондый ак карны күрмисең,— диде кунак, кызның күңелендәгеп җөпләгәндәй.— Кайчандыр заводларны шәһәргә тереп салганнар...

— Шулай да, безнең калалар көнбатышныкылардан пагьрак.
— Сөремгә ысланган Лондонны истә тотасыз дисез инде.
— Әйе, һавасының шакшылыгы буенча ул дөньяда беренче урында тора. Аннан кала Будапешт...
Юлдаш һәр иҗегенә басым ясап әлеге шәһәр исемен кабатлады:
— Бу-да-пешт... Геллер калкулыгы... Шуның башында мадьярларны фашистлардан азат итешкән гаскәрләргә һәйкәл бар. Мин аларның исемнәрен куен дәфтәремә күчереп алып кайттым.
— Анда минем әтинең дә исеме булырга тиеш.
Ләйсәнгә бөркү булып китте. Ул толып якасын артка кайтарды. Күзләрен ярым йомып, тирә-якны каплаган кардай ак мәрмәргә уелган фамилияләрне хәтерләргә тырышты. Әйе, рус, украин, латыш исемнәре белән рәттән тезелгән татар фамилияләрен кат-кат укып торды бит ул: Галим Шакиров... Гайса Мөхәммәтшин... Камалетдин Гайнуллин...
— Әйе, бар ул исем минем дәфтәрдә,— диде кыз, авыр сулап. Аннан соң Гайнуллинга беренче мәртәбә әтисенең исемен кушып дәште.— Бар, Сабирҗан Камалетдинович. Бар!..

*
* *

Август киңәшмәләре килеп җитте. Сәфәр абый аны укытучыларның сабан туе дип атый иде. Ләйсәнгә дә шулай тоелды. Бу көнне үзәккә машина-машина халык агыла. Халык дигәнебез — районның хөрмәтле мәгърифәтчеләре. Язгы чәчүләреннән бушагач печәнгә төшәр алдыннан бераз көч сынашып алырга теләгән игенчеләргә охшыйлар алар бу көннәрдә. Ярата Ләйсән алтын көз башында шаулап үтә торган бу җыелышны.
Быел докладны ул ясаячак. Мөдир кисәктән авырып китте. Больницага салдылар. Ашказанында зыян бар икән. Операция ясамый булмый, диләр.
Киңәшмәгә мәгариф министры урынбасары киләчәк. Ләйсән элеккесен якыннан күрешеп-сөйләшеп белә иде. Ләкин аның шушы көннәрдә генә РСФСР министрлыгына күчкәнен ишетте. Янасы кемдер, телеграммада фамилиясе әйтелмәгән. Вәкилне каршыларга райком машинасына утырып үзе чапты.
Киләсе самолетның якынча ике сәгатькә соңгаруын ишеткәч, кире борылмакчы иде, аны аэродром радисты туктатты:
— Иптәш Мөслимова, әле генә радиодан хәбәр иттеләр: сезгә киләсе кунак санавиация самолеты белән оча. Алар инде һавада. Көтегез.
Кызыл хаҗ тамгалы «ЯК-12» очкычына трап куясы түгел, люк ачылуга очучы артыннан ук чирәмгә бер-бер артлы ике пассажир сикереп төште.
Тукта, боларның берсе инспектор Сабирҗан абый түгелме соң? Шул, билгеле. Икенчесе?!.
Ләйсәннең йөрәге тетрәнеп куйды. Исәнләшергә дип ачылган иреннәр тартылып китте. Кунакның танырга теләп текәлгән үткер карашыннан әсәрләнгән күзләр кыюсызландылар.
Рахман Еникеев! Өнме бу? Төшме?
Кеше дигәненнең, ерактагы якты йолдыздай, яшьлек томанлыгында үзенә тартырга теләгән берәве булмый калмый. Ә менә аны онытырга еллар, еллар кирәк булса, хәтерне яңартырга секунд җитә. Мөҗәһит хыянәтеннән соң ул аның исемен бушанган йөрәк сандыгына бикләде. Менә шул йозакка аз гына орындыңмы, чыңлап китә. Әлеге «чың» күңелләрне айкап, хәтергә сеңгән истәлекләрне яңарта.

Бер елны Лэйсэн Казанга кышкы сессиягә барышлый авыру балалы хатын белән бер купега туры килгән иде. Арган апаны ял иттермәк булып, ул елак сабыйны көйли-көйли ишекле-түрле күтәреп йөрде. Авыру баланың уймак иреннәрен үзенең пакь яулыгы белән сөртте.

Ә берничә көннән үзе аяктан егылды.

Аны больницага салдылар.

— Сездә паротит,— диде доктор, авыру кызның кысылып беткән дымлы күзләренә карап,— колак төбе бизләрегез шешкән. Бүген үк операция ясыйбыз.

Лэйсәнне дару исе аңкыган якты бүлмәгә илттеләр. Үзен кабул иткән кичәге докторны ул башта танымый торды. Битенә марля каплаган халат өстенә полиэтилен алъяпкыч япкан, җиңнәре сызганулы. Күзләре — кырыс. Ул сестрага нидер ымлады, шприц тотып Лэйсәнгә иелде.

— Санагыз,— диде доктор авыруга.

— Бер, ике, өч...

Кыз унбишкә кадәр санады.

— Тагын,— диде әлеге кырыс тавыш сестрага,— организм яшь. Бирешми.

Лэйсән ничек йоклап киткәнен хәтерләми, ул тамак төбе чатнап, сусап уянды, яңак элеккечә башны тулгандырып түгел, ярылган урыннан сызлый, әчеттереп сызлый иде.

— Су, су-у-у...

Палатага хирург керде. Ул, зур күзләрен туры аңа төбәгән килеш, карават янына ук килде дә, юрган итәген кайтарып, янына утырды. Лэйсән шундый оялды, яткан җирендә көзән җыергандай бөгәрләнеп куйды.

— Борчылмагыз, борчылмагыз,— диде доктор аңа йомшак тавыш белән һәм елмаеп.— Мена хәзер сезнең шартлы рефлексларыгыз эшли. Ятсына башладыгыз. Кызларга килешә ул.

Хирург иплэп кенә кызның кулына үрелде. Баш бармагын беләк тамырына йомшак кына басып, йөрәк тибешен санады. Читкәрәк карап, дәшми генә кан басымын тыңлады. Аның кинәт сүзсез калуы авыруны сагайтты, шуңадыр, ахры, үзе дә сизмәстән, сабыйларча сорап куйды:

— Доктор, мин терелерменме икән?

— Әлбәттә,— диде аңа доктор көлемсерәп,— менә бүген сөйләшәсез инде, иртәгә торып утырачаксыз, ике көннән елмая башларсыз. Аннан соң инде аякка басасы гына кала. Бер атнадан танцага җибәрәм мин сезне.

Чынлап та, биш көн дигәндә аякка басты Лэйсән.

Больницадан чыгасы көн иде. Ул докторына рәхмәт әйтеп саубуллашырга керде. Хирург җитди иде. Сирәк елмая икән дип уйлады аның турында Лэйсән. Өстендә шул ук килешле пакь халат, түшеннән ак якасы белән кызыл бөрчекле галстугы күренеп тора. Аягында ялтыравык шиблитләр.

— Рәхим итегез,— диде ул, ишек катында кыяр-кыймас басып торган кызны кечкенә өстәле янына ымлап, үзе шул ук секундта ачылып китте:

— Мөслимова!..

Лэйсән ни әйтергә белми кызарып куйды.

— Шулай...— диде аңа бераз карап торгач доктор,— вакытында операция ясамасак, шешегез мигә үк үрмәлисе иде. Шундый чибәр кызга яшәргә дә яшәргә кирәк бит әле.

Лэйсән аның больница листогына куйган имзасын кат-кат укыгач кына төшенде: Еникеев икән, ә исемен озатырга чыккан сестрадан сорарга базды. «Рахман Харрасович дип дәшәбез без аңа. Егет кеше. Өченче елын эшли. Быел ординатурага китә»,— дигән җавап алды.

Аннан соң кыз доктор Еникеевне җәйге сессия чорында Җәлил театрында очратты. Ләкин бу очрашу йөрәккә тамыр җибәрергә өлгермәгән үсенте хисләрне утагандай булды. Егет үзе генә түгел, хатынымы, кызымы шунда, кыяфәтенә, кыланышына ятышлы ялтыравыклы күлмәк кигән берәү белән иде.

Ләйсәннең йөрәге тырналып куйды. Көнләшепме? Алай дисәң, ни хакы бар әле аның моңа? Югалтуданмы? Нәрсәсен? Кемен? Хәер, югалтулар да төрлечә була. Күңеленә дә матур эз салган бер хатирәсе җуелды аның шул көнне.

Очар кош җимен, тыйнак кеше тиңен эзләр, ди. Ә инде аны эзлисе юк. Ул — бар. Кызның ялындырып йөргән көне генә. Шул кичне ул Мөҗәһитенең бер атна элек килгән хатына җавап язды. Күп итеп язды. Җылы итеп язды.

*

* *

Тукта, бу көтелмәгән очрашуны нигә ул аның исеме белән күләгәли әле. Шуның тәэсиредер, кинәттән алланып киткән яңаклар сүрелде. Оялып керфекләре астына поскан күзләр ачылды. Үзен кулга алды һәм беләзексез-нисез нәфис кулларын Еникеевкә сузды. Ул кунакка исеме белән дәшмәкче, докторым дип әйтмәкче, аның бу якка килүенә бик шат булмакчы иде. Әмма Гайнуллин бүлдерде: ят кунак белән таныштырырга ашыга, янәсе.

— Мине үз буксирына алган бу мәрхәмәтле юлдаш доктор Рахман Харрасович була инде. Ә бу иптәш,— диде ул, яңадан Ләйсәнгә борылып,— безнең инспекторыбыз Ләйсән туташ!

Кайчандыр күңелне алгысыткан үткер күзләр белән яңадан очрашкач, тагын каушап китте кыз.

Юл уңаенда алар кунакны больница янында төшереп калдырдылар.

— Ул бүген Габбасовка операция ясаячак,— диде Гайнуллин,— бәхете бар икән: шәп хирург чакырткannар.

— Киңәшмәгә сезнең үзегез килүегезгә мин бик шатмын,— диде инспектор әлеге башны әйләндергеч күрешүләрдән, сөйләшүләрдән арынгач.— Ят вәкил киләчәк дигәч, әллә ничегрәк тоелган иде.

— Сез көткән бәндә, ят бәндә без үземез буламыз инде, кем әйтмешли...

*

* *

Район культура йорты бу көнне шау итте. Фойелар, тамаша залы гөр килә. Түрдәге ялтыравыклы өстәл гөлләргә күмелгән.

Киңәшмә алкышлар белән ачылды. Президиумга түшләрен орден-медальләр бизәгән ветераннар, мактаулы укытучылар, кунаклар күтәрелде. Тантаналы минутлардан соң Мөслимова трибунага чыгып басты.

Сәгать ярымга сузылган доклад дәвамында сәгатенә багучылар сизелмәде. Алкышлардан соң сораулар яуды. Җаваплар тапкыр иде. Кызыклы чыгышлар, тәкъдимнәр белән киңәшмәнең беренче көне тәмамланды.

*

* *

Гайнуллин белән Ләйсән больницага барып килделәр.

— Габбасов «сират күперен» узган,— диде кыз җиңел сулап.

— Рахман Еникеев ни житте хирург кына түгел, доцент кеше.

— Рәхмәт аңа.

— Анысын үзенә әйтеп җибәрергә кирәктер, иртәгә китә инде ул. Кунак йорты яныннан узабыз түгелме, әйдә, янына кереп чыгыйк. Ул анда хәзер.

Лэйсэннең миң тамган бит очлары алланып китте. Бу сөйкемле кунак белән тагын бер очрашырга күңел бик тели, тик... Шул чак аның башына кисәктән кызыклы уй килде:

— Бередә мин түгел, сез үзегез кунаклар. Вакытыгыз сыйдырса, мин сезне үзебезгә чакырыйм, чәйне бездә эчәрбез.

Лэйсәннең тәкъдиме кунаклар күңеленә хуш килде.

Суфия апаның ашы өлгергән, самавары куелган иде. Лэйсәнгә ашъяулык җәеп кашыклар гына таратасы калган. Табын әзер булгач, кыз кече якка апасын чакырырга керсә, ни күрсен, суыткычтан торна борынлы шешә чыгарып ята теге.

— Кире тык,— диде ул апасына ялварып.— Ир-ат алдына хатын-кыз эчемлек куямыни? Килешми!

Суфия апа аның сүзен колагына да элмәде, алай гына да түгел, кунаклар ягына шешәсен болгап сөйләнә-сөйләнә узды:

— Синнән сорап тордым ди менә, үзем сыйлыйм, рәхмәтен дә үзем алам. Кызым саран,— диде, үзе табындагыларга күз кысып,— беркем алдына бернинди шешә куйдыртмас, үзе дә бер тамчы капмас. Ни печән ашамый, ни сарыкка ирек бирми, дигәндәй.

Шау килеп көлештеләр.

Суфия апа Гайнуллин Сабирҗанны ишетеп тә, күреп тә белә. Ә менә Лэйсәннең юка иреннәренә, елмайганда тоташа язган озын керфекләренә карангалап алган Казан докторын астан гына сынап утырды. Чырайга яшь күренсә дә, чигәләре агарган, бу иргә кырык өч-кырык бишләрне шикләнмичә бирергә була. Күзләре акыллы, хәрәкәтләре салмак, сабыр холыклыдыр. Күңелгә ятмаган җире юк. Ят кунак алдында юашланып калган кызга да караштырып алгалады. Киңәшмәгә барганда салган алкасын яңадан таккан, йөзеген кигән, кашын озайткан, хәерле булсын. Моңарчы исеме-ние чыкмаган кызкайның башы әйләнеп китмәгәе тагын. Сайлаган сазга, тап булган «нигә» дигәндәй. Бу бәндә таз ук түгел түгелен. Әмма шундый чибәр, дәрәҗәле ир шушы яшькә чаклы гаиләсез торамыни?! Менә бит хикмәт кайда. Мөҗәһит дигәне егет килеш тә әллә нишләп китте...

Хуҗа апа әнә шулай үзенчә юраштыргалаган арада, кунаклар яратып аш ашадылар, чәй эчтеләр. Башланган күңелле әңгәмә ашъяулык алышынгач та дәвам итте. Лэйсәнгә татар, рус, көнбатыш әдәбияты шактый таныш. Андый кешеләрне тыңлавы күңелле. Рахман — галим кеше, медицина әһеле. Шуның өстенә ана телендә гаҗәп матур сөйләшә. Шулай да сүз аралаш мөрәҗәгать иттем диясе урынга «мөҗәрәгать», министр урынбасары урынына «министр юлбасары» кебек имгәнгән сүзләр дә ычкынгалады. Хуҗаларның мондый чакта көлмәскә тырышып сүзне икенчегә боруларын сизенгәч, түзмәде, үзе үк елмайды:

— Үртәмәгез. Сез әле минем кайчандыр ярым-йорты милләт булып йөргәнемне белмисез. Безнең өебездә татарча аңлашалар иде. Ә мин исә, ул чакта дөнья офык белән чикләнә дип уйлый торган малай, һәр ике телгә дә тиешле игътибар бирмәгәнмен, күрәсең. Аспирант чак иде, Мәскәүдә Куба яшьләре белән очраштык. Алар белән иркенләп испанча аңлашкан бер олы галим, Казан егете икәнлегемне белгәч, искәрмәстән миңа минем ана телемдә дәште: аннары аптырап калуымны сизептер, сүзенә ачыклык кертте:

— Кеше кайсы гына баскычта тормасын, туган теленең барлыгын тоймаса, башка милләт телләренә игътибарсыз була. Югарырак күтәрелергә омтылган фән кешесе өчен бу зарури,— диде.

— Менә шуннан мин телемнең нигез ташы ныклыгына чынлап иман китердем. Гафу итегез, монысы да татарча яңгырамый, ахры.

— Кайберәүләргә аңлашыла, иман — гарәпчә ышаныч дигән сүз. Әйбәт сүз.

Рахман Ләйсәнгә тагын бер сөеп карады. Ә Ләйсән күңеленнән инде ничәнче тапкырдыр шуны уйлый торды: бу бит, бу бит мине үлемнән диярлек коткарып калган докторым, әйтимме икән шуны... Кирәкми лә. Бер вакыты, җае чыгар әле.

Ул җитдиләнеп китте. Кунакның медицина әһеле булуын искә алып, сүзне шул якка юнәлтте. Доцент моны бик хуп күрде. Һәм үзе дә тел очында торган фикерләрен әйтергә ашыкты.

— Яхшы әсәрләр укыганда мин шуны тоям, язучы — психолог ул. Латинча рецептлар гына яза белми. Академик Павлов кешеләрне нервларына карап дүрт төргә бүлә: холерик, флегматик, сангвиник һәм меланхоликларга... Язучы да персонажларын әнә шул категорияләр аша тасвирлый булыр.

— Монда гаҗәпләнер урын юк,— диде Ләйсән, кунакның якты күзләренә карап.— Сезнең белән язучылар арасында уртаклык бар. Сез, һәр икегез дә, кешеләр яратучы, кешеләрне яхшы аңлаучы. Гомер буена кешеләр тормышын җиңеләйтү өчен көрәшәсез. Доктор кеше гомере сагында торучы солдат булса, язучы — кеше күңеленең инженеры.

Рахман башта, шәрабтан баш тартып, туры карарга кыймый утырган бу нәзакәтле туташның кыюлана баруын тойды.

— Уртаклык бар дисез инде сез. Ләкин бит сәләтле һәр кеше медицина институтына имтихан тота ала һәм биш-алты елдан «кешеләр гомере өчен мәңге көрәшәчәкмен» дип ант бирә, ягъни врач була. Ә бит язучылар мәйданына филология факультетыннан меңгә берәүләр генә күтәрелә.

— Бу фикернең асылы сезгә таныш. Сүз медицина өлкәсендә ачыш ясаган галим-табиплар белән кешеләр рухын тәрбияләүче язучылар турында гына бара. Кешеләрне врач әнә шул галимнәрнең гасырлар буена ача килгән дарулары белән шифаласа, без — гади әдәбиятчылар, шул ук гасырлар тудырган язучыларның әсәрләрен бәяләүчеләр, шулар аша яшь буынны тәрбияләүчеләр, дөресрәге, әдипләребездән калган мирасны һәм бүгенге әдәбиятны халыкка җиткерүче илчеләр.

Һәр минутын исәпкә алырга күнеккән галим бу юлы сәгатькә карамаска тырышты. Сәдә күңелле мондый акыллы кыз белән саубуллашырга ашыкмый иде әле ул.

— Ләйсән,— диде ул, кызга тагын исеме белән дәшәсе килеп,— әдәбиятка медицина өлкәсеннән килгән язучылардан кемне аеруча яратасыз?

— Ак халатын ак кәгазьгә алмаштырган әдипләргә образлар тудыру җиңелрәктер шикелле. Алар аек психологлар. Бар алар.

— Шуның өстенә артык реалистлар да.

— Чеховны күз алдында тотасыз, әлбәттә. Бер генә хикәясен алыйк. «Милочка»дагы ханым саф күңелле, беркатлы кеше, ә үзе бичара. Кеше дөнья яктысын тоеп рухланырга, яманын күреп гыйбрәтләнергә тиеш. Ә ул шул ике арада адаша. Чөнки ул яхшыны яманнан аера алмый, мөхите тар.

— Вересаев?

— Викентий Вересаев ул доктор чагында ук кешеләргә, сез әйткәнчә, дөрес диагноз куярга ант иткән. Шуңадыр кешеләрнекенә генә түгел, үз күңеленә дә чаршау кормый, чөнки кешеләр берсе дә коеп куйган фәрештәдәй саф, Гомердәй даһи, «Гали» батырдай пәһлеван түгел. Ул шуны раслый. «Врач язмаларын» гына хәтерлик.

Аннан сүз элекке ипи салучы Максим Горький, юрист Гомәр Бәширов, шахтер Шәйхи Маннур, журналист Муса Җәлил, кавалерист Бабель, комиссар Шамил Усманов, архитектор Андрей Вознесенскийлар турында барды. Кешене институт кына түгел, ә тумыштан бирелгән

сәләт, аяусыз тырышлык, тормыш язучы ясый икән дигән уртак фикерне расладылар.

Саубуллашканда Еникеев Ләйсәнгә өендәге һәм эшендәге телефоннарын әйтте.

— Әңгәмәне Казанда дәвам итәрбез дигән өмет бар...

Бу затлы ирнең гаиләсе белән чынлап торып кызыксына башлаган Суфия форсаттан оста файдаланды:

— Шалтыратырмы икән, белмим шул. Минем кызым кемнәрнедер көнләштерергә теләмәс шул.

Кунаклар бер-берсенә карашып елмаештылар.

— Рахман Харисович — өйләнмәгән, егет кеше.

— Алайса, була!..

Ләйсән, күңелендә рәхәт бер талпыну сизсә дә, апасының Сабирҗан абыйсына биргән җавабын өнәмәде: «алайса...» имеш.

Рәхмәт әйтешеп, кул бирешкәндә, ул Еникеевнең кайнар учын тойды. Чынлап та, Рахман кыз белән күңеленнән сөенеп саубуллашты.

Урамга чыккач, ул Гайнуллинга да сак кына шуны әйтеп куйды:

— Мине бу кыз белән таныштыруыгыз өчен рәхмәт.

— Сез инде аның белән таныштым дип уйлыйсызмыни?

— Аңламыйм? Сез Ләйсәнне яхшы беләсезме?

— Ике соравыгызга бер җавап: җилгә сыгылмый, кыраудан көелмый торган кыр чәчәге ул. Тигәнәк сыман...

— Алайса, теләсә кем өзә торган түгел.

— Әйе, сәламәт куллар, тәвәккәл йөрәкләр генә үрелә андыйга!

*

* *

Бер айдан Габбасов терелеп эшкә чыкты. Атналар буена ташпулатта аунау уен түгел шул. Агарып, суырылып калган. Авырудан соң кеше сабый сыман көйсезләнүчән була, диләр. Дөрестер, менә ничә көн рәттән инде ул кара коелып йөри. Бүлмәсенә әле методика кабинеты мөдирен, әле Әкбәрованы чакыра. Башкалар Әкбәрованың үзәк кабинетта сәгатьләр буе утыруын өнәп бетермиләр. Ләйсән елмая гына, «шикле генә чикмән бөркәнә» диләр, гөнаһсыз-нисез юрап-юранып утырмагыз ла, ди ул. Ә үзе муеннан эшкә чумган. Министрлыктан формалар белән генә йөртелә торган әллә никадәр кәгазь килгән. Ничә укытучы, күпмесе югары белемле, ничә укучы, кайсы милләттән һәм башкалар, һәм башкалар. Аннан соң ул шул кәгазьләрне тутыргач, хисап бирү өчен Казанга барачак. Туганнары белән күрешәчәк, Сабирҗан абыйсы янына кереп чыгачак, киңәшәчәк. Бәлки, бәлки күңелне алгысыткан теге телефоннар санын да җыяр... Шул минутта аның битләре кызышып китте. Юктыр, кыюлыгы җитмәс монысына. Аңа шалтыратып сәлам бирү һавада очып барган кошка кул болгап калу белән бер.

Габбасов турсайган, күз кабаклары кабарган. Әллә сырхавы яңарамы икән,— дип куйды кыз аңа карап. Ләкин мөдир аның кызгануына бүген бер дә мохтаҗ түгел иде.

— Сезнең белән сөйләшәсе бар, Мөслимова,— диде ул.— Сорауларыгызны, аңлатмаларыгызны соңыннан бирерсез.

Ләйсәннең бу кысыр кисәтүгә хәтере калды: аның беркайчан да каршында сөйләшеп утыручының сүзен бүлдергәне юк. «Кешеләрне игътибар белән тыңлый белү үзе бер сәләт»,— дигән Сократ.

— Мин моңарчы сезнең бар эшләрегезгә дә — яхшысына да, уртачасына да әйбәт тамга куеп килдем. Ләкин дә соңгы вакытларда эшегез ифрат дәрәҗәдә сүлпәнләнде. Менә ел ярым инде аппаратка өстегездән языптыр, шалтыратыптыр торалар.

Лэйсәннең иреннәре шәмәхәләнде, кашлары кушылды. Директор Җәләлов белән Сәкинә Галимова әмәлләгән уйдырмалардыр бу, дип уйлады ул эченнән.

— Ә нигә мине ул хатлар белән таныштырып бармыйсыз? Ялгышсам, төзәтер, нахак яксалар — яклар идегез. Сез бит җитәкче...

Соңгы сүзләрне ишеткәч, мөдир бер мәлгә йомшарып киткәндәй булды. Әмма әлеге кырыслыгыннан чигенергә теләмәде:

— Ялганга саналган һәр язмада өлешчә дөреслек тә була.

— Шул өлешләрне җыеп зуррак нәтиҗәләр ясарга җыенмыйсыздыр ич?

— Нәтиҗәләр чыгарырга сез үзегез дә бик остарып барасыз. Мәсәлән, Шәмдәл урта мәктәбен тикшердегезме?

— Тикшерү акты өстәлегездә.

Мөдир телен чатлатып куйды.

— Больницага кеше үләргә керми... Мине көтмәгәнсез, диюем.

Инспектор йомры иңбашларын кузгатып куйды:

— Сез савыгып чыкканчы эшләрне бераз җиңеләйттим дидем.

— Катлауландыргансыз гына сез аны. Язган актыгызга таянсаң, директор Җәләловны эштән алырга кирәк.

— Анысы безнең уртак эш.

— Күп нәрсәләрне уртаклый башладыгыз сез, иптәш Мөслимова. Беренчедән, укыту-тәрбия эшләрен тикшерә башларга иртәрәк әле. Уку елы башы гына. Икенчедән, яңа программага күчеш чоры. Бәхәсле, кыен мәсьәлә хәл ителә. Яңалык ул — яңа кар кебек: бүген ява, иртәгә эри. Әнә шулай ява-ява, эри-эри генә иңә ул тормышка. Өченчедән, ул мәктәптә шунда туып үсеп, гомергә шунда төпләнгән йортлы-җирле укытучылар эшли. Менә шуларның көен табып эшләргә гайрәтле директор кирәк. Җәләлов шундый. Кемнәрнендер йөрәгенә сары май булып ятмый икән — анда безнең эшебез юк. Мин андый директорны аяз көнне кулыма шәм тотып түгел, прожектор яндырып эзләсәм дә таба алмыйм. Вот так!.. Менә синең шундый дуамал нәтиҗәләрең аркасында туган чуалчыкларны без бүген җыелыш җыеп тикшерергә булдык. Бер сәгатьтән — барыгыз да минем кабинетка!

Лэйсән Габбасов яныннан чыккач китапханәгә күтәрелде. Өстәлдә яткан журналга иелеп яңагына таянды. Үзе укыганга сабышты, ә уйлары аны Шәмдәл мәктәбенә алып киттеләр.

Былтыргы тикшерү вакытында анда яңа программа буенча укытуга искитмәс караш сизелде. Директор горбиянланган, коллектив фикере белән исәпләшми башлаган иде. Лэйсән, быел яңа уку елы башлану белән, дүрт укытучыдан торган комиссия төзеп, тагын шул якка юнәлде.

Ә директор Җәләлов исә аларны, вакытсыз килеп йөдәткән эрсез кунакларны каршылагандай, эреләнеп кенә кабул итте. Чөнки ул шактый еллар уңган җитәкчеләрдән саналып килә. Үзен районның иң шәп укытучысы итеп хис итә. Моңа азмы-күпме җирлек тә бар. Ул институт эскәмиясеннән генә торып әзер постка баскан җитәкче түгел. Элекке фронтовик. Польша туфрагына каны аккан. Демобилизацияләнгәч погоннарын салу белән физкультура укыта. Техникумны да, институтны да читтән торып тәмамлый. Аннан соң — укыту бүлеге мөдире. Менә ун еллап инде директор булып тора. Бу дәрәҗәгә ул тормышның ачысын-төчесен татып, үз тырышлыгы белән ирешкән кеше. Хуҗалык белән оста идарә итә. Яңа мәктәп салдырды. Аның каршында кечке урта мәктәп ачылды. Мәктәп тирәли гөлбакча шаулап утыра. Түшендә — мәгариф отличнигы значогы. Үзен илчелек вәкилләредәй төз, вәкарьле тота белә. Елмайганда да күзләре уяу аның. Дәрәҗәсенең ныклыгына ышана. Берәүләрнең кичергән авырлыклары яки үзен данга күмгән шатлыклары, тырышлык бәрабәренә килгән җиңүләре аны киң күңелле, хөрмәтле кешегә әверелдерсә, икенчеләрне — гади кешеләрдән аера.

Юл биргәннәрне сәламләп, каршы килгәннәрне таптап уза башлый андыйлар. Мондый кеше әйләнә-тирәдәгеләрен кимсетә, шәхси каршылык уята. Иптәш Җәләлов соңгы вакытларда әнә шул тайгак юлга баскан. Аны бөтенләй үк абындырмас өчен ипләп кенә читкәрәк чыгарып куярга, постыннан вакытлыча азат итәргә кирәк иде. Инспекторлар шундый карарга килде. Мөдир Габбасов тикшерү комиссиясенең бу тәкъдименә кушылмады: «Үзсүзлерәк кыз булып чыкты ла бу Мөслимова... Миннән узыбрак эшли башлады», дип уйлады ул.

Киңәшмәнең максаты — киресенчә, Җәләловны түгел, инспектор Мөслимованың үзен «читкәрәк чыгарып кую» иде.

*

* *

Мөдир урыныннан торды, тамырлары бүрткән ябык куллары белән өстәлгә таянды:

— Иптәшләр,— диде ул,— көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: инспектор Мөслимова Ләйсән Гәрәевна өстеннән килгән жалобаларны тикшерү.

Үзе Мөслимова ягына карарга кыймады. Инспекторның сиземләвенчә, бу гаугалы киңәшмәне кемнәрдер мәҗбүр итеп кенә оештырганнар түгелме икән?

Маһибә атылып торып басты. Кечкенә буйлы, тутлырак чырайлы бу ханым сүзгә оста, җыелыш карарларын гел аңардан укыталар. Бу юлы да ул каушамый-нитми сүзне дилбегәсеннән тотып башлады:

— Яшерен-батырын түгел, дуслар, иптәш Мөслимованың үз сүзен генә санга санаучы, хәйләкәр һәм иптәшләреннән һәрчак бер башка олырак булырга тырышуын мин, безнең аппараттагылар күптән беләбез. Аның бу сыйфатларын раслаучы хатлар кулга төшкәч, мин моңа тагын бер мәртәбә ышандым.

— Менә бу хатны укыганда,— диде ул, учында йомарлап таушалдырган кәгазьне селкеп,— йөрәкләрем әллә нишләп китте. Менә дигән отличник директор Җәләловны эшеннән куарга, дигән карар әвәләмәкче булган. Нәтиҗәсе нәрсә белән беткәнен соңыннан ишетерсез... Икенче хатны Каенсудан салганнар. Азгын укытучылар саналган «Җәмилә белән Кифаяне тикшерергә килгән инспекторыгыз үзе дә шундыйрак нәрсә, ахры», дип язганнар авылдашлары. Чөнки сез, иптәш Мөслимова, аларны акылга утыртып кайтасы урында, үзегез дә алар компаниясенә кушылып, төне буе җырлашып, күңел ачып утыргансыз. Соңыннан, кунак ашы кара-каршы дигәндәй, үзләрен мактап газетага яздыгыз. Монысының да нәтиҗәсе аяныч. Соңыннан... Өченче хат — Сарсаздан,— дип, икенче як кесәсеннән тагын бер табак кәгазь тартып чыгарды Маһибә. Дерелдәгән куллары белән күзенә үк якын китереп укый да башлады: «Бу хатны аноним хат итеп кабул итмәгез. Имзабызны куярга шикләндек. Әгәр дә мәгәр хат Мөслимова кулына төшә икән, бетте баш. Бәлки ялгызак яшәгәнгә ул шулай кешеләр ярат-мыйдыр...»

Маһибә тотлыгып калды һәм хатны укудан тукталмакчы иде, иреннәрен бөрештереп ачуташ капкандагыдай утырган ярсулы Ләйсән телгә килде:

— Укытучы кеше хатына охшамаган бу, соңгы җөмләсенә кадәр укып бетерегез!

— «Кияүгә чыкмаган кызлар шулай усал булалар инде, ләкин ул үзенең нинди постта утырганын беләме икән?..»

Әлеге сүзләр Ләйсәнгә ядрә булып атылдылар. Йөрәге урыныннан купкандай сулыгып алды. Йөзе киндердәй агарды. Кан йөреше үзгәрүенә бераз түзеп торды да, үзенең чынлап та инде утыздан узганын исенә төшерде. Аның яшьтәшләре барысы да диярлек тормышта инде. Ә ул, ә ул... нигә һаман ялгыз соң әле? Кеше карамастай ямьсез дә, кеше ярата алмастай җансыз да түгел лэбаса.

Булдылар. Аңа караучылар да, яратучылар да булды. Әнә шуларның берсенә пар була алмавына бары «ул» гына гаепле. Ә бит ышанган иде ул аңа, вәгъдәләшкән иде ул аның белән. Соңгы саубуллашулары да хәтердә. Мартның сигезе иде. Хатын-кызлар яшәрә торган көн. Ул, йөз чакрым ара үтеп, Ләйсәнне бәйрәм белән тәбрикләргә килде.

— Арлы-бирле килэп салудан ардым. Соңгы килүем икәнен бел,— диде егет, кызның салкыннан кызарган колак яфракларына җылы сулышын өреп.— Нишлибез? Бар, кереп ят. Уйлан. Кара аны, иртәгә беретка кимә, шәл урап чык.

Егетләр авызыннан берәүгә генә ычкына торган тәкъдим бу. Ул аның кайчан да булса бер әйтеләчәгенә ышана, көтә иде инде. Тик менә, сөйгәне алдында каушауданмы, әллә басынкы булырга тырышыпмы, барысын да кыз хөкеменә куеп торган тыңлаучан егетнең болай дуамал кыюланып китүенә аптырады ул.

— Нигә шулай ашыктырасың, синнән башка беркемем юклыгын, булмаячагын да беләсең ич инде, ышан миңа...

Ләйсән боларны чын йөрәгеннән кабына язып әйтте. Беренче мәртәбә үбешкән, үз күргән егете иде аның Мөҗәһите.

Яңа ел кичәсендә булды бу хәл. Алар, бии-бии башлары әйләнгәч, фойега чыктылар. Анда беркем дә юк, барысы да залда, дөньяларын онытып вальс әйләнәләр иде. Шул чак Мөҗәһит як-ягына күз ташлады да, кызны күкрәгенә кысып, иреннәренә үрелде. Менә шул кичәдән бирле инде кыз егетне үз итеп, аннан оялып, үзен аныкы санап йөри... Егет узгынчы түгел. Алар бер-берсен инде алты ел буена беләләр. Институтлары аерым булса да, бер чорда укыдылар. Җәйге-кышкы сессияләр аларны очраштыра торды. Егет, диплом алганчы ук, туган колхозында инженер булып эшли иде инде. Кыз да, институт тәмамладым дип, моңарчы әллә кая үрелмәде, шул ук мәктәбендә укыта торды, тик күрешүләр сирәкләнә барды. Күрше районнарда гына яшәсәләр дә, эш кешеләренә гел очрашып тору тәтеми иде. Ике йөрәкне бәйләгән мәхәббәт җепләренең өзелмәслегенә артык ышана иде Ләйсән. Мөҗәһит аны беркайчан да рәнҗетмәде, оялтмады. Кайбер кызлар егетләре турында ни генә сөйләмиләр. Имеш, ул «тегендирәк, мондыйрак». Мине дә сынамакчы иде дә, көрәшеп кенә җиңдем, дип мактаналар. Ләйсәнне беркем дә алай сынаштырганы юк әле. Мөҗәһит — инсафлы егет. Чөнки ярата ул Ләйсәнне. Ләйсәннең моңа ышанмаска хакы юк. Акыллы егетнең сөйгән кызын, җил-яңгыр тидерми, киләчәге өчен саклаганын белә ул. Мөҗәһит шундый булырга тиеш... Әмма ир-атның күңелендә иярләгән ат ятар дигән мәкальнең мәгънәсенә ул соңрак төшенде. Бу вакытта чибәр инженерның күңелен тагын берәү били башлаган иде шул инде. Егет ул сылуны клубка чыкса да күрә, урамда да очрата тора, юк сәбәпне бар итеп ул эшли торган медпунктка да сугылгалый. Яңа сылу Ләйсәнгә караганда күндәмрәк күренә. Тавышы йомшак, хәрәкәтләре салмак. Нәрсә әйтер икән дип, егетнең авызына гына карап тора. Куллары күпереп пешкән кабартмадай җылы. Кыскасы, кызыйның нәкъ пешеп-өлгереп җиткән чагы. Тәҗрибәсе аз. Мондыйлар ирләренә баш иючән, санлап кына торучан булалар, имеш.

Март башлары иде. Егет ике юл чатында калды: кайсы якка юырттырырга икән шул күңел сараендагы иярле атны? Ләйсән тарафларынамы, әллә күрше йортка гынамы?..

Бу юлы Ләйсән җиңде.

«Ләйсән!.. Пакьлыгына ышансам да, чаялыгыннан шикләнәм. Шулай да, үкенечтә калганчы, тагын бер күреп кайтыйм, йөрәк кылларының тартыйм әле. Әгәр дә күзләремне йомып тәкъдим ясасам...»

Әнә шундый җилбәзәк уйлар гына алып килгән иде аны бу юлы Ләшәүгә. Әмма ул аннан үзгәреп кайтты. Икеле-микелегеннән айныды. Атна буена клубка чыкмады. Күршедәге сылуның ялынып төбәлгән өметле карашларын күрмәмешкә салышты.

Ә бер айдан Ләйсәннән кайтарма адресы үзгә булган хат килеп төште.

Ләйсән яңа эшкә күчәчәген Мөҗәһитенә хәбәр итәргә ашыкмаган иде.

«Үзенә калса яңалык ясамакчыдыр. Көтмәгәндә генә миңа шулай үстереп җибәрделәр әле дип, бәясен күтәрмәкче булгандыр. Яратсаң, якын итсәң, яныма күчеп кил диюедер». Хаттагы юл араларыннан әнә шул ишарәләрне укыды егет. Аннан соң башын кушучлап утырдыутырды да буфеттагы графинга үрелде. Бер рюмканы тутырып аракы йотты. Тәэсирен сизмәде, икенчесенә сузылды... Өченчесе дә юатмады. Киресенчә, ачуы гына кабарды аның. Һы... Башлык буласы килгән. Дан ярата икән. Ничек мин элегрәк аның бу гадәтләрен сизмәгәнмен. Хәер, чаялыгы, үзе артыннан ияртергә теләве, өстен буласы килүе бар иде аның барын. Хәзер нишләргә? Үзенә үпкәләсенме әллә?! Үзенә!!!

Ул кызган баш белән чөйдән бүреген алды, иңенә пальтосын салды. Урамга чыкты. Язгы тамчылар тыпылдый иде. Тамчы? Түгелдер, яңгыр бу. Ләйсән яңгыры диләр беренче яңгырны. Егет бер мәлгә капка төбендә таптанып торды: Ләйсән яңгыры, имеш. Әллә «әүлиялыгы» бармы? Минем кая юл тотканымны сизенәме? Әллә аның үкенечле, үпкә яшьләре шулай тамчы булып тамалармы? Мин бит, мин бит инде аның ягында идем... Ә ул...

Ләкин Мөҗәһит бу минутта үз хисләренә үзе хуҗа түгел иде инде. Шешә пары аны күрше йортка өндәде. Шушы ук төнне ул, ниһаять, үзенең татлы да, оятлы да булган яшерен максатына иреште...

*
* *

Егетнең көтмәгәндә өйләнгәнен ишеткәч, Ләйсән бик гарьләнде, әмма сер бирмәде. Урамга чыгып тамчыга кушылып түгел, кешеләрдән качып, чигешле мендәрен кочаклап үкседе:

— Йа дөнья, нигә син адәм балаларының язмышы белән шулай шаярасың?! Ул бит минеке, бары минеке генә булырга тиеш иде! Тыштан ялтыраса да, эче тулы хәйлә, ялган булган икән, хыянәтче! Я, нигә кирәк булды мине шул кадәр газапларга, алдап, ышандырып йөрергә?! Я, ни зарарым тиде минем сиңа, әйт?! Саф күңелле солдаткалар кебек тугрылыклы идем мин сиңа. Я, хәзер башкаларның тасма телләренә ничек ышаныйм инде мин?!

Ышанмады башкаларга Ләйсән. Ул аларның яратырга маташуларыннан киная белән көлде:

— Ышан егетләргә! — диде ул, матур башын югары чөеп.— Мәхәббәт көенә сайраучыларның нинди кош икәнлекләрен таныйм инде мин.

Юк, юк, Ләйсән бичара түгел. Һәм ялгызак калганына да үкенмәячәк. Тик кемнәрдер генә йөрәктәге шул җәрәхәтсез сызлавыкка орынмасыннар иде. Кыз килеш, пакь җанлы, кешелекле кеше булып картайган күпләрне белә ул. Юк, юк, алар сугыш кәсафәте тиеп, ирексездән чәчәк атмый, чәчәк коймый шиңгән иясез гөлләр генә түгел,

алар артык горур җанлы сак кызлар. Ә ул андыймы? Түгел. Ул алар алдында баш июче генә. Аның күңеленә тамыр җәйгән берәү бар. Ул бар. Рахман абыйсы бар. Ләкин ул үзенең бу садә хисләрен шундый ерак яшергән ки, еш кына үзе дә җепнең очына чыга алмый аптырап кала. Нигә ул бүген шундый шат әле, нигә ул бүген шулай дәртләнеп эшләде әле... Ә-ә-ә, ул бүген аны төшендә күрде. Имеш, Ләйсән авырып егылган да аны больницага салганнар. Ярдәмгә доктор Еникеев килгән.

— Ләйсән, Ләйсән, шундый тере кыз, шундый сак кыз. Сез дә авырый беләсезмени?!

Ул төшен өненә юрарга тырышты... Ул бүгенге газапларына дару эзләми, ул беркемнән дә ярдәм сорап ялвармас. Мине нахакка, гөнаһсызга кыйнадылар дигән рәнҗеш ишеттермәс. Вакыт — барлык авыруларга да дәва, диганнәр.

Шул чак... Тирә-ягына каранды. Бу вакытта Мәһибә әлеге хатларны укып бетерә иде инде. Кем сүз ала дигән сорауга тагын сискәнеп китте. Моны мөдир түгел, укытучыларның профсоюз райкомы председателе әйтте. Инспектор җыйнак, матур башын күтәреп иптәшләренә карап алды. Берсе башын аска игән. Ул бу көтелмәгән вакыйгадан аптырап калган һәм әлеге чыгыш ясаучыдан чиркангандай йөзен сыткан. Бухгалтерның урыны буш. Ялда шул ул. Сәфәр абыйның элекке дусты Мәсгуть абый сирәк әйтә, әйтсә берәгәйле әйтә. Кем белә, бәлки аның юклыгыннан файдаланганнардыр бүген.

Каршыда урындык култыксасын сыпыргалап Әкбәрова утыра. Сүз алырга җыенуыдыр. Соңгы вакытларда Ләйсән нигәдер аны үз күрә башлаган иде. Ул август киңәшмәсендә ясаган докладында фамилиясен атамый гына Әкбәрованы чеметеп алды, алай гына да түгел, йомшак кына җәеп катыга яткырды. Ә методист исә, моны ишетмәмешкә салышса да, эшен көйгә салды. Авылларга чыгып кергәләде. Моңарчы бик санга сугарга теләмәгән инспектор белән киңәшә һәм үзе дә аңа «акыл бирә» башлады. Ләйсәнне Шәмдәл мәктәбенә озатканда хәтәр кешелекле булып тоелды:

— Директор Җәләлов белән сак кылан, каты орынма, хәсрәтле чагы, хатынында яман шеш бугай дигән сүз йөри.

— Мөдирнең соңгы көннәрдә кәефсез йөрүенә эчең пошмасын,— диде ул, бер көнне кабинетта икәүдән икәү генә калгач,— синең киңәшмәдәге докладыңны мактадык без аңа. Ир халкын белмисең шул әле син, алар хатын-кыздан да болайрак көнчеләр...

Ләйсән шулай фараз кылып утырган арада, Әкбәрова торып басарга өлгергән иде инде. Инспектор аның кыяфәтенә күз салу белән барысын да аңлады: ал пудрасын ягынып, иреннәрен иннекләсә дә, зәһәрләнгән чакта бу чибәр хатын күңел кайткыч булып ямьсезләнә икән.

— Мин Фәйрүшинаның сүзләрен дәвам итәм,— дип башлады сүзен.— Инспектор Мөслимованың саксызлыгы, кешеләрне аңламавы аркасында килеп чыккан нәтиҗәләрне саныйм. Беренчедән, инспекторның фронталь тикшерү нәтиҗәләрен тыңлаган көнне иң яхшы директорыбыз иптәш Җәләлов йөрәген тотып ауган. Врач белешмәсе бар. Миндә ул. Икенчедән, иптәш Мөслимова мактап кайткан Каенсу кызы Кифая Мөлекованың икенче өлкәгә күчеп китү сәбәбен әйтергә тел әйләнми — ир-ат бар. Укытучы кеше бөтен мәктәп йөзенә кара якты.

Ләйсән сискәнеп китте. Бу сүзләр аның тез буыннарына чаклы йөгерде. Күзән җыергандай тартылып куйды.

Я, нәрсәләр ишетәсең, газиз башым? Төшемме-өнемме бу? Ул атсыз бармагындагы йөзеген кымшатып куйды. Өнем! Абау, аның мондый ямьсез гайбәтле киңәшмәдә дә утырганы юк иде әле. Кайчан гына шушы ук кабинетта бер пенсионер укытучының сиксән яшен билгеләп үттеләр алар. Шушы ук кешеләрнең изге теләкләреннән башы әйлән-

гән мөгаллим агай түзмәде, яшьләре сакалына тамды. Әле кайчан гына, моннан нибары ике генә ел элек, шушы ук бүлмәдә өч кешегә мәгариф отличнигы значогы тапшырылды. Аларның берсе Ләйсәнгә иде.

— Кешеләргә медальләрне, орденнарны, гадәттә, илледә, алтмышта, җитмештә тагалар,— диде тәбрикләү өчен Казаннан үзе килгән кадрлар бүлеге мөдире.—Ә без сезгә аны өч дистәгез тулганда ук тапшырыйк әле. Кеше үз сәләтен үз вакытында тоеп, хезмәт җимешен үз вакытында татып калсын.

Әле кайчан гына Әкбәрова Ләйсәнне өйләренә озата килде, бергәләп чәй эчтеләр. Ләйсән сүз арасында Җәләевнең авырып торганын әйтте.

— Иркәлектер,— диде Әкбәрова елмаеп.— начальниклар отставкага чыккач чирләштерә башлый бит.

— Дөрес,— диде аңа Ләйсән,— бәйге атыдай гел ашкынып-чабып эшләгән куәтле кешеләргә тормышның салмак агымына кушылуы кыен...

Шушы кеше, кайчан гына әле авыру Җәләевнең гайбәтенә төшкән, хатын аерган кешегә кыз килеш кияүгә чыккан Каенсу кызы Кифаяны яклашкан кеше, касәсен өрә-өрә, Ләйсәннең кайнар чәен мактап утырган кеше бүген ни сөйли. Мостай Кәримнең андыйларны чага торган бер шигыре хәтеренә төште:

Елан зәһәр булыр өчен агу эчми,
Алсу чәчәкләрне сыгып агу эшли,
Сине мактап тәмли-тәмли ширбәт эчкән,
Бу, мөгаен, бал кортыдыр,— димә эчтән.

Үз уйларына чумган Ләйсән җыелышның соңгы өлешләрен аз хәтерли. Әлеге ике хатын салган чүпрәдән күпергән кинәшмә аның җанын кыйнады, күңелендә әлеге иптәшләренә булган җылы хисләрен суытты.

Район укытучыларының профсоюз комитеты председателе нәтиҗә ясардай төпле фикер әйтә алмады, әмма мөдирнең тел төбен бик яхшы төшенде Ләйсән. «Инспекторның соңгы айларда сүлпән эшли башлавы иптәшнең аспирантурага хәзерләнүеннән киләдер (кайдан белгән әле ул аны?). Бәлки аңа шартлар җитмидер, аппарат кысандыр». Димәк, Габбасов Мөслимованың гариза язып, шау-шусыз гына эштән үзе китүен тели...

*
* *

Ләйсән ишек катында утыра иде. Җыелыш гүләп утүгә бусагага атылды. Ләкин аяклар, төшендә каядыр ашыкканда артка сөйрәп интектергәндәй, авырайганнар. Ул чайкала язып калды. Кесәсеннән калтырана-калтырана ачкыч чыгарды. Кабинетына кереп бикләнде һәм чуар тышлы журналлар яткан өстәленә капланып еларга тотынды.

Ишеккә орындылар. Кактылар. Дөбердәттеләр. Ләйсән күтәрелмәде. Аның сыгылып чыккан күз яшьләрен һичкем күрергә тиеш түгел. Ләкин ачкыч яраттылар. Берәү атлап керде дә шым гына чождырдатып чөйдәге плащын алып чыгып китте. Атлавы, мыштым хәрәкәтләре анык — әлеге дәгъвалы хатларны куертучы Әкбәрованыкы иде.

Аның артыннан башкаларның да керүе мөмкин. Туй узкәч дөмбергә дигәндәй, юатмакчы булырлар. Кирәкми. Кирәкми... Ул җәһәт кенә башын күтәрде, өстәл тартмасында яткан көзге кыйпылчыгын алып каршындагы каләмнәр вазасына сөяде. Күзләре җилсенгән, йөзе бик

нык үзгәргән иде аның. Батист кулъяулыгының очын бөтергәләп күз төпләрен, борын очларын пудралагандай итте дә, ачкычын ишектә калдырып, акрын гына урамга чыкты. Таныш-белешләр очрый калса күрмәмешкә салышу өчен, башын югары күтәреп, билгесез бер ноктага текәлгәндәй атлый бирде.

Өйгә кайтып кергәч, күңел тагын да әрнебрәк сулыкты. Ичмасам, Суфия апасы да өйдә юк чак.

Я, хәзер нишләргә? Ул туфлисын салып атты да, өс-башын алыштырмый-нитми, түргә узды. Күз кырые белән генә өстәлдә яткан китапка карап алды. Мавыгып укый башлаган иде ул аны. Америка язучысыныкы. Очучылар, очыртучылар тормышыннан. Башларын диванага салган хәйләкәр кешеләрнең эчке дөньялары шәп ачылган. Ләкин ул китапка үрелмәде. Телевизор кашагасын ачты, кабызмады. Чәйнегенә су тутырды, утка утыртмады. Суыткыч янына килде, ак киштәсендә тәгәрәп яткан бердәнбер алманы алды, тешләмәде. Нишләргә икән? Тахтасына янтаеп, башын чиккән тышлы мендәрчеккә салды да, рәнжешле күзләрен түшәмгә текәп, уйга калды. Күңелне тырмап торган әлеге сорау ырмаулы койрыклары белән тагын алга килеп басты:

— Нишләргә?..

Ишек кактылар... Бераздан ул тагын кабатланды: тук-тук... Кем булуы мөмкин? Хәлсез генә тавыш белән рөхсәт бирде:

— Керегез.

Үрелеп караса, аптырап китте. Бусагада Мәйсәрә апа. Һы, Мәйсәрә апа!..

Ул сикереп торды. Исәнләшәсе урында, алар бер-берсенә моңсу гына карашып алдылар.

Мәйсәрә апа гадәтенчә киенгән. Затлы соры күлмәктән. Таушалмаган туфлилардан.

— Узыгыз, Мәйсәрә апа.

Мәйсәрә апа күрше урамда яши. Райүзәк мәктәбендә химия укыта. Күп белә, аз сөйли диләр аның турында.

Менә шул Мәйсәрә апа бүген аның фатирына килгән. Чакырып та түгел, йомыш белән дә түгел, башны кая куярга белмәгән чакта иптәш булып килгән... Ләйсән моның шулай икәнен күңеле, җаны белән сизде.

Кунак әле генә Ләйсән аунаган тахтаның читенә килеп утырды. Һәм күзләрен тагын аңа борды.

Көтмәгәндә пәйда булган кеше алдында каушап калган Ләйсән кече яктан түгә-чәчә ике пыяла кофе күтәреп чыкты. Кунак исә кофены бер-ике йотты да кызга күтәрелеп карады.

— Кеше ике нәрсәнең кадерен: икмәк һәм үз кадерен белергә тиеш. Үзен дөрес бәяләгәннәр — егылмыйлар, абынганда еламыйлар. Тор, чәчләреңне рәтлә. Эшеңә утыр. Бүгенге эшеңне иртәгәгә калдырма. Кар явуы бар.

Ләйсән кунакны озаткач көзге каршына басты да яңгырлы кояш чыккандай яшьле күзләре белән елмаеп куйды: дөньяда дөреслек сагында торучы зур гаскәр бар бит. Шуның бер вәкиле булып китте бит әле аның янында.

Ул арада күңелне берничә сәгать элек кенә гөжләп узган җыелыш болыты тагын сарды. Ул шунда ук, тәмәкече төтен кугандай, кулларын белән ишарәләп алды. Кирәкми, кирәкми, хәзергә ул җыелышны күз алдына китермәскә, китермәскә...

Йокларга яткач, Ләйсән мендәрен күтәребрәк куйды. Монда да баш югарырак торсын әле. Нәрсә диләр, иелгән башны кылыч кыймый, иелгән баш кояш нурын да тоймый, диләрме?..

*
* *

Лэйсэн укытучы булып янадан мәктәпкә кайтты. Дөресрәге, кайтардылар.

— Хәзергә районэктә укытып тор, яңа уку елы башыннан үзең теләгән мәктәпне сайларсың,— дип куярга да җөрьәт итте мөдир. Ләкин артык үз күрми иде лә ул бу мәктәпне. Сәфәр абый әйтмешли, үрнәге бар, гыйбрәте юк. Инспектор чакта ул монда сирәк килә, аның үзен дә кайберәүләр бик «хуш киләсең»ләп каршыламыйлар иде. Әмма приказны кулга алгач, икеләнүләр бетте. Хәерсезрәк саналган һәр адымның бер уңай ягы була, диләр. Бәлки...

Ияген ими генә исәнләшкәнгәме, сәламен җиңелчәрәк кабул иттеләр сыман тоелды аңа. Хәтта астан гына карап алган берсенең «куласа, әйләнә дә бер баса, син дә безнең рельска бастыңмы?» дигән карашын тотып алды.

Аның моңа бер дә исе китмәде. Пальтосын чөйгә элде дә стенадагы расписаниегә борылды. Лэйсәннең күзләре стенада булса, кайберәүләрнеке аның тышкы кабыгында иде.

«Матур киенеп, чәчләремне ясап барыйм әле,— диде ул үз-үзенә.— Яшерергә тырышсам да, кәефемнең китек чагы, күңеленә хуш килгән затлы кием рухны күтәрешә, күңелдә бәйрәм хисе уята».

Шкафтан кершәндәй ак кофтасын алды һәм көзге каршына басып түшенә куеп карады. Ярый бу. Тик изүе, җиң очлары гына челтәрле, күпереп тормас микән?.. Ләкин килешле көрән костюм аларны каплый төште.

Ялгышмаган Ләйсән, кемдә нинди яңа фасон күрсә, иртәгесен шундыйны киеп килә торган Марсельеза күзләре белән Ләйсәннең кофтасын өтеп алды.

«Исемең җисемеңә туры килми,— дип шаярта иде бу кызны Ләйсән инспектор чагында.— Үзең балаларга Каюм Насыйрины, Тукайны тәкърарлыйсың,. ә исемең французский, туфлиың чешский, күлмәгең болгарский».

Тегесе дә сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел: «француженка татар баласына Тукай иҗатын өйрәтә икән, бу нәрсәдер сөйли», янәсе. Ләйсән, аның игътибарыннан читләшергә теләп, сәгатенә күз салды: вакыт җиткән икән.

Дәрес әйбәт үтте. Балалар арасында барысын да онытасың. Күңелләре күшекмәгән, хисләре саф аларның.

Ләйсән дәрестән кайтып тамак ялгаган арада телефончы кыз кагылып китте. Ләшәүдән директор Рәхмәтулла абзый шалтыраткан. Шушы кыз аша аңа «хәл итәрбез» сүзенең мәгънәсен үзе төшенсен» дигән шартлы хәбәр җиткерергә кушкан. Берчак Ләйсән «мөмкинлек туса, Ләшәүгә кире кайтыр идем, районэктә рус телен генә укытыр мөмкинлек бар, минем татар әдәбиятын укытасым килә» дигәнрәк сүз ычкындырган иде шул. Искә алган. Рәхмәт, рәхмәт Рәхмәтулла абыйга. Ләйсән аңа шалтыратып тормас, чыбыктан аңлашу — елга аша сөйләшү белән бер. Ул аңа әйбәтләп хат язар.

*
* *

Ә берничә көннән соң Ләйсәнне райкомга чакырып алдылар. Кабул итү бүлмәсендә ул Ләшәү егете — үзенең укучысы Миргасыйм белән очрашты. Биредә эшли икән.

— Ләйсән апа,— диде егет, урындыгыннан сикереп торып,— утыра торыгыз. Мин хәзер...— Үзе секретарь бүлмәсенә атылды һәм шул минутта ук ялт әйләнеп тә чыкты.

— Керегез, апа, ул сезне көтә.

«Т» хәрефе ясап кушылган ике озынча өстәлле иркен кабинетта аны беренче секретарь аягүрә басып каршылады. Елмаеп, әтисенең исемен кушып дәште. Кызның эченә тагын җылы керде. Күңелсез киңәшмәдән соң һәртөрле шалтыратулар, чакыртып алулар һаман шөбһәләндерә бит әле.

— Сез яңа эшкә күчкәнсез икән?! — диде секретарь җитди итеп.

— Күчмәдем, элекке эшемә кире кайттым.

— Күчешме, кире кайтышмы, анысы барыбер: әмма андый чакта безнең белән киңәшергә кирәк иде. Сез бит җаваплы эш башкарган кеше.

— Шулай кирәк булган икән...

— Сәбәбе?

— Үзем теләгән атлы булып гариза язып киттем.

— Анысын да ишеттек,— диде секретарь, яңача салынган бинаның тоташ стенасын хасил иткән тәрәзәгә ымлап,— райкомнан дөньяга панорама киң ачыла ул. Барысын да ишетеп торабыз. Казаннан шалтыраттылар.

«Сабирҗан абый! Бары шул гына!» Ләйсән читкә караган боек күзләрен секретарьга борды. Төз гәүдәле, күзлек кигән яшь җитәкче кызның бу халәтенә игътибар итми калмады.

— Алай икән! — диде ул сүзенә аерым мәгънә өстәп.

— Әйе. Әмма кабат кайту ниятем юк. Мине дөрес аңлагыз. Сезнең ул аппаратның эшенә, кадрларының үз-үзләрен тотышларына күз-колак булуыгызны теләр идем. Бу минем фикерем генә түгел! Фәйрушинаның әтисе кемлеген шәйлисездер, ул кайбер гөнаһлары белән бергә аңа сыенырга тели, монысы да исегездә торсын.

— Аңлашылды!

*

* *

Суфия апа Кырымда ял итеп, кояшта янып, каралып кайтты.

Ул Ләйсәннең РОНО аппаратыннан читләштерелгәнен хат аша гына ишеткән, әмма әлеге ямьсез, күпертелгән дәгъвалар турында берни дә белми иде. Шунадыр, Ләйсәннең хәлен сорашудан бигрәк, гел үзенекен тезде: нинди бүлмәдә, нинди хатын белән торган, нинди доктор дәвалаган, кемнәр белән танышкан, ниләр сатып алган һәм башкалар. Һәм башкалар...

Әнә шундый килделе-киттеле яңалыкларны уртаклашып самавар катында утырганда, Мәйсәрә апа килеп керде. Суфия апа аны елмаеп, шулай да бераз гаҗәпсенеп каршылады.

— Әйдәгез, Мәйсәрә ханым, әйдәгез, мактап йөрисез икән. Җәелгән табынга тап булу әйбәт галәмәт дия торган иде безнең Сәфәр.

— Рәхмәт, рәхмәт,— диде кунак, шаянын-ниен бергә кушып, — сез өйдә юкта мин бу аулак өйгә ияләштем бит әле. Ләйсән туташка яман-су булмасын, хуҗасыз өйдә «азып-тузып» китмәсен дигәнрәк идея белән инде...

Ят кунак алдында тагын ни әйтергә белми аптырап калган Суфия апага сүз ялгап китәр җай чыкты.

— Минә рәхмәт. Кызыма иптәш булуыгыз иллә әйбәт булган. Ул андый-мондый юлга баса торганнардан түгел түгелен, шулай да ялгызлыкны беркем дә хуп күрми.

*
* *

— Хәерле иртә,— диде Суфия апа әкрен генә радиола тыңлап яткан Ләйсәнгә,— ике көннән синең көн!..

Ләйсәнгә бозлы су чайпалгандай булды. Анда туган көн кайгысы бөтенләй юк иде әле. Әбиләр-бабайлар искә дә алмаган бу көннәр, ниһаять, гадәткә кереп бетте. Теләсәң-теләмәсәң дә, сине табын әзерләргә, кунаклар каршыларга, аларның төче теләкләрен тынларга мәҗбүр итәләр. Авылда чакта искә дә алмый иде ул декабрьның тугызынчы көнен. Монда килгәч менә исенә төшерделәр. Аппараттагы бераү анкетасын актарынган, кайда, кайчан, кайвакытта тууы белән кызыксынган һәм шуны тиешле кешеләренә таратып өлгергән. Районга күчкән генә ел иде. Суфия апасы белән икәүдән-икәү генә шул көн хөрмәтенә бәләкәй табада пешкән бәлеш капкачын ачулары булды, өйгә бер төркем кунак кереп тулды.

Ярый әле, кибеткә чыгып йөгерәсе булмады, ризыклары тулы иде: шампаны да, «ак паны» да, кабымлыклары да, хәтта бүләкләре дә...

— Бездә гадәт шулай,— диделәр алар берсен-берсе бүлә-бүлә,— чакырып алмавыңа хәтеребез калса да, шундыен хөрмәтле кешебезне газиз көне белән тәбрикләми булдыра алмыйбыз.

Икенче елны анын үзенә бу хакта кайгыртырга туры килде. «Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә»,— ди халык. Менә ничә ел инде рәттән декабрьның тугызы җиттеме — өйдә шундый мәшәкать, мәхшәр...

*
* *

Ләйсән эштән кайтып кергәндә, өй эче эссе, таба исләре чыккан, табын җәелгән иде. Иренми дә инде бу Суфия апа пешеренергә. Өстәлдә чәчәкләр! Тамырларын җибәрми, кояш нурын күрми су эчеп кенә хәл җыйган бу чәчәкләрне алар үзләре «кыстап» аттыралар. Кыш уртасы дип тормыйча, шомырт яки сәрби ботакларын пәке белән кисеп алалар да җылымса суга салалар. Башта ботакчыкларга кечкенә бөречекләр тибә, шулар вак-вак яфрак яралар, аннан кәүсәләр бөреләнә башлый. Инде унбиш-егерме көн дигәндә, син күр дә мин күр: алдында ап-ак чәчәкләр! Ләкин Ләйсән үз иркендә үсеп аткан әрсез кыр чәчәкләрен — арыш арасыннан баш калкыткан, болыннарны ямьләп утырган күкбашларны ярата. Алар суга да сусамыйлар, узгын җилләрдән дә бөгелмиләр, җәйнең җәй буе шиңмиләр. Аларны такыя үреп башка киярга дә, хрусталь вазага салып табынга куярга да була.

Ләйсән биленә алъяпкыч япты та тәрәзәгә карады: озакламый килә дә башларлар инде. Тегеләрнең килеп чыгуы ихтимал. Әйбәтрәк каршыларга кирәк. Эчле кешедәй куенда таш йөртеп булмас, бер табынга сыенгач, үпкәсе-ние таралыр әле.

Суфия апасы белән шулай гәпләшкән арада бәлешнең йөзе килде, токмач киселде. Ит туралды. Сәгать сигезенче китте, әле капка шыгырдамый, чү...

Ләйсән иплән кенә ишекне ачты һәм кунакны кочып алды.

— Мәйсәрә апа!

— Тәбриклим, Ләйсән!

Ләйсән кунакны, тунын салдыргач, житәкләп залга алып керде, телләрен чатлатып аны «борғаланырга» мәҗбүр итте:

— Күлмәгегез лә күлмәгегез!..

Кече яктан елмая-елмая Суфия апа чыкты. Чынлап та, кунакның яңа фасон белән үзе бәйләгән кара чия төсендәге күлмәге, аның түшенә кунган ике тәлгәш чия брошкасы җәлеп итәрлек килешле иде.

Ул арада тагын ишеккә килделәр.

— Әйдәгез, әйдәгез, хуш киләсез, күршекәй! Нигә парлап түгел, Хөрмәтулланы өй сакларга калдырдыңмы әллә!

— Колхозга вәкил итеп җибәрделәр.

Нурҗамал Кәримова — беренче класс укытучысы. Өйләре бер-берсенә орынып кына тора. Аһ-зарларын, шатлыкларын уртаклашып, йомышка йөрешеп яшиләр алар.

Ләйсән ике кунакны кара-каршы утыртты да Суфия апасы янына кухняга кереп китте. Савыт-сабаларны, кашык-пычакларны барлаган арада күңеленнән шуны уйлады: Нурҗамалларның бирелгәге аш-судан калганы юк, ә менә нигә Мәйсәрә апаның аның туган көненә беренче тапкыр килүе? Хәер, сәбәбе шул: моңарчы килеп йөргән таныш-белешләрнең берсен дә хат җибәреп, хат артыннан ат җибәреп чакырганы юк иде ич аның.

Токмач кабарды, бәлеш шулпаланды. Кунаклар да ялыга-ачыга башладылар. Ә хуҗаларның күзләре — тәрәзәдә, ишектә. Сәгать уклары инде тугызынчыга авышты. Димәк, калганнарның килер исәпләре юк.

— Ярар ла,— диде Суфия апа, Ләйсәннең колагына гына үрелеп,— кирәкле суган яфраклары килмәүдән ни беда!

— «Кирәксез» кишер яфраклары, диген, суган яфрак ярмый, кыяклана гына!

Ун-унбиш урынлы табынга дүрт кеше иркенләп утырдылар. Нурҗамал гына эчтән көлемсерәп алды: Ләйсәннән түгел, аның кунакларыннан. Бүгенгеләреннән түгел, элеккеләреннән. Ләйсән аппаратта утырганда бу көнне кочак-кочак чәчәкләр, төргәк-төргәк бүләкләр күтәреп килүче Маһибәдән, Әкбәровадан... Бичара хуҗа ул бүләкләргә бер дә мохтаҗ түгел иде түгелен. Ләкин ул боларны үзенең ягымлылыгы, әйбәтлелеге өчен киләләрдер дип уйлагандыр әле. Шуңа күрә табыны бүген дә әнә нинди мул. Рәхим итсеннәр, янәсе...

Ә Мәйсәрә апага килгәндә, ул табын каршындагы буш урындыкларны күрмәмешкә салышты. Аның бик сирәк әйтә торган тапкыр бер сүзе бар: ашъяулыкны таплаучы түгел, аны искәрүче һәм искәртүче гаепле, дигән бер зирәк. Әмма ничек кенә булмасын, Ләйсәннең дөньяга килүенә утыз ел тулган бу көн күңелле үтте. Кунаклар көмеш башлы шампанның төбенә үк төшмәсәләр дә, «бераз» киметтеләр.

Суфия апа ай-вай итеп кыставын белде:

— Йотыгызсана, йөзем согы гына бит бу. Витамин! Әй, ашагызсана, әй, капкалагызсана...

Аннан соң кичә икән чын кичәчә булсын диптер, каяндыр мандолинасын алып чыкты. Полякча такмаклар әйтте. Татарча «Утыр әле яннарыма»ны көйләде. Аның артыннан Ләйсән кузгалды. Башын аз гына артка чөеп, Шәйхи Маннурны укыды:

...Мин күтәрәм, дуслар, бокалымны
Алсу ялкын салып эченә,
Ялкыннан да кайнар сәламнәрне
Китергәнсез туган кичемә.
Уйныйк та без, көлик,
шатланыйк та,
Мәңгелек җыр моңы шикелле.
Мин сәламлим иркен гомеребезне
Һәм ирекле туган илемне...

— Тагын берне укыйммы?

— Укы!!! Укы!

— Монысы башкортча:

Елдәр искән һаен, каеннарда
Япрак кәмей, шәйлә,
Йылдыр үткән һаен, табыннарда
Дустар кәмәй төшә.

Йылдар-елдәр. Шәфкать көтеп булмый
Улар ваемыннан.
Япрак кеүек койла кай исемдәр
Йөрәк каеныннан.

Әллә кояшыбыз һаранаеп,
Ййлаймы көз аен?
Бәлки безгә акыл утырадыр,
Гомер үткән һаен.

Шулай әйткән Мостай Кәрим.

Аннан соң Нурҗамал апа, әле авыздан гына төшкән кызык бу, дип, бер мәзәк сөйләп алды. Башларына азмы-күпме шампан, моң киткән дуслар кычкырып көлештеләр. Соңгы сүзне Мәйсәрә апа алды. Ләйсәнне эреләми-вакламый гына бәйрәме белән котлады да, рөхсәт сорап, стенага сыенган рояль капкачын ачты. Сәфәр абыйдан соң ничә еллар тынып торган моңлы зур тартма телгә килде, уйнаучының балдаклы бармаклары клавишалар буйлап йөгерде.

*
* *

Югарырак чөйсәләр дә, түбәнрәк тәгәрәгәндә дә тиңдәшләрең белән саубуллаша бел икән. Ләйсән Ләшәү укытучылары белән аерылышканда: «Вакытлыча гына китүем, кире кайтуым да мөмкин», дигән иде. Ул аны чынлапмы, кыланып кына әйттеме, хәтерләми инде. Юраган юш килде, быелгы уку елының яртысын Ләшәү урта мәктәбендә каршылады ул.

Директор Рәхмәтулла абый да, укыту бүлеге мөдире дә хуплап каршыладылар аны:

— Солдат үз постына кайтты, көчәябез!..

Борынлап очып киткәч, оясына яраланып кире кайтып төшкән коштай хис итте үзен Ләйсән. Биредә хәл җыеп яңадан канатланыр шартлар бар.

Директор Рәхмәтулла Гатауллин — утыз ел укыткан орденлы укытучы. Чал башы, көмеш кысалы күзлеге, аксыл костюмы белән ул күңелдә гел изге тойгы уята. Аның урынында укыту бүлеге мөдире булып калган шул ук Сәхибә апаны да хөрмәт итә иде Ләйсән. Сугыш корбаннарына авыл уртасына куелган һәйкәлгә аның әтисенең дә, абыйсының да, энесенең дә, хәтта кырык бернең сабан туенда ярәшергә сүз бирешкән егетенең дә исемнәре уелган. Тумыштан укытучы булып туган бу кеше балаларга, иптәшләренә гашыйк. Шуңадыр, аның беркайчан да ялгызлыктан ямансулаганы, алдынгылардан көнләгәне, гайбәт сөйләгәне юк.

Җаны теләгән мәктәбенә әнә шулай әйбәт кенә килеп кунды Ләйсән. Ләкин ашыкмыйк... Авылдан авылга, мәктәптән мәктәпкә гел әйдәп торган ялыктырмас сәфәрләр сагындыра башлады аны. Ару-талу белмичә юлларда йөреп, тынгысыз көннәр эчендә янып яшәргә яралгандыр, күрәсең. Мәктәптән мәктәпкә алып киткән таныш сукмаклар күз алдына килә. Ул аларның күбесеннән рухланып, дуслары белән бүлешердәй җим алып кайта иде. Мәктәптә бары тик усаллыгы белән янап ябышып торучы яки бил бөгеп, яраклашып яшәүче кайбер бичара укытучыларны да исенә алып елмаеп куя. Хәзер барысы да артта калдымы инде?.. Хәер, алай уйларга да базмый Ләйсән. Нәрсә дия иде Сәфәр абыйсы: Укытучы кайда гына эшләмәсен — балалардан таяк санатамы яки кафедрага басып лекция укыймы, ул — барыбер укытучы, зурлап әйткәндә, остаз булып кала. Ул һәр чак юлда. Ул һәр чак алга карап яши. Күпме тырышлык белән яуланган бу мөкатдәс исемне синең белән миннән беркем дә, беркайчан да тартып ала алмас!

*
* *

Көн артыннан көн узды. Февраль урталары җитте. Ярата Ләйсән бу айны. Буранлы-карлы ай бу. Озакка сузылган явымсыз аяз көннәр шыксыз булып тоела аңа. Бу ай, ичмасам, давыллана да, елмая да белә.

Якшәмбе көн иде. Ул авыл башындагы әрәмәлектә карга бата-чума ялгыз башы чаңгы шуды. Арып алсуланып кайтып керсә, өстәлдә калын конверт ята.

Суфия апа кулы! Шуныкы! Ачты. Ачты да аптырап калды. Конверт эчендә тагын конверт. Бумы — бусы... Казаннан... Адресы ят... Ул бу юлы кайчы-фәлән алып тормады, конвертны ертып кына ачты:

«Кадерле Ләйсән дустыбыз!

Сезне чын күңелдән Яңа ел белән котлыйбыз. Эшегездә уңышлар телибез. Быелгы яңа ел безне күрештерер дигән өмет бар.

*Сабирҗан абыең белән Рахман»*.

Ләйсән бу тәбрикнамәне өченче кат укып чыккач кына исенә килде һәм әлеге конвертларны ашыгып ачканда идәнгә төшкән кыска гына хатны күтәрде:

«Ләйсән акыллым!

Бу хат мәктәп адресына килеп сине көтеп яткан. Соң булса да кабул ит! Хатыңны алдым. Язгы каникулда очрашырбыз. Мәйсәрә апаңнан сәлам. Сине сагынабыз.

*Үбеп, Суфия апаң»*.

Ләйсән хатны йомарлап күкрәгенә кысты да мендәргә капланды. Иөрәге басылгач, күзге алдына килде. Буран аралаш елмайган февраль кояшыдай, үзеннән-үзе көлде:

«Җүләр син, утызга җиткән, утырган кыз. Ә акылың юк. Җүләр син, менә кем!»

Тышына зәңгәр таҗлы кыр чәчәге төшкән бу открытканы салганда Рахман белән Сабирҗан абыйсының нәрсәләр уйлавын, нинди киңәш тотканнарын белсә — ул ни эшләр иде икән әле. Әйдә, белми торсын, ике күк капусын берьюлы ачмыйк.

*
* *

Ләйсәннең класска кереп, аягүрә торган балалар каршына басуы булды, ишек кактылар.

Укытучының ник дәресне өзең дигән сыман салкын карашыннан секретарь кыз каушап китте.

— Апа, апа, сезне телефонга...— диде ул, әйтәсе җөмләсен дә очлап бетерә алмыйча.

— Тәнәфестә шалтыратсыннар.

— Булмый, апа, Казан таңелте Казаннан!

Укытучы класска үзгәреп керде. Ул куанычын никадәр генә сиздермәскә тырышса да, булдыра алмый. Күзләре ялтырабрак китте, тавышы ачыла төште. Шатлык дигәнең, хәсрәткә караганда, тизрәк атылып чыгучан шул. Укытучының яхшы кәефенә ияреп, класс та үзенә бер төрле җанланып тора. Шулай да Ләйсән аларның игътибарын тартыр көч тапты.

— Бүген без «Кем булырга телим» дигән темага сочинение язабыз. Дәфтәрләрегезне ачыгыз, каләмнәрегезне алыгыз!

Берничә минут үтүгә, башлар партага иелгән иде инде. Укытучы үзе өстәл артына утырган килеш ике яңагын учлап уйга чумды. Үткән

хатирәләр әле генә күңелне җилкеткән яңалыкларга үрелеп яңарды: «Мин кем булырга телим?»... Кайчандыр үзенең дә нәкъ шушы хакта язган сочинениеләре искә төште. Онытылмас остазы — Сәфәр абыйсы «инша» дип яздырта торган иде аны. Ул телгә карата бик талымлы кеше иде. Сүзләрнең онытылырга йөз тотканнарын тикшерә, сайлый, кирәк дип тапканнарын куллана бирә, янарак кергәннәрен чамалабрак кабул итә. Укучылар аныңча сөйләшергә тырышалар: циркульне — җәзбә, линейканы — правила, материкны — кыйтьга, тапкырлаулар таблицасын — җәдвәл диләр. Чирек азакларында яза иде алар иншаны. «Мин нинди һөнәр сайлар идем» дип атала ул. Менә шунда Ләйсән аптырап кала инде: я, кем булырга телим соң әле мин? Уйлана башлый, як-ягына карана, барысы да кыштыр-мыштыр килеп яза инде. Аның шулай каушап калганын Сәфәр абыйсы күзлек астыннан гына күзәтеп тора да ярдәмгә килә:

— Я,— ди ул, кызның партасына иелеп,— күңелгә хуш килердәй хезмәт таба алмыйм әле, дисең инде, ә? Уйла, уйла, вакыт ул шулай уза...

Укытучының соңгы сүзе Ләйсәнне сискәндереп җибәрә. Менә ул каләменә тотына һәм җилкенә-җилкенә очучылар һөнәрен мактый башлый. Шул чакта ук иске китаплардан укыган геройлары Мәгүбә Сыртланова, Марина Осипенколар төшә... Яза, яза, яза...

Әмма аңа карап Ләйсән очучылар мәктәбенә гариза язмый. Язмый гына түгел, хыялланмый да. Әнә каршыда язып утыручы укучыларның дәфтәрләренә генә күз төшер: арада инженер, космонавт, Алтын йолдызлы бригадир, капитан һәм тагын әллә кемнәр булырга омтылучылар бар. Ә менә шул язмаларны бүген сандык төбенә салып, нәкъ ун елдан янадан алып карасаң, нәрсә мәгълүм булачак? Һәркем дә яшьли хыялланган теләгенә ирешеп бетә алмый шул. Берәүләр, сәләт чамалы булганга, икенчерәк эш сайларлар. Юраганы юш килүчеләр дә булыр, әлбәттә. Әмма арада бер-икесе үз сүзен сүз итми калмас!..

Ул тагын уйга чумды.

Еллар йомгагына уралып ераклашканнан-ераклаша барган сөенечле-көенечле көннәрне хәтерләү югалткан китабыңны табып, таныш геройларыңны очрату белән бер. Аларга инде хәзер син икенче күзлектән карыйсың. Вакытында бик мәхәббәтле булып тоелганнары төссезләнеп киткәннәр... Нәфрәт уятканнарыннан шактый гыйбрәт алынган. Алар инде сиңа хәзер дошман булып түгел, менә миңа охшый күрмә, шундый хәлдә калуың бар, дигәндәй кыймый гына читтә басып торалар. Ә шул чакта игътибар да ителмәгән шәхесләр арасында, каршында чекрәеп тормаса да, күңеле тулы нур булган гаҗәеп матур кешеләр булган икән...

Тәнәфескә чыгарга дигән кыңгырау авазы Ләйсәнгә бу юлы әле генә хәтергә төшкән вакыйгаларга озаткыч марш булып яңгырады.

Ул, бер кочак дәфтәр күтәреп укытучылар бүлмәсенә үтешли, директор белән очрашты.

— Рәхмәтулла абый!?

— Барысын да беләм. Әле генә Габбасов белән дә сөйләштек. Сәлам әйтергә кушты. Озатырга төшәчәкләр. Сез бездән бөтенләйгә китәчәксез, сеңелем. Министр үзе чакырткан.

— Ышанып бетмим әле...

— Мин Сезне беләм һәм ышанам, Ләйсән. Иртәгә колхоз машинасы белән аэропортка озатачакбыз. Хәзер өегезгә кайтыгыз, озын юлга хәзерләнегез.

Шунда Рәхмәтулла абыйның әлеге сүзләренә үрелеп кайсыдыр бер якын кешесенең фикере өстәлде: — Дөреслек юк ул дигән мәнсез, иман-

сыз бәндәләргә ышанма син. Иртәме-соңмы, барыбер калка ул. Син Идел уртасында чайкалган йомычка түгелсең, син — кеше. Әйләнә-тирәң тулы кеше. Алар барысын да күреп-сизеп торалар. Берәүләрнең күңелендә хөсетлек булырга мөмкин, синең нәрсәңнедер күпсенәләр. Икенчеләре юашраклар. Якларга кирәк чакта сүзләрен әйтә алмый читтә калалар. Өченчеләре — синең өчен утка-суга да керергә әзерләр. Болын төрле чәчәкләрдән торган кебек, кешеләр дә әнә шундый күп төрлеләр.

*
* *

Ләйсән берьюлы ингән ике шатлыктан сүзсез калды.

Самолет җиленнән кыр чәчәгедәй тузган чәчләрен төзәткәләде дә трапка атлады.

Менә ул, самолетка кереп урнашкач, иллюминатор тәрәзәсеннән үрелеп аска карады. Саубуллашырга төшкән дуслары кулларын маңгайларына куеп күкне күзәтәләр: ярый әле, көн аяз!

Барысы да аңа хәерле юл тели:

— Юлыңа ак җәймә, кызкай!

— Кара аны,— диде шунда Ләйсән үз-үзенә,— сине югарыга очыртып, үзләре түбәндә калган бу кешеләргә таянып яшә. Кешенең хыяллары күктә булса, аяклары барыбер җирдә.

Арада узган көннәр хатирәсеннән аныңча сабак алыпмы, уйланыпмы аска иелгән бүтән башлар да бар иде. Әмма бу минутта Ләйсәннең иелгән башлар турындагы мәкальне искә аласы килмәде: син тәрбияче, син мәгърифәтче кеше. Йомык күңелләрне яктыртырлык, тайгак юлдагыларны турайтырлык көчең бармы? Якты күңелләрдән алган нурыңны, гайрәтлеләрдән алган куәтеңне алар белән уртаклаш! Сиңа да таянсыннар. Кешеләр ышанычын акларга кирәк.

Әйе, Ләйсән бу минутларда үз алдында шундый имтихан тота иде. Соңлап килгән бәхет яктырак та, татлырак та. Ул баш очындагы кояшлы көн күгедәй аяз, галәмдәй киң күңелле кешеләрне генә ярата. Син аңа лаекмы?!

Казан, 1973 ел.

## Рәшит Гәрәй

### Васыятен дә әйтеп калдырмаган

Йокы диеп бер дә исем китми,
Бүленсә дә татлы төшләрем.
Ничек инде күрми калыйм соң мин
Үзәннәргә чыклар төшкәнен?!

Таң беленмәс борын уянам да
Аланнарга чыгып йөгерәм.
Ә чыкларда эзләр... Инде кемдер
Миңа кадәр торып өлгергән.

Басып тора әнә юл читендә,
Күңелем моны һич тә көтмәгән:
Күп гомердән сырхау Гыйлаҗ бабай
Офыкларга күзен текәгән.

Исләренә әллә төште микән
Ут уйнаткан егет чаклары.
Ат ялларын җилдә җилфердәтеп
Бәйгеләрдә алдан чапканы?..

Бу иртәнге изге сәгатьләрдә
Бүлдермәдем аның уйларын.
Шулчак бәлки дога кылгандыр ул
Иминлеген телән илләрнең.

Күз яшьләрсез булсын, дигәндер ул,
Бормаланып яткан су юлы.
...Гыйлаҗ бабай кичтән күзен йомган,
Мәңгелеккә йомган бу юлы.

Васыятен дә әйтеп калдырмаган,
Тел яшергән гүя барсыннан.
Серкәләнгән тик бер учма арыш
Чыкты аның мендәр астыннан.

## Сездә калыр идем...

Кырларыгыз сезнең иркен дә бит,
Кызларыгыз сезнең матур да...
Бакчаларда сайрар кошларыгыз
Күңелемә бик-бик якын да...

Бөтенесен мактап җырлый-җырлый,
Сездә калыр идем гомергә...
Туган якның җылы туфраккаен
Онытырлык кына түгел лә.

Суларыгыз сезнең тәмле дә бит,
Таңнарыгыз сезнең алсу да...
Йомшаклыгы кечке шәфәкъларның
Офык булып җәелә басуга.

Шул шәфәкъка төреп хисләремне
Сездә калыр идем, ихластыр,—
Сезнең якта менә кояш кына
Мин күнеккән яктан чыкмастыр.

Тауларыгыз сезнең биек тә бит,
Күкләрегез сезнең зәңгәр дә...
Уйламас та идем ак биләүдә
Яткан чагым булса әгәр дә.

Ризалыгын алып әнкәемнең,
Сездә калыр идем, билләһи!
...Чит җирдә бит йөрәк кунак кына,
Йөрәктә бит туган җир яши!

## Барысы да шул ук...

Без аунап үскән үзәннәр,
Без йөргән болын...
— Саумы сез, саумы сез, — диеп,
Сузамын кулым.

Алар да, саумы син, диләр,
Рәхәт соң җанга!
Эх, яшьлек үтте дип, йөрәк,
Янма син, янма.

Шул ук бит әнә чәчәкләр,
Ужымнар шул ук.
Шул ук кошларым сайраша
Талларга кунып.

Шул ук чишмәләр челтери,
Тавышын тыңла:
Без яшь чактагы кебек ук
Бай алар моңга.

Йөрәкләрнең тибеше дә
Шул ук бит һаман.
Бу җирдә кайнар эзебез,
Җырыбыз калган.

Җырлы эздә яшьлек сүнми,
Син шуны аңла...
Кылларың өзелгән булса,
Шушында ялга.

## Елмаюлы таңнар хакына

Кайчагында боек йөрүебезне
Күрәләр дә әйтеп куялар:
— Сезнең өчен, — диләр, — ят нәрсә ул
Ашкынулы хисләр, хыяллар.

Бишектә үк, имеш, еларгамы,
Көләргәме диеп ятканбыз.
Бәйгеләрдә читкә тайпылганбыз
Йөрәк кагып килгән аттан без.

Сабырсызлар, нигә ашыгасыз
Безгә шундый мөһер сугарга?..
Чабышларның каеш тезгеннәре
Төенләнде безнең кулларда.

Кирәк чакта көмеш дагалардан
Тубал-тубал утлар чыгардык.
Булды көннәр... качып ят күзләрдән
Ат ялларын сыйпап еладык.

Тормыш безгә гел-гел елмаймады
Сыйлы-җырлы бәйрәм шикелле.
Бер шатлыгын бирсә, артыннан ук
Тау-тау өеп кайгы китерде.

Әтиләрен белгән малайлар без
Ишетеп кенә кеше теленнән.
Үзләренең сүзе ишетелмәгән
Туп җимергән окоп төбеннән.

Чын дуслардан иртә аерылдык
Бөтенләйгә я бик озакка.
Төзәлмичә калган җәрәхәтләр
Йөрәкләрне һаман сызлата.

Кайчак шуңа боек күренәбездер,
Гаепләргә кемнең ни хакы?!
Уйнап-көлеп яшәр өчен генә
Киләмени җиргә ир заты?!

Башкаларга бирми күтәрәбез
Иңебезгә салган йөкне без.
Елмаерга кирәк булган чакта
Көр хисләрне бикләп йөртмибез.

Елмаябыз... безнең елмаюдан
Иң караңгы төннәр яктыра.
Боексак та бары боегабыз
Елмаюлы таңнар хакына!

## Ак канатлы иде казларың

Казлар асырарга әвәс идең,
Ак канатлы иде казларың.
Шул казларсыз, әнкәй, бер ямен дә
Тапмый идең, ахры, язларның.

Бәбкәләрең кичтән борынласа,
Төн буена янды утларың,
Сабырлыгың җуеп көтә идең
Тыкрыкларда чирәм шытканын.

Күзсенерлек матур, шук бәбкәләр
Синнәнме соң инде ятсына...
Күңелең йомшаклыгын сизгән кебек
Уралдылар аяк астыңда.

Алар ничек шулай өйрәнгән соң
Тавышыңнан сине танырга?!
Тының белән өреп җылыта идең
Күшексәләр җилдә-яңгырда.

Безгә атап куйган казларыңның
Бәбкәләре ишле быел да...
Тик нишләптер быел аларның да
Кайгысы бар сыман тоела.

Сине, ахры, шулай юксыналар,
Бер-берсенә сыенып таңнарда.
Сүзләр өйрәт миңа... Нәрсә диеп
Җавап бирим, әнкәй, аларга...

«Үлде бит ул»... диеп әйтер идем,
Ышанмаслар минем сүземә.
«Әнкәң вафат», — дигән хәбәргә мин
Ышанмыйча йөрдем үзем дә.

Казлар турында мин бик күп яздым,
Тик барысын ашыгып язганмын.
...Зират капкасына тияр-тимәс
Очып уза бәбкә-казларың...

**Хәким Хәйруллин**

# УРГЫЛ

РОМАН

*
* *



Якуп икенче атнасын инде конвейер штрегендә забойщик булып эшли. Бер ай буе ат куып, көче сүлпәнәйгән, беләкләре, кәйлә урынына дилбегә тотып йөреп, йомшарган. Кичләрен бөтен тәне сулкылдап сызлый, балтыр сөякләре авырта. Эштән туктаса, кузгалып китүе мең бәла. Мондый хәлләр элек тә, шахтада беренче көннәрен азапланып ятканда да, булган иде. Менә һәммәсе яңадан кабатлана.

Инде элекке эзенә төшеп килә иде, беркөнне Степанов аңа кичкә үз янына керергә кушып китте.

Забойщиклар кытлыгын шахта хуҗалары хатын-кызлар җир астына төшкәнче дә татыганнар иде инде. Әкияттәге саескан шикелле: томшыкны алсаң, койрык ябыша, койрыкны алсаң — томшык. Үз вакытында штрекләрне дә төзи барырга кирәк, лавадан анда кеше алсаң, күмер чыгарырга калмый. Штрекләр төземәсәң, ахыр чиктә лавалар бөтенләй килеп төртелә. Степанов Якупны үз бүлмәсенә әнә шул хакта сөйләшергә чакырган икән. Якупка берьюлы алты забойщик беркетеп, ике забойга җибәрде. Үзең дә тир түк, эшләтә дә бел дип, колагына киртләде. Проходка, тик проходка! Югыйсә, лавалар стенага килеп төртелә. Хәер, Якуп боларны үзе дә яхшы белә. Шахтаның законы шундый: кергәнче, чыгар юлыңны кара!

Хәзер Якуп аңын җыя алмый: тышта ат белән икәү генә булса, монда алты забойщик. Анда ничек тә көнне төнгә аударып уздырды. Шахтага кире кайткач, куанычтан авызы ерылды. Аңлый ул хәзер: йодрык төеп, аяк тибә-тибә гайрәт чәчүләр, сугыш вакыты булса да, күккә чөйми икән. Хәзер аның башына әнә шул хәсрәт төште: ничек итеп алты кешене берьюлы, орышмый-нитми генә эшләтергә? Ничек иттереп аларның барысын бергә бертигез тир түктерергә?..

Бик пошаман хәлдә ике забоен да җентекләп тикшереп чыкты: җаның нихәтле тели — шултикле күмер шартлатылган. Әле Талигага, әле Варяга текәлеп, беркавым карап торды: кайсын кая җибәрергә?

---

Ахыры. Башы 10, 11 саннарда.

— Без Таня белән конвейерныйга барабыз,— диде Варя, аның уен сизенгәндәй.

Якуп каршы килмәде: риза, болар махы бирмәс, конвейерныйга бик тә кулайлар. Шулай да кисәтеп әйтеп куйды:

— Карагыз аны, көн саен икешәр тапкыр шартлатып, икесен дә җыештырып бетерәсе! Үзегезгә Шабанов белән Петяны да ияртегез! — Ә эченнән: «Наприенко авыр сөякле, үземә калыр»,— дип уйлап куйды.

Наприенко сүзгә катнашмыйча бер читтә тәмәке пыскыта. Моңарчы Ухановның стена газетасына төшерүе дә, Степановның җыен хатын-кыз алдында гарьләндерүе дә бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга барды аның, ә Якупны санга да санамады, тик газетага төшерүеннән генә бераз шүрләп йөри. Хәзер нишләр икән? Якуп аны Степановтан үзе сорап алды, тазалыгына кызыкты. Андрейга күз төшерде: монысына көрәк сабын гына чыдасын! Көр тавыш белән әйтте:

— Ну, туганнар, сез икәүләшеп вагонеткалар китереп төйи торасыз, ә мин сезгә якынрак итеп ыргыта торам. Шулай итмәсәк, төяргә ерак, иртәгә рельсларны якынрак китереп салырбыз. Бүген янда гына рельслар юк.

Өстен чишенеп атты да, эш тансыклаган кешедәй, көрәгенә ябышты, ни арада бер-ике вагонеткалык күмер ыргытып та өлгерде, бүтән урын юк иде.

Наприенконың сөмсерләре коелды.

— Миңа дисә, бөтен штрекен күмеп ташла. Барыбер тауны актарып бетерә алмассың, балаларыңның балаларына да җитәр. — Иренеп кенә урыныннан кузгалды: читкә китеп утырмакчы иде. Андрей аның алдына буш вагонетка китереп куйды да төяргә керешә.

— Утырмый тор әле, — диде Якуп, Наприенконың шылыр юлын томалап, күмер ыргыта башлады.

— Кулларыңны син дә уйнат, бабай! — диде Андрей хихылдап.— Иртәдән үк нәзегәеп китәрсең дә, теләсә кайсы ярыктан узып йөри башларсың.

«Мин сине биетермен әле, үҗәт», диде Якуп эченнән һәм Наприенконың алдына күмерне өйгәннән-өя барды.

Наприенко аңа усал бер караш ташлады, көрәген алып, иренеп кенә төяргә керешә, вагонетка белән стена арасын тизрәк бушатып, чыгып шылмакчы итә иде. Бер көрәк сала да Якупка карый, икенчесен сала да тагын карый.

Менә вагонетка туп-тулы булды. Якуп шундук бушын китереп куйды.

— Наприенко агай, егет икәнсең! Теләсәң, күптән түшеңә орден тагып йөрер идең, — дигән булды. — Давай, давай, җиңел кулдан тагын бер шартлатырбыз.

— Бригадир! Хәләл хатыным хакына үтенәм, ыргытмый тор азрак, сабыр ит! Тамак ялгагач та җитешербез, — дип ялынды Наприенко.

— Утыр күмер өстенә, Наприенко агай, аша. Ләкин тиз тот! Забой сине көтми... — диде аңа Якуп. Наприенкодан канәгать ул: кирәксә үгез егар, теләсә тауны ишәр. Моны өчаяк тагып йөргән Шабановка тиңләп булмый. Наприенко шахтага көн саен ризык тутырган сумка күтәреп йөри, ипие дә, шикәре дә, чәе дә, ите дә бар. Хатыны бер җирдә дә эшләмәгәч, ашамлык эзләп әллә кайларга барып кайта...

Бераздан тагын эшкә керештеләр. Якуп забойга унбишләп тишек бораулады. Һәрберсе икешәр метр тирәнлектә, баш бармак кына сыярлык. Шартлатучы шул тишекләргә аммонал тутырачак та, тишекләрнең авызын кызыл балчык белән тыгызлап томалагач, детонатор шнурына ут кабызып, Прошка әйткәндәй, трах-бах иттерәчәк. Бораулап бетергәч, Якуп, шартлатучыны табарга, яки десятникка әйтергә дип, баш штрек буйлап ашыга-ашыга конвейерныйга китте. Каршыга вагонетка этеп баручы Талига очрады. Болай икәүдән-икәү генә күптән очрашканнары

юк иде. Талиганың кулыннан тотып, күзләренә карады. Күзләрендә аның сүнәргә торган таң шәүләсе, юк, сүнәргә торган түгел, балкып китәргә әзер торган ай нуры иде.

— Талига! — дип пышылдады Якуп. «Мин синсез яши алмыйм», дияргә авызын ачты, тик... Талига, аның кулын сүзсез генә читкә этәреп, китеп барды.

*
* *

Алешасыннан хат килә башлаганнан бирле Талига көннән-көн үз кабыгына төренә бара. Гайбәтчеләр теленә юлыкмас өчен, кетүдән качкан кәҗә шикелле, иптәшләрен читләтеп үтә, сүзләренә катнашмый, шаярмый, көлми. Кичә иртән Степанов нарядныйда: «Әхмәтҗановка нәреп барырга кем риза?» дип сорагач, ул да теләк белдерде. Варя да шушы бригадага кергәч, икәүләп эшләве уңайлырак булыр дип уйлады. Алар икесе дә үткән-сүткәнне сорашып, бер-берсенең теңкәләренә тимиләр.

Иртән Варя әйтеп куйды:

— Нык бул, Таня! Җебеп торсаң, бәян бер тиен бу дөньяда.— диде.

Забойга килүгә, вагонетка китереп төяргә керештеләр. Петя эре кисәкләрне ваклап аларга якынрак ыргытып торды. Күмерне төяп озатып бетергәч, Петя бораударга тиеш. Шабанов вагонеткалар йөртә, монда вагонетка алып килеп һәм аны илтеп йөрүләре озакка сузыла: ара ерак иде. Шулай биш-алтыны төяп озаткач, Шабанов һаман килми дә килми.

— Эшне юри өзмәкче, әшәке җан! Олакты да батты, — дип, Варя аны сүгәргә кереште. Һаман күренмәгәч, Шабановны эзләп йөгерде. Монысы да китте дә югалды. Менә хәзер Талига штрек буйлап атлый. Варя Шабановны тукмап ташламагае дип курка ул. Штректә утлар җемелдәгән җиргә хәтле килсә, вагонетка рельстан төшкән. Варя аны куярга азаплана, аты-юлы белән сүгенә, тәгәрмәч асларына кыстырган такта кисәкләрен типкәләп кенә очыра. Бераздан тынды да көлә-көлә сөйләп бирде. Шабанов, мескен, төш вакыты җитте дип, вентиляция штрегенә чәй кайнатырга китеп барган. Анда җиләс һава, ут-күз куркынычы да юк, кеше-фәлән дә йөрми. Рельстан төшкән вагонеткасын үзе генә куя алмагач китеп барган икән.

Ул арада Шабанов үзе дә килеп җитте. Кәефе ярыйсы күренә иде. Бу карт гүя ашау өчен генә яралган, ашау өчен яши һәм ашап үләчәк икән диярсең: бөтен эше шуңа җайланган, сүзе дә шуңа корылган иде.

— Тамак ялганды. Солы кибәгеннән тагын кесәл пешерергә куеп калдырдым, — диде, кулындагы чүмеч кадәрле агач кашыгын ялый-ялый.

Варя, ачуын йотып, әйтеп куйды:

— Ярый, кесәлең пешеп җиткәч, бергәләп сугарбыз.

— Дүртебезгә дә җитәр, мул куйдым. Пешекченең ире кайда? — Шабановның шулай Петя турында сорашуы иде, колагын торгызды, нигәдер кәйлә тавышы ишетелми. Шуннан соң сөйләп китте: — Ул бичара ир заты хатыны белән минем күршедә генә тора. Көн саен ишег алдында ирле-хатынлы кәмит куялар. Бүген иртән Петя, бичара, эшкә җыена, теге мичкәсе чәрелди: «Ирмени син! Квартирант кына шунда. Пешмәгән сөяк!» — ди. Ә бу, мескен, дерелди, калтырана. Күрәсең, бүген дә борчаклары пешмәгәндер. Сугыш бетмичә өйләнмәскә ант итеп куйдым, хатыннар. Такыр ашым, тыныч башым.

— Ул пешекче түтәй үзеннең дә бирер иде кирәгенне! — дип хихылдый Варя.

— Ә нигә? Берәр табак аш куйса, аның янына ярты чиләк бәрәңгесе белән бер ипиен дә кызганмаса, без дә курыкмас идек әле. Ни әйт-

сәң дә шахтер кисәге бит! — Шабанов борын киереп еш-еш иснәнә башлады, кесәле көйгәнгә охшый, тик бу ис өчаяк калдырган яктан түгел, забой ягыннан килә иде. Шабанов кинәт: — Кесәлне чәлдергәннәр! Мине кәкре каенга терәткәннәр! — дип ысылдый башлады.

Варяның күзенә изүләрен чишеп, янып-пешеп өчаяктан кесәл ашап утырган Петя чалынды.

— Ай, кесәлем! Хараплар гына иттең, булдыксыз ир! Күз яшем тотар әле бер, бәдбәхет! — дип, Шабанов Петяны куа китте.

Петя урыныннан торды да өчаякны тибеп тә очырды. Кесәле Шабановның өстенә, битләренә чәчрәде, ә өчаяк штрек буйлап, колашаларга бәрелә-сугыла, «мич» буенча түбәнгә очты.

— Каһәр суккан американец! Өйрәнгәнсең берьюлы йөзәр йомырка тыгынып...

Талига белән Варя Петяны шелтәләргә тотындылар: карт кешене ник алай мыскыл итәсең? Хатыннар йомшак тел белән сөйләшә-сораша торгач, Петя эч серен ачып салырга мәҗбүр булды. Аны берничә көн хатыны ашатмаган икән. Ипи карточкалары да аның кулында ди. Карыны бик ачканга, кесәлгә кызыккан, шаярудан түгел икән.

«Мич» буйлап менеп килгән Якупның кулында өчаягын күргәч, Шабанов сөенеп куйды, йөзе яктырып-ачылып китте.

Бу забойда күмер бик аз калган, яңадан бораулап шартлатырга бик мөмкин. Якуп килгәч, Варяга штрек киңәеп, биегәеп киткән кебек тоелды. Соңгы көннәрдә аның һаман Якуп белән сөйләшәсе, аны гел күрәсе килә иде. Әмма егет Талигадан күзләрен алмый.

Талига, бер дә исе китмичә, борылып та карамыйча, күмер төйи. Ихтимал, шуңадыр Якупның кәефе юк, ул Петяга җикеренә башлады:

— Нигә эт кырып йөрисең, бүкән! Син забойщик түгел. Сиңа кайлә тоттырдың ни дә, тирес сәнәге тоттырдың ни...— Сүзеннән кинәт кенә туктап калды. Бераздан җайлабрак эндәште: — Караны, Петя, мин икенче әйләнеп килгәнче бораулап бетермәсәң, үзеңә үпкәлә. Минем бригадага аяк басармын дип уйлама. Безгә бөтен участок күзен баглый, эшләп күрсәткәнебезне көтә.

Петя, аңлашыла дигәндәй, ияк какты.

Якуп «мич» буйлап үзенең забоена, Наприенко янына төшеп китте. Хәзер ул, Андрейны лавага күчергәннән соң, Наприенко белән икәү генә эшли. Караңгылыктан аның: «Күмер кирәк, күмер!» дигән тавышы яңгырады. Аңа җавап биргәндәй, баш штректа гөрс-гөрс иткән шартлау тавышлары ишетелде. Гүя әллә кайдан сугыш авазлары, туп гөрселдәүләре биредә кайтаваз булып яңгырый иде.

*

* *

Икенче көнне Петя эшкә чыкмады. Якуп аны эзләп өенә барды, больницага сугылды, сорашты, белеште, беркайдан да тапмады.

Бу вакытта Петя мунча чормасында төн җиткәнне көтеп утыра иде. Караңгы төшкәч, поездга утырып, фронтка китмәкче ул. Малай чагында урам буенча яшьтәшләре арасында өстенлек алып яшәгән, аларны һәр вакыт үзенә буйсындыра алган Петяны шахта якларындагы тормыш чанасы салулы юлда аударды да салды.

Менә төн дә җитте, әмма Петя чормадан төшеп, капчыгындагы бер сынык ипие белән ыжгырган суыкка чыгып китәргә батырчылык итми әле. Ә монда ана ышык, җылы...

Андрей, Якуп бригадасыннан лавага күчкәч, шулай ук авыр эштән сыгылып төште. Дүрт-биш көнен ничек кирәк алай уздырды.

Ә Ургылда моңарчы гомер булмаган хәл туды.

Бик каты салкыннар башланды. Урамда кешеләр йөрүдән туктады. Барысы да тизрәк өенә кайтырга яки шахтага, җылыга керергә ашыга. Анысы бер хәл әле: кеше суыктан җылы җиргә качып котыла ала, түзә белә. Поездлар йөрми, алдагы семафорлар, вагоннар күренми. Бөтен тирә-якны томанлы сыкы баскан. Участокларга терәүлекләр ташу да тукталган. Тракторлар, автомашиналар, бәрелешүдән куркып, йөрмиләр, салкында тәгәрмәчләре әйләнми. Эстакаданы күмер баскан, төяп озатырга вагоннар юк. Ашханәләргә, кибетләргә китереп җиткергәнче, ипи бозга әйләнә. Суык баш штректәге су торбаларын эштән чыгарган, канауларны боз каплаган.

Партия оешмалары һәм шахта җитәкчеләре бөтен Ургыл халкын салкын белән көрәшкә чакырды. Бу көннәрдә карт-корысы, карчыгы-кызы, малай-шалае кәйлә тотып боз чаба, носилкаларга тутырып боз ташый. Кешеләрнең күзләре генә җемелди. Башлары, аяклары, куллары кем нәрсә тапса, шуңа төренгән. Һәммәсен ап-ак бәс чорнаган, урмандагы чыршыга охшап калганнар. Ямау-ярыклардан, тишек-тошыклардан үтеп, суык сөякләргә хәтле чеметтерә. Тик кеше дигәнең барыбер үзенекен итә: шахта эшли, һавасы да әкрен-әкрен генә тора, бозлары әрчелә, поездларны йөртергә дә әмәле чыга. Салкын көннәр айлар буе тормас, туктар, эш тагын элекке җаена кайтыр, тормыш җайланыр. Тик Андрей гына...

Кичә ул боз ташыганда уң кулының баш бармагын вагонетка тәгәрмәче астына кыстырып, эштән азат ителмәкче иде, көче җитмәде. Бармагы кешенеке түгел, үзенеке ич. Гитлерның басып керүенә ул гаепләмени?! Юк, бүтән түзәр әмәле калмады. Тизрәк башны алып качарга, бу газаптан котылырга кирәк.

Өйдә бик озак эзләнгәч, капчыкка бер кат эчке кием, әнисенең ефәк күлмәкләрен тутырды, өйдә булган бөтен ризыкны — бер сынык икмәк белән бер ит консервасын салды, кирәк булып куюы бар дип, әтисе бүләк иткән аю тиресен дә алды. Өстенә каракүл якалы постау пальтосын, куян бүреге белән киез итеген киеп, караңгы төшкәч, мунча янына килде. Як-ягына каранып алгач, песи шикелле генә өскә үрмәләде. Мунча чормасын ул күптән чамалап йөри иде инде. Әнисе көндез боз чапса, төннәрен шушы мунчада кизү тора. Ана кеше ничек тә улын ташламас, ашарга-эчәргә китереп йөрер...

Андрей чорманың эченәрәк, зур мичкәләр янына шуышты. Андый мичкәләр монда биш-алты. Бер дә бәсләнмичә, җылы бәреп торганнары да бар. Коридордан мунча җылысы да күтәрелә. Сүз дә юк, рәхәт, бик рәхәт. Әмма саклык кирәк, бик сизгерлек кирәк. Ничек тә тотылмаска! Җир астында унбишәр сәгать тубыктан пычрак ерып йөрисе юк, көрәк һәм кәйлә дә җелекне суырмас. Тик нигәдер бик шомлы, кемдер сагалап торадыр кебек тоела. Әле анда, әле тегендә чыж-пыж итә, нидер чыптырдый, сызгырып-сызгырып ала.

Булмаса, тамак ялгап алырга кирәк. Бөтен запасы бетә бетүен, әнисе ни дә булса китерми калмас әле.

Менә тамагы да тук. Мичкә өстенә менеп аю тиресен җәясе дә рәхәтләнеп сузылып ятасы. Юк, һаман әле күңеле үз урынында түгел. Анда кыштырдый, тегендә пытырдый. «Күселәр такта кимерә торганнардыр, йокыга талсаң, шыр сөякләреңне генә табарлар», — дип, ятарга коты оча. «Әллә берәрсе бармы? Шайтан мәллә?»

Ахырда ятарга батырчылык итте, ләкин тагын торды. Консерва тамагын киптергән, су эчәсе килә иде. Су алып булмасмы дип мичкәләрдән эзләде. Иң читтәгесенең өсте ачык, бераз салкынчарак та бугай. Эх, бәхет! Торбаларга баса-баса, мичкә өстенә үрмәләде, аннары аска төште. Бармакларының юешкә тигәне сизелде. Авызын тамчы астына тотып, туйганчы эчте. Кире өскә үрләде, менеп җиттем дигәндә генә аяклары таеп, мәтәлеп суга чумды. Ярый әле, муеныннан гына икән.

Нишләмәк кирәк, шәрә калып, кием киптерергә мәҗбүр. Кайнар торбалар өстенә өс-башын элде. «Чормага менә башласалар, шушы мичкә эчендә качып калырга була икән». Җылы мичкәгә аркасын терәп басып тора, киемнәре кипкәнен көтә, калтырана, тешләре шак-шок итә.

Шул вакыт теге башта аяк тавышлары ишетелде. Андрей, бөтен гәүдәсе белән мичкәгә сеңде. «Шайтан, шайтан!» дип кычкырганын үзе дә сизми калды ул. «Шайтан» чорма авызындагы яктылыкка килеп житте. Андрей танып алды: Петя икән ич бу. Күреп торган, ахры, нәкъ бире таба килә.

— Бондаренко! Теш арасына кыстырырдайниең бар?

— Үземә дә юк.

— Күзгә күл очырма, яме! Әлерәк кенә ит консервасы тыгындың.

Андрей юеш киемнәрен киеп маташа иде. Көтмәгәндә Петя аның җиңеннән тартты:

— Киттек!

— Кая?

—Прокурор каршына.

Петяның шушы ике сүзе Андрейны тетрәтеп җибәрде, күз аллары караңгыланып, бөтен тәненә эсселе суык йөгерде. Үзалдына: «Куык очыра. Күрәләтә утка барып төшмәс. Таң атканчы күмер вагонына утырып кая да булса шылмакчыдыр. Бу вакытта нәкъ поезд китә, әнә кычкырта. Әллә аңа нярәп үземә дә чамаларгамы? Сабыр кирәк, сабыр! Тышта суык шатырдатып усакларны яра, ә монда җылы»,— дип уйланды.

Петя киткәч, Андрей тагын ике көн шушында ятты. Ә карын үзенекен итә: ашарга сорый иде. Әнисе һаман юк та юк. «Ана улын ташламас, кич булмаса төнлә, төнлә булмаса иртән китерер»,— дип уйлады Андрей.

Өченче төне дә рәхимсез узды. Ә әнисе Настяның эшкә чыкмавына да өченче тәүлек булды. Аны да үзе турында кайгырту мәшәкате йөгәнләп алган. Ул, Михаилга нярәп, Ургылдан китеп барган иде...

## УНИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Хәмзә ике көннең берендә Хәертдин абыйсының өенә килеп йөри. Абыйсы аңа һәр вакыт улым дип эндәшә, ә үзе улының сорауларына рәтле җавап та кайтармый. Юк, малай үпкәләми моңа, аз сүзле кеше икәнен белә ич. Бер кемгә дә җикеренмәс, авыр сүз әйтмәс, эш күп дип беркайчан да зарланмас. Барлык буш вакытын китап укып уздыра. Кайчакта тальян гармунының каешын кулбашына эләктерә дә: «Күңел ачып алабызмы, улым?» — дип сорый. Хәмзәгә җыр гына булсын: көн-төн тыңларга да әзер, үзе дә кушылып җырлый.

Кайтырга артык соң булса, Хәмзә кунып та калгалый. Мичкә яга, утын яра, су китерә. Хәертдин абыйсы моңа бик куана. Тик шунысы бик сәер: Хәмзәнең Оксана янына йөрүен бер дә өнәп бетерми ул.

Бер көнне Хәертдин абыйсы уйламаганда-көтмәгәндә үзе үк сүз башлады:

— Төсне табакка салмыйлар, улым. Үзеңнән үзгәне әүлия дип белмә. Башта аздыралар, аннары башны ашыйлар алар. Ашны сеңгәч, хатын-кызны үлгәч кенә макта икән...

Ул шулай Оксанага төрттереп әйтә. Бирелеп тыңлаганны күргәч, яңадан тезәргә керешә:

—Бәхет кошы тоткандай, алды-артны белми очынасың, җаныңны йолкып тоттырырдай буласың, ә ул бик матур гына кояшлы бер көнне сине төп башына утырта да калдыра. Йөрисең аннан: «Эх, сукыр булганмын икән!» дип.

Хәмзә аптырый: «Нишләп болай начар уйлый ул безнең хакта?». Аннары төшенеп ала: «Теге серле альбомның серен ача түгелме сон абзыйсы?»

Тора-бара Хәмзәне Оксана янына җибәрүдән тыймый башлады карт. Бик якты өмет чаткысы кабынды анда: улын, килене белән бергә, үз янына алып кайтырга була ич. Йорты иркен, яңа, җылы. Ә үзенең бүген-иртәгә Газраил якасыннан тотачак: җан биргәндә авызына кем су салыр да кемнән бәхиллек сорар? Йорты тулы әйберсен кемгә калдырыр?..

Хәмзә анын янына берничә көн килми торса, Хәертдин аны эзләп Ухановларга килә. Яшьләрнең күңел ачып утырганнарын күреп мыек астыннан гына елмая. «Булма икән күрекле, бул икән бүрекле. Ә минем кара сакалым кая гына барсам да артымнан калмый. Давыллап килгән яшенле янгыр көнне туганмын, бөтен гомеремне давыллы елларда яшьнәп-күкрәп уздырдым, актык сулышым да күк күкрәп, яшен яшьнәгән минутларга туры килсен иде...» дип уйлана үзе.

*

* *

Бу көннәрдә нарядныйга яки шахта идарәсенә килеп керсәң, стенага эленгән газеталар һәм радио тирәсендә төркемләп кеше очратасың. Бөтенесендә дә бик зур сөенеч: безнең гаскәрләр Сталинград янында һөҗүмгә күчкән һәм дошман оборонасын өзеп, Сталинград сугышчылары Көньяк фронт белән кушылганнар, фашистларның бик зур көчләрен камап алганнар.

Шахтерларның да бу җиңүдә өлешләре бар ич, ничек куанмасыннар да ничек көлешмәсеннәр. Әнә, читтәрәк Гитлердан көлеп чыгарган җыр җырлаганнары да ишетелә. Җиңү көненә яңадан берничә адым атладык дигән сүз.

Кузбасс, Урал шахталарына элек шунда эшләгән солдатларны фронттан кайтарып җибәргәннәр. Монда да күптән өзелеп көтәләр аларны. Әнә шул тиздән булачак шатлыклы кавышулар турында да сүз куера.

Якуп та нарядныйдан бик күтәренке күңел белән чыкты бүген. Степанов аны яңадан десятник итеп куйды.

Яңарак кына төзелеп беткән лава беренче көннәрен генә эшли иде. Монда забойщиклар әле күнекмәгән, ияләнмәгән, әмәлен дә табып бетермәгәннәр. Яңа лава берәзгәләнүчән дә була. Кетмәгәндә түшәмнән ком катыш су ага башлый. Колашалар һәм йөк ташу тасмалары, әлегә көйләнеп бетмәгәнлектән, бик еш өзелеп торалар. Күмер дә монда тегеләреннән катырак, ярты смена селтәнмисең, кәйләң үтмәсләнә. Бораулаганда борау кермичә азаплый, кайчакта сынып ук кала. Сай бораулсаң, күмер аз шартлатыла, смена буена забойщикка төяргә дә, план тутырырга да җитми, әле анда, әле монда терәүләр теткәләнеп ярыла, түшәмнән ком, таш сибелеп тора.

Гел яман яклары гына түгел, уңайлыгы да күп: буй җитмәслек биек түгел, җирлек көзге боздай шоп-шома, көрәк шуып кына йөри, һава да тизрәк җилли.

Якуп баш штрек буйлап барганда, каршысына Хәертдин очрады. Эшен бетереп, кайтып баруы анын.

— Ну, энекәш, кара аны, шахта тулы хәвеф-хәтәр. Маңгай күзләрең дә, күңел күзләрең дә үз урынында булсын!

Забойларның торышын сөйләп бирде: күмер шартлатылган, тәтене кудырылган, һавасы саф, конвейерлар сыналган, түшәм һәм җирлек коп-коры. Киткән чакта: «Степанов әйткәндәй, хәерле юл, җанкисәгем! Кергәләп йөр, яме!» — дип, Якупның аркасыннан сөйде.

Якуп бөтен забойларны үзе дә ныклап тикшереп чыкты. Терәүләрнең, түшәм дә чатнамаган, такталар да сынмаган. Забойларның стеналарын да тикшерде: ул-бу күренми. Тик урта бер җирне узып киткәндә, аның күзе җирлектән түшәмгә таба сузылган кул яссылыгындагы ярыкка төште. Хәтта кул яссылыгы кадәр дә булмас, кәрәк очы гына сыярлыктыр. Чү! Колак тояр-тоймас кына чыжлаган тавыш ишетелә түгелме?! Шундук бөтен тәненә салкын йөгерде. Борын төбендә генә куркынычлы газ сагалап ята түгелме? Әйе, бик мөмкин, метан газы шушындый җеп сыман ярыклардан чыжылдап чыга, дип сөйләгәннәре бар десятниклар курсында. Менә сиңа чүп өстенә чүмәлә! Хәзер үк начальникка һәм тау эшләре инспекциясенә шалтыратырга!

Якуп баш штреккә телефонга йөгерде.

*

* *

Хәмзә Оксаналарда утыра. Маринаның да өйдә чагы. Өчәүләшеп «Священная война»ны җырлыйлар:

> Вставай, страна огромная,
> Вставай на смертный бой...
> С фашистской силой темною,
> С проклятою ордой.

Җыр үзәкләргә үтеп керә, үзеннән-үзе йодрыклар йомарлана.

Тышта җил улый, дөм караңгы. Тәрәзә пыялаларына өзлексез эре кар бөртекләре бәрелә, ирексездән күзләр шул якка карый. Мондый яман төндә әйбәт хуҗа этен дә урамга чыгармас. Шык-шык-шык!... Кемдер тәрәзә шакый. Кем икән? Әнә хәзер ишекне дөбердәтә, ә үзе керми — ишекнең бикләнгәне дә юк.

— Зинһар өчен ачыгыз!

«Апа янынадыр», — дип пышылдый Оксана Хәмзәгә, күрше бүлмәгә чыгып торырга ымлый.

Алар чыгып киткәч, Марина калтыраган куллары белән ишекне ачуга, Андрей килеп керде. Аның бөтен битен сакал-мыек баскан, күзләре курыкчнакы кебек усал.

— Мин аю түгел, күзләреңне алартма, ашамам! — дип, эчкә үтте.— Кырынырга пәке китер! Аннары берәр меңне табарсың бит? Сугыш беткәч тә исәп-хисапны өзәрмен. Әйдә, берәр нәрсә кабарга да бир тизрәк!

Марина аптырашта калды, ничек хәл кылырга да белмәде. Беренче юл — булса, аны ашатып-эчертеп, акча тоттырып, каядыр озатырга кирәк, яки, алай итмәсәң, идән астында яшереп кенә асрап яткызырга. Өченче юл — хәзер үк милициягә озату. Нишләргә? Әллә куып кына чыгарыргамы? Теләсә кая олаксын.

— Андрюша, — диде ул ахырда, — иртәгә үк прокурорга бар!

Андрей беравык аңламый торды, тик Марина кабатлагач кына үз хәленә төшенде, күзләре шар булды.

— Әгәр дә минем андый изге ниятем булмаса, ул чакта нишләтерсең?

— Мәхәббәтем хакына бәйләп илтермен. —

— Үзең генәме? — Хәзер инде Андрей каушап калырга исәп тотмый иде. Монда ул кызлар боерыгын үтәргә кермәде, тамак туйдырырга, җылы урын тансыклап керде. Мич янынарак елышып, карлыккан тавыш белән: — Марина... Марина... Мәхәббәт хакына дисең... Эх, син!...

Марина отыры Андрейга якынайды, кулларын йодрыклады. — Без, дошманны тар-мар итү хакына, хатын-кыз башыбыз белән дә шахтага төштек. Ә син... Сатлык җан!...

— Коры хәсрәт! — диде Андрей теш аралаш... — Күзгегә кара, ичмасам! Тәнеңдә песнәк чукырлык та ит әсәре калмаган. Битләреңдә — күмер тузаны. Я, нигә коелып төштең? Әллә дөрес түгелме?

Марина чыннан да коелып төшкән иде. Үзенең яман хәлен күптән белә, гарьләнә, азапланып йөри иде ул. Сөйгән егете авызыннан чыккан бу сүзләр аның йөрәгенә хәнҗәр булып кадалды. Бу сүзләрне әйткәнче, буып үтерсен иде, ичмасам...

Мендәргә капланып, үксе-үксе еларга кереште.

Әйе, ул кыз бала. Сөяр һәм сөелер чагы. Аның бик матур киенеп йөрисе, бизәнәсе, төс-битен чибәр күрсәтәсе килә. Тәннәрен чуан басмаса, бөтен гәүдәсе төннәр буе ватылып сызламаса, эшләгән җире коры, җылы, якты булса, мондый хәлләргә дучар булыр идемени? Ләкин кемгәдер шахтада эшләргә, күмер чыгарырга кирәк. Корал заводлары, электр станцияләре, шәһәр мичләре күмер көтә. Менә сугыш бетәр, авырлыкларның барысы да үтеп китәр, гомерне бушка уздырмадык дип, горурланып сөйләрлек истәлек калыр...

Андрей үзенең артыкны ычкындырып ташлавын сизенде. Хәзер Маринаны юатып кына, иркәләп кенә матурлыгына, чибәрлегенә ышандырырлык түгел. «Ялынып-ялварып, гафу үтенеп карарга мы?» — диде ул эченнән, тик алай итәргә көче җитмәде. Идәнгә ауды да үгез шикелле үкерергә тотынды.

— Мин яшәргә тудым. Яшисем килә минем. Ник таптың мине, әнкәй? Шушындый газап утларына ташлар өченмени?! Кайда син, әни?!

Биредәге шау-шу, елашка әсәреп, эчке бүлмәдән Хәмзә белән Оксана килеп чыктылар, ни әйтергә дә белмичә туктап калдылар.

Шул чак һич көтмәгән хәл булды.

Андрей, кинәт сикереп торды да, куеныннан ниндидер тимер кисәге чыгарып, кыргый бер тавыш белән:

— Якын килмәгез!.. Тотып бирмәкче буласызмы?.. Юк, булмас! У-у... — дип кычкырды.

Үзе арты белән ишеккә таба чигенә барды, тавышы әллә ничек кыргыйларча яңгырый, күзләре дә кыргыйланып елтырый иде. Ул арада Андрей томан пары эченә күмелеп юкка да чыкты.

*
* *

Хәмзә палаткасына кайтып кергәндә бик соң иде инде. Оксана белән икәүләп, бөтен шәһәрне бетереп, Андрейны эзләп йөрделәр. Егетне җир йотты. Милиция бүлегенә кереп, булган хәл турында сөйләп чыгудан бүтән чара калмады.

Палаткада токарный станоклар дөбердәп эшләп ята, идән тулы тимер-томыр, борылырлык та урын юк. Механически мастерскойда урын булмаганлыктан, яңа кайткан станокларны вакытлыча шушында куеп торырга мәҗбүр булдылар.

Менә Хәмзә, кызыксынып, токарьне күзәтеп ята. Эшен белеп эшли кебек, шулай да сүлпән, иренчәк кыймылдый. Фронтовик булса кирәк, өстендә яшел гимнастерка, аякларында обмоткалы ботинка, сул аягы бераз аксый.

Хәмзә бераздан аңа сүз кушты:

— Абый, эшең бик кызыклы икән! Мина да синең кебек оста куллы булырга иде. Мине дә өйрәтче?

Якын күреп сүз катуга, үзенең эшен олылауга токарьның йөзе ачылып китте, станогын туктатып, Хәмзәнең карават читенә килеп утырды.

— Шәп һөнәр бу, агай-эне! Өйрәнсәң, мәңгегә үкенмәссең. Әмма, яшерен-батырын түгел, үзем дә бүген үк шахтага күчәр идем. Госпи-

тальдән чыккач, шахтага дип кайтардылар. Ә монда, син җир асты эшләренә яраксыз дип, шушы тимер-томыр арасына бастырдылар.
— Алайса, алтын куллы кеше икәнсез.
— Бик дөрес сукалыйсың, агай-эне. Бүгенге көндә шахтер күмер түгел, дан күрәр, авызы туйганчы ипи төяр.
Хәмзә аптырап калды: менә сиңа кычытмаган башка тимер тарак! Әллә бу озын балтыр шахтерны уникешәр сәгать җир астында тамак ялына гына эшли ди микән?..
Шул турыда әйткәч, токарь ансат кына җавап кайтарды:
— Ә син ни өчен дисең?
«Менә сиңа вәт: елмаймый да, ичмасам. Бер ни дә аңламаган сабый дип уйлый микәнни мине?! — дип уйлады Хәмзә.
Ә теге һаман үзенекен тукыды:
— Забойщиклар бригадиры үзенә алса, начальстводан эш тормаc иде. Тик менә бригадирны кайда очратырга?
Хәмзәнең кинәт бу абый белән сөйләшәсе дә килми башлады.
— Мин бригадир,— диде ул, кырт кисеп.— тик синең миңа кирәгең юк, абый.— Шулай диде дә икенче якка әйләнеп ятты.
Ул бригадир түгел, әлбәттә, әмма намуслы хезмәтне корсакка гына буйсындырганны вөҗданы кабул итми аның. Шундый уйларына чумып йокыга гына китә башлаган иде, токарь аны селеккәләп:
— Әй, бригадир! Тор әле! — диде. — Бөтен палатка тирәсе шау-шу килә. «Сивак»та фаҗига булган, диләр. Әллә ниткән газ шартлаган. Бәла-казадан башаяк, барып кайтыр идең.
Хәмзә сикереп торганын сизми дә калды. Төнге сменада десятник булып Якуп эшли иде, тагы ни булды икән?!

*
* *

Ничек болай килеп чыкты соң әле бу?
Якуп исен-һушын да җыеп өлгермәде... коточкыч хәл!
Телефоннан әле берсенә, әле икенчесенә шалтыраткан арада, тонык кына шартлаган тавыш колагын ярып үтте. Конвейерны моңарчы ук туктаткан иде туктатуын, әмма хатын-кызларны, лавага кермәскә кушып, кисәтә алмады, телефонга ашыкты ул.
Шартлаган урынга әйләнеп килгәндә барысы да бер җиргә укмашкан иде. Эче «жу!» итеп китте Якупның, тамагына төер утырды. Зоя-ның сөйләвенә караганда, яшь кенә бер кыз, лампасы сүнгәч, шырпы сызып ут кабыза башлаган һәм... коточкыч шартлау булган. Бу юлы фаҗиганең корбаны Талига икән. Ул ике учы белән йөзен каплап уртада басып тора, бармак араларыннан кан саркый, өстендәге бөтен киеме теткәләнеп беткән. Шырпы сызган кыз «яман да курыктым» дию-дән бүтәнне белми, агарып каткан, дерелди, Варя аны тынычландырып маташа иде.
Хатыннарны баш штреккә төшергәч, Якуп забойларны яңабаштан тикшереп чыкты, бүтән җирдә дә сизелер-сизелмәс кенә газ чыганаклары табылды. Моңарчы беренче шахтаның ике участогында да газ юк иде әле. Гомумән, шахта газлылар рәтендә саналмый иде.
Күп тә үтмәде, комиссия иртәнге, Степанов килеп җитте. «Сивак» тулы шахта җитәкчеләре, тикшерүчеләр, белгечләр һәм тагын әллә кемнәр участокның һәм шахтерларның язмышын хәл итәләр. Бигрәк тә Әхмәтҗановка, тәҗрибәсе бары-югын төпченеп тормыйча, хатын-кызларны лавада эшләткән өчен бәйләнәләр.
Якуп һушын җыя алмый каткан: ни белән бетәр бу хәл? Яңадан дилбегә тоттырырлар микәнни? Алай гына булып калса... Егет башы белән нарядныйда утырыр иде дә үкси-үкси елар иде.

Бар да бетте! Хуш, «Сивак!» Хушыгыз, дуслар!

Шундук күңеленә икенче уй килде: «Талиганың хәле минекеннән дә яман ич!»

Хәмзә дә дустының хәлен белергә чаптырып килеп житкән: «Койрыгыңны кысма, малай, юлың төзек, туп-туры»,— ди. Ә үзенең күзләрендә яшь бөртекләре.

Якуп больницага Талига янына китте.

*
* *

Хәмзәнең эштән буш вакыты хәзер уку-өйрәтү бүлегендә уза. Алар Оксана белән икәүләп электровоз машинистлары курсына йөриләр. Күңеле көр: сөйгәне янында утыра, парлап кайталар, озатып та куя. Кайчакларда белмәгәнен Оксанадан сораша, ни әйтсәң дә, ул сигез класс бетергән. Хәмзә, картайганчы, Хәертдин абыйсы шикелле шахтада эшләргә уйлый. Шахтада тамыр җәймәгән өстә черер, ди бит абыйсы. Шуңа күрә егетнең дә өстә череп каласы килми. Сугыш беткәч, әтиәнисен алып килмәкче. Оксанага да өйләнеп җибәрсә, дөньясы түгәрәкләнер иде... «Туктале, нишләп Оксана укырга килмәде икән бүген? Әллә чирләгәнме?»

Ухановларга йөгерде. Килсә, ишекләрендә йозак. Келт итеп башына Талига апасы килеп төште: җыйнаулашып аның янына больницага киткәннәрдер. Шунда юнәлде Хәмзә.

Коридоры кысан булса да, больница тәрәзәләреннән кояш кереп тулган; чиста, пөхтә итеп җыештырылган, гөлләргә тикле үсеп утыра. Ул керүгә һәммәсе әйләнеп карады, үзләре пыш-пыш сөйләшәләр.

— Каян табарга соң ул әҗәл даруын? — ди Фатыйма.

— Шөшле сораганга балта бирмә, яме? — ди кайсыдыр.— Дару димиләр бит сиңа.

— Сыерның карынындагы бер айлык бозавы кирәк диләрме? Әллә ниткән әкәмәтләр уйлап таба бу духтыр халкы! — Фатыйма башын чайкый-чайкый гаҗәпләнә.

— Ялт иттереп тиз генә барып кайтырлык авылы булсын икән якын-тирәдә.— Монысы Марина тавышы.

Оксана да сүзгә катнаша:

— Киек хайваннар ярыймы соң? Сорамадыгызмы?

— Боланныкы яисә сарыкны да яраклы, диделәр.

— Дуңгызныкы гына эләгә күрмәсен, Таняга аны ашау хәрам,— дип әйтеп куйды Фатыйма. Аңар игътибар итмәделәр.

Хәмзәгә Оксана төшендереп бирде. Талига апаларының йөзе тулы кабырчык икән, тәне дә чи иткә калган. Врачлар әйтүенчә, бер айлык карын бозавы яки карын бәрәне кирәк, ди. Шуны ниндидер даруларга буташтырып пешкән җирләренә сыламакчылар икән. Биш йөз чакрымдагы болан совхозына хәбәр иткәннәр, тик кайчан китерәселәре билгесез: ара ерак, юл өзек чак.

— Наприенконы җибәрергә кирәк иде. Ул аучы карт, тирә-якны яхшы беләдер,— диде кайсыдыр.

— Әйтерен бармы! Аңар сүзең тыңлатканчы, тавыктан сөт саварсың. Хәертдин маһирны дисәң әле бер хәл,— дип куйды Фатыйма.

Врач әйтүенчә, бер айлыктан дүрт айлыкка тиклесе ярый икән,— диде Варя.

Бераз шулай сүз көрәштереп торгач, хатыннар нәтиҗә чыгара алмыйча таралыштылар.

— Мин барам ауга,— диде Хәмзә Оксанага.— Җиденче класста укыганда «Төз атучы» дигән значок та биргәннәр иде. Кайда кыр кәҗәләре барын да беләм.

Оксана аңа күтәрелеп карады. Хәмзәнең алып кайтарына ышанды да, ышанмады да, шулай да дәшмичә генә битеннән үбеп алды.

Хәмзә пошына да башлады. Теләге изге дә изгесен, тик үз белдеге белән генә эш ташлап чыгып китә алмый шул. Степанов җибәрәме әле, юкмы? Хәертдин абыйсы ни әйтер? Коногон булып кем калыр?

Бу хакта Оксана белән шактый ара киңәштеләр һәм Хәертдин абыйлары белән сөйләшеп карарга кирәктер диделәр.

Нарядныйга барып, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, йомышларын сөйләп бирделәр.

Хәертдин малайга горур караш ташлады, авыз чите белән генә елмаеп алды.

— Батырлык та батырлык дип хыяллана идең, тәки булырсың, ахры... Теләгең изге, юлың уң булсын! Кайчанрак сәфәрең?

— Таң беленгәч тә.

— Хәстәрен кичтән икәүләп карарбыз. — Хәертдин бераз хафага төште: «Исән-сау әйләнеп кенә кайтса ярар иде». Аның өчен үзе ауга чыгып китәр иде дә, урынына калып торырга кеше табылмас. Аннары егет тә китәргә атлыгып тора...

Иртәгесен таң белән торып, Хәмзә күңеле ашкынган сәфәргә чыгып китте.

*

* *

Талига больница караватында ята. Куллары, башы бәйләүле, бер күзе чәнчеп авырта. Күкрәге белән аркасына тикле ак марляга төрелгән. Бөтен җире өзелеп әчетә, сызлана, меңләгән инә кадап азаплыйлар шикелле. Аяклары селкенә, авыртмаган да кебек. Юрганын ачты да әкрен генә торып басты.

Тиздән аны операция бүлмәсенә алып киттеләр.

Аңына килгәч, самовар шикелле ялтыравыклы лампа абажурында үзенең йөзен күреп алды. Битләре чеп-чи кызыл ит, борыны яньчелгән, иреннәре асылынып төшкән, ияге дә иякә охшамаган, колакларына тикле ертылып беткән, уң күзе күгәреп чыккан иде. Шунда ул тагын аңын югалтты.

Яңадан күзләрен ачканда, караваты читендә сестра утыра, аның авызына ниндидер дару сала иде. Талига үзенең уң кулы селкенгәнен сизә, күтәрә дә ала һәм ачык күзе янына китереп карый: бармаклары бәйләүсез, димәк, әйбер тотарга була. Күзләрен йомды да үзенең борчулы уйларына чумды.

Әле шушы фаҗигага хәтле үк чем-кара чәчләре арасында ак бөртекләр күргән иде ул. Шуннан соң үзен тәмам сулган чәчәккә тиңли башлады. Моңарчы да коты очканы иртә картаю иде, Маринага карап йөрәге өзгәләнә иде. Ә хәзер үзе... Чәчләргә чал төшкән, авыр эштәндер, алга таба бөкрәебрәк йөри, аз гына булса да йөзгә сарылык йөгергән... Үзеннән ирләр затын читкә тайпылдыру дигән сүз түгелме соң бу? Кайсы хатын тели соң моны? Матур хатын иблистә дә вәсвәсә уятыр, диләр. Ә аның артыннан карап калмыйча түзә алган ирләр булмагандыр. Ул моңа куанып яшәде, шуны теләде, шуңа омтылды. Хәзер боларның берсе дә булмаячак. Ичмасам, ир белән яшәп бала да тапмады. Нәселе-ыруын дәвам итә алмагач, дөнья пыскытып яшәүдә ни мәгънә!...

«Мәхәббәтебез язгы ташкын кебек ярсулы, көчле иде, үкенечкә булган икән. Ел буе гел ташкынлы яз гына була алмый икән шул».

Караңгы төшүгә, караватчитенә утырып, тумбочка өстендә яткан китапның беренче буш битенә калтыранган куллары белән язарга кереште. «Зинһар өчен бәхилләгез шахтага «кояш ташучы» кызыгызны»

Төзәлсәм дә, йөземне җыерчык басачак, ә мина нибары егерме ике генә яшь. Убырлы карчыкка охшап яшәргә теләмим. Алешамны каршы алырга мин бу килеш-килбәтем белән булдыра алмыйм. Намусымның бер чите китек булмаса, түзәр идем, ә бу килеш — юк. Сау булыгыз, бәхилләгез, туганнар! Булдыра алса, Алеша да кичерсен мине!»

Һәм Талига башындагы, сул кулындагы бәйләүләрне чишеп алып, бөтерә-бөтерә, бау ишә башлады...

*

* *

Унҗиде яшенә җитеп, тавык та суйганы юк иде Хәмзәнең. Ә хәзер ул иркендә йөргән кыр кәҗәсен атып үтерергә бара. Кеше гомерен саклап калу өчен.

Ургыл утлары күптән артта калды. Әкрен генә таң атып килә. Тиздән кояш та шәфкатьле җылысын аркага бәреп җанны рәхәтләндерә башлар. Әле язның башы гына булса да, кар өстендә матур-матур бизәкләр җемелди, бөтен җиргә челтәр җыеп куйган төсле. Усаклар да өсләреннән ак җәймәләрен салып ташлаганнар.

Яз яме Хәмзәнең йөрәген җилкетсә дә, күңеле пошынып бара. Табармы ул «шүрәлеләрне», юкмы? Сыңар гына мөгезле булганга, мондагы кәҗәләр әкияттәге шүрәлеләргә охшыйлар. Ургыл аръягындагы таллыкта ФЗО га аяк баскан көнне үк бер көтү кыр кәҗәсе күргәннәр иде бит. Малайлар авызларына бармакларын тыгып сызгырып калганнар иде.

Хәмзә ул урманны чыккач, тубыктан кар ерып, вак усаклыкка юл тотты. Бара торгач, кайрылары кимерелеп, кәүсәләре генә елтырап калган таллар очрый башлады. Әйләнә-тирәсе тапталып беткән. Кәҗә мәлгуньнән бүтән кем эше булсын?

Мондый кимерелгән усаклар-таллар тагын, тагын очрады. Ләкин кимерүчеләр үзләре кайда соң?

Кояш инде өй биеклеге күтәрелде. Урман моң гына шаулый, кыштырдый, кайдадыр шартлап ботак сына. Ә «шүрәлеләр» күренми.

Һәм, ниһаять...

Хәмзә, «эһе, эләктегезме!» дип, чак кына кычкырып җибәрмәде. Кечкенә генә аланлыкның теге башында бер көтү кәҗә тора иде! Курыкмыйлар да үзләре. Җыенысы, эсәрешеп, аучы егеткә бер генә мизгел карап тордылар да яңадан усак кимерергә керештеләр. Хәмзә, җилкәсеннән мылтыгын алып, бик озак төзәп торды, урманны яңгыратып атып та җибәрде, көтү күз ачып йомганчы юк та булды.

Беренче атудан ук тидерә алмагач, ни була инде бу? Буш кул белән ничек кайтып керер? Оксанага нинди күз белән карар? Күзләрен йомып бармакка-бармак туры китереп карады: яңадан табармы кәҗәләрне, юкмы? Тидерә алырмы? Бармакка бармак тия тиюен. Юраганы юш килә генә күрсен.

Тагын бик озак каңгырып йөрде Хәмзә. Булмаса, тамак ялгап алырга кирәк. Капчыкны бик мул тутырып җибәргән Хәертдин абыйсы. «Аучының тамагы ач булса, күзләре күрми башлый аның», — дигән була.

Чү! Ботак сынган тавыш. Усакка елышты Хәмзә. Әнә бит, бер көтү мал. Юк, биш-алты гына, ахры, кар астыннан күренеп торган былтыргы үләнне кыркып йөриләр. Көтүнең читендә сакалы тезенә җиткән олы гәүдәлесе чуала, аның янында кечерәкләре. Берсе кая атлый, икенчесе дә шунда ашыга. «Зурысы — тәкәсе, кечтекие — саулыктыр». Аучы соңгысына мылтыгын төбәп атып җибәрде. Җан ияләре кайсы кая чәчелеп сибелде, ә челтәрле ап-ак кар өстендә кан тамчылары күренде. Кызыл тамчылар буйлап атлый торгач, бозлы күлләвеккә килеп чыкты. Ты-

пырчынып, яртылаш су эчендә яткан яралы кәҗәне өстерәп чыгарды да пәкесе белән тиз генә чалып ташлады. Ут ягып җибәрде. Кулларын, аякларын җылытты, ыштырларын киптереп урады. Хәзер кәҗәне эшкәртү мәшәкате калды. Әтисенең сарык суйганын күргәне бар иде, хәтта булыша да торган иде аңа. Шуңа күрә артык аптырамыйча, эчен ярды да, актарынып, карын бәрәнен табып алды. Ярты түшкәне кисеп, бәрәне белән бергә тирегә төрде дә капчыгына тыкты. Калган итне чыбыкка кадап учак өстенә элде. Хәертдин абыйсы хәтта тоз тыгарга да онытмаган. Ипие, суганы, шикәре. Рәхәтләнеп сыйлан!

Инде кайтырга да була. Җиңүче булып, сүзен сүз иткән, вәгъдәсендә торган чын ир булып кайта ул.

Эңгер-меңгер чак. Җәяүле буран купкан. Урманны чыгуга, тездән кар ерып атлыйсы. Күз ачар хәл юк, пыяла китекләре кебек каты кар бөртекләре биткә китереп бәрә. Хәмзә җилгә бер артын куеп, бер кырын-кырын атлый. Җил дигәне бишмәт аша җелекләргә кадәр үтеп керә. Оксаналар өенә килеп кергән Андрей күз алдына килә. Ул, үләргә теләмим, яшәргә тудым мин, дигән иде. Хәмзәнең исә яшәү генә түгел, Талига апасын да үлемнән коткарасы бар. Оксана, Хәертдин абыйсы, Якуп аны өзелеп көтәләрдер, ул кайтыр юлдан күзләрен алмыйлардыр...

Әнә, ерактагы йолдызлар кебек, эстакада утлары җемелдәп үзләренә таба чакырып торалар. Тау итәкләрендә — палатка утлары. Шул тирәдә больница, Ухановлар йорты, Хәертдин абыйсыныкы. Тик шул утларга, шул йортларга кайтып җитәргә, шуларга таба омтылырга кирәк!.. Үзенә-үзе сөйләнә Хәмзә, шулай иткәч атлаулары җиңеләя кебек. Әмма җил дә малайга бер карыш бирешергә теләми, кисәк-кисәк бик каты китереп бәрә, котырынып, аяктан екмакчы итә, йөгенне ташлап калдыр, җиңелрәк булыр, малай актыгы, ди гүя. Ә малай актыгының алай итәргә исәбендә дә юк, егылса да торып баса, атлый алмаса, мүкәли.

...Ул кайтып житкәндә, төн урталары булгандыр. Больница ишегеннән керүгә, соңгы хәлләре дә бетеп, идәнгә изрәп төште.

— Булды... Капчыкта карын бәрәне. Алыгыз... Талига апага,— диде ул ишек ачкан санитаркага. Үзенең җилкәсендәге биштәрен салырга да, капчык актарырга да хәле юк иде.

Сестра да килде. Биштәрне салдырдылар, үзен чишендереп, кулларын, аякларын уа башладылар. Нигә аның белән маташалар соң әле алар? Нигә капчыктан бәрәнне алмыйлар?

Ул арада бер палатадан ике санитарка носилка күтәреп чыкты. Носилкадагы гәүдә башыннан аягына хәтле ак җәймә белән капланган иде. Хәмзәнең эче «жу!» итеп китте.

— Кем? Кем ул?! — дип кычкырганын сизми дә калды.

Санитарка сүзсез генә мәетнең йөзен ачты. Хәмзә бәгырь үзәкләреннән сытылып чыккан ыңгырашу белән «аһ!» диде дә яңадан идәнгә ауды.

Әйе, Талиганы алып чыгып баралар иде санитаркалар.

*
* *

Талиганың хәлен Хәертдин генә аңласа аңлар иде. Аның үзенең дә гыйшык тотып шашынган көннәре булды. Үзен бик бәхетлегә санап, бөтен шахтага рекордлар куеп, дан яулаган чакларында гына үлеп яраткан хатыны, бердәнбер улларын ияртеп, әниләренә кунакка дигән булып, «берәр атнага гына» китте дә бүтән кайтмады. Бик озак көтте аларны Хәертдин, хараплар гына булмадылар микән, дип ут йотып йөрде. Артларыннан эзләп барырга гына торганда, хатлары ки-

леп төште: «Кичер мине, Харитон, мин кияүгә чыктым. Улың өчен көяләнмә, ирем бик тә үз итә»... дип язган иде.

Менә шул көннәрдән башланды аның михнәтле минутлары. Тотынды җәфаларга йокысыз газаплы төннәр. Әгәр дә кайтып керсә, гафу да итәр кебек тоела, буып та ташлар төсле иде. Азакта түзмәде, эш урыныннан рөхсәт алмый-нитми, хатыны артыннан китеп барды. Әмма елларның шундый вакыты иде, эштән качканы өчен өч айга хөкем иттеләр. Аннан котылгач, янадан малаен эзләп китте, тик алар ул белгән җирдә яшәмиләр иде инде. Тапмый кайтты. Ахырда үзен-үзе гаепләп, мең кат ярату-сөюләр кыстырып, көн саен хат язарга кереште, язган берен җибәрмичә сандыгына сала барды. Шактый вакыт узгач, милиция аркылы адресын тапты һәм барлык хатларын да берьюлы салып җибәрде. Ә хатын җавап итеп менәниләр язып бетергән иде: «Җитте, Харитон Харитоныч! Синең кәйләң белән көрәгең аркасында тәүлекләр буе ут йотып уздырган йокысыз төннәремне кызганам. Мин үз бәхетемне таптым, улың ятимлек тоймас. Син дә бәхетенне эзлә, бәлки табарсың. Улыңа ярдәм итмәсәң дә ярый, үзебезнеке җитәсе. Миңа бүтән хат язма», дигән иде. Мондый мәрхәмәтсез юлларны укыгач, тынгысыз йөрәк бөтен хатын-кызны күрә алмас булды. Кулыннан тәмам эш төште, төшенкеләнде: ике-өч тапкыр хәтта эштән китеп югалып торды. Ике тапкыр Уханов, бер мәртәбә Степанов эзләп табып алып кайттылар. Шулай итеп, ул аздан гына кешелектән чыкмый калды. Тора-бара эшкә чын күңелдән бирелеп, иптәшләренең дуслык кадерен белеп, аларга таянып, үзенең кирәклеген аңлап яши башлады.

Бу фаҗигале мәхәббәт турында аның авыз ачып берәүгә дә сөйләгәне юк. Хәзер инде мәхәббәт тойгысы сүнгән. Анда икенче тойгы — ата буласы килү тойгысы уянган, аның үз баласы турында аталарча кайгыртасы килә. Шушы кайгырту нияте күңеленә ләззәт бирә, тынычландыра, шуның аркылы эшеннән дә ямь таба. Аның уйлавынча, үзенеке һәм Талиганыкы шикелле көчле сөю белән яшәп калу иң зур бәхет дигән сүз. Гомерең буе пыскып ятканчы, бераз гына булса да дөрләп януга ни җитәр! Менә хәзер аның улы бар — Хәмзәсе. Хәрби комиссариатта комиссия узарга аңа повестка тоттырганнар. Әгәр дә аны сугышка алсалар, тагын ялгызы гына кала түгелме?!

*
* *

Клубның тышкы һәм эчке стеналары тулы күп төрле лозунглар, плакатлар. Нинди генә юк монда! «Кангa — кан, үлемгә — үлем!» «Ватан-ана чакыра!», «Безнең урамда да бәйрәм булыр!» «Дошманны үз өнендә дөмектерербез!», «Шахтер! Синнән Ватан күмер таләп итә!», «Син бүген җиңүгә өлеш кертерлек нәрсә эшләдең?» һәм шундый бик күпләр эленгән.

Хәмзәне күрүгә, Якуп елмаеп килеп күреште. Аның инде чәчен дә кырыкканнар. Яшьләрнең кайберләре инде комиссия каралып чыккан, документ көтеп утыралар. Моңарчы тылда яткыргач, кайберәүләр кимсенәләр иде. Менә бүген аларның язмышы хәл итәлә, хәзер комиссар бүлмәсеннән чыгар да, «иртәгә фронтка китәсез», дип, кулларына кәгазь тоттырыр шикелле.

Юк, бирсенә дә кәгазь тоттырмадылар, берсен дә фронтка озатмадылар аларның.

— Ватан-ана сезне, солдатлар, хезмәт фронтында калдыра. Сез бүгеннән башлап Совет гаскәрләре сафында. Иртәдән башлап яңа хәрби өйрәнүләр башлана. Көндез эшләүчеләр төнлә, төнлә эшләүчеләр көндез тактик укуларга йөриячәкләр. Кирәк була калса, Ерак Көнчы-

гышны япон самурайларыннан саклау безнең өстә. Батальон белән үзем командалык итәчәкмен. Приказ сезгә дә, миңа да закон! — диде комиссар.

## УНӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Михайлов «Сивак»тагы бөтен штрекләрне әйләнеп чыкты, көнен шунда уздырды. Бүлмәсенә кергәч, лампасын сүндереп тә тормыйча өстәлгә куйды, манма су булган брезент киемнәрен салып урындыкка ыргытты. Өстәлгә комбинаттан килгән кәгазьләрне таратып ташлады, арадан ике бит тутырып язылганын кулына алды. Бик озак текәлеп торды ул бу кәгазьгә. Арыганлыгын онытып, язудагы борчулы сүзләргә чумды. Эшче көчләре житмәгәнлектән, «Сивак» участогын ябарга, диелгән иде анда.

Тәүлекләр буе аяк өсте булып арылган, тез буыннары өздереп сызлый, күзләр йомылырга гына тора.

Әкрен генә атлап Степанов килеп керде. Михайлов шундук аягүрә басты. Күрештеләр. Хәл-әхвәл сорашып тормадылар: болай да яхшы танышлар. Степанов куен кесәсеннән дүрткә бөкләнгән дәфтәр бите алып, Михайловка сузды.

— Бу нәрсә?

— Гариза.

Михайлов кинәт кенә кашларын җимереп күтәрелеп карады, аннары укып чыкты, коры гына:

— Мә, тыгып куй кесәңә,— диде.

— Мин аны сиңа резолюция салырга дип бирдем.

— Тык диләр кесәңә. Сугыш беткәч, көлә-көлә рәхәтләнеп укырсың.

— Мин, җанкисәгем, сугыш беткәнне күрә алмамдыр. Үз хәлемне үзем генә беләм. Куып чыгара белмәдегез, үземнең мондый гариза язарга көчем житмәде. Вакыт, бик вакыт инде,— диде Степанов, чыраен сытып. Бик авыр иде аңа бу сүзләрне ычкындыруы, ашказаны авыруы газапламаган булса, түзәргә дә иде әле исәбе. Шул авыруы сәбәпле аны партия җыелышында парторг итеп тә сайламадылар, аның урынына Уханова Зоя сайланды. Әмма бөтен сәбәп картлык яки чирдә генә түгел. «Сивак»та һаман фаҗигаләр булгалап торуында ул үзен гаепләде. Якупның тукмалуын да, Варяның җәфалануын да һәм Талиганың дөнья куюын да үз өстенә алды, шулар аны тинтерәтте, йөрәген ашады.

Бик озак дәшми торганнан соң, Михайлов сүз башлады:

— Димәк, Федор Иванович, таярга булдың? Камытларны әкрен-әкрен сала барам дисең? Мич башына урләмәкче буласың?

— Шулай диярга ничек телең бара?! Участок хәтле участокны сөйрәп барыр чагыммы соң минем. Лавалар күмер стенасына килеп терәлде, штрекләр әзерләргә җитешмим, шахтерларның җанын кыям... Моннан ары нишләргә кушар идең тагы? Тәмам таркалып беткәнне күтәргәме?

— Әллә миңа ансатмы? Хатын-кызларыңа, кордашларыңа?

— Сугыш беткәнче түзәргә кушасың. Аңлыйм. Курортларга барырсың, ялга чыгарсың, улларың кайтыр дисең. Юк, улларым кайтмаслар. Туган Донбасслары өчен башларын салганнар... Бу хакта авыз да ачканым юк иде. Борчыйсым килмәде. Ел буе карчык белән икебез генә көйдек...

Михайлов Степановның бу олы кайгысын белә иде инде. Аны юанарту кирәк тапмады, әйтә куйды:

— Ә мин синнән, Федор Иванович, коелып төшү көтмәгән идем. Безгә болай һич тә килешми. Без — карт гвардия. Минем дә хәлем

синекеннән артык түгел. Ынгырашырга кушасыңмы, тартәне артка борыргамы? Юк, бормыйк әле! Фашизмның җанын алмыйча үзебезнекен дә бирмибез Газраилга. Ә шахтадан чыгу — ул безгә җан бирү дигән сүз. Часовойның сакта торганда һәлак булганы ил өчен кадерлерәк.

— «Сивак»ны ташлап китүе, андагы бөркетләрне калдыруы әллә миңа җиңел булыр дисеңме? Иптәш Михайлов, мин ике уйлый торган кеше түгел. Резолюциягезне салыгыз да участокны кемгә тапшырырга икәнен әйтегез.

Михайлов аңа комбинатның приказын сузды.

Степанов аптырап торды-торды да, кәгазьне алып, эчтән генә укырга кереште. Бик озак укыды ул, тирләп чыкты, иреннәре калтыранды, әйтәсе сүзен әйтә алмыйча тотлыгып торды. Тик бераздан гына:

— Бөркү... Күгебез болытлы,— дип куйды. Аннары каты гына: — Ник чаң какмыйсың? — дип өстәде.

— Сер итеп саклыйм, Федор Иванович, шахтерлар кайгырмыйча торсыннар, ичмасам.

— Без капчыкта ятмый, иптәш начальник. Хәл кылырга туры киләчәк.

— Гаризаңны тык кесәңә...

— Эх! Эш андамыни хәзер! Менә монда яна башлады.— Степанов күкрәгенә сугып күрсәтте.

Михайлов икенче кәгазь сузды.

— Монысы Әхмәтҗановны десятник итеп калдыру турында.

Степанов, кәгазьне алып, дәшми-нитми чыгып китте. Аяклары үзеннән-үзе «Сивак»ка таба атлый иде. Юл буе «Сивак» турында, Якуп хакында уйлап барды. Әйе, күңеленә Якуп ошаган иде, үзенә иярләндермәкче иде аны, улы итмәкче иде. Булмады. Нибары бер генә тапкыр килеп китте дә бүтән эзен дә күрсәтмәде. Әнә Харитонга Хәмзә бик тиз ияләште. Җылы бөркемимдер, ахры. Бөтен дусларымнан, якыннарымнан Прошка гына калды. Эх, Прошка, ярый әле, син бар...

*

* *

«Сивак»тагы фаҗигадән соң Якуп атна-ун көн забойда эшләп торды. Иң курыкканы — яңадан шахтадан куып чыгарылу иде. Талиганың үлеме дә бик нык тәэсир итте, атна буе беркем белән сөйләшмәде, беркая чыкмады, кайтты да ятты, Хәмзә килгәләп йөрсә дә, барыбер юата алмады. Талиганың үлемендә ул үзен дә гаепле дип хис итте. Забойда күмер чапканда да, өенә кайтып яткач та, күз алдына һаман көләч йөзле, матур киенгән гүзәл хатын килеп баса иде. Аның күңелендә Талига якты истәлек булып калды.

Фаҗигане тикшерү гаять озакка сузылды, нәтиҗәне һаман әйтмәделәр. Бу да Якупның йөрәгенә кадала торды. Соңгы көннәрдә ул тәмам ябыкты, саргая башлады, эштә дә сүлпәнләнде.

Шул көннәрнең берендә Степанов, аның теләр-теләмәс кенә күмер төягәнен карап торганнан соң:

— Әйе,— дип куйды. Аннары: — Җанкисәгем, аргансың бугай? — диде. Аның кулына Михайловның приказын тоттырды. Якупка каты шелтә белдереп, яңадан десятник итеп куярга карар кылынган. Моннан ары участокның бу лавасын газлылар исәбенә кертергә, каты режим урнаштырырга кушылган иде.

Әйе, кызулыгы белән хатын-кызларны кисәтергә онытып җибәргән иде ул. Юк, уйламаган иде яңадан десятник булырмын дип, башына да китермәгән иде. «Авызың бер тапкыр сөткә пешсә, суны да өреп эчәрсең», дигәндәй, бу эштән баш тартып карады. Әмма участокта десят-

никлар житешмәвен яхшы белә. «Бүредән куркып, урманга бармый торырмыни?» Шулай итеп, ул Зоя бригадасын яңадан кабул итте.

Десятник булып эшли башлаган беренче көннән үк Якуп күмер кистерү машинасы турында хыяллана башлады.

Әйтеп калдырды бит аңа Уханов: «Врубмашинаны кабат «Сивак»-та сынап карарга кирәк. Моңарчы «Сивак»ның күмере каты, машинаны гына харап итәрбез дип, кул селтәп килдек. Мең мәшәкать белән, үземнең чынлап тотынырга кулым житмәде. Күрсәт егетлегеңне, Әхмәтжанов, шул машинаны «Сивак»та гөрләт! Синдәй егетләргә буйсынмый калмас ул машина — ышанычым зур», — диде.

Фронтовикның бу васыятен тормышка ашыру эшенә чын-чынлап керешергә вакыт, бик вакыт.

Якуп «Чаланык» участогына барып, бу машинаның эшләгәнен карап йөрде. Шул турыда китаплар эзләп тапты. Көчле машина икән! Гигант кәлтәгә охшаган. Гәүдәсе калынлыгы белән берәр метр чамасы булыр, ә озынлыгы ике метр. Ике кул яссылыгында койрыгы да бар. Күмер стенасы кырыйлатып шуыша-шуыша, шул койрыгына беркетелгән корыч тешләре белән күмерне кистереп бара. Күмер астыннан эчкә ике метрга хәтле үтеп керә. Ул кистереп узгач, бораула да шартлат кына. «Сивак»та бигрәк тә уңайлы: катлам тәбәнәк, җирлек тә, күмер дә каты, түшәме дә нык. Газ да әлегә бер генә лавада.

Якуп хыялга муеныннан чумды. Бу машинага гашыйк булды. «Шуны хутка салсак, кәйләне музейга куяр идек»,— дия башлады. Әмма теләккә ирешү өчен нишләргә соң? Мондый фикер башына килсә, әти нишләрие? Берәр нәрсәне хәл итәргә туры килсә, «Бу мәсьәләне әти ничек чишәр иде?» дигән уй башына төшә аның. Иптәшләрен дә, бүтәннәрне дә этисе белән чагыштырып бәяли ул хәзер.

Һич онытасы юк — заманында, бөтен тирә-як халкын шаккатырып, әтисе колхозга агачтан борчак суктыру машинасы ясап бирде. Моңарчы елдан-ел борчакны тимер машина белән суктыра иделәр, борчак теткәләнеп, ярылып бетә иде. Агачыннан ник бер ярылган борчак заты чыксын. Гомумән, мәктәптә укулар тәмамлангач, әтисе җәй буе тимерчелектә кайнаша, чәчкечен дә, сабанын да төзәтә иде. Якуп яшьли шул тирәдә чуалырга яратты, я чүкечен китереп бирер, я машиналарның боргалар җирен боргалар иде. Әтисе колхоз кәнсәләренә кереп, хуҗалар белән киңәшә, бәхәсләшә, үзен дә бирелеп тыңлап утыралар иде. Авыл халкы аны якын итә, ярата. Гел дуслар гына булмый икән шул, арада дошманы да табыла. Ямьле җәй көннәренең берендә авылда, «Әхмәтҗанны каптырганнар бит», дигән яман сүз таралды. Амбардагы бодайны юри череткән, имеш. Чыннан да, шул җәйне глубинка амбарларында мөдир булып эшләгәндә шактый гына бодае күксеп янган, бозылган иде. Киптерелми салган чүпле ашлыкның бозылуы да гаҗәп түгел, аннан да битәре — амбарлар хан заманыннан калган, тишек түбәләреннән су үткән булган.

Атасының җәзага тартылуы Якупка да газаплы көннәр китерде. Баштарак аналы-уллы аның кайтырын көттеләр, менә-менә ишекне киереп ачар да килеп керер кебек тоелды.

Менә бүген дә күңеленә күмер кистергеч машина хыялы кереп утыргач: «Әти ярты юлда туктап калмас иде»,— дип, Михайлов белән Степанов янына юнәлде Якуп. Бәлки «Сивак»та машинаны сынап карарга рөхсәт итәрләр...

Шахта идарәсендә берсен дә очрата алмагач, кире «Сивак»ка килде. Кирәкле кешеләре анда да юк иде. Аптырагач, иртәгә иртүк эшкә барасы дип тормыйча, төн уртасында участокка керде. Һәр тәүлектә Степанов шунда килеп, забойларны тикшереп йөрергә яратучан. Якуп аны ныгытучылыкка өйрәнүче малайларга бер потлы чүкеч күтәреп булышып йөргән җирендә очратты. Үзенең хыялын сөйләп бирде.

Степанов иплэп кенэ чүкечен куйды да, күзлэрен шар ачып, Якупка карап алды, әйтергә теләгән җавабы бугазында төртелеп калды: бик яман хәбәр әйтергә тиеш ул аңа.

Ә Якуп ялынып сорый бирде:

— Федор Иванович, сынап карыйк әле, зинһар өчен!

Степанов егетнең өметен өзәсен белеп әйтте:

— «Сивак»ның язмышы кыл өстендә тора, улым. Аны ябарга ниятлиләр,— диде.

Якуп ышанмады: ничек инде гөрләп күмер биргән шахтаны ябсыннар?!

— Бездән сорамыйча ябмакчыларммы? Без бит монда хуҗа, Федор Иванович. Ник дәшмисез?..

*

* *

Ниһаять, көндезләрен эшләп, кичләрен курста укып уздырганнан соң, куаныч та килеп җитте Хәмзәгә. Оксана белән икесе кулларына «Электровоз машинисты» дигән таныклык алдылар. Әмма бүгенге көнгә хәтле «Сивак»ның язмышы хәл ителмәгәнлектән, Хәмзәгә электровоз утыргычына утыру тәтемәде. Степанов аны «Синдәй батыр егетнең урыны забойда. Менә фронтовик шахтерларыбыз кайта гына башласын, иптәш кавалерист, иң беренче сине утыртырмын корыч аргамакка»,— дип вентиляция штрегенә куйды. Ә «кавалерист» тарткалашмады, риза булды. Шулай да аның эчендә мәчеләр тырмаша. Оксана белән бергә эшкә барып, парлап кайтып йөрисе иде нияте. Кичә генә бүләк итеп бирелгән соры төстәге трико костюм, калын табанлы кызыл ботинка, күзнең явын алырлык яшелле-зәңгәрле йон оекбашлар алып кайтты. Бу хәтле үк әләкмәс тә иде аңа, Хәертдин абыйсы: «Миңа кирәкми, минем өлешне Ибраевка бирегез»,— дип әйтеп киткән. Яшьләрнең һәммәсенә дә бераз өс-баш юнәтелде, юкса, тәмам умырылып беткәннәр иде. Хәзер палаткаларда чын бәйрәм кебек. Кызларга зәңгәр төстәге йон юбка, ак күлмәк, оекбаш һәм эш ботинкалары бирделәр. Оксана да үзенә тиешлесен алып кайткан. Хәмзәнең оекбашына бик кызыга ул, әллә тагын ун тапкыр киеп карагандыр. Ахырда яулыкка алыштылар. Яулыкның читләре чигүле, сүзләре мәгънәле иде: «Йөртерсең үзеңдә, сакларсың исеңдә».

Костюмны киеп алгач, Хәмзә бөтенләй матур егеткә әйләнде. Хәзер инде ул дөньяның ачысын-төчесен татыган, хезмәттән, тормыштан тәм һәм ямь табып яшәргә өйрәнә башлаган. Тормышны, тирә-якны матур итеп күрергә теләгән һәм күрә дә белгән, мәңгелек тунлыкта гөлбакчалар ясарга ниятләнгән егет ул бүгенге көндә. Шундый ук хыялларны Оксана да аңа сөйли, бергәләп тормышка ашырмакчы булалар.

Тик Хәмзә яздан бирле «тавык күзе» авыруыннан җәфа чигә. Шуның аркасында Хәмзә беркая да чыгып йөри алмый, әнгер-меңгер чак җиттеме, янып торган электр лампочкаларын да күрми. Яз башындарак булган зәңгелә авыруын ылыс суы эчеп ничек кирәк алай җиңгән иде, ә «тавык күз»не фәкать атланмай белән генә җиңеп була икән.

Шундый көннәрнең берендә караңгы төшкәнче Хәмзә палаткасына кайтып керә алмады, аяк астын күрми башлады. Оксананың әзләп килгәнен көтеп, мунча янындагы тирәүлекләр янына килеп утырды. Күп көттермәде, сөйгәне килде дә култыклап үзләренә алып китте.

Менә Оксана сөйләнеп кайта:

— Бүген, Хәмзушка, тавыгыңны әтәч итеп кычкыртабыз,— ди. Әнисе кайдандыр бераз бавыр юнәткән икән. Шуны суда кайнатып, Хәмзәнең күзләрен шул пар эчендә тотарга икән исәбе. Кайтып җитүгә, «тавык»-

ны карават читенә утыртты да, бер җиргә дә кузгалмаска кушып, бавыр кайнатырга кереште. Чәй кайнатып куйды. Әшен бетергәч, көлә-көлә, егетнең битеннән үбеп алды.

— Караны, кузгаласы булма! Ашханәгә ипигә чабам. Кузгалма, яме!

«Эх, тавышларың чылтырап аккан чишмәнекенә охшый, йөзеңне генә ачык күрә алмыйм!» — ди Хәмзә. Кузгалып кая бара алсын, күтәргә кушылгач, күтә. Әллә кайда әллә нәрсәләр кыштырдый. Бер адым атлый, икене атлый һәм, урындыкка абынып, егыла. Үзе рәхәтләнеп шаркылдый. Кармалый-кармалый урындыкны күтәреп куя да, утыра, бүтән кузгалмаска сүз бирә. Гарьлектән янарсың, үкереп еларсың егет башың белән: ут чыкса, сүндерә алмыйча, янып үләрсең. Аптырагач, өстендәге бишмәтен идәнгә җәйде дә бөгәрләнеп ятты. Болай тынычрак, урын-җир дә пычранмый. Алҗыган кешенең йокысы сизгер икән,— төш күрә башлады. Төшендә авылына кайткан, әтисе-әнисе, сеңелләре янында йөри, имеш. Оксананы да ияртеп кайткан икән. Кояшлы матур көндә болында чәчәк җыялар, аннары ямьле арыш басуын карап йөриләр...

Оксана кайтып кергәндә, бозау хәтле кара песи мыекларын ялап утыра, мискидәге бавырдан җилләр искән иде. Мияубикә сиздe кемнең маен сукканын, шыпырт кына мич астына шылды да, күзләрен утлы күмердәй елтыратып, Оксана кулындагы кыскычны күзәтеп утыра башлады. Оксана көләргә дә, еларга да белмичә мәчегә яный: караны, мәнге анда ятмассың, янәсе, чыгарсың, кирәгеңне бирермен, уткүз!

Хәмзәне уятып, бавырның язмышын сөйләп бирде.

— Тотарсың койрыгын,— диде егет. Эченнән: «Әдәм көлкесе бит, күз алдында бавырны алып китсеннәр әле»,— дип ачынды.

— Хәмзушка,— диде кыз, кашык тоттырып,— бавырдан колак кактык, монысыннан да коры калмыйк! — Өстәмә ризыкка бәрәңге алып кайткан икән, шуны ашарга кушты. Әмма Хәмзә кашыгын кая китереп төртергә дә белмичә аптырады. Ә тегесе, аның мөшкелләнеп утыруын аңлап җиткермичә: «Нигә көйсез кияү шикелле, авыз күпертеп утырасың?» — дип шелтәләп тә алды.

— Нигә уйга чумдың, Хәмзушка? — диде Оксана аннары.— Бер дә кайгырма, хәзер дәваларга тотынам.— Бавыр кайнаган сулы миски авызына Хәмзәнең башын тыкты, күзләрен ачарга кушты. Шулай шактый гына утырдылар. Башын алгач, Хәмзә яна гына күргән төшен сөйли башлады, аннары хыялланырга керешге:

— Өй артында гына буа, аннан арырак — өстеңә аварга торган каен урманы. Кайтсак су керер идек. Көймәдә йөрербез, урманда каен җиләге җыярбыз. Мин сиңа чәчәк җыеп тоттырырмын. Болын тулы чәчәк, урман тулы чәчәк бездә... Ярый, монда да үсәр әле. Үсмәсә, чәчеп-карап үстерербез, ярыймы?

— Ярый, Хәмзушка, үстерербез. Сөйлә, сине тынлавы миңа бик күнелле,— ди Оксана, якынрак елышып.

— ...Безнең авылдан туп-туры Мәскәү янына китәрбез. Николай Михайловичның каберенә чәчәкләр куярбыз. Минем әтинекенә дә...

— Каберләрен кем күрсәтер?

— Батырлар һәйкәленә куярбыз.

— Үзең генә кайтып китсән, кире әйләнеп килерсенме? — дип сорый Оксана.

— Синнән башка кайтып та йөрмим, билләһи. Миңа монда да эш муеннан. Тау итәкләренә алмагачлар, чия, шомырт утыртасым бар. Чәчәкләр үстереп парклар ясарбыз. Үзең дә шулай хыялланасың ич...

— Минем таулардан да биек йортлар саласым килә...

— ...Паркның түренә ил батырларына һәйкәл куярбыз. Сезгә, кызларга да! Үзебез үстергән бакчаларда, кулга-кул тотышып, таң атканын

каршыларбыз. Ул чакта ел саен ял бирә башларлар, берәр айга. Атна саен ял итәрбез. Эш сәгатьләре дә уникешәр булмас...

— Сөйлә, Хәмзушка, хыяллан! Син әйткәндәй, кеше күрмәгәндә мин үзем дә шулай хыялланып, шашынып бетәм...

— Хыялсыз кеше кешемени ул!.. — ди Хәмзә.

— Беләсеңме, Хәмзушка, — дип бүлдерә аны Оксана, — Донбасста безнең бозау кадәрле бик дәү кәҗәбез бар иде. Мөгезләрен күрсәң, коты очар: әллә тагы үгезнеке хәтле булыр. Көтүдән кайтмыйча интектерде, каһәр төшкере. Беркөнне шулай эзли-эзли хәлдән таеп беттем, балавыз сыгып капка төбендә утырам. Артымнан килеп сөзеп торып җибәрмәсенме! Шушы җирем бер ай авыртып йөрде. Ата казыбыз да усал эт белән бер иде, дуңгыз. Ботымны бора да ала, бора да ала иде. Тәмам кара көйдереп бетерде...

Шулай сөйләшеп туялмыйлар алар.

— Ялгызың кайталмассың бит, Хәмзушка. Илтеп куйсам, берүзем ничек кайтырмын? — диде ахырда кыз.

Бу төнне Хәмзә Ухановларда беренче тапкыр кунарга калды.

Ә бер атнадан туй хәстәрен күрергә керештеләр.

Шул көннәрнең берендә Марина Оксанага:

— Апаңнан алда кияүгә ашкынасыңмы? Мине кияү тапмас ди торгансыңдыр! Булмый торсын әле, ярыймы! — дип ачу белдерде һәм фырт итеп чыгып китте.

•

* *

Бер килмәсә килми, бер артка китә башласа, гел артка тәгәри икән ул: Якупның хыялы тагын тормышка ашмады. Кая барырга, кемнән ярдәм сорарга? «Сивак»ны япмыйча һич тә булмый микәнни? Әллә бөтенебез җыелып Михайлов янына барып, япмавын үтенеп караргамы?

Менә Якуп хәзер Михайлов бүлмәсендә. Хуҗа үзе стенада эленеп торган җир асты участокларының картасы каршына баскан да каткан. Кулында бер башы кызыл, бер башы зәңгәр карандаш. Шуның белән картага ниндидер билгеләр сызгалый, төрткеләр куя. Бу карта янында ук СССР картасы. Анда бик күп кечкенә генә әләмнәр төшерелгән. Бу әләмнәр данлы Кызыл Армиябез фашистлардан азат иткән олы шәһәрләр. «Генерал һөҗүмгә әзерләнә», — ди Якуп эченнән. Шушы кеше аңа бик якын. Әнә теге өстәл янындагы урындыкта, җир өстенә куып чыгарылгач, комачтай кызарып утырганы бар. Ярыйсы гына каты куллы карт. Калыная төшкән олы гәүдәле. Озын, куе чал кашлары түгәрәк коңгырт күзләре өстенә үк төшеп диярлек җәелгән. Кешегә төбәлеп караганда һәм ачуы килгәндә шушы кашлар еш кына җимерелә, шомлы карурманны хәтерләтә башлый. Кеше керде дип исе дә китми, ишекле-түрле салмак кына атлап йөрүен белә. Усал кебек күренә, хәтта аннан шүрлиләр дә. Мәсьәлә хәл иткәндә озак уйлап торучан, сөйләүчене бирелеп тыңлаучан.

Михайлов, Ургыл якларына күчеп килгәнче, берничә дистә елын Мәскәү яны шахталарында уздырган. Партия аны Ерак Көнчыгышка яңа күмер ятмалары ачарга җибәргән. «Сивак»ның беренче начальнигы булган, менә хәзер ике участоктан торган шахта начальнигы ул.

«Ничек батырчылык итеп «Сивак»ны ябарга әмер бирден?» — дип сорыйсы килә Якупның, ә тегесе, телен йоткандай, бер сүз дә дәшми.

— Мин сезнең янга килгән идем, иптәш начальник, — диде Якуп, аптырап арыгач.

— Көттем, күптән көттем, берәрегез килеп чыкмасмы дидем. Синең күмер кистерү машинасына гашыйк булуың да миңа билгеле. Тик менә,— чал кашларын усал җыерып, дәвам итте: — юлыңа аркылы киртә корсалар, аны нишләтәләр?

— Җимерәләр яки сикереп утәләр.
— Ә син нишләмәкче? Кире борылмакчымы?
Якупның телен ниндидер шайтан тотып тора, йомырка тавыкны өйрәтми дип, кырт кисәр төсле тоела. Аннары үз-үзенә: «Алайса, нигә кычытмаган җирне кашып йөрисең? Тотынгансың икән, ныгытыпябыш!» — ди.
— Безгә ул кулай килер иде, — ди Якуп ахырда.
— Машинаның эшләвенә ышанасыңмы?—Михайлов текәлеп карады. Якуп та аңа туры карады, ышанам дип теш-тырнагы белән тартышырга исәбе. Нишләптер, каушап калгангамы, өздереп берни әйтә алмады.
— Барып чыкмаса, яңадан дилбегә тоттырыр идегезме?
— Бу синең сүз түгел, Әхмәтҗанов. Кыюны кыстамыйлар, кыю юлны үзе яра. — Бүтән такылдап торырга вакыт юк дигәндәй, Михайлов, өстәл артына кереп утырды да кәгазьләр актара башлады.
Ярты сәгать диярлек басып торгандыр Якуп. Гаҗәеп сәер кеше икән бу шахта начальнигы, ифрат үзсүзле. Әйтте — кисте, бетте.
— Иптәш начальник, башымны кисәргә бирәм, машина «Сивак»та җил уйнатачак. — Якуп, шулай дисә дә, шикләнә калды: җиңәсе урында, тешләрен койса? Ул чакта яңадан «әйдә, бахбай!»га калырмы? Сүзне икенчегә борып җибәрде: «Сезнең «Сивак»ны ябарга хакыгыз юк! Ул безнең туган йортыбыз, сез безне, малайларны, анда егет иттегез».
— Үскәнеңне сизмим. Үзең машина юллап килгәнсең, үзеңнең дилбегәдән котың оча. Тагын ни йомыш?
— Әй, нигә сезгә сөйләп вакыт әрәм итәргә?! Барыбер үз туксаныгыз туксан. Лутчы машинаны сөйрәтеп «Сивак»ка китерәм дә лавага илтеп, эшкә тотынам.
Михайлов торып басты, кашларын җыерып Якуп каршына килде. «Башбаштаклык өчен судка бирермен!» — дип акырып җибәрер төсле иде, әмма алай итмәде, ипләп кенә егетнең башыннан сыйпады.
— Сиңа укырга кирәк булыр, иптәш Әхмәтҗанов. Синнән яхшы гына инженер чыгачак. Менә, Гитлерны гына дөмектерик, безгә бик күп катлаулы техника кайтыр. Бөтен эш яңа технология, яңача оештыру таләп итәчәк. Күмерне күп итеп кенә түгел, арзанга төшереп чыгару, аз кеше эшләтү инженерның төп бурычы саналыр.
Якуп аны йотылып тыңлый, менә бит: таш-кыялы җир астына гына түгел, киләчәккә дә гашыйк икән!
Михайлов һаман, каты чабып килгән ат туктый алмаган шикелле, элеге сүзен дәвам иттерә:
— Иң әүвәл, бөтен штрекләрне гигант адымнар белән төзергә керешергә кирәк. Лавалардан күмерне дә бүгенгедән күбрәк чыгаруны таләп итәләр. Ә киләчәктә җир астында шахтерлар бармак белән генә санарлык калачак, барлык эшне техника башкарырга тиеш. Бәлки күмер урынына аның энергиясен генә чыгара башларлар. Менә кайда укымышлы, фәнгә гашыйк егетләр кирәк булачак.
— Ә без «Сивак»та «кәлтә» сынап карарга да куркабыз...
— Әлбәттә, әлбәттә... Синең яшьтә үзем дә «мин булдыра алмаган нәрсә юк» дип гайрәт ора идем. Машиналар бертуктаусыз ватыла, ә без төзәтә-төзәтә җәфа чигә идек. Әгәр син дә шулай шахтерның гайрәтен чигереп бетерсәң, машинаны өскә чыгарып ташларсыңмы? — Михайлов яңадан, күзгә керердәй булып, карашы белән кадалды. Әмма Якуп күзләрен читкә алмады.
— Әгәр хәзер үк икебезне дә җир йотса? Шушында ук упса?
Начальник шаркылдап, рәхәтләнеп көлде.
— Ярый. Баш инженер белән киңәшербез. Парткомда сөйләшербез. Врубмашинаның «Сивак»ны коткарып калырга ярдәм итүе дә ихтимал.
Якуп, бередән чыгуга, «Чаланык» участогына, күмер кистергеч машинасы янына йөгерде. Бүген аның буш көне, эшкә кичкә генә чыгасы.

* * *

Марина Андрейдан хат алды, әмма сөенергә дә, көенергә дә белмәде. Андрейны хезмәт фронтыннан качып йөргәне өчен штрафнойга озаттылар. Госпитальгә эләккәнче ул Маринага хат язмады.

Менә кыз исе китмичә генә конвертны ачты да укырга кереште. Бик күп сәламнәрдән һәм үкенүләрдән соң Донбасста бергә укыган чакларын, соңрак бергә уздырган кадерле минутларны искә алган. «Гомерем буе музыкант булырга хыялландым, шуны тормышка ашыра алмавыма йөрәгем сызлана,— дигән.— Әти-әниләрнең кайда икәннәрен белмим. Терелеп чыксам, кая барып сыенырмын?] Алгы сызыкта ятып калган булсам иде, ичмасам. Газап чигәсе минутларым бетәр дә китәр иде. Кичер мине, Марина, элекке мәхәббәтебез хакына гафу ит, мөмкинлек табып күрешергә телим. Уң аяксыз калуым ихтималы да бар. Сау бул!» — дигән.

Баштарак хатка бер дә исе китмәгән иде Маринаның. Ләкин торган саен хәтеренә хат сүзләре ешрак килә башлады. Күз алдына бик мескен кыяфәттә Андрей килеп баса иде. Култык таякларын шыгырдатып, бик азап белән Маринага каршы килә кебек егет. Күзләре бик борчулы, хәсрәтле карый...

Әллә ничә тапкыр җавап хаты язарга утырды. Ләкин яза башлады да ертып ташлады.

Ниһаять, Марина әнисе белән киңәшеп карарга булды.

Бик озак укыды Зоя хатны. Әллә инде бөтенләй укымыйча хатка текәлеп кенә торамы?

— Нишләргә миңа, әни? — диде Марина, түземсезләнеп.

Зоя башын күтәрде. Сиздермәскә тырышып кына авыр сулап куйды.

— Йөрәгең ничек кушса, шулай эшлә, кызым.

— Аны кеше итәргә кирәк ич, әни.

— Кеше итә алырыңа ышанасыңмы соң?

— Мин аны яратам, әни. Яратсаң, хаталарны гафу да итәләр. Үзеннең шулай дигәнең бар бит.

— Кызым, эш сөймәгән кешегә изге нәрсә юк бу дөньяда.

— Аның музыкага сәләте бар, теләге көчле. Бөтен кешегә дә шахтер гына булырга димәгәндер бит!

— Кызма, балам.— Зоя җитдиләнә төште.— Сүзне син башладың, киңәш сорадың. Андрейны музыкага әти-әнисе, укытучылары көчләп өйрәттеләр, көчләп мәктәптә укыттылар, хәтта ашату-эчертүләре дә көчләп кенә иде.

Марина аны сүзеннән бүлдерде:

— Әни, ул үзенең хаталарын аңлаган ич инде. Ул монда кайтырга тели. Аның бүтән кешесе юк.

— Беләм, кызым. Яратасың микән соң син аны, әллә кызганасың гынамы? Күрәм, икеләнәсең, шикләнәсең...

— Тик юләрләр генә икеләнә дә, шикләнә дә белмиләр. — Марина байтак дәшмичә торды. — Мин аны шушында алып кайтам да эшкә урнаштырам. Җиңелрәк, кулыннан килерлек эшкә. Сугыш беткәч, музыка мәктәбенә кертәм. Син уйлаганча, ул алай ук томана түгел...

Зоя: «Урнаштырам... Кертәм...» — дип кызының сүзләрен кабатлады да кырт кисеп әйтте:

— Балам, беразга сабыр ит, госпитальдән чыксын, кая барырга икәнен үзе сайласын. Теләге булса килер, кумабыз.

Марина, тагын әнисен бүлдереп, кыза-кыза тезеп китте:

— Алаймы? Кызыңа ныклабрак карале, әни кеше! Бөкрәя барган аркама да, җыерчыклы йөземә дә кара! Билем, кулбашларым, беләкләрем төннәр буе сызлап чыга. Юк, күз яшемне моңарчы берегезгә дә күрсәтмәдем. Өч елга якын юеш, караңгы штрекләрдә күмер төяү бер

эзсез генә үзмый икән ул! Ә сез, хуҗалар, бу кыз таза, көче җитәр диеп, мин шундый забойларга теләп барсам, куана идегез. Ә мин, юләр, үземне яклап авыз ачарга да котым очып йөрдем...

Зоя кинәт урыныннан торды, яңадан утырды.

Кызы әйткәннәрне белә Зоя, нишләмәк кирәк? Аның шикелле сөрән салып кычкырыргамы? Шахтага күрә һәм белә торып кердек. Менә кайда хикмәт һәм безнең өстенлек! Шулай да Марина хаклы бераз. Тик, нигә үзеңне кызгандырып торырга?

— Сугыш вакытында бөкрәеп-саргаеп харап булган бу карчык дип, мине хәтта Прошка агай да хатынлыкка алмас. Ә... ә? Дәшмисеңме? Ошамыймы?

— Кызым, бөтенесен дә йөрәгеңә авыр аласың. Тынычлан бераз, аннан сөйләшербез.

Ана кызын ничек итеп юатырга да белмәде, сатулашып та файда юк иде.

— Ә Оксана белән бер дә болай тарткалашмадың. Тоттың да ризалык бирдең...

— Кызым, кеше бәхетенә кеше керми. Сугыш кына бетсен, ял йортына, курортка барып кайтырсың. Бер дә көяләнмә, сеңелеңнән һич ким җирең юк. Ирсез калмассың.

Ана, шулай дисә дә, баласын юата алмаганын белә. Андрей турында «алырга бар» дип тә, «кирәкми» дип тә әйтми. Күңеле ятмый аның бу егеткә. Тик... аяк тибеп, бугаз киереп кенә егет белән кыз арасын аера торган түгел шул.

Тагын ике көннән соң Марина, Оксананың туен да көтәргә теләмичә, Андрей янына ерак юлга чыгып китте.

*

* *

Туйга ике генә көн калып бара.

Сивакта «Күгәрчен оясы» дигән штрек бар. Күмер катламының иң югары башыннан барганга күрә кызык итеп аны шулай дип атыйлар. Моннан җир өстенә чаклы егерме-утыз метр чамасы гына кала. Көчле вентилятор шахтаның барлык забойларыннан исле һаваны, газны һәм төтенне шушы «Күгәрчен оясы» аша көн-төн туктаусыз суыртып тора.

Менә айга якын инде Хәмзә белән Наприенко шушы «Күгәрчен оясын»да эшли. Бүген алар ике тапкыр шартлатырга йөкләмә алдылар. Җәй көне яшьләр бу штреккә шахта аша йөрмичә, тау итәге буйлап, кыя-ташларга, карагайларга тотына-тотына, турыдан гына үрмәлиләр. Хәмзә, нарядныйдан чыккач, тау башына үрмәләп менеп китте. Анда, лампасын кабызып түшенә асты да, вагонетканы этеп, караңгыга кереп чумды. Забойга кадәр ярты чакрым бардыр, буш килеш шактый үр менәсе.

Пөкләмә зур булгангамы, әллә йөрәге ашкынгангамы, бүген кешедән алданрак керде ул забойга. Хәер, җил уйнап торган бу забойга шартлатканнан соң ук та кереп күмер төйи башларга була. Менә вагонетка күмер өеменә килеп терәлде. Мул өелгән, Прошка агай аммоналын да, төйгечләрен дә кызганмаган.

Әх, тын алулары тыштагы белән бер диярсең. Ныклап басыбрак кимәсәң, башыңдагы бүрегеңне очыртып шурф аша җир өстенә алып менеп китәрлек. Шулай да, бер яхшының бер яманы да була икән. Җир өстенә артык якын булганлыктан, күмер стенасы буйлап сузылган бармак яссылыгы ярыклардан сары буяу сыман балчык сыекчасы агып тора, болай да комлы, вак ташлы күмернең сыйфатын түбәнәйтә. Шуңа күрә бу күмер тимер юл вагоннарына төяп озатырга яраксыз, аны тау

итэгенэ чыгарып түгэлэр дэ шуннан атлар белэн Ургылның үз кирэк-яракларына ташыйлар.

Хэмзэ бередэ Наприенко белэн йөзлэгэн метр проходка бирде инде. Шурфчылар забойдан ун-унбиш метр чамасы ераклыкта гына яңа шурф казып куйдылар. Бергэлэп тырышып эшлэмэсэлэр, бу шурф булмый иде бит. Тиздэн тагын яңа шурф казу өчен чыбыркылыйлар бу штрекне. Болай барса, шахтада саф һавага кытлык бетэчэк диган сүз.

Бөтен штрек буйлап тышка кадэр рельслар сузылып киткэн. Йөк белэн гел үр төшэсе. Вагонетканы бушату ансат: артык көчэнмичэ генэ эрҗэне бер якка янтайтасың да, бөтен күмер тау астына тэгэрэп төшеп бетэ. Көн саен Хэмзэ тышка вагонетканы ялгызы йөртэ, Наприенконың аяклары сызлый, бөгелеп йөрергэ биле чыдамый. Беренче көннэрдэ озын, каткан гэүдэсен бөгэ алмыйча, тэбэнэк җирлэрдэ бэрелеп, башын тишеп бетерде, бер чыгып керүдэ эллэ тагын ун тапкыр егылгандыр. Шундый чакларда булса да бер сукранып алсын иде ичмасам, юк, тының да ишеттерми, мышный-мышный селкенеп йөрүен белэ.

Тыныч бу штректэ. Көн буенча ник кенэ бер җан иясе күренсен. Смена башында һэм смена бетэрэк десятник килеп киткэли дэ, агач ташучылар шурф аша терэүлеклэр төшерэ.

Хэмзэ күмер төйи, Наприенко терэүлеклэр алып калырга ашыга. Вагонеткасын тутыргач, Хэмзэ лампасын түшенэ асты да этеп китте. Вагонетка җиңел тэгэри. Кияү-балакай җырлап ук җибэрде.

Шахтер егет күмер чаба,
Кемнэр ала исэбен.
Гомерем булса, таш басмаса,
Ташламам, җанкисэгем.

Күңеле дэ җырлый аның бүген. Өйлэнэ бит, башлы-күзле була, яраткан кызын ала. Хэзергэ Оксанасы белэн Хэертдин абыйсының өендэ яшэп торачаклар, тора-бара үзлэре дэ йорт салып чыгарлар. Туйда этисе белэн энисе дэ булса иде. Аралары бик ерак шул. Әйдэ, сугыш беткэч, тагын бер туй ясарлар. Барысы җыйнаулашып.

Күңел көр булганда, эш дигэне дэ берни түгел икэн. Вагонетканың тэгэрмэчлэре җырлый, рельслар зыңлый сыман, Хэмзэ дэ җырлый. Э Наприенко, җырның сүзлэрен аңламаса да, елмая-елмая колак сала.

Менэ Хэертдин абыйсы да кияү балакайның хэлен белергэ килеп җиткэн. Наприенко белэн икэүлэп, түшэмгэ, терэүлэргэ бармаклары белэн төртэ-төртэ нидер сөйлэшэлэр. Хэмзэ аларны тыңлап тормады, күмер төяп чыгаруын белде. Өйлэнеп кергэндэ Хэертдин абзыйсы юк иде инде, э Наприенко күмер алынып беткэн урында терэүлэр кую белэн мэшгуль иде. Бераздан ул да көрэген тотып төяргэ кереште. Ул үзенчэ төйи, көрэген ашыкмыйча гына шудыра, чүмэкэй итеп тутыра да, бөртеген дэ чэчмичэ, вагонеткага сала. Э Хэмзэ көрэкнең тулу-тулмавын тикшереп тормый, кулы кулга йокмыйча, тиз-тиз төйи.

— Карале, йолкыш, болай эшлэсэк, икенче тапкыр шартлатучыны алданрак чакыртырга туры килмэсен,—диде Наприенко. Тавышы Хэмзэ моңарчы һич ишетмэгэнчэ, ягымлы яңгырый иде аның.

Аяк аслары юеш лай, аяклар тая, өем астындагы җирлек кантарлы, бүселеп чыгып торган ташларга көрэк килеп төртелэ дэ керми азаплый. Маңгайдан тир ага, биткэ, муенга түшэмнэн тамчы тама, ком коелып куя, вак таш төшкэли. Йодрык кадэрле таш кисэге лайга килеп төште дэ ыргагы белэн терэүгэ кадап куелган лампа пыяласына пычрак сылады, тирэ-як караңгыланып калды. Наприенко забойга күз салды, колагын шул якка борып, бик озак тыңлап торды, аннары көрэген ташлады да забойга таба юнэлде. Ни булды аңа бүген? Корт чаккан кебек кылана. Шахта шахта инде ул, шытырдамый-чатырдамый тормый.

Ярты йөкләмә үтәлде, тамак ялгап алырга да ярый. Коры җиргә утырып әбәт ашарга керештеләр. Оксанасы бигрәк мул салып җибәргән бүген ризыкны, әллә Зоя әбисеме? Чәе дә, бәрәңгесе дә бар. Әнә, тамчылар тама. Өй түбәсеннән тамган язгы тамчыларга охшап тып-тып итә. Шул тып-тыплар арасында шап-шоп иттереп таш, балчык кисәкләре төшкәли, болай да колакларын үтә торгызган Наприенконы бөтенләй тынычсызлый. Ул инде тамактан калды: ризыгын сумкасына тыкты да балтасын тотып забойга атлады. Шахтада болай гына була инде ул, күнегергә вакыт. Шарт-шорт итеп терәүләр сынганга да исләре китми, янәшә узып йөри бирәсең, эшеңне беләсең.

Бер-бер артлы яңадан берничә вагонетка төяп чыгарып түктеләр. Забой түрендә калган берничә вагонеткалык күмерне Наприенко якынрак иттереп ыргытып ук бетерде. Төяргә уңайлырак булсынгамы? Әллә берәр хәвеф-хәтәр сизеп, хәзер үк ныгыта башларгамы исәбе? Әле вакыт шактый бар кебек. Ныгытырга да, бораулап шартлатырга да өлгерәчәкләр.

Бу юлы вагонетканы майлап алырга кирәк, юкса тәгәрмәчләр бигрәк иләмсез шыгырдый.

Менә Хәмзә яңадан тышта, тау башында. Эстакада, йортлар, кешеләр — барысы да аста, кеп-кечкенә булып күренәләр.

Эх, рәхәт тә соң якты дөньяда! Тау итәкләрендә карагайлар шаулый, тирә-як ямь-яшел. Һавасы да һавасы! Күкрәкләрне тутырып сулыйсың, барыбер иснәп туймыйсың. Карагайлар, карагайлар! Кош ояларыннан, кошлар моңыннан мәхрүм шул сез. Ярый, килерләр әле монда да, килми калмаслар, ерак-ерак җирләрдән без дә килдек ич...

Вагонетка да майланды. Ләкин карап торсынчы тагын берничә генә минут! Әнә бит, бик тә матур булып, бормаланып-бормаланып Ургыл елгасы ага. Әнә, кычкырта-кычкырта пассажир поезды китеп барды. Сугыш беткәч, алар да хатыны белән шул поездга утырып авылга кайтырлар. Әнә Ургыл елгасы буенда Оксаналарның өйләре... Хәертдин абыйларыныкы да...

«Сау бул, якты кояш! Сау бул, Ургыл тау башы! Карагайлар, сезнең җылы кочагыгызда ятып торулары бик рәхәт тә бит, тик минем эшем бетмәгән шул әле».

Әнә бик ерактан, баш штректән, вагонеткалар дөбердәтеп электровоз килгәне ишетелә. Ара-тирә, тальян моңнары чыгарып, узган-барганга сигнал звоногы белән сәлам бирә торган гадәте бар Оксананың. Бигрәк тә йөрәккә үтеп керә шул тавыш.

Йөрәк дәртен кая куярга белмәгән чакта, вагонетка да бик җиңел, тиз тула икән, забой белән тыш арасы да якынайган кебек. Менә яңа шурфны да узды, тиздән забой. Чү! Забойга ук килеп җитмәде ич әле, нигә вагонетка килеп терәлде?!

Хәмзә түшеннән лампасын алып, баш очына күтәрде... Бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Вагонетка алдында аркылы-торкылы сынган терәүләр, олы ташлар өелгән иде.

— Наприенко агай!! — дип аваз салды. Забой түрендәниләр булганын вагонетка өстеннән күрә алмый иде ул. Ләкин нидер булганын сизенә. Яман нәрсә авария, завал. Әле дә шартлап терәүләр сынган тавыш ишетелә, шап-шоп таш коела. Коточкыч хәл ич бу!.. Кайда Наприенко агай?! Әйе, Наприенко агай шул богырдап кайнаган казан эчендә булыр. Әнә! Әнә ич ул! Уты җемелди. Исән, бик исән.

Хәмзә стена белән вагонетка читенә тулган вак ташларны актараактара эчкә үтә башлады.

— Терәүлекләр! — Терәүлекләр китер тизрәк! Күбрәк! — дип кычкырды Наприенко.

Шурф янында бер олау терәүлек. Хәмзә вагонетка өстеннән шуларны шудырды да яңадан эчкә үтәргә тотынды. Элгәре бик ансат кына үтеп йөри иде, ә хәзер сыярлык түгел.

— Кемгә әйтәләр?! Кермә монда! Якты дөньядан туймагансыңдыр ич! Кач бу җәһәннәмнән!..

Хәмзә бар көченә вагонетканы артка тарта башлады. Юк, бер генә карыш та кузгалмый. Келт итеп башына: «Минем урында Якуп булса нишләр иде? Әтием нишләр иде? — дигән уй килде. Наприенко абзый да ташлап кача алмас идемени бу җәһәннәмне? Әнә, ул завалны шурфка уздырып җибәрмәскә азаплана...»

Хәмзә, кысыла-кысыла, вагонетка читеннән забой ягына керде. Забой танырлык түгел иде. Аяк астында олы таш кисәкләре ишәйгән, баш очында урталай сынган өрлекләр дә бар, терәүләрнең кайберләре баш-башларыннан пумала шикелле булып чәрдәкләнеп беткән. Юк, мондый хәлне күргәне юк иде әле Хәмзәнең. Шушы үзе микәнни «забой уйнаклау» дигән тамаша?! Мондый уйнаклауны тыеп кала алмасаң, берничә сәгать эчендә айлар буе эшләгәнеңне күмеп калдырачак... Бу хакта карт шахтерлардан ишеткәне бар.. Нишләргә?

Хәмзә Наприенкога ярдәмгә ташланды, терәүләр куярга кереште.

— Таш капчыкта каласың киләмени? Йолкыш! Тай тизрәк! Кемгә әйтәләр?!.

Ләкин Хәмзә аны тыңламады.

Икәүләп манма тиргә баттылар. Утлары гына сүнә күрмәсен.

— Ярдәм итегез! Завал... Авария...

Ләкин аларны беркем дә ишетмәде. Алар авызын бәйләп куйган капчыкта кебек иделәр. Шахтага кергәнче чыгар юлыңны кара дип, борынгы шахтерлар юкка гына әйтеп калдырмаган.

Хәзер бөтен өмет завалны вагонетка тирәсендә туктату. Күзләрне әчеттергән ачы тир тамчыларын сөртеп алырга да вакытлары юк. Наприенко өрлекне баш очында тотып тора, Хәмзә өрлек башына терәүләр кагып кертә. Чытырдаулар бераз кимегән кебек, әллә шулай тоела гынамы? Чү! Монысы нәрсә?! Забойдан читтә чытырдый, өрләкләр урталай сына. Наприенко агай! Тизрәк!

Хәмзә кулындагы терәүне шул якка өстери, нибары ике-өч кенә адым. Ник килми Наприенко? Күренми. Кайда ул? Әнә! Бер стена сынык өрләкләр белән капланган. Әллә...

— Наприенко агай! Наприенко!.. — Хәмзә кулындагы терәүне ташлады да өстенә коелган ком-таш, шарт-шорт сынып торган терәүләр янына ташланды, аннан вагонетка янына килде, Наприенконы тапмады. Менә кайчан ул үзенең чын фаҗигасен аңлап алды. Ялгызы калган. Иң яманы, иң коты очканы ялгыз калу иде аның. Штрекне саклап кала алса, кайчан да бер казып тере килеш табарлар. Әгәр завалны шушында туктата алмаса...

— Наприенко агай!.. — дип тагын кычкырып карады ул, тавыштын ишетелмәде. Актык көчен җыеп, терәүлекләргә ябышты. Башына бер уй килде аның: вагонетка янынннан бер адым гына калдырып, баганадан стена корырга. Коткарса шул гына коткарып калачак. Кызурак!.. Тизрәк кыймылда!.. Менә бер багана утыртылды. Икәү, өчәү... Тагын, тагын. Бүтәннәргә терәүлекләр юк. Бетте. Баганалар артында өскә ишелми әлегә. Теге яктагы, тере килеш җаныңны качырырдай тавышлар бу якта ишетелсә дә, ул кадәр өркетми. Ул якта өермә. Эх, Наприенко да шушында булса! Әгәр дә завал моннан узса, шурфка биш-алты гына адым. Бар да бетә. Шахта һавасыз кала. Наприенко агайны тапса яңадан берәр әмәле чыгар иде дә... Кайда соң ул? Аны таш астында калдырып, үзе исән чыкса, шахтерлар ни диярләр? Якуп, Оксана нәрсә уйларлар?

Хәмзә өрмәле якка шуышып чыкты да забойга таба юнәлде. Монда завал һаман котыра, тынычлану сизелми. Менә сыңар галош. Наприенконыкы. Әйе, аныкы.

— Наприенко агай! Кайда син?

Наприенконың тераү куеп ятканда башына таш төшеп егылганын күрми калган иде шул ул, бу вакытта тераүлеккә дип иелгән иде. Наприенко нәкъ стена буендагы сынык өрлекләр артына туры килде, урыны иркен булып, өстенә таш-мазар төшмәсә дә, аңын югалтты. Бераздан һушына килгәч, пышылдарга кереште:

— Ибраев!.. Ибраев!.. — Ул кеше ярдәменнән башка чыгарлык җирдә түгел иде, кыймылдый да алмыйча ята бирде.

Хәмзә Наприенконы ишетә алмады. Дөм-караңгы. Аяк асты тулы аркылы-торкылы тераүләр, ташлар. Вагонетка тирәсен чамаларга, лампаны кабызырга... куллар кесәдәге шырпыны кармалый, сызарлык түгел: суга салып торгызгандай юеш. Нишләргә?.. Шуыша-шуыша, кармалый-кармалый кайсы яккадыр мүкәләде. Үзе утырткан баганалар стенасы шушы якта булыр кебек. Шулчак башына шактый зур таш килеп төште, Хәмзә артына ауды, аягына тагын нидер китереп бәрде, кыймылдатмый да. Юк, ничек тә кыймылда, тор, үрмәлә, мүкәлә, куыш ягын чамала, кер шунда...

Бөтен көченә тезләнмәкче итте, булдыра алмады, аны төрле яктан кысып алган иде. Шулай да әле куллары буш, кыймылдыйлар да. Тик тын алуы кыенлаша, өстәге таш күкрәкне кыса, әллә кайсы төшләре өздереп авырта. Иреннәре пышылдый:

— Коткарыгыз!..

Юк, бирешмәскә! Һушы бар ич әле аның. Бармаклары белән казынып, тирә-ягындагы балчыкны учлап алды да читкәрәк атты, учлап алды да читкә атты.

Күз алдына Оксана килеп баса. Бүген кияү гомер эшләмәгәнне эшләмәкче иде, ике тапкыр шартлатып, ике көнгә тиешле проходканы бирү иде исәбе. Ике көннән туй. Менә ничек күңелле, матур була икән ул туй дигән нәрсә! Бөтен кеше бәхетле кебек...

Уянып киткәндәй булды. Аякларының авыртуына түзәрлек хәле юк, куллар әле селкенә... Яңадан казынырга тотынды. «Ничек тә туйга чыгарга моннан! Чыгарга!..»

Инде бу чакта, «Күгәрчен оясы»н бетереп, аларны эзлиләр иде. Забойщиклар, ныгытучылар, тау-коткару командасы белән берлектә башта вагонетканы казып чыгардылар һәм Хәмзә корып куйган баганалар стенасы каршына килеп керделәр.

— Наприенко! Ибраев!..

Икесе дә исән иделәр әле.

Икесен дә ашыгыч ярдәм носилкасына яткырдылар, врачлар үз эшләренә тотынды. Оксана, күз яшьләренә буылып, Хәмзәнең күкрәгенә капланды. Хәертдин бугазына төер булып утырган күз яшьләрен йота алмыйча катып калды. Наприенконың якыннары сырып алды. Хәмзәнең иреннәре селкенә башлады, хәтта бераз елмайган да кебек тоелды.

Бу аның соңгы тапкыр күзләрен ачуы булды.

Наприенко, носилкада килеш бераз күтәрелеп, Хәмзәгә таба иелгәндәй итте:

— Эх, әҗәл, әҗәл! Нигә минем якадан тотмыйча, аныкына үрелдең?..

Наприенко үксеп елый иде.

## УНДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

Ага да ага Ургыл. Ургылып-ургылып ага.

Ургыл ага, ә Якупның аягын күтәреп бер генә адым да атлыйсы килми.

Бүген Хәертдин Хәмзәнең кырыгын үткәрде. Табын ярыйсы мулдан иде. Туйга дип әзерләнгән эчемлек һаман бетми...

Якупны иң гаҗәпкә калдырганы шул булды: башка вакытта авызыннан бер кәлимә сүз тартып ала алмаслык Наприенко бу юлы бөтен мәҗлесне авызына каратты.

Ә Хәмзәнең исемен бер генә тапкыр да телгә алмады.

Рәхмәт, картлач, Якупның җәрәхәтле йөрәген авырттырмас өчен шулай кирәген сизенгәнсеңдер син.

— Яша, караңгы төшә бит инде. Кайтыйк.

Якуп сискәнеп китте. Әйләнеп караса, янында Оксана басып тора иде.

Якуп сүзсез генә зират ягына ымлады.

— Әйе, шуннан, — диде Оксана.

Күпмегәдер, тагын тынлык урнашты,

— Яша, мин билетлар алдым. Икебезгә дә. Иртән сәгать сигездән юлга.

— Нинди юлга?

— Әбәү! Конференциягә. Әллә оныттыңмы?

Ах, әйе. Аларның икесен, Оксана белән Якупны, комсомолның өлкә конференциясенә делегат итеп сайлаганнар иде бит. Ни арада китәргә вакыт та житкән...



*

* *

Өлкә үзәгендә поездан төшкәч, Якуп белән Оксана бергә атлап киттеләр. Киң генә олы урам.

Кунак йортына урнашып беткәч, алар шәһәр карарга чыктылар. Монда үзеңне читлектән котылган кош кебек хис итәсең икән. Өч-дүрт катлы агач йортлар да галәмәт биек тоела. Ындыр табагыдай тап-такыр киң урамнар, кунак йортында олылап каршы алулар дисеңме, — һәммәсе дә яңа, ят нәрсә. Урамнарда вак алмагачлар, юкә, кәрлә карамалар үсә. Драма театры каршындагы зур мәйдан тулы аллы-гөлле бакча чәчәкләре үсеп утыра. Оксана шуларга сокланып туя алмый.

— Үзебезнең Ургылда да гөлбакча ясарга кирәк, Яша.

— Бездәге салкында чәчәк үсү түгел, баһадир карагайлар да шартлап ярыла.

— Бәлки арада салкынга түземлеләре дә бардыр. Әйдә, вакыт барында белешик!

Шәһәрне яшелләндерү бүлегендә күңелне юатырлык әллә ни әйтмәделәр, «андый сортлар белән шөгыльләнәбез, тик хәзергә биреп җибәрерлек чәчәкләребез юк әле»,— диделәр.

Аннан чыккач, Оксана Якупны култыклап алды.

— Чәчәк үстерергә бездә кемне табарбыз икән соң? — диде Якуп. Мондый эреләрне, йодрык хәтлеләрне күргәне юк иде әле аның.

— Беләсеңме, кем? Минем әни. Донбасста чакта өй каршында гөлбакча үстергән иде.

Егет аңа мөлаем гына елмаеп карады.

— Гөлләрнең тиңдәшсезләрен Зоя Ивановна Донбасста гына түгел, Ургылда да үстереп җиткергән.

Оксана бармак янады да башын аска иде. Шулай атлый торгач, базарга килеп җиттеләр. Бик озын өстәлләр рәт-рәт тезелеп киткән. Коймa буенда капчыклап әллә нәрсәләр өелгән. Ниләр генә юк базарда! Уч төбе хәтле генә бәрәңге котлеты дисеңме, өстеннән пар бөркелгән, ярып пешергән бәрәңгенең үзен телисеңме, кабыклысынмы,— барысы да бар. Олы гына бер хатын әчегән сөткә хәтле сатып утыра. Чеметемләп тәмәке дә сатыла. Көнбагыш сатучылар да күренгәли. Шуларның берсеннән

Якуп бәясен сорады. Стаканы егерме биш сум яки ярты кило иллы хакы тора иде бер стакан көнбагыш. Ә Ургылда илле сум. Аның караву, мүк жиләге бер сум, ә монда биш. Тозлы кыяр, тозлы кәбестә сатучылар да: «Биш сум, биш сум», дип кычкырып торалар. Якуп икесенә дә берәр стакан көнбагыш сатып алды, аннары берәр стакан әчегән сөт тәкъдим итте. Оксана тозлы кыяр ашыйсы килүен әйтте. Аны да алдылар. Алай да күңелләре булып җитмәде.

— Әйдә, Яша, туйганчы бәрәңге ашап кайтабыз!

Яшел чирәм өстенә утырып берәр тәлинкә бәрәңгене дә ялт иттерделәр. Бәйрәм шикелле тоела аларга бүген. Әллә ят җирдә йөргәнлектән, әллә бүтән сәбәптән, монысын үзләре дә белмиләр. Якуп сиздерми генә Оксанага күз төшергәләп ала. Өстендә зәңгәрсу ситсы күлмәк, алсу кофта, башында карага ак юллар төшкән йон башлык, чәчен муенына тикле генә калдырып кистергән. Аякларында тәбәнәк үкчәле ак туфли. Бөтен киеме бик ятышлы. Ә күзләре тулы моңлы сагыш. Адымнары да элекке шикелле уйнаклап тормый, салмак кына, әкрен генә атлый.

— Исеңдәме, өченче ел клуб әйләнәли йөргәндә мин сиңа ни дигән идем? — Якуп матур гына итеп карап алды.

— Кирәкми, Яша! Иптәш булып каласың килсә, андый уйлар белән башыңны катырма, яме. Миңа сезнең дус булып калуыгыз бик кадерле. Янәшәмдә иптәшләр күп булганга куанып яшим. — Оксана алкалар, йөзекләр, тагын шундый әллә нәрсәләр сатылган төшкә юнәлде, бик озак нидер сайлап азапланды. Ә Якуп кызыл мал өстәлендәге ситсымазарны караштыра торды: күлмәк-чалбары былтыр ук сусәргән иде, шуларны бөтенәйтмәкче. Андый әйберләрне урта яшьләрдәге, таза гәүдәле бер ир кеше сата. Өстендә яшел гимнастерка, аякларында кирза итек, бер кулында кәкре башлы таягы бар.

— Метры күпме? — дип, Якуп күңеленә ошаган юллы-юллы ситсыны күрсәтте. Янәшә генә ак батист та ята, анысы хатын-кызларга әйбәт. Сатучы бәяне әйтте.

— Нигә бик кыйммәт? Бу бит забойщикның айлык хезмәт хакы.

Сатучы хәйләкәр генә карап тора иде, күзләрен кысып, йомшак кына итеп әйтте:

— Теләсәң — алдың, теләмәсәң — артың! Көчләүче юк. — Әйберләрен өстәлгә әйбәтләбрәк җәйгәләде, үзе пышылдап кына:

— Мондый алма кебек гүзәл хакына айлыгын түгел, еллыгын да җәлләмәссең! — дип кеткелдәгән булды.

— Сез бит боларны миннән сораган хакка алмагансыз!

— Анысы безнең эш, энекәш! — диде, әкрен генә кеткелдәп. Аннары бераз катырак итеп: — Ә син, тыл күсесе, яхшы чакта таеп кал! Фронтовик нервысында уйнарга телисеңме?! — дип җикеренде, үзе тирә-якка каранды, игътибар итүче күренмәгәч, тагын гайрәтләнде: — Бар, бар, юлыңда бул!

Оксана Якупның җиңеннән тартты.

— Яша, ташла әле шуны! Әйдә, китик! — диде. Якупның җиңелеп китәсе килми иде. Йөзгә бәреп әйткән пычрак сүзләре егетнең йөрәгенә барып кадалды. Моңарчы аның беркемнән дә «тыл күсесе» дип ишеткәне юк иде әле. Шахтер җир астында йөрсә дә, күсе түгел, кеше хакына тими. Бәлки Ургылныкылар кайбер фронтовиклар да күрмәгәнне кичерә торганнардыр. Әгәр сугышка алсалар, бүген үк китәргә риза. Үзен фронтка җибәрмәгәнгә шахтер гаепләмени?..

— Анда, фронтта, без кан койганда, сез монда безнең солдаткалар белән типтереп ятасыз! Һәммәгезне «ура» кычкыртып атакага ташлатасы... — Сатучы таягын болгый-болгый җикеренде. Чибәр генә бер хатын шыпырт кына килеп төртмәсә, телен тыярга исәбе юк иде, ахры

— Миша, алдың-артыңны карап болган! Яшьләр бит әле, ни аңлыйлар? — диде хатын.

— Син, Настя, кысылма! — дип хатынны тыйды сатучы. Аннары усал гына көлеп дәвам итте: — Нигә, дөрес әйтмиммени?

— Кабахәт! — дип кычкырып җибәргәнен Оксана үзе дә сизми калды.

Моңарчы тешен кысып түзгән иде Якуп. Хәзер чыдар чамасы калмады.

— Әй, син! Спекулянт! Шахтер синең кебек кизәнеп кенә калмас, келтәнсә, берәгәйле кундырыр, күзеңнән утлар чәчрәтер!

— Ә сез уйнап әйткәнне аңламыйсыз икән. Сынап карар өчен генә сүз кузгаткан идем бит, — дигән булды сатучы. Ситсыларын күрсәтте.— Кайсын аласыз? Бәясен килешербез.

— Рәхмәт, абый! Белеп тор: шахтерга тел тидергән кеше мең пот сабын белән дә гөнаһсын юып бетерә алмас. Җир шарын уч төбе белән кулбашында тотып тора шахтер. Аның җилкәсенә таулар таяна, — диде Оксана.

Кәкре таяклы нидер мыгырданды. Әлеге чибәр хатын, башын иеп, тиз-тиз әйберләрен капчыкка тутыра башлады. Оксана белән Якуп, җитәкләшеп, үз юллары белән киттеләр.

Оксана да, Настя да бер-берсен танымаганга салышты.

Ә яшел гимнастерка киеп алган бу кәкре таяклы кешенең үсмер чакта ук печәнлеккә күкәй урларга менгән җиреннән егылып төшеп аягын имгәткән, шунлыктан хәрби хезмәтнең нәрсә икәнен дә белмәгән бер зат икәнлеген бу якларда, ихтимал, берәү дә белмәгәндер.



## УНБИШЕНЧЕ БҮЛЕК

Ухановлардан кеше өзелеп тормый. Кайсы мүк җиләге, кайсы бәбәй чүпрәк-чапрагы китерә. Яшь ананы котлыйлар, Оксананың үзенә дә, бәбәенә дә сәламәтлек телиләр... Степанов беренчеләрдән булып килеп җиткән, куанып бетә алмый, туктаусыз сөйләнә:

— Җанкисәгем, кызым! — ди.— Әтиең, мәрхүм, Николай, хатын-кызларны забойда эшләтсәк, имгәнмәгәйләре дип курыккан иде. Тере бала табып, бөтенебезгә дә җан керттең. Рәхмәт! — Аннары бәбәй белән сөйләшкән була: — Син, улым, шәһәребезнең иптәш гражданины хәзер. Бабаең Николай, әтиең Хәмзә шикелле батыр бул! Төеп тутыргандай мул бәхет телим! Тизрәк терел, кызым. Җиңелрәк эшкә күчәргә теләмисеңме?

Оксана баш тартты, бераз электровозда эшләп карыйм әле, диде.

Менә ай буе инде эшкә йөри ул, сәламәтлеге ярыйсы шикелле. Өйгә кайткач улына карый да, ирен искә төшерә, сагыш өстенә юксыну килеп өстәлә. Яшьли, бик яшьли тол калды шул...

Шулай беркөнне өйдә ялгызы гына моңаеп утырганда, Хәертдин килеп керде.

— Кызым, гафу ит мине, озак килә алмый тордым, — диде ул.

Оксана үзе дә уңайсызланды, аның хәлен белергә бер генә тапкыр кереп чыкканы бар. Хәертдин бик озак больницада ятты, төсләре көзен агачыннан өзелеп төшәргә торган яфрак төсле сап-сары иде.

Дөньяның бөтен гүзәллеге Хәмзә белән бергә яшәү иде. Ул исән чакта: «Шахтер йөрәге чабыш аттай җилкенә башлады», дип сөенеп, шахтага эшкә ашкынып, аннан өенә ашыгып кайтыр иде. «Саф һаваның тәмен, якты дөньяның ямен җир астына төшеп карамыйча белә алмыйм мин», — дияр иде. Хәмзә вафат булгач, сынды сабыр канатлары, бөтенләй коелып төште янар чәчәк. «Кабереңдә тыныч йокла, яшь-яшь шахтер!» Ул һәлак булган «Күгәрчен оясы»н хәзер шахтерлар «Хәмзә штре-

ге» дип йөртәләр. Бу исемне район, шәһәр советлары да яки шахта житәкчеләре дә карар чыгарып кушмады, егетләр һәм кызлар яраткан иптәшләрен хөрмәтләп искә алыр өчен шулай атадылар. Наряд биргәндә, десятник яисә бригадир «бүген син «Хәмзә штреге»нә барырга» дип җибәрәләр.

Ана белән баланы күргәч, Хәмзәне дә күргән кебек булды Хәертдин. Оныкны кулына алыр иде дә куркрагенә кыса-кыса сөяр иде. Юк, ярамый: беләкләре калтырана. Чиреннән терелмәгәнгә түгел, ә ничәмә еллар бала тотып карамаганга.

Оксана өстәл әзерли, улы «үә-үә-үә» итә, тавыш бирә. Бабай бишек тирбәтә, иреннәрен очлатып, үпкәндәй итә, чөңгерә, йөзенең яктырып киткәнен үзе дә сизә. Эченнән генә нидер мыгырдый, тора-бара аермачык итеп көйли:

Әлли-бәлли итәр бу,
Үсеп буйга житәр бу
Үсеп белем алыр бу,
Илгә хезмәт итәр бу.

Оксана аңламый, бабайга карый да, елмаеп, җиңел кулдан үз эшен эшләвен белә. Ә Хәертдин бишектәге сабый белән серләшә: «Менә кем укыр минем шүрлек тулы китапларымны. Галим булыр оныгым, зур кеше, әйе бит? Әһә, көләсеңме бабаңнан, бөтенләй аңгыраеп беткән дисеңме? Ә син акыллы булып үсәрсең, шахтер булырсың. Бәхетеңнең чите китек булмас, балакай, сезнең заманнарда...»

— Әбәү, менла Хәертдин, нишләп үзеңә-үзең лыкылдыйсың?

Хәертдин сискәнеп китте: Фатыйма икән. Күз чите белән генә карап куйса да, сүз дәшмәде: хыялларыннан бүлдергәнгә үпкәләде, ахры. Хатын-кыз дигәне оста да соң! Менә бит: килеп тә кермәгән, иплэп кенә бәбәйне кулына алды да чут-чут үбә, сөйләнә башлады:

— Алла биргәне, сөбханалла, күз генә тимәсен, үсеп беткән ич малай!.. Карале, Хәертдин абзый, шахтерларны сугыштан монда, шахтага кайтаралар икән дип сөйләгәннәр иде. Нигәдер берсе дә күренми, әллә фронтта эшләр хөртигә киттеме безнең?

— Безнең анда эшләр ал да гөл, Фатыйма. Тиздән Донбасс үзебезнең кулга кайтачак. Сталинградта немчуранын арт сабагын укыттылар ич Маликлар. Киткән кошлар да әйләнеп кайта, Малигыбыз да...

Фатыйманың куанычы эченә сыймый, биеп кенә тора. Саубуллашканда кунакка чакырып чыгып та китте.

Караңгы төшеп килә. Аш табагы хәтле булып тулган ай тау башына менеп кунаклаган да шуннан Ургыл өстенә нурларын сибә. Тәрәзә аша Хәертдин узган-барганны күреп кала. Үзе һаман, тез башларына терсәкләрен кадаган килеш, ияген ике куллап учлаган да утыра да утыра. Ә бала изрәп йоклый, кисәк-кисәк көлгәндәй итә. Хәертдин үзенең кечтеки улын да, кабыктан бишек ясап, миләш сиртмәдә тирбәтеп утырган чакларын исенә төшерә. Ул чакта аның малае да, хатыны да, дәрт-дәрманы да бар, гел үз якларына кайтасы килеп кенә тора иде. Тау итәкләрендә чылтырап аккан улаклы чишмәләрне, авыл өстенә ишелеп үскән каен урманын, чәчәкле болыннарын, күрше-күләннәрен юксынды, сагынудан үзәкләре өзелә иде. Шул болыннарда печән чабасы, басуларда арыш камылларына басып тәпиләрен канатасы, җилкәсенә салып бодай капчыкларын ташырга теләде. Тик боларның берсе дә насыйп булмады.

Күңеле әле дә әрни: яшьли ахмак чакларда карт әбисенә явызлыклар эшләгәне бар, шуның каргышы төшмәде микән? Шаярып, кызык итеп, әбисенең тәһарәткә йөри торган җиз комганына кызыл борыч тутырды. Бермәл ахшам алдыннан тәһарәт алырга утырса, әбисе шырылдап кычкыра башлады. «Муеның астына килгере!» — дип, муен тамы-

рына комган борыны белән кундырып та алды. Юк, еламады малай, авызын ерып, әбисенең сукранганын карап тик торды. Берничә көннән шул җиз комганны баскыч төбеннән чәлдереп, тимер-томыр җыючыга бер пипрузга сатып җибәрде. Тимер-томырчы арбасын чүмәкәй тутырып урам буйлап узып барганда, әбисе олау өстендәге комганны танып алды да тавыш куптарды. Комганны бер дистә йомыркага кире алыштырып алырга туры килде әбисенә. Шулай, рамазан аенда әбисе бәләкәй Хәертдинен һәр кичне мәчеткә авыз ачар вакытны белергә җибәрә торган иде. Кояш баер-баемас борын ук йөгереп кайтыр иде дә, «мәчеттә авыз ачтылар», дип әбисен алдар иде. Карчыкның авыз ачканын кызык итеп карап торыр иде. Ә әбисе, җитмәсә, бер уч йөзем җимеше белән сыйлар иде. Шул гөнаһлар өчен әбисенең каргышы төшмәде микән...

«Әйдә, забойда тир түгеп юарбыз гөнаһларны. Күктән күңел күрлеге көтеп яту шахтер эше түгел».

Каткан буыннарын көч-хәл белән җыеп, ишек янына килде, саубуллашкан булып, оныгына ияк кагып тел шартлатты. Шул арада Зоя кайтып керде.

— Ыланнар! Туганнар! Безнекеләр Донбассны азат иткәннәр! — дип хәбәр салды ул.

Оксана белән икесе бик сөенештеләр алар.

Хәертдин дә йомшарды, күзләре дымланды: Горловка шахталары аның икенче туган йорты иде, икенче туган ягы, хәтта бүгенге көндә авылыннан да якынрак, кадерлерәк — анда аны кеше иттеләр ич. Ә Ургыл — өченче туган ягы. Саубуллашып чыгып китте. Урамда, клуб яныннанмы, җыр ишетелә иде:

Спят курганы темные,
Солнцем опаленные.
В забой отправился
Парень молодой...

Хәертдин дә күңеленнән кушылып җырлый. Сүзләрен бик яхшы белә ул, үлеп тә ярата. Шахтерлар турындагы «Зур тормыш» дигән киноны берничә тапкыр карады. Бу җыр да шул фильмнан. Артыннан бәбәй күтәргән килеш Оксана белән Зоя килеп җиттеләр. Икесе дә агарып киткәннәр, күзләре дымлы, әйтәсе сүзләрен әйтә алмыйча тотлыгып торалар. Көчкә генә аңлатып бирделәр. Әле генә Степанов хәбәр иткән икән. Маринаны шахтадан һушсыз килеш больницага алып киткәннәр.

— Ни булды икән?! — дип, Хәертдин дә, салмак адымнарын тизләтеп, алар артыннан больница ягына борылды.

*
* *

Зоя, кызын эшкә озаткач, оныгын сөяргә керәште.

— Сагындым баламны! Көнозын күрмәдем бит бәбчегемне! Марина апаң да больницада ята. Авыр күтәрмәсә, үзең шикелле кечтеки сеңелең булыр иде... — Зояның бугазына төер булып хәсрәт утыра, еларга итә, күзеннән яшь чыкмый. — Вакытында тыя алмадым, сырландай ябышты шул җан көегенә...

Култык таякларын шыгырдатып «җан көеге» үзе дә килеп керде. Баскан килеш тәмәке төреп кабызды. Бөтен хәрәкәте салмак, күз карашы моңсу, үкенүле.

— Өйалдында тартыр идең, кияү,— диде Зоя, ишек ягына ымлап.

Андрей, дәшми генә, калтыранган куллары белән хат сузды. Бераздан әйтеп куйды:

— Әнине кулга алганнар...

Хатны укып чыккач, Зоя, авыр сулап:

— Эх, Настя, Настя...— дия-дия киявенең борчулы йөзенә күз төшерде: элек тутырган тавык шикелле тулы иде, хәзер кипкән балыкка охшап калган. Тәмәке тартырга да өйрәнгән.— Язмыштан узмыш юк, әмма язмышыңны кулыңа ала белмәсәң, михнәтен дә китерә.

Шулай дип әйтүенә Зоя үкенеп тә куйды: нигә кешенең җәрәхәтенә тоз сибәргә иде!..

Андрей әбисен тыңламый: үз кайгысы бугаздан иде.

— Маринага да укыттым. Әнине барып күреп кайтырга куша.

— Ә аякларың? — дип борчылып сорады Зоя.— Аксак килеш ничек әллә кайларга китеп йөри аласың?!

— Анысына түзәрсең. Җан өзгәләнә, сулкылдап сызлый, Зоя Ивановна. Терсәк якын да якынын, тешләп булмый икән аны!..

Бик озак уйларына чумып утырдылар. Андрей мунча чормасында качып ятканнан бирле Настя сату итеп йөргән, эшен ташлаган. Ансат кына юл белән сугыш вакытын уздырып җибәрергә теләгән.

— Әй, әни, әни... — дип куйды Андрей. — Әти дә исән икән бит. Аның да хаты бар, кайтыгыз дип язган, Донбасска. Марина каршы килмәсә, ул терелүгә үк китәрбез дип тора идем. Тик ни күзем белән күренермен?! Әни турында нәрсә әйтермен?..

Зоя бернинди дә киңәш бирә алмый иде.

— Кияү, Марина больницадан чыкканчы үзебездә торып тормыйсыңмы? Тәрбия кирәк сиңа.

— Рәхмәт! Иртәгә Марина янына бара алмам, ахры. Бүген хәле бераз җиңеләйгән шикелле, сөйләшә дә. Әни янына китәрмен. Тик менә аңа әти турында нәрсә диярмен?..

— Настяга сәлам әйтерсең. Барыбыздан да, — дигәч, Зоя бишектәге балага иелде. — Улым, жизнәң Андрей шушы була инде.

Андрей бәбәйгә елмаеп карап алды да чыгып китте.

Әби яңадан оныгына сөйләнә башлады:

— Шахтер чыкмады жизнәңнән. Бәхетенең чите китек мескеннең. Син андый булмассың, балам. Бәхетле булырсың... Китәм яныңнан, китәм. Эш муеннан: доклад язасым бар.

Ул доклад язарга утыруга, ике баласын ияртеп Фатыйма килеп керде, теле-телгә йокмый, сөйләнә башлады:

— Зоя Ивановна, бәгырем, Малигымны каршыларга барабыз ич. Бөтен халык стансага җыелган, фронттан кайтучы шахтерларны каршы алалар. Менә, күз нурларым, өзелеп тә көтәләр, аталарын күрер көннәребез бар икән! Ярый әле, үзебезне саклый алдык, эштә дә махы бирмәдек, бирмәбез дә, иншалла! Син бармый torгансыңдыр?

Зоя бераз дәшми торды. Аңа барырга кирәк, тик каршылар кешесе юк. Колясы кайтмас инде. Барса, фронтовикларны каршыларга барыр, бер-ике сүз әйтергә. Ә Фатыйма бөтен затлы киемнәрен кигән, ислемай да ягынган, улларын да киендергән, бөтен килешләреннән шатлык ташып тора.

— Мин соңрак, Оксана кайткач. Поезд килеп җиткәнче житешермен. — диде Зоя.

Фатыйманы урамга хәтле озата чыкты. Әйе, урам тулы халык станциягә ашыга, кайсы әтисен, кайсы туганнарын каршы алырга бара. Бәлки, барсыныкы да кайтып кермәс, нибары йөз фронтовик кына кайта Ургылга. Ярдәмгә генә. Тора-бара бүтән исәннәре әйләнеп кайтыр... Зоя күзләрен сөртеп алды. «Николай кайтса, оныгын күреп туя алмас иде».

*
* *

Алеша ашханә башындагы бүлмә ишеге каршына килеп туктады. Кесәсендә вагонны төшкәч тә Фатыйма биргән шушы бүлмәнең ачкычы ята. Әмма ишекне ачып кирәргә кулы бармый, тагын бер адым якынрак атларга аягы тартмый. Урам тулы кызлар шаркылдаша, куанышып гөрләшә-серләшә, ирләре белән парлап хатыннар үтеп бара. Берсенә дә игътибар итми ул. Шахтага эшкә фронтовиклар кайту хөрмәтенә клубта тантаналы җыелыш уздырыла. Боларның берсе дә аның күңелен күтәрми: көлгән кызлар арасында Талигасының чылтырап аккан чишмәдәй тавышы ишетелми... «Эх, Танюша, җир астына кояш ташучы кыз, син дә, бүтән хатыннар шикелле, иреңне каршы алсаңчы!..» Менә хәзер дә ишекне киереп ачар да йөгереп чыгар, «Алешенькам!» диеп муенына асылынып кебек.

Үлгәннән соң терелде диярлек Алеша. Окопта танк күмеп киткәч, казып алдылар. Госпитальдә рәткә керттеләр аны. Әмма яман хәбәр Талигага тапшырылган иде инде...

Алеша калтыранган куллары белән ишекне ачмакчы булып азапланды. Яртышар тәүлек берәр потлы отбой чүкече күтәреп күмер чапканда да, фронтта да ару-талуны белмәгән куллары бүген калтырый. Ачып кергәндә, ишеккә тикле моңлы шыгырдады, гүя ул да апаларын юксынып елый иде. Бүлмәнең тәрәзәләре тышкы яктан такта белән кадакланган. Эчтә караңгы. Түшәмдәге электр лампочкасын әз генә боруга, бүлмә эче яктырып китте. Лампочка өстендә Танясының нәни куллары яшел ефәктән тегеп кигезгән абажур эленеп тора. Ишек кырыендагы чөйдә икесенең дә брезент киемнәре, каскалары, шунда ук Кузбасс истәлеге — шахта лампалары. Менә Таня тужуркасының куен кесәсендә ак яулыкка төрелгән кечтеки көзгесе, бөтен штрекләргә исен аңкытып йөргән бармак очы хәтле генә ислемай шешәсе һәм вазелин савыты. Алеша шул әйберләрне уч төбендә тотып күзләрен алмыйча карап торды. Фронтка озатканда, үзенә дә шушындый бәләкәй генә көзге биргән иде Талига: «Үз-үзеңне карап йөр, шамакай малай булма, бу көзгегә күз төшерүгә, мине дә күрерсең», — дип калган иде.

Киемнәр янында баш-башларын чачаклап ясаган, матурлап төрле-төрле җепләр белән чигеп бетергән озын-озын сөлгеләр, тастымаллар эленгән, өстәл өстендә юллы-юллы кызыл ашъяулык. Карават астында такта сандык. Хәтта ачкычы да йозак тишегендә килеш сакланган. Беренче тапкыр ул шушы сандык янында сөйгәнен кочып үпкән, шуның өстенә утыртып урам буйлап тартып өенә алып кайткан иде...

Алеша җайлап кына сандыкны ачты. Монда бөтен нәрсә гомергә онытылмаслык якты хатирә булып саклана.

Менә хатынының йорт эшләренә кия торган ярым түгәрәк итәкле ак алъяпкычы. Һич тә кер кундырмый торган иде ул моңа. Әле дә шул чиста килеш. Икесе дә үлеп яраткан, туйга дип атап тектергән зәңгәрсу күлмәге. Бик килешә иде бу күлмәк йөрәккә җылы ташучы хатынына. Танюшасы шушы күлмәген киеп штольня авызына ирен каршыларга бара иде. Менә аның Кузбасста төшкән карточкасы, ябык, агарып калган чагы. Әйе, бик озак больницада ятты ул, көчкә терелеп чыкты. Берьюлы унлап лампа күтәреп шахтерларга илткәндә аягы таеп егылган иде дә үле бала китергән иде. Шуннан соң балага да узмады. Моның өчен икәүләшеп бик борчылып йөрделәр. Курортка барып терелергә генә йөргәндә, сугыш чыкты...

Әйберләрне берәм-берәм ак җәймәгә төрә бара Алеша, ә күңеле һаман узган көннәргә әйләнеп кайта. Шушы минутларда чыркылдый-чыркылдый ишектән Танясы килеп керер кебек тоела. Сандык тулы әйбер аны хәтерләтә, аны юксындыра, үкереп елап җибәрәсе килә фронтовикның.

Сандык төбеннән Талиганың зурайтылган фотосы килеп чыкты. Бөтен йөзеннән елмаю, тормышка мәхәббәт, куаныч бөркелә. Ике толым кара чәчен күкрәгенә асылындырган. Кайсы гына якка Алеша борылмасын, хатын һаман аңа карап тора, гүя бүтән беркайчан да, беркая да үз яныннан җибәрергә теләми ирен. Алеша тын гына пышылдый: «Исән, исән бит син, Танюша, җаным! Ник дәшмисең? Сине сагынып кайттым ич мин, алдында Алешаң басып тора ич! Күрмисеңмени, кояшым?» — ди.

Иплән кенә төреп фотоны үз урынына салды. Юк, йөрәге түзмәде, яңадан алды да, бик озак күкрәгенә кысып торганнан соң, куенына тыкты. Нишләп аның ялгызын гына сандык төбендә яткырсын!

— Эх, каһәр суккан сугыш! Нишләттең син минем Танюшамны?! Нишләттең? Нишләп син мине көтмәдең, җир астына «кояш ташучы» кыз? Минем бу дөньяда синнән бүтән беркемем дә юк иде, тагын калмады. Шушы михнәткә юлыкканчы, нигә танк... — Алеша сабый бала шикелле үксеп җибәрде: күз яшьләре сандыктагы кызыл яулык өстенә тамды.

Бөтен нәрсәне үз урынына куйгач, яңадан бүлмә эчен күзәтеп чыкты. Сөеклесе белән гомер итә башлаган бу бүлмәне, аның куллары тигән әйберләрне калдырып китүе бик авыр иде аңа. Монда яшәргә калса да, җаны көн саен өзгәләнәчәк.

Әйберләрнең сыярдаен сандыкка тутыргач, калганын җәймәгә төреп төенчек ясагач, кайсын аркасына, кайсын кулына тотып, караңгы урамнар буенча Маликларга юл алды.

## УНАЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

Алеша ай буе шахта юлын таптый, тик әле һаман рухын тергезеп җибәрерлек очкын таба алмый. Сугыш ул шәһәрләр җимерелү, йортлар ишелү һәм корбаннар гына түгел икән, тереләрнең дә өметләре өзелү, бәгырьләре киселү дә икән. Таба алырмы ул, әллә мәңге таба алмасмы Танясына тиң мәхәббәтне?

Кайтып төшкәннән бирле «Чаланык» участогында машина белән күмер кистерә ул. Атна эчендә күмер катламын ныклап өйрәнгәч, бер сменада бөтен бер лаваны буеннан-буена тураклап узды. Моңарчы мондый нәтиҗәнең булганы юк иде әле.

Шул көннәрнең берендә, машинасының кистертү тешләрен алыштырып ятканда, янына Якуп килеп туктады. Алешаның Якупны машинистлар курсында да, конторда да, шахтада да күргәне бар, егет турында мактау сүзләре дә ишеткәләде. Тик явыз телләр әллә ниләр дә сөйли. Талига исеме белән дә авыз чайкыйлар...

Бик озак басып торды Якуп, ә Алеша кырын карап алды да эшен дәвам иттерде.

— Мин синең янга килгән идем.

— Беләм. Тераүләр янына түгелдер, билгеле.

— Үтенечем бар.

— Һе...

— Теләсәң, тик син генә ерып чыгасың.

— Ни кирәк тагы миннән? Чакырып китермәдем ич. Ишетмәсәң ишет — тирә-ягың ишек! — Шулай диде дә машинасын забойга таба бора башлады. Якупның һаман китәргә исәбе күренмәгәч, каты итеп сорады. — Ну, ни йомыш?

— Бу машинаны «Сивак»та сынап карарга кирәк.

Алеша иелгән җиреннән торып басты, маңгай чәчен каскасы астына кыстырды, битендәге тир тамчыларын җиңе белән сөртеп алды, анна-

ры, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, машинага бераз карап торды. «Фатыйма апа да шулай дигән иде бит, нишләп аның үтенечен кире кагарга? Бәлки шаулатып эшли башлар». Ә Якупка:

— Андагы гранит шикелле каты күмергә корыч тешләр түгел, алмаз да түзмәс, — диде.

— Башыбыз бүрек эләргә генә яраклымыни?

— Күмер катламы астында тешләр кырылып бетсә, яныл чыксалар? Ул чакта катлам чылбыр өстенә кала. Нәрсә белән алырсың?

— «Кәлтә»неке генә түгел, үзебезнең тешләр дә коелыр. Шуңарчы сынамабызмыни?

— Барып чыкмасын белә торып тамы?

— Эх, син! Куян йөрәк дип уйламаган идем.— Якуп шулай диде дә китә башлады.

— Әй, тукта! Минем йөрәккә тел тидерергә тозны аз ашагансың әле син.— Өскә ыргылган танклар каршында да каушап калмадым мин, — димәкче иде дә, тыйнаклык йөзеннән, әйтми калды.

Ә Якуп кызып-кызып тезә башлады.

— Кайчанга кадәр, «Сивак»ның күмере катылыгына сылтап, машина юлына киртә корырбыз? Түмгәкләр кәйләләп, уч төпләрен канга батырудан кайчан туктарбыз? Хәер, нигә сорап торам әле синнән. Үзең яшьләрне өйрәтеп яткан буласың тагы....

— Нидән тотынмакчы? Берәрсеннән рөхсәт алдыңмы?

— Синең машинага тимибез. Механически мастерскойдан ремонтлап беткәнен алабыз. Механиклары белән килештем. Эш беткән, котың очмасын. Ул-бу була калса, гаепне үз өстемә алам. Син башлап кына җибәр, өйрәт мине ныклап.

— Тарттыр «Сивак»ка шуны. Чылбырны яртылаш кына калдырып кистерсәк, уңайлырак, чыдамлырак булыр.

— Ятып калганчы, атып калабыз. Или грудь в крестах, или голова в кустах! Яртысын гына түгел, өчтән икесен кистереп ыргыт, тик хутка гына китсен. Картларда зирәк акыл булса, бездә сүнмәс дәрт бар, Алексей Иванович. Я гөл, я көл, агайне. Бир бишне!

Шул ук көнне күмер кистерү машинасын Оксана электровоз артына тагып «Сивак»ка тарттырып та куйды. Менә машина лавада. Тирәсе тулы кеше, барысының да күрәселәре килә. Хутка китәме, юкмы бу могҗиза? Степанов күптән корыч баулар, юан-юан терәүлекләр әзерләп куйган. Забойлар күмердән әрчелгән.

— Җиде тапкыр үлчә, бер кат кис, — диде Степанов. — Белегез аны, кечкенә генә хата да олысын тудырачак, машинага ышанычны киметәчәк. Бик кечтеки генә ялгышуны да җир асты кичерми. Ишеттегезме? — Шулай диде дә икенче лавага китеп барды. Алеша белән Якуп икәүләп план кордылар. Ахырда, машинаны лебедка ярдәмендә Хәмзә штрегенә хәтле өстерәтеп менгезергә дә өстән аска таба кистереп төшәргә, дигән нәтиҗә ясадылар. Машина, тигез һәм шома җирлек буйлап, аска таба җиңел шуышачак, монда катлам да шактый авыш.

Менә Алеша катлам астына чылбырның корыч тешләрен терәтеп куйды, рычакларны кыю гына боргалады. Машинаның бөтен гәүдәсе, үз көчен сынап карарга теләгәндәй, калтыранып алды да, чылбыр выжлатып әйләнергә тотынды.

— Кистерә! Билләһи, кистерә!

— Күрербез, кайда утырыр.

Корыч тешләр ике метр биеклегендәге күмер катламының аскы өлешеннән үк кимергәннән-кимерә бара, чылбыр беркеткече отыры эчкә үтеп керә. Гасырлар буе биек таулар астына яшеренеп яткан антрацит стенасы, кеше көченә һәм акылына бирешергә теләмичә, яман тавышлар чыгарып кытырдый, шытырдый. Машина артыннан чикләвек-

чикләвек, борчак-борчак кыйпылчыклар сибелә, тузан күтәрелә. «Кәлтә» һаман лава буйлап аска таба шуыша. Алеша машинаның кинәт-кинәт кирәкмәгән яман тавыш чыгарып улап алуын, кайчакта бик җиңел генә выжлап китүен тыңлап тора, борчылуы йөзенә чыккан, күңеле үз урынында түгел. Тешләр «түмгәк» дип атала торган граниттай каты урыннарга туры килә дә, мотор улый башлый, чылбыр бер урында әйләнеп тик тора. Аннан ычкынгач, яңадан выжларга керешә. Бу бик начар хәл. Чылбырның өзелүе яки тешләрнең янып чыгулары мөмкин. Туктатырга уйлый Алеша, тик кыю өмете генә туктатмаска куша. Нәкъ шул чакта, кистереп үтелгән кул яссылыгы ярыктан бер-бер артлы биш-алты теш атылып чыкты да зыңгылдап тирәүләргә килеп бәрелде. Кулга да алырлык түгел үзләрен, кызганнар, кәкрәеп һәм ашалып беткәннәр. Алары урынына тагын да кыскаракларын куеп карадылар. Машинаның моторы яңадан гүләргә керешә, тик элекке шикелле кинәт-кинәт котырмый, бер тизлектә җиңелчә генә әйләнә иде.

— Алексей Иванович, шикләнерлек җир юк. Бир әле, эшләтеп карыйм? — диде Якуп. Алеша башын чайкады: «Бирмим, чит кешегә тоттырырга кушылмый», янәсе. Якуп һаман ялына. Ахырда Алеша түзмәде, читкә тайпылып, машина белән идарә итүне Якупка тапшырды.

Менә Якуп масаеп як-ягына карана, күзләре әйтә: күрдегезме абзагызны, пыран туздырып күмер кистерә. Тик күңеле иләс-миләс: машина яңадан килбәтсез уларга һәм чытырдарга керешә. Юк, бу аның үз тавышы түгел, әллә ни булмагае тагы! «Нәрсә чытырдый икән бу хәтле?» Әллә инде катлам кистереп узган җиргә утыра башлаганмы? Ул чакта чылбыр күмер астында кысылып калачак...

Яшен тизлегендәге уй Якупка машинаны тизрәк туктатырга куша, һәм ирексездән бармаклары төймәгә баса. Тик соң инде: чылбыр ни алга, ни артка кыймылдамый. Машина хәзер Алешага да буйсынырга теләми.

«Аптыраган калтырар, — ди эченнән Якуп. — Үзебез ботка пешердек, савытын ничек ялап куярбыз?»

Шул чак баш штректән люковойлар: «Әхмәтҗановны телефонга чакыралар», — дип кычкырдылар.

«Кем булыр икән? Әллә эти шалтыратамы?» Юк, райкомолга килергә кушалар икән. Бүген үк. Мөмкин булса хәзер үк. Өлкә комитетыннан килгәннәр. Ни йомышлары төште икән өлкә комитеты кешеләренең? Әллә әтисе турында хәбәр килгәнме? Күптән үз хатына җавап көтә иде ич.

## УНҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

Степанов лавада бер ялгызы. Машинаның җылынган моторы өстенә утырып, десятник килгәнен көтә. Бик күп уралды ул машина тирәсендә, ничек итеп ватмыйча-җимермичә тешләр чылбырын катлам астыннан коткарырга план корды. «Гөрләп эшләргә тиеш машина, ничек тә яшьләр күңелен төшермәскә!»

Әнә, алпан-тилпән атлап, Хәертдин килә. «Әсир» тирәли хәзер икәүләп кайнашалар, тирәүгә сөялеп киңәшә башлыйлар, аннары кистергеч өстендә генә ике тишек бораулап ташлыйлар. Кистерелеп узылган җирне ныгытырга ныгытучылар килгәнен көтәләр. Лава буйлап югары үрмәләгән биш-алты ут җемелди. Менә алар якынаялар. Алдан балта һәм пычкысын култык астына кыстырып, Малик мәһабәт кенә атлый. Үзенә бер дистә ФЗО укучылары иярткән. Ул хәзер ФЗО мәктәбендә мастер булып эшли, «Сивак»ка малайларын өйрәтергә йөри.

Аларны күрүгә, Хәертдиннең йөзенә куаныч йөгерде.

— Шөкер, киләсез, Малик туган! Төкле аягыгыз белән.
— Вәгаләйкемәссәлам, Хәертдин абый! — дип, Малик ике куллап күреште.
— Рәхмәтләр яугыры! Шәп, бик шәп синең килүең, Малик Халикович. Көтеп тора идек, — дигәч, Степанов ныгытасы җирне күрсәтеп чыкты.

Егетләрнең кайсы агач ташый, икенчеләре үлчәп кисә. Лава быгырдап кайнап торган казанга охшап калды. Малик үзе бер малай белән терәүләр утырта. Аның һәр хәрәкәтендә осталык һәм төгәллек сизелә. Һәр адымы үлчәүле. Өйрәнчекләреннән дә шуны ук таләп итә, ахры: куллары эшкә ябышып тора.

«Шахта каһарманы бу Малик, — ди Хәертдин эченнән. — Уч төбендә гөлләр үстерер, иңбашында кошлар сайратыр кеше бит ул. Кыен эшкә кыю кул — теләсә, тау түнтәрер. Җир астында урман үстерә, терәүләр урманы. Иҗтиһат иткән — морадына җиткән!»

— Теге лавада хатын-кызларга күмер җитәсеме, белеп кенә килсәнә, Харитоша,— ди Степанов.— Анда җитмәсә, монда әзерләрбез җанкисәкләремә.

Баш штректән чыгып, беренче лавага менә башлауга, Хәертдин каршысына, төчкерә-төчкерә, ютәлли-ютәлли, Прошка атылып чыкты, аның артыннан бөдрә-бөдрә сасы төтен ыргылды. Ул инде бу лавада трах-бах итәргә дә өлгергән икән. Хәертдин «мич» буйлап тынны буып ала торган зәңгәр төтен эченә кереп чумды, күпме күмер шартлатылганын тикшермәкче. Прошка аның артыннан кычкырды:

— Харитоша, кире борыл! Тончыгып үлсәң, синең өчен мине Себер куачаклар. Кемгә әйтәләр! Десятник башың белән кагыйдә бозасың!.. Үзенең кыюлыгына үзе аптырады карт. Әллә нишләде ул соңгы көннәрдә. Йөрәге җилкенгәндәй итә, кирәк чакта тартыша да, үзенекен әйтергә дә коты очмый.

Беркавымнан, корык-карык ютәлләп, лавадан Хәертдин килеп чыкты.

— Прокопий Ильич, бу эш түгел. Нибары бер-ике уч күмер шартлаткансың. Потлаган шартлаткыч төтенгә очырылган. Күмер хатыннарга бирәр сәгатькә генә җитәрлек. Эшеңне кабул итмим. Риза булмасаң, начальникка зарлан!

Прошка колак артын кашып куйды.

— Башта яхшы аммонал, коры аммонал китерт, десятник, аннан соң мине гаепләрсең, белдеңме? Ә күмере җитмәгән тагы хатыннарга...
— Яраксыз аммонал белән шахтага кереп тә йөрмә, андыйны складтан ук алып чыкма, аңлыйсыңмы? Ә хатыннар турында андый сүз ишетәсе булмыйм!

Прошка гаҗәпләнә: «Әллә нишләде бу Харитоша соңгы елларда. Хатыннарга тел тидерүне серкәсе күтәрми. Солдаткалар тирәсендә күп чуалганлыктан, берәрсенә күзе төшкәндер, тәгаен. Бер аягы белән гүргә басты дигәндә генә өйләнеп куймакчыдыр, билләһи. Эх, үземә дә Варвара шикелле берәр матурын каптырырга!» Прошка терәүгә сөяләп дә тәмәке бөҗралары очыра башлый.

Лавада Степанов аның килгәнен көтеп тора, машина өстендәге ике шнурны шартлатканны үз күзләре белән күрергә тели. Кесәсендәге ипи сыныгын вак-вак кабып бик озак чәйни. Авызына кайнар ризык кермәгәненә тәүлектән артык, һәр вакыт үз янында йөртә торган җылы чәй тутырган шешәсе дә кичтән үк бушаган. Кайчакларда кинәт кенә бөгәрләп салучан ашказаны авыруы ябышса, сода болгатып шуны эчкәли дә басыла төшә иде бераз. «Нигә озакладылар икән Әхмәтҗанов белән Алексей?» Степанов эчен тотты, егылып китмәс өчен, терәүгә тотынды.

*
* *

Баш штрек забоенда шартлатканнан соң, Прошка белән Хәертдин насосныйга йөгерделәр. Монда сасы төтен исе юк, һава саф, штрек биек, иркен. Хатын-кызлар да кайчакта шушында жыелып, забойларда төтен беткәнен көтәләр иде.

Фатыйма гадәттәгечә Прошканы ирештерә башлады:

— Прокопий Ильич, хәлең мөшкел, ахры. Өйләнәм дип ел буе йөрисең, һаман булдыра алмыйсың.

— Өе юк бит аның,— дигән булды кайсыдыр,— өе булса, үзем дә баш тартмас идем.

— Ире ир булсын, идәне жир булсын, име, Прошка? — диде Зоя.

— Тавыкны йомырка өйрәтми, әйе бит, Прокуп агай? Солдаткалар дөнья тулы, менә дигәнен үзем димләрмен, яме?

— Солдатка кирәкми миңа. Әйләнгеч булса да юл яхшы, карт булса да кыз яхшы. Кыз булсын миңа, яшь кыз! — дип, Прошка кеткелдәп көлә. Эченнән: «Ә менә Варвараны бүген үк алыр идем, күренми әле, кая китте икән?» дип уйлый, күзләре Варяны эзли.

— Акылың алтын икән! — ди аңа Фатыйма.

— Шахтада шыгырдап торган терәүләрдән дә ышанычлысы юк: чытырдый-чытырдый озак яшәүчән алар, чәрдәкләнеп бетсә бетәр, әмма таш бастырмас! — Прошка элегрәк хатыннарның күңел кылларына чиртүләрен өнәп бетерми иде. Ә хәзер аларга кушылып үзе шаяра, үзе көлә. Хәтта бераз күңеле дә күтәрелә: өйләнеп куйса шәп булыр иде...

— Лавада күмер көнозынга житәрлекме? — дип сорап куйды Фатыйма Хәертдиннән.

— Әллә ни түгел. Монда бетерсәгез, икенче лавага күчәрсез.

— Я, ниятлибезме?

— Вакыт, бик вакыт.

Караңгыдан хатыннарның һаман да сөйләшә барган сүзләре ишетелә.

— Эттәй алжыдым, хатыннар. Сугыш тизрәк бетсә, өскә чыгар идем. Володям кайтып керсә, бәлки гел өйдә генә ятар идем.

— Сиңа нәрсә?! Көтәр кемең бар. Менә Зоя белән безнең күз яше генә түгәргә калды...

— Кияүгә чыгарсыз, бер дә кайгырмагыз...

— Авызыңны томаласаң, сәдака бирерием...

Хәертдин баш штрек буйлап хатыннарга шаккатып бара. Менә бит, күмер һәм вагонеткалар төткәзер хәл юк, тәмам каешландылар. Әүвәлрәк кәйләнең кайсы башыннан тотып селтәргә белмиләр иде, бичаралар. Ничек аларны жир астында калдырып, ир кеше өскә чыксын! Авыр, бик авыр үзенә дә, сәламәтлеге шәптән түгел, яшьли хастадан саклана белмәде, теләмәде. Эш, бары тик эш — жанына да, тәненә дә бердәнбер дәва булды аның.

Баш штректә, тау хәтле өелгән күмер каршында басып калды ул. «Лавадан бушагач, әрчергә Маликны сорарга булыр, ныгытып та китәрләр», дип уйланды. Кулына йодрык хәтле күмер кисәге алды, аңа бик озак карап торды. Аннары, борын төбенә үк китереп, озак-озак итеп иснәде. «Менә нинди бит ул күмер! Жансыз булса да жанга жылы бөрки». Карт елмаеп алды. Уала күрмәсен дигәндәй, күмер кисәген өем өстенә куйды. Ихтимал, жир өстенә, Гитлерны дөмектергәч, хатыннар белән бергәләп чыгасы булыр.

Әнә, дөбер-шатыр килеп, конвейер лавадан күмер ташый, люк астында вагонеткалар бәрелешә: «төяргә дә тотынганнар икән». Тик эстакадада вагоннар гына булып торсын. Шуны белешү өчен, салмак кына атлап телефон янына китте. Баш штрекнең тыштан керә торган

ягында электровоз дөберди, уты күзләрне чагылдыра. Ике терәү арасына посып калды Хәертдин. «Зин-зин-зин» иттереп, машинист аңа сәлам биреп узды. Электровоз машинисты тыштагы хәлләрне яхшы белүчән, ул күнозын тышка күмер ташый. Тимер юл вагоннары турында аннан гына сорашасы булыр. Электровозда Оксана икән. Житен чәчкәсе күк зәңгәр күзләре гел тирә-якны айкый, кемнедер эзли. Хәертдиннең вагоннар турында соравына җавап кайтарасы урында, Оксана үзе борчылып сораша башлады:

— Харитон Харитонович, Әхмәтҗанов кайда? Шахтага кердеме бүген?

— Лавада врубмашина янында ул, сеңелем, кичәдән бирле.

— Ә Варвара эшкә чыктымы? Эштән азат итмәгәннәрме? Кичә аягын авырттырган иде.

— Варяны берәр көнгә генә насосныйга куйдык.

— Кичә сез дә килмәдегез... Яша да... Бүген килерсезме?

Бик үк өнәп бетермәде карт аның пошынуын: «Хәтере берәр генә айлык икән!» Янәсе, сөйрәлә дә башлаган. Шундук икенче уй: «Әйдә, җаны булгач, үзенекен кылмый нишләсен?» Оксанага болай диде:

— Уйлап кара, сеңелем, нигә ул сиңа Яша бүген? Тәүлекләр буе аяк өстендә, аттай эшли ич. Ярый, килде ди. Күзле бүкәндәй каршыңда эчпошырып утырса? Ул бит ирләр затыннан, «алҗыдым, йокы килә» диярга горурлыгы ирек бирмәс. Анысы ярар, анда минем онытым нишләп ята?

— Көлә инде. — Оксана Хәертдинне тыңламады, электровозын чаптырып китеп тә барды.

«Әнә, насосныйда десятникны чакыралар, ни булды икән?» Шунда юнәлде Хәертдин. Насос эшләми икән, слесарь кирәк. Ул гына да түгел, күл булып су җыелган, мотористка Варя да күренми. «Кая киткән булыр? Әллә берәр җиргә кысылган-ниткәнме? Су чокырына төшмәгәндер ич?» —Хәертдин, пошынып, насос тирәләрен карап чыкты. Аннары, манма тиргә батып, таяк кисәге белән коены актара башлады.

*
* *

Бу вакытта Варя штольня буйлап тышка таба атлый иде.

Люковой кыз һич көтмәгән хәбәр китерде аңа. «Варя апа, анда сине эзләп бер солдат килгән, үзе таза, үзе озын, штреккә генә сыешлы түгел»,—диде.

Варя, хәле бетеп, такта стенага сөялде. Кем булыр ул? Ходаем, әллә, берәр гаеп табып, аны яңадан эзлиләрме? Әллә... Николаймы? Мәрхәмәтеңнән ташлама, ходаем, юньлегә генә булсын...

Тышкы якка чыгуга, Варя мыш-мыш килеп туктап калды. Әнә... әнә ул солдат. Бирегә арты белән басып, тәмәке кабыза. Я, хода, чыннан да Николай ич!..

Солдат, үзенә төбәлгән күз карашын тоептыр, ялт итеп бу якка борылды.

Икесе дә бер-берсенә карашып катып калдылар.

Күпме басып торганнардыр, кинәт икесе берьюлы кузгалып, бер-берсенең кочакларына ташландылар.

— Николай!

— Варя! Варюша!.. Барыбер эзләп таптым үзеңне!..

Варя, бер сүз дә әйтә алмыйча, сулык-сулык килеп елый башлады.

Тынычлабрак сөйләшү өчен шактый вакыт кирәк булды.

— Варюша, иртәгә безнең команда Ургыл стансасына килеп житәчәк. Солдатка яраклыларны фронтка озаталар. Ахмет абзый да китә. Күп сорый торгач, жибәрделәр.

— Ә син һаман аларны саклыйсыңмы?

— Варенька, иртәгә, бәлки берәр көннән мине дә фронтка озатырлар. Аңарчы әйтеп калыйм. Иртәгә иртүк китик загска. Сатанка поселогында сиңа эш тә әзерләдем, штукатур-малярлыкка. Синең яраткан эшең бит ул.

Варя һаман да исен җыя алмый: берьюлы ничаклы аяктан еккыч хәбәр. Николайдан күзен ала алмый: уйчан соры күзләр, кылыч борын, текә маңгай. Сакчылар арасында иң әйбәте, акыллысы иде ул. Әллә нинди мөмкинлекләр табып, юкларын да бар итеп, эзләп таба да сүз башлый иде. Шулай танышып киттеләр. Аннары мәхәббәтен белдерде. Икесе дә киләчәккә өмет баглап яшәделәр. Әмма өйләнешү мөмкин түгел иде. Соңыннан икесе ике җиргә эләкте. Менә тагын очраштылар. Аларны мәхәббәтләре очраштырды.

— Үзем теләп китәм фронтка, Варюша. Шулай кирәк таптым. Син мине көтәрсеңме? Көтәр булсаң, өзелеп көт...

Варя сүзсез генә ияк какты.

— Коля, син миңа сугыш беткәнче шахтада эшләп торырга рөхсәт ит. Кайтырыңны өзелеп көтәрмен. Әти-әниләреңне дә монда алып килермен. Үземнекеләр шикелле кадерләрмен, яратырмын.

— Варюша, кадерлем! Дөньяда миннән дә бәхетле кеше юктыр.

— Ялгышасың, Коля. Мин бар бит.

Варя, егеткә сыешып, аның күкрәгенә башын куйды, тагын үкси башлады.

*
* *

Мәш килеп күмер кискеч машина янында кайнашкан җиреннән Якупны Варя читкә, караңгыга чакырып алды. Үзе чакыра, бераз шикләнә дә төшә: әтисе булмавы да мөмкин ич! Ай, шул булып чыкса!..

Аның үзенең бүген иң куанычлы көне. Кичә Николае белән загска барып кайттылар. Озакка сузылмады шул кавышу минутлары. Бүген иртән фронтка озатып җибәрде ирен. Елаудан шешенеп беткән яшьле күзләрен әле дә сөртеп бетерә алмый. «Бәхет дигән нәрсә бар икән ул дөньяда, рәхмәтләр яусын, раббым, кавыштырдың... Каһәр төшкән сугыш аны миннән тагы тартып алды... Әгәр, раббым, син дөньяда бар икәнсең, нигә шул сугышларны тыймыйсың?..»

Варя өстән-өстән генә Николае турында, кавышулары хакында сөйләп бирде дә Якупка хат тоттырды, шундук китеп тә барды.

Ышаныргамы, юкмы моңа? Әтисеннән ич бу хат! Бик таныш, бик кадерле почерк. «...Улым, шушы хатта язылган вакытка төгәл килеп җитәрсең дип уйлыйм. Мин дә кулга корал алырга булдым, теләгем кабул булды, фронтка узып китешем. Хәзергә хуш, балам!».

Якуп чайкалып китте, аның тез буыннары дерелдиләр, бөтен тәненә салкын су сипкәндәй калтырый иде. Иртәгә әтисен күрергә барачак! Әтисе исән! Алар очрашачаклар! Ышаныргамы, юкмы моңа? Төш кенә түгел микән бу? Кыек-мыек атлап машина янына юнәлде.

Машинаның койрыгы чылбыры белән ансат кына, пычак камыр кискән шикелле, катлам астына күмелгәннән-күмелә бара. Кистереп узган ярыктан борчак-борчак, чикләвек-чикләвек кыйпылчыклар сибелә.

— Могҗиза! Тәки китә бит худка! — ди берсе.

Үз кулы белән күмер чапмаган, шахтада эшләмәгән кешегә бу гадәти хәлдер. Әмма шахтерларга, бигрәк тә яңарак кына җир асты хезмәтенең газаплы тәмен тоя башлаган малайларга, кызларга бу инде чынлап та могҗиза. Авыр эш җиңеләя, күмер чыгару арта, «Сивак»та бу машинага киң юл ачыла, димәк, ул яши.

— Эх, үзе тураклап, үзе төясен дә иде бу машина! — дип куя кайсыдыр.

— Кеше күңеле өметсез яши алмый, сеңелем. Без генә ул әүвәл кулбаш имгәтеп, яшьли картайдык, аркага бөкре үстердек, билне катырдык. Минем уемча, җир астында да комбайннар эшләячәк. Мәнә күрерсең, Харитонов юләр әйткәнне диярсең...

Прошка да уйга чумган: беренче тапкыр шахтага аяк басканда, бер кулында карбид лампасы тычкан уты хәтле генә җемелдәсә, икенчесендә кәйләгә охшаган обушок һәм иңбашында көрәге иде. Аның күз алдында бензин лампалары, аннары аккумулятор, тора-бара аммонал белән шартлату, отбой чүкече барлыкка килде. Сукыраеп беткән атларны электровозлар алыштыра. Күмер төягән чаналар өстерәп, егерме яшеннән гүргә керүчеләр дә юк хәзер, җир астын янгыратып колашалы яки тасмалы конвейерлар күмер ташый штрекләрдә. Тагын әллә ниндиләрен уйлап чыгарырлар әле, күрергә генә насыйп итсен!..

— Бирешмәгез, туганнар! Җанкисәкләрем! — дип пышылдый Степанов. Үзе ике куллап әчен тоткан да алга таба бөкрәйгән.

— Федор Иванович, ни булды сезгә? — дип сорый Якуп.

Степанов җайлап кына терәүгә сөялә.

— Гүләсен җир асты, улым, гүләсен. Туктатма минем аркада. Бу картлачны да егып салдым дип әҗәл сөенмәсен әле! Без түгел, әҗәл үзе калтырасын!..

Хәертдин йөгереп кенә хатын-кызлардан бер шешә җылы су алып килде.

— Яткыр мине, Харитоша туган? Бераз югарыга карап яткач, җиңеләя торган иде. Әй, машинистлар! Гүләтегез, гүләт! «Сивак»та гына түгел, бүтән шахталарда да ишетсеннәр! Җир астын дер селкетегез!..

Авыру карт җир өстендәге кояшка карап ята, ул кояшны күрми, әмма өстәгеләрдән һич тә ким тоймый, бәлки күп тапкыр артык тадыр. Бераздан торгызырга куша. Прошка аны торгызып утырта.

— Федя, Федюшка, бирешәсең ич, кордаш! Ничек, бик нык азаплыймы? Соданны эчмисеңме?

— Эчмим, җанкисәгем, эчмим хәзер. Бераз басылгандай итә. Ыланнар, чылбырны эчкәрәк кертегез әле! — ди авыру һәм иплән кенә чалкан ята. Моңарчы машина ярты көченә генә эшли иде, хәзер бөтен куәтенә сынап карамакчылар.

Алеша күмер кискеч машинаны Якупка тапшырды да, Степановны култыклап, Хәертдин белән икәүләп баш штреккә алып киттеләр. Конвейерныйга житкәч, Степанов утыртырга кушты.

— Җир асты симфониясен тыңлап калырга телим, — диде пышылдап. — Ишетәсеңме, Харитоша, Прокоп, безгә лаеклы алмаш үсә. Эстафетаны аларга ышанып тоттырырга мөмкин. Сугыш беткәч үк...

Степанов сөйләшүдән туктый, тыңлап ята, йөзендә сизелер-сизелмәс елмаю. Баш штреккә хәтле үзе атлап төште, анда көтеп торган ашыгыч ярдәм машинасы аны больницага алып китте.

*
* *

Мәшәкатьләр һәм борчулар тулы, куанычлар тулы, җир астыдай караңгы төн узып бара. Якупның куллары машина идарә итү рычагларында, ә уйлары күптән станциядә. Аның еллар буе көтеп алган кадерле минутлары якынлаша. Әтисе белән очрашачак ул бүген!

Юл уңаенда Якуп почтага сугылып хат сорады. Берьюлы икене тоттырып чыгардылар. Берсе әнисеннән иде, тизрәк шунысын ачып укый башлады. Әниләре таза-саулар, бик сагынып яталар икән. Авылга бик күп яралылар кайткан. Үлү хәбәрләре дә һаман килеп тора. Әтисе турында сорашканнар. Икенче хат Судаковтан иде. Яраланып госпитальгә

кергән. Ихтимал, яңадан мылтык тотарга ярамамдыр, дигән. Барып сиеныр кешем юк, дигән. Кайтсын монда, слесарь булып керер. «Сагынам», — дип язган. Әллә мин сагынмыйммы синең тырпайган муеның белән җирән чәчләреңне! Әрләшсәк тә, үпкәләшсәк тә, без бергә идек бит.. Үз кешеләр, мәгарә егетләре. Кайт, дускай, кайт Ургылга! Фашистларны нык тукмагансыңдыр: «Кызыл йолдыз» орденын тикмәгә бирмәсләр?..

Кызарып кына кояш чыгып килә. Аның иртәнге нурлары, рельсларны ялтыратып, күзләрне чагылдыра. Бик озак паровоз кычкыртып тора. «Пых-пых» итә, тиздән кузгалып китәчәк.

Озакламас, пассажир поезды да килер. Шуңа утырып әтисе дә... Аңарчы мунчада юынып чыгарга да өсне алыштырып өлгерергә кирәк. Тизрәк кыймылда, Якупҗан. Фашистларның арт сабагын укытырга китә бит әтиең. «Ил язмышы хәл ителгәндә беркем дә читтә торып кала алмый», дигәне бар иде аның. Менә күрәсезме, Якупҗан абзагызның да әтисе читтә торып калмый!

Бик килештерергә тырышып, затлы дигән өс-башын да киеп алды, көзге каршында да әйләнде, ә колаклар һаман-һаман тышта — тимер юл буенда: поезд тавышы ишетелмиме?

Менә ул, шпалдан шпалга сикереп, Ургылга, станциягә чаба. Йөрәге дөп-дөп тибә, үзе туктаусыз артына карана, ә поезд һаман күренми дә күренми. «Нигә килми соң инде поезд?»

— Килә! Әнә...— Иреннәре шулай дип пышылдап куйды.— Кайсы вагонда икән? Алдамы, арттамы?..

Ашыга-ашыга Варя да килеп җитте.

Якуп якынаеп килгән поездны күзләре белән йотардай булып карый: әтисен дә күрер көннәр бар икән! Аның онытылмас сүзләре искә төшә: «Яшьлек таңыннан ук таштан салынган нигезебезне мүкләтмик, имән өрлекләребезне черетмик!». Шулай дигән иде ул бик күптән. «Тырышам, бик тырышам, әти».

Якуп паровоз каршына йөгерде, күзләрен вагон ишекләреннән алмыйча өч-дүрт вагонны узып китте: юк, әтисе баскычта басып тормый. Менә поезд туктады. Пассажирлар вагоннардан сикерешеп төшә башладылар. Якуп арттагы вагоннарга таба атлады. Менә соңгы вагон, әтисе юк. «Әллә күрмичә үтеп киткәнме?» Алга таба йөгерде. Баштарак иреннәре пышылдап кына: «Әти, әти!» дисәләр, хәзер ул кычкыра. Аннан Варя калышмый, ул да: «Ахмет абзый!» дип кычкыра. Кинәт кенә өченче вагон каршында катып калдылар. Һәм менә ата белән бала каракаршы басып торалар.

— Балам! Якупҗан!.. Варвара!..

— Әти!..

— Ахмет абзый!

Ата белән бала кочыштылар, күзләре юешләнде.

Әйтәсе сүзләр бетәрлек түгел, тик бу минутларда сүз сөйләү артык. Ата аларның башларыннан сыйпап калырга ашыкты, ә алар ата кешедән күзләрен алмадылар. Әнә, җәелеп киткән кыйгач кара кашлар да, кысык кара күзләр дә, озын-озын керфекләр дә, текә маңгаендагы җыерчыклар да — барысы да элеккечә, берсе дә онытылмаган... Тик маңгайда җыерчыклар ишәйгән шул инде, атакай... Артка таба ятып торган кара чәчләре агарган... Озын гәүдәсе әле дә нык күренә. Кылыч борын астыннан кечтеки генә мыек та үстереп җибәргән. Башындагы картузын кыңгыр салган, монысы да элекке гадәте, күлмәк якасын ычкындырып җибәргән, җиңнәрен сызганган...

— Улым! Варвара! Балалар... Сезнең өчен куанам, хатыгыздан барысы да мәгълүм. Менә мин дә фронтка китәм... Күптән сорый идем дә, тоткарладылар, тылда да кирәгем булган, күрәсең. Сезнең кебек үк.

Сезнең шартлаткычларны без ясадык. Менә шул. Хәзер немецны тукмап карыйк, юкса, миннән башка...

— Эти... Мине дә җибәрмәделәр... Эти! Әнә паровоз китәргә кычкырта... Шулай бик тиз аерылабыз дамыни?..

— Сугыш беткәч күрешербез, улым, бергә яшәрбез, әниегез белән бергә...

— Эти... гел-гел исемдә син минем... Исән-сау әйләнеп кайт!..

— Исәнлектә күрешергә язсын, балалар... Сугыш беткәч...

— Әнә поезд кычкырта...

— Хушыгыз, балалар! Әниеңә, сеңелләреңә миннән бик күп сәлам әйт. Барып җиткәч, адресымны салырмын, язып тор, яме?..

Әхмәтҗан кузгала башлаган вагон баскычына сикереп менде. Якуп белән Варя вагон яныннан янәшә атлыйлар, поезд әкрен генә кузгала-кузгала кызулый ук башлады.

— Хушыгыз, балалар!..

— Хушыгыз!..

Әнә Әхмәтҗан вагон баскычыннан балаларның шпаллар буйлап йөгергәннәрен күреп бара, аларга бертуктаусыз кул болгый, иреннәре нидер пышылдый.

Якуп ахырда туктады, күзләрен поездан алмыйча, нәүмизләнеп:

— Нәләт төшкән сугыш! — диде. — Рәхәтләнеп эти белән күрешергә дә ирек бирмәдең!..

Аңа тик паровоз гына үзенең моңлы тавышы белән еректан җавап кайтарды.

Ике рельс арасында, шпаллар өстендә басып торган Якуп янына кемнәрдер килеп туктады.

— Кайтыр этиең, Якупҗан, кайтыр, кайтмый калмас. Фашистларны тәмам юк итеп кайтачак. — Хаертдин абыйсы икән болай диюче. Ул ата белән балаларның кавышуын башыннан ахырынача карап торган.

Якупның күзләре көнбатышка текәлгән, ике бите буйлап эре күз яшьләре тәгәри, иреннәре:

— Кайтыр эти, кайтыр. Җиңеп кайтыр. Нигә балавыз сыгарга, иеме?! — дип пышылдый.

Шахта ягында, кайдадыр яшьләр җырлый, тавышлар аермачык булып ишетелә.

Там, на шахте угольной
Паренька приметили.
Руку дружбы подали,
Повели с собой...

## Шамил Анак

### Тыйнак табын

Алар ашыкмыйча, берәм-берәм
җыелалар кичләрен минем бүлмәмә,
килеп утыралар тартына-тартына
сый-шәрабсыз өстәлем артына.
Хас булганча кунак халкына,
шау-гөр килмиләр,
табын яңгыратып көлмиләр,
тостлар күтәрмиләр очрашу хакына,
шаулы бәхәсләр дә кормыйлар
бүлдерә-бүлдерә бер-берсенең сүзләрен.
Утыралар алар тын гына,
һәркайсысы үз урынында,
тик тирән сагыш белән карый күзләре...
Бөтенесе сөер бу кунаклар —
минем туганнарым, минем якыннарым:
менә — әти, менә — абый, ә болары —
ике туган, өч туган абыйларым...
Ничәү алар — бишме, унмы, әллә күбрәкме —
хатирәләрдә миңа кунакка килгәннәр:
мең тугыз йөз кырык беренчедә,
мең тугыз йөз кырык икенчедә,
кырык өченчедә, дүртенчедә үлгәннәр?
Ниһаять, күпме еллар үтеп,
җыелдылар алар минем тар бүлмәмдә,
һәм без бергә менә тагын...
Хатирәләрдә генә мөмкин булган
сагышлы һәм тыйнак табын.

### Карбыз

Чыпчыклар качып беткән.
Тышта — минус утыз — кар, боз...

Утырабыз кухняда.
Өстәл өстендә — җәй, челлә,
Өстәл өстендә — карбыз.

Утырабыз гаҗәпкә калып,
күз текибез кызыгып —
җир шарыдай йоп-йомры,
буй-буй кара юллары —
меридиан сызыгы...

Өстәл өстендә — дөнья:
җиләс сулар, шәфәкъ утлары,
бөтен юанычлар, вәгъдәләр,
иң татлы сөю минутлары...
Утырабыз гаҗәпкә калып:
тышта — салкын, кар-боз,
өстәл өстендә — җәй, чиллә,
өстәл өстендә — карбыз,
пычак ал да яр урталай,
телем-телем итеп кис —
балкыр кояш, сайрар кошлар,
җәелер җәйге хуш ис...

Чыпчыклар качып беткән.
Тышта — минус утыз,
декабрь кары.
Өстәл өстендә — карбыз,
олы дөнья, бөтен җир шары.

**Гыйлемдар Рамазанов,**
башкорт шагыйре

## Райнис

*Рига каберлегендәге шагыйрь Райнис һәйкәлен скульптор яшь, чибәр егет итеп ясаган.*

Ак сакаллы булып үлгән шагыйрь —
Рәсемнәре таныш күпләргә,
Ә ул менә — япь-яшь гүзәл егет,
Хыяллары ашкан күкләргә.

Мәңгегә ул шулай унсигездә,
Туган төягенә охшаган,
Ышанам мин аның яшьлегенә,
Шагыйрь икәненә ышанам.

Ул мәңгегә шулай: юлдаш аңа
Бары бөеклекләр, сафлыклар,
Ерак йөри аннан түбәнлекләр,
Кара мәкер белән ваклыклар.

Олылыкны, изгелекне җырлый,
Үзе белми ләкин ул даһи,
Шул яшь егет кебек беркатлы ул,
Шушы сафлык кебек илаһи.

●

Бәйрәмнәрдә сагынам эш көннәрен
Эш көнендә — олы бәйрәмне,
Кайчагында тыныч тугайларда
Юксынам мин шаулы мәйданны.

Эссе көнне кетәм яңгыр җилен,
(Ай-һай, кыен ярау кешегә!)
Дуслар белән булсам, туганнарны,
Якыннарны искә төшерәм.

Чыршы чыңлап торган урманнарда
Искә алам сагынып мин бүген —
Крещатикта җылы апрель кичен,
Невскийда алтын көз көнен.

Торганым бар аяз күк астында
Җәйге төндә йолдыз яуганда,
Дуслар белән таң аттырган булды
Ирек мәйданында Казанда.

Күз алдымда: казакъ далалары
Тюльпан ялкынына күмелгән,
Шул язларны әле җырламадым,
Ләкин алар китми күңелдән.

Эш көннәрем — минем бәйрәмнәрем,
Салса салсын тормыш сагышка,
Җирдә дуслар, кулда каләм булса,
Үпкә сүзе әйтмәм язмышка.

## Яшьлегемнән миңа хат килде

Үсмер чакка, күңел, кайт инде —
Одессадан миңа хат килде.
Узам гүя мәшһүр урамын,
Аша атлап еллар ызанын.
Ни дип кенә җавап бирәсе! —
Аңа да бит илле тирәсе...
«Саумы, — дигән, — ерак танышым!
Радиодан синең тавышың
Ишеттем дә сәлам җибәрәм
Кушып илгә искән җилләргә.
Исеңдәме, Идел буенда,
Яшь чактагы кечке уеннар?
Хәтерлисең микән төсемне, —
Икәү идек бер үк исемле.
Шомырт чәчәк аткан чакларда
Булдым былтыр туган якларда.
Агыйделне төшеп буйладым,
Бер җырладым, берчә еладым.
Туган җиркәй белән хушлаштым,
Диңгез белән күптән дуслаштым.
Өйрәтте ул гомер итәргә —
Түзем-сабырлыкка, көтәргә.
Адресымны хәбәр итмимен,
Җавап хаты синнән көтмимен.
Яза калсаң яңа җырларны,
Бел бу җирдә мин дә булганны».
Сәер бер хат. Ни дип әйтергә?
Һәммәсе дә төште хәтергә.
Уналты яшьмени бүген дә —
Шул ук хисләр күңел төбендә.
Үткәннәргә, күңел, кайт инде, —
Яшьлегемнән бүген хат килде.

## Беркет Исхаков,

казакъ шагыйре

### Тукай

Тукай ул — олы Тукай,
Бөек халык акыны,
Татарның улы Тукай —
Казакъның да якыны.

Кырлай авылында туган,
Булган казакъ җирендә,
Сөйгән башкорт бауырын да [1],
Җырлаган Русь илен дә.

Абай кебек, Тукай да
Йөрәгендә казакъның,
Инанган ул ак таңга,
Туар, диеп, азат көн.

Бөтен илгә танылган
Егерме җиде яшендә,
Җырын мирас калдырган
Егерме җиде гасырга!

1974

### Чулпан йолдыз

Алыстагы алтын шәүлә — арманым [2],
Йолдыз булып күк йөзендә җайнадың [3],
Күпме җанның күңелен тартып үзеңә,
Күркең белән уй-хыялын арбадың.

Канмасам да [4] тылсымыңа-сереңә,
Илһам булдың үләңемә-җырыма.
Сөйгәнемне исемең белән атадым,
Ак йөзләрен тиңләп асыл нурыңа.

---

[1] Бауыр — кардәш, туган.
[2] Арман — теләк, омтылыш.
[3] Җайнау — ялтырау.
[4] Канмасам да — эчеп туя алмасам да.

Житте нәүбәт яннарыңа барырга,
Ракетада көмеш канат кагарга,
Кояш булып ал йөзеңне иркәләп,
Ак муйныңа муенсалар тагарга.

1961

## Татар кызы

Әллә кайдан күрәм үзен —
Ерак ындыр башыннан.
Көн яндырган нурлы йөзен,
Җилләр сыйпый чәченнән.

Сүз кушып карыйм, дим, аңа,
Ниятем бер — танышмак.
Якынлашкан саен бара
Ара никтер алыслап:

Ындырда эш кыза гына,
Буш минут өмет итмә,
Булмый мондый чакта кызга
«Сөям, бәгърем!» диеп тә.

Китәм бер сүз әйтәлмичә
Гүзәл татар кызына,
Ниятеннән кайталмыйча,
Күңел һаман кызыга.

Һәр таң саен бер юл, бер эз —
Машинам оча гына.
Мине бар дип тә белми кыз,
Һаман эш кочагында...

1959

Казакъчадан НУРИ АРСЛАНОВ
тәрҗемәләре.

# «ЯШИ АЛМЫЙМ ШУЛ МИН ЯНМЫЙЧА»

Киң катлау укучылар алдында үзен татар совет әдәбиятының күренекле вәкиле итеп таныткан Шәйхи Маннурга бу көннәрдә җитмеш яшь тулып килә. Шушы гомернең ярты гасырлык өлешен ул әдәби иҗат мәйданында, олы максат һәм хыял-теләкләр белән янып яшәп, социализм төзү эшенә «җыр белән кирпеч салышып» үтте.

Шәйхи Маннур таланты әдәбиятыбызның төрле-төрле өлкәләрендә, жанрларында ачылды.

Егерменче һәм илленче еллар арасында ул барыннан да бигрәк социалистик җәмгыять шартларында яңа шәхес формалашуын сурәтләп биргән эпик поэмалар шагыйре буларак уңыш казанды.

Шәйхи Маннур авыл тормышын, кешеләрен яхшы белә. 1905 елда туып, ун яшькә кадәр Тулбай авылында (хәзерге Мамадыш районы) тора һәм ятим тормышның (аңа җиде яшь чакта әнисе үлә) ачысын татый. Сезонлы эшче Фәрхулла абзый улы Шәйхине бер кайтуында шахталы җирләргә — «Ерак күмергә» — алып китә.

Октябрь революциясе миллионлаган Шәйхиләрне — эшче һәм крестьян баласын — ачлы-туклы тормыштан коткарып, уку, яңа җәмгыять төзү өчен көрәшүчеләр булып үсү мөмкинлеге тудыра. Яңа революцияне «яңа җыр» итеп кабул иткән, күңеле ашкынулы дәрт белән тулы Ш. Маннур да белемен күтәрү уе белән яна, үзешчән сәнгатьтә бик теләп катнаша, газеталарга хәбәрләр яза. Тукай, Гафури, аеруча Такташ әсәрләре белән ныклап танышу, Свердловскида гөрләп торган культура тормышы, йөрәкне биләп алган романтик хис-кичерешләр аны шигырь язуга алып килә. Аның беренче шигъри тәҗрибәләре 1923—24 елларда Урал, Себер газета-журналларында дөнья күрә.

Талантлы шагыйрь булып Ш. Маннур 1928—29 елларда танылa, бу чорда аның иҗат активлыгы да бермә-бер арта. Рухи дөньялары «елмаюлы кояш» нуры белән яктыртылган кеше образларын тудыру юлында беренче уңышлы адымын Ш. Маннур «Чуен ташкыннар» (1930 ел) поэмасы белән ясый. Бригадир Хисмәт образында бишьеллыклар чорының ашкынулы атмосферасы, гражданнар сугышында җиңеп чыгып, тыныч төзелештә дә фронттагыдай ярсу һәм дәрт белән көрәшкә күтәрелгән гади кешеләрнең күркәм сыйфатлары калку гәүдәләнеш таба.

«Чуен ташкыннар» поэмасын шагыйрь социалистик төзелешнең алгы сызыгында торып яза, Донбасста прокатчы, Днепростройда бетончы булып эшләү аңа үз әсәрләрендә чорның героик сулышын тулырак сурәтләргә юл ача.

Утызынчы еллар башы крестьян тормышында да тарихта тиңе булмаган гигант үзгәрешләр килеп чыгу белән характерлана. Күмәк хуҗалыкларга берләшү, ата-бабадан калган гадәт-йолалардан арыну авыл кешесенә җиңел генә бирелми. 1932—33 елларда «Коммунист» газетасы (Мәскәү) редакциясе хезмәткәре, ә аннары Казан педагогия институты студенты Шәйхи Маннур да, башка татар шагыйрьләре кебек, коллективлашуның зарурилыгына, якты тормышка чыгуда бердәнбер юл икәнлегенә төшенә баручы крестьян психологиясен аңларга омтыла һәм, «Меңнән бер кичә» поэмасын язып, Гата образын иҗат итә.

Гата образында Ш. Маннур социалистик чынбарлыкта хезмәт кешесе күңелендәге хыял-омтылышларның чынга ашуын шактый нечкә психологик детальләрдә күрсәтүгә ирешә.

Шулай да Маннурның үзенчәлекле шигъри таланты бар куәтенә «Гайҗан бабай» әсәрендә ачыла. Азат, коллектив хезмәтнең кешене күтәрүен, аңа канатлар куюын күргән, яшәү тәмен татыган хөр күңелле, җор телле Гайҗан бабай менә кырык ел буе безнең күңелләрдә яши.

Бөек Ватан сугышы башлангач, шагыйрь үзе теләп фронтка китә, хәрби газеталарда эшләп, күп санлы хәбәрләр, очерклар, шигырьләр бастыра. Бу чорда иҗат ителгән «Шофер һәм малай», «Моңар нинди исем табарга», «Халык улы» кебек шигырьләре һәм балладалары безне хәзер дә дулкынландыра. Ә «Чәчәкләр һәм снарядлар» балладасы исә олы мәгънәлелеге, эмоциональ көче белән сугыш чоры татар поэзиясенең күренекле әсәре булып танылды.



Утлы елларда тупланган тормыш тәҗрибәсе, солдат батырлыгын, рухи матурлыгын күрүдән туган хис-кичерешләр материалны иңләбрәк ала торган жанрга мөрәҗәгать итүне сорый. Сугыш тынуга бер ел да үтми, аның «Казан кызы» поэмасы басыла. Дилбәр образы аша канлы көрәшнең фаҗигале чынлыгын сурәтләп, хатын-кызларыбызның ирләр белән янәшә геройларча сугышуын җырлап, Ш. Маннур сугыш темасына язылган җитди әсәр тудыра.

60—70 еллар әдәби хәрәкәтендә Ш. Маннур прозаик буларак катнаша. Дөрес, әле егерменче елларда ук, иҗатының яңарак кына башланып килгән чагында, ул берничә чәчмә әсәр бастырган иде. Ләкин ул вакыт поэзия җиңде. Һәм менә хәзер дистәләрчә еллар буе бөтен күңелен шигърияткә багышлаган әдибебез прозага килә.

Иҗат эшчәнлегенең характеры үзгәрүгә тормыш тәҗрибәсе дә йогынты ясады булса кирәк. Ул үз гомерендә күпне күргән, төрле-төрле шәхесләр белән очрашкан: сугыш кырларында аның дистәләрчә каләмдәшләре һәлак булды.

«Муса» романының туу-язылу тарихы турында уйланып, Ш. Маннур: «Муса үзе сорады кебек»,— дигән иде. Бу сүзләрдә дә проза жанрына, аеруча аның роман кебек катлаулы формасына мөрәҗәгать итүнең очраклы түгеллеге ачык күренә.

Муса Җәлил образын Шәйхи Маннур яратып иҗат иткән, ул романның беренче битләрендә үк күңелгә кереп урнаша һәм соңгы битенәчә уй-хисләрне үзенә тартып яши. Аеруча Мусаның героик характерын, көрәштәшләренә мөнәсәбәтен күрсәткән вакыйгалар Ш. Маннурның прозаик буларак көчлелеге турында сөйли.

Күптән түгел әдибебез укучылар игътибарына өр-яңа әсәрен — «Агымсуларга карап» повестен тәкъдим итте. Анда чирек гасыр эчендә автор башыннан узганнар тасвирлана. Авторның тормыш юлы — татар ярлы-ябагае баласына Бөек Октябрьның ни бирүе ачык мисал бит! Шул сәбәпле ул үзенең малайлык, яшүсмерлек елларын (1910—1920) бигрәк тә тәфсилләп сурәтли. Әсәрдә сезонлы эшче Фәрхулла малаеның революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы язмышы төп урынны биләсә дә, автор аның янәшәсендәге тормышны, авыл крестьяннарының, шахтада бил бөгүчеләрнең истә калырлык образларын да бирел бара.

Шагыйрь һәм прозаик Шәйхи Маннурның балалар өчен язган әсәрләре дә күп. Ул кечкенәләр һәм мәктәп яшендәгеләр психологиясенә хас үзенчәлекләрне яхшы белә, шигырь, поэма, хикәяләрен кызыклы итеп, бала күңеленә үтеп керерлек итеп яза.

Ш. Маннур фидакарьлек, зур осталык сорый торган әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә бирелеп эшләде. Пушкин, Лермонтов, Шевченко, Җамбул, Стальский, М. Бубеннов,

С. Михалков, К. Паустовский әсәрләрен татар телендә яңгыратуы өчен китап укучыларыбызның аңа рәхмәте зур.

Ш. Маннур ярты гасырлык иҗат гомерендә очерк һәм публицистик язмалар, кыю тәнкыйть мәкаләләре авторы сыйфатында да актив чыгыш ясаучы әдип.

Әнә шундый күпкырлы иҗат кешесе ул Шәйхи Маннур. Аның әдәби эшчәнлеге хөкүмәтебез тарафыннан югары бәя алды: ул 1939 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1957 елда «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнде. Әдәби тәнкыйтьтә, әдәбият тарихында да (Г. Ахунов, Н. Юзиев һ. б. мәкаләләре) Ш. Маннурның «Чуен ташкыннар», «Гайҗан бабай», «Казан кызы» һәм башка күп әсәрләре татар совет әдәбияты хәзинәсендә урын алган әсәрләр итеп карала.

...Моннан егерме еллар элек әдибебез:

**«Ник ямасың!» — диләр дуслар миңа,**
**Яши алмыйм шул мин ямыйча;**
**Кешеләрнең күңел почмагына**
**Энҗедәй дә якты салмыйча,**

— дигән иде.

«Кешеләрнең күңел почмагына якты салу» дөньяда иң мактаулы эшләрнең берсе бит ул!

**ЗӨФӘР РӘМИЕВ.**

# Шәйхи Маннур

## Гомер белән гомер арасы

I

Чыгыйк әле Идел ярларына,
Дамбалары буйлап әйләник.
Әллә нәрсә булды җаннарыма,
Күңелем дә тынмый әллә ник...

Чал Идел дә миндәй моңсу микән,
Уйнаса да кояш көлгәләп.
Шул дөньяны икәү гизеп иртән,
Йөрик әле, әйдә, бергәләп.

Җитәкләшеп,
Бер сөйләшеп йөрик,
Сабыйлардай чәчләр тузгытып.
Сабыйлыктан ерак китсәк тә бик,
Ераклыкны гел дә онытып...

Мин аңламыйм, аңлый алмыйм һаман:
Нигә болай килеп чыкты соң?
Син тик уйнап әйткән татлы ялган
Ирлегемне җиргә екты соң?..

Каршы килдем, инкарь иттем сине,
Күрешмичә йөрдем күп көннәр...
Тик барыбер җиңде, йотты мине
Синең белән гизгән тын төннәр,

Тургай тыңлап каршылаган таңнар...
Болар да соң ялган булырмы?
Җуелырмы бар да эзсез алар,
Ком баскандай яшел болынны?..

Бер нәрсә дә,
Хәтта бер сулыш та
Күңелләрдә уелып калмасмы?
Җаннар җанга уртак омтылыш та
Үкенечкә генә салмасмы?
Юкка йөрәк сызып янмасмы?..

II

Чыгыйк әле Идел буйларына,
Дамбаларын икәү әйләник.
Тынгы тапмыйм һаман уйларыма,
Күңелем дә үсми әллә ник...

Әллә нигә һаман боек йөрим,
Нидер җуйган төсле эч поша.
Сәбәпләрен эзлим,
Мәгәр белмим,
Капма-каршы хисләр тартыша.

Җан теләмәс үкенечле көннең
Бер киләсен алдан сизенеп,
Биреләме гамьгә бу күңелем,
Сызланамы шуңа өзелеп?..
Өзелүләр кирәк микән аңа,
Кирәк микән җаның борчылу?
Идел ага,
Ярсый-тына,
Туңа!
Бар да уза —
Нигә моңсыну?..

Соң узмасы бармы бу дөньяның?
Кадерлесе бармы күңелгә —
Тик үзенә матур бер хыялның
Балкуыдай күкләр түрендә?..

Бармы синнән берәр сөенечем?
Көенеч кенә мәллә көйдерә?
Нәрсәң газиз икән минем өчен,
Нәрсәң җанга якын китерә?

Чыңлап чыккан бала тавышыңмы,
Шуклык уты чәчкән күзеңме,
Һәлак булган сөю сагышыңмы,
Сагыш кунмас ап-ак йөзеңме?

Көлә-көлә җылап китүеңме —
Уенчыгын җуйган сабыйдай,
Ул яшьләрнең шундук кибүеме·
Кояшлы бер энҗе яңгырдай...

Күбәләктәй, чәчәк сайлап кына
Очуыңмы яшел болында,
Сайлап кына,
Шулай сайрап кына
Йөрүеңме яшәү юлында,
Нәрсәң якын миңа?..

Җиңел генә итеп уйлавыңмы,
Җиңел генә «җиңүләрең»ме?
Малайнымы,
Абый, бабайнымы —
Үз чанаңа җигүләреңме?..

Нинди генә язмыш тукмаса да,
Имгәнмичә калган җаныңмы,
Әшәкелек сиңа йокмаса да,
«Әшәке!» дип чыккан даныңмы?

Өзгәләнгән күңел кылларыңның
Өзелмичә калган береннән,
Өзәләнеп чыккан йөрәк моңың
Тамчы-тамчы булып түгелгән
Җырларыңмы —
Нәрсәң якын миңа?..
Җавап эзлим:
Нәрсәң кадерле?

— Ашыкма! — дип яный акыл миңа,
Ә янар хис — өтә бәгырьне...
Сөюме бу?
Әллә юри генә
Изге хисләр белән уйнаумы?..
Күпме көннәр ялгыз йөри бирәм,
Чишә алмыйм авыр уйларны,
Чишә алмыйм...

III

Чыгыйк әле Идел ярларына,
Җитәкләшеп тагын әйләник.
Әллә нәрсә булды җаннарыма,
Рәхәт миңа бүген әллә ник.

Юк, әллә ни түгел,
Сөйлим әле,
Төш белән өн тәңгәл килүен:
Мин үзем дә белмәс серләремне
Кинәт кенә ачып бирүен.

Җырлап уяндым мин бүген иртән
Әллә нинди матур бер көйгә.
Тавышым да шундый көчле икән:
Күкрәгемнән күкрәп бәркелә!

Гомеремдә һичбер ишетмәгән,
Җырланмаган бер көй иде ул.
Әллә керде бикле ишекләрдән,
Әллә кинәт күктән иңде ул.

Көн буена
Татлы исерүдән
Мин онытып йөрдем юлларны,
Гүя кемдер
Чын дус хисе белән
Бирде миңа бөтен дөньяны!

Бирде миңа күкнең тулган аен,
Йолдызларын,
Киек каз юлын,
Кояшка җыр илткән тургайларын,
Ак чәчәкләр яуган яз моңын.
Бирде миңа,
Бирде барлыгын!

Күп уйландым: тукта, нәрсә булды?
Ник уяндым җырлап бу таңда?..
Кинәт бу Җир кояш белән тулды —
Син икәнсең күңел уртамда!
Син икәнсең!

Йөрим, йөрим хыял юлларыннан,
Куанычым сыймый дөньяга.
Җир йөзенә
Күкләр ерагыннан
Мин белмәгән сихри моң ява!

Инде күптән ал гөлләре көйгән
Буш даладай йөрәк түрендә,
Башлап Орфей кылларыннан килгән
Көй яңарыр, диеп, бүген дә —
Кем уйлаган?
Кем соң?..
Хәзер инде
Мең сорауга миндә бер җавап:
— Ишет, дөнья!
Миңа сөю килде!
Мин яратам!
Миңа кул янап
Торма, гореф!
Югал, йола, күздән,
Баш күтәрмә, акыл, син миңа!
Мин барыбер курыкмамын сездән,
Кул сузмагыз изге тойгыма!

Шул барлыгы белән кабул итәм,
Шул «яманат» белән яратам.
Кояшта да тап бар, имеш, күптән,
Тик саф алсу булып яна таң!

Без китәрбез җитәкләшеп бергә,
Тар итсәгез бу киң дөньяны.
Кошлар гына яши торган җиргә
Тапмабызмы яшерен юлларны?..

Тау өстендә әләм җилфердәтеп
Тукталгандай әкият батыры, —
Тормасмыни сирпеп сөю дәртен,
Мәхәббәтнең зәңгәр чатыры?
Тормасмыни?..

## IV

Төшик әле Идел ярларына,
Дамбалары буйлап йөрербез.
Уралышып шәфәкъ алларына,
Соңгы тапкыр бәлки бүген без
Узабыздыр моннан синең белән
Җитәкләшеп,
Көлеп,
Шукланып.
Күңелләргә тулган сөю белән
Идел кичләренә сокланып...

Акчарлактай ак лайнерлар килер,
Тын көзгесен ярып суларның.
Таулар тибрәндереп гудок бирер,
Тавышлары моңлы шуларның...
Гел аерылу төяп йөри алар,
Кавышулар булса — йөзгә бер.
Акчарлаклар нигә моңаялар?
Сагышлары бәлки безгәдер...

Безгә дә бит, ахры, шул таң ата.
Котылуның бармы чарасы?
Арабызда, имеш, Көндәш ята —
Гомер белән гомер арасы!

Диңгез давылыдай дуласам да,
Акыл тоткан кысып якамнан:
Тезләнеп, мин
Колдай сорасам да,
Ваз кичәргә куша «хатам»нан.

— Юк, алданма, мескен! — ди ул миңа,
Бу хисләрең — көлке фаҗига.
Ут белән су бергә кушылмый ла!
Билгесезме чалбаш сабыйга?..

Ни кылыйм соң?
Алчак күңелемнең
Каршылыгы җитәр күпмегә?..
— Иртәгәсе бар,— ди,— бүгенгеңнең! —
Акыл — кансыз!
Акыл — күп белә.

Юк, ышанмыйм аның сүзләренә.
Бу бөтенләй башка. Бөтенләй!
Кабат төшеп яшьлек эзләреңә,
Кабат сөеп,
Яныл бетүдәй
Олы бәхет
Кемгә тигән соң?
Кемгә килгән соң?..

## V

Чыгыйк әле Идел ярларына,
Сулыйк аның җиләс һавасын.
Яралы кош төсле җаннарыма
Тапмасам да
Өмет дәвасын,
Йөрик әле бу кич буйдан-буйга,
Дамбаларын кат-кат әйләнеп.
Кулларыбыз кулга,
Уйлар уйга
Лианалар кебек бәйләнеп.

Сөйлим әле сиңа «яңа» хәбәр,
Әлмисактан килгән ул хәбәр.
Ике ярым мең ел миңа кадәр
Булган икән инде бу хәлләр.
Илледәге мәшһүр философның
Егермедә булган сөйгәне...
Нидә икән сере бу гыйшыкның?
Әллә картның
Күп булганмы алтын дигәне?..

Юк, Афина буйлап, ялан аяк
Калдырган ул сүнмәс эзләрен.
Тик кулында булган артыш таяк,
Һәм ияртеп йөргән гүзәлен.

Ник артыннан гизгән ул яшь хатын
Бер бакырсыз булган картының?..
Әйтми безгә тарих артыгын...
Бәлки җыры
Кабызгандыр изге ялкын?..

Ул фәлсәфи җырны өзгәләп,
Алып килгән Заман безгә дә:
«Белмим,
Һични белмим,
Нигә сине
Бу хәтле мин өзелеп сөямен?
Сорама син миннән, и таң җиле,
Мин бит, һични, һични
Белмәвемне генә беләмен!..»

Дөнья гизгән Гашыйк ялан аяк,
Шушы җырны көйләп гүзәлгә.
Тик кулында булган артыш таяк
Олимп тауларына менәргә...

И Кешелек!
Ник сабыйлык чорың
Шулай бик тиз узып югалган?
Ник килмәгән шул гадилек Чының
Бу заманга
Ерак еллардан,
Ник килмәгән?..

Төкереп бер гореф-гадәтләргә,
«Ярамый»га, «Яхшы түгел»гә;
Һәм төкереп зәһәр гайбәтләргә,
Тик буйсынып сөяр күңелгә, —
Йөрмәс идеммени
Мин дә шулай
Ялан аяк
Идел итәкләп,
Табигатьнең бәйсез баласыдай,
Кулларыңнан сине җитәкләп.
Көпә-көндез,
Дөнья күз алдында
Иңнәремә сине күтәреп,
Сине генә назлап җырларымда,
Юлларымда
Таулар түнтәреп
Йөрмәс идеммени?..

VI

Флейталар кайгы көен суза,
Курайларда сагыш моңнары,
Күңел умартамнан
Кортлар туза...
Булмады шул...
Берсе булмады...

Идел ярын урап
Атлыйм ялгыз,
Дамбалар буш,
Дөнья күңелсез.
Ник суына җырлар?
Ник гөл җансыз?
Ник берегез
Мәңге түгелсез?..

Ник кабына сөю?
Ник югала,
— Мәңгелек бу! — дигән чагыңда...
Ялгыз гизәм бүген бу юлларда,
Син юк инде минем янымда.

Кая киттең мине ялгыз итеп?
Ничек кичерим мондый гарьлекне?
Күңел китек синсез,
Җаным китек...
Юк, син түгел моңа гаепле...

Үзем бирдем сине ят кулына,
Тәхетемне үзем калдырдым.
Һәм салават күперен дә шуңа
Үз кулларым белән яндырдым.

Ул барыбер кавыштырмас иде, —
Сүнә бит нур кояш иңүгә...
Суык кулдай суык акыл җиңде,
Үлем килде актык сөюгә.

Көймәбезне
Упкыннарга бордым,
Шул әчке дау чиктән ашканда...
Понти Пилат кебек
Сукыр тордым,
Мәхәббәтне акыл асканда.

Дәшми калдым.
Телсез...
Ә үземнең
Йөрәгемә сауды кара кан.
Шулай үлде хыял җыры безнең...
Үзем сине һаман яратам!
Бу ярлардан һаман бергә узам,
Бар да шул күк тирә-ягымда.
Җитәкләргә теләп кулны сузам,
Тик табалмыйм сине янымда...

Ак сакаллы акыл издә мине,
Теләмәде көлке булуны.
Ә хәзер мин көлке түгелмени?
Чыпчык алдым...
Биреп былбылны.

Ак сөенеч булып яшеренгән
Ак былбылым очып югалды.
Ник баш тарттым
Синең яшьлегеңнән?
Дөньям хәзер суык,
Томанлы.

Нигә бирдем сине Көндәшемә,
И билгесез ана баласы!..
Юк идеме көчем көрәшергә?
Юк идеме җиңү чарасы?..

Булмады шул...
Чигенергә кушты
Гомер белән гомер арасы.
Тотып булмый бер очырган кошны,
Мин китәсе,
Ә син — каласы...
Үпкәләмә инде, күңел якты м,
Үкенүләр басмый яраны.
Ялан аяк сөйгән теге Картның
Узган икән гамьсез заманы...

Узган гомер кайтмас,
Җыр табылмас,
Йолдызның да нуры сүрелә.
Иртәгә кич бәлки
Ул кабынмас,
Кабат менмәс күкләр түренә...

Гомер табылмаган гыйшкым сыны,
Бар йөрәгем,
Җаным синеке.

Ямьсезме син,
Белмим, матурсыңмы?
Нинди генә булма — сөекле!
Тик шулай да
Синнән баш тартам,
Үзем һаман үлеп яратам!..

Суламифен җуйган Сөләйманның
«Җырлар җыры» килгән... чүлләрдән.
Мин ни бирим?..
Өзгәләнгән җанның
Актык моңы сиңа юнәлгән...

Хуш инде, хуш...
Идел ярын урап,
Сабыйлардай чәчләр тузгытып,
Сабыйлыктан китсәк тә бик ерак,
Аермалар барын онытып,
Төштәгедәй йөргән чагыбыз...
Хуш инде, хуш...
Күкнең тулган аен,
Йолдызларын, киек каз юлын,
Кояшка җыр илткән тургайларын,
Ак чәчәкләр яуган яз моңын
Безгә биргән сөю кичләре...

Хуш инде, хуш,
Кайнар яшьлек хисем,
Бетмәс җырым,
Актык сөюем.
Актык көнем,
Актык төнем килсен,
Күңелемдә һаман син минем
Таң йолдызым булып янарсың.
Хуш инде, хуш...

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

### ДЕКАБРЬ, 1973 ЕЛ

Воронеж авыр механик пресслар заводы коллективы КамАЗның еллык заказын вакытыннан элек үтәде, «К-2,5-35 А» моделендәге, югары җитештерүчәнлекле тугыз пресс әзерләде. Алар автомобиль рамнарын ясау өчен кулланылачак.

**«Советская Россия», Мәскәү.**

Чаллыда яңа типтагы, 320 урынлы «Алтын әтәч» балалар бакча-яслесе ачылды. Яңа ел алдыннан балаларга бу бүләкне «Соцкультбытстрой»ның «СМУ-11» төзүчеләре өлгертте. Алар бетоннан, пыяладан, металлдан һәм агачтан бөтен бер шәһәрчек кордылар.

Татарстан художество фонды осталары «Алтын әтәч» стеналарына чәчәктән чәчәккә, агачтан агачка төрле төстәге күбәләкләр, чикерткәләр, кошлар очып йөргән матур бакча рәсеме төшерделәр.

Җанлы почмакта да балаларга бик күңелле. Анда ботактан ботакка попугайлар очып йөри, аквариумнарда алтын балыклар йөзә, ә иртә белән, бөтен тирәякны яңгыратып, «алтын» әтәч кычкыра.

**«Правда», Мәскәү.**

КамАЗның төзелеш мәйданнарында еш кына гаять зур фургонлы автомашина күренә. Фургон стеналарына зур хәрефләр белән «Кинотеатр» дип язылган. Бу күчмә кинотеатр төзүчеләр арасында киң популярлык казанды. Аның экранында алдынгы хезмәт алымнары, прогрессив төзү конструкцияләре һәм материаллары, төзелеш индустриясе яңалыклары күрсәтелә. Алты ай эчендә аларны унбер мең чамасы төзүче һәм монтажчы карады.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

КамАЗ төзелеше тугызынчы бишьеллыкның төп төзелешенең үзәге булган Чаллы шәһәре тормышын тамырдан үзгәртте. Кама буендагы бу борынгы шәһәрнең халкы көннән-көн арта.

Автомобиль комплексын кору белән бергә, монда яшәүчеләрнең үскәннән-үсә барган таләпләрен канәгатьләндерү өчен продукция җитештерү дә зур темплар белән арта. Шушы елның башында Чаллыда куәтле суыткычы белән ит комбинаты сафка басты. Күптән түгел сөт заводы эшли башлады... Ул Венгрия Халык Республикасыннан килгән машиналар белән җиһазландырылган. Барлык товарлар кибетләргә сатып алучыларга уңайлы итеп, төреп чыгарыла.

**«Сельская жизнь», Мәскәү.**

Кама автомобиль комплексының ремонт-инструменталь заводында якшəмбе өмəсе үткəрелде. Аңа өч меңнəн артык кеше катнашты. Якшəмбе өмəсендə эшлəнгəн 3 мең 436 сум акча, Чили патриотларына ярдəм итү өчен, тынычлык фондына бирелде.

«Социалистическая индустрия» на строительстве
Камского автозавода».

Кама автогиганты өчен зур габаритлы пыяла кою буенча еллык заданиене Володарский исемендəге Курловск заводы коллективы вакытыннан элек үтəде. Чаллыга биш мең квадрат метр продукция җибəрелде. Бу пыялалар производство корпусларының тəрəзəлəренə һəм түбəлəренə куелачак.

ТАСС, Владимир.

Комсомолның Мəскəү шəһəр комитеты 1972—73 еллардагы иң яхшы əдəбият һəм сəнгать əсəрлəренə Мəскəү комсомолы премиялəрен бирү турында карар чыгарды.

Мəскəү комсомолы премиясенең беренче лауреатлары арасында РСФСРның халык артисты, М. Н. Ермолова исемендəге Мəскəү театрының баш режиссеры Владимир Алексеевич Андреев та бар. Аңа бу премия татар драматургы Д. Вəлиевнең «Сиңа тормыш бүлəк итəм» əсəрен сəхнəгə куйган һəм спектакльдə баш рольне башкарган өчен бирелгəн.

«Комсомольская правда», Мəскəү.

«Татарстан радиосының бүгенге барлык тапшырулары Кама автомобиль заводын һəм Чаллы шəһəрен төзүчелəргə багышлана...» Менə инде ике елдан бирле һəр атнаның шимбə көнне республика радиосы үзенең тапшыруларын шундый белдерү белəн башлый. Республика радиосы үзенең тыңлаучыларын бининһая зур төзелеш белəн, автоград районнары белəн, төзүчелəрнең күп миллəтле дус семьясы белəн таныштыра.

«Социалистическая индустрия» на строительстве
Камского автозавода».

Паневежис автокомпрессорлар заводында яңа куəтле технологик линия эшли башлады. Анда чыгарылачак барлык продукция — КамАЗ өчен. Предприятие коллективы агрегатларның беренче партиясен яңа ел башында җибəрергə йөклəмə алды.

ТАСС, Паневежис шəһəре, Литва ССР.

Шәүкәт Садыйков

# ПРЕДСЕДАТЕЛЬ

## Ел башланды. Ел дәвам итәр



Әйе, һәр яңа елны без үткәндәге уңышларга сөенеп, киләчәккә тагын да зуррак өметләр баглап, бәйрәмчә каршылыйбыз. Аның бусагасына ныклап торып аяк баскач, уйлыйбыз: ел башланды, ел дәвам итәр, һәм ул, һәр вакыттагыча, зур эштә, көндәлек көрәштә узачак. Ә иң мөһиме: яңа елда тагын да күркәмрәк казанышлар яуланырга тиеш.

Шулай уйлады Нурислам Кадыйров — районда иң зур хуҗалыкның җитәкчесе. Шулай уйлады ул ел тәүлеге башланганда, январь кичләренең берсендә, актив белән бергәләп бик мөһим документны укып тикшергәннән соң өенә кайтуынча. Кышкы җайсыз юлда да «газик»ны очырттырып кайткан шоферы Хафиз Гайнетдиновның, гадәтенчә, төрле мәзәкләр сөйләп баруына да председатель әллә ни колак салмады кебек. Чөнки әлеге документ — КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының 1973 елда авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне һәм хәзерләүне арттыру өчен авыл хуҗалыгы работникларының Бөтенсоюз социалистик ярышын җәелдерү турындагы карары иде.

Төнлә дә Нурисламны тиз генә йокы алмады, шактый вакыт уйланып ятты ул. Әйе, сигезенче бишьеллык заданиеләре әйбәт үтәлгән иде, биткә кызыллык килерлек булмады. Кесәсендә һәр вакыт йөртә торган калын дәфтәрендәге саннарны тагын бер мәртәбә күңеленнән кичерде. Ул бишьеллыкта колхоз дәүләт амбарларына пландагы 166 мең чамасы центнер урынына 329 меңгә якын центнер ашлык озатты. Ике миллион поттан артык икмәк бит бу! Шуңа өстәп 654 мең ярым центнер шикәр чөгендере сатылды. Элекке бишьеллыкларда мондый нәтиҗәгә ирешелгәне юк иде әле. Ит җитештерү ул еллардагыдан 42 процентка, сөт 40 процентка артты...

Әйе, «Гигант» кебек эре хуҗалыкны җитәкләүчегә бик күп нәрсәләр хакында уйланырга, «баш ватарга» туры килә шул. Колхоз алты комплекслы бригададан тора, унике авылны берләштерә. Аның бер як чигеннән икенчесенә җитәр өчен 34 чакрым үтәргә кирәк. Бу авыллар-

ның һәркайсы кайчандыр аерым бер колхоз булган. Төгәлрәк әйткәндә, күмәк хуҗалыклар оешуның тәүге елларында бүгенге «Гигант» территориясендә барысы унбиш колхоз булган. Хәзер исә Буа районындагы бу гигантның барлык авыл хуҗалыгы җирләре 12 мең гектардан артык, шуның 9 700 гектары — сөрүлек җир. Ә республика буенча сөрүлекләр бер колхозга уртача 4 мең ярым гектар чамасы туры килә. Тик әнә шул, кем әйтмешли, тәртә тыксаң тарантас үсеп чыгардай кара туфраклы шул җирләрдә илленче (колхозлар берләшкәнгә кадәр), хәтта алтмышынчы елларда да әле уңыш дигәнең беркемне дә канәгатьләндерерлек булмады. Терлекчелек буенча да эшләр хөрти иде. Әлеге вак хуҗалыклар күбесенчә дәүләттән бурыч алып яшәде. Авыл хуҗалыгын күтәрү өчен партиябез колхозларга техника белән дә, башка яктан да, шулай ук кадрлар белән дә төпле ярдәм итү чараларын күрде.

Шул уңайдан партия райкомы 1955 елның җәендә хәзерге «Гигант» колхозының үзәге булган Бюрган авылындагы колхозга председатель итеп, утыз менче сыйфатында, Хәзерләүләр министрлыгының район уполномоченные булып эшләүче Нурислам Җиһанша улы Кадыйровны тәкъдим итте. Колхоз членнары аны, үзләренең авылдашын, хуплап каршылады.

— Нурислам абый, шундый зур, җаваплы эшкә җигелгәч, беренче адымнарны атлау бик җиңелдән булмагандыр?— дип сорадым мин аңардан. Председатель бераз уйланып торды, гүя илле бишенче елны бүгенге «Гигант»ның гигант уңышлары белән чагыштырып, көрсенеп куйгандай итте.

— Ул елларны искә төшерәсе дә килми хәзер,— диде ул аннары. — Бер авыр төш кебек алар. Ләкин, ни әйтсәң дә, баштан үтте бит.. Ансат булмады, әлбәттә.

Һәм председатель сөйләп китте. Әйе, җиңелдән булмаган. Төп тарту көче булган атлар аз. Күбрәк үгез җигәләр. Яңа председатель кабул итеп алганда колхозның Дәүләт банкысындагы счетында нибары... 27 тиен акча була. Хуҗалык хәтле хуҗалыкта исә «юрганына карап аягыңны сузып» яшп алмыйсың. Һәм Нурислам үзенең уполминзагтан китканда алган айлык эш хакын, тиешле ял акчасын, үзенә һәм семьясына бирелгән подъемныйларны — җәмгысе мең сум (ул чагында ун мең сум) акчаны колхозның хуҗалык мөдиренә тоттыра да аны сәнәк-көрәк, тырма кебек иң беренче кирәк нәрсәләрне алырга җибәрә. Монысы экономика ягы. Ә халык белән эшләү, йөзләрчә кешеләргә «ярау» — аннан да катлаулырак. Яңа башлыкка каршылык күрсәтүчеләр, аңа усал кеше ул, без аны авыл советы рәисе булып эшләгән чагыннан бирле бик яхшы беләбез, дип бәя бирүчеләр дә була. Эленке-салынкы эшләүчеләр, «колхоз — диңгез, без — корабль, чапылдатабыз гына» дип, мыек астыннан хәйләле елмаючылар, «үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын» дип фикерләп, җәмәгать милкенә «минекеме әллә ул» дип караучылар белән дә эшләргә — барысын тәрбияләргә, яхшыга юнәлтергә кирәк.

Берсеннән-берсе зуррак кыенлыкларны җиңгәндә аңа, әле яшь, аз тәҗрибәле башлыкка, тумыштан, ата-бабадан килгән изге сыйфат — җир-анага, туган якка, аның кешеләренә мәхәббәт булыша. Бу изге сыйфатны егеткә утызынчы елларда колхоз төзешкән, аннары авыл советы рәисе булган, Ватан сугышында ил өчен баш куйган этисе Җиһанша агадан күчкән сыйфат дип тә белергә кирәк. Нурислам үзе дә 1943 елдан башлап фронтта була һәм армия сафларында җиде ел рәттән хезмәт итә. Сапер-понтончы булып, ул Днепр, Березина, Неман, Висла, Одер елгаларын кичә. Күп тапкыр дошман тылына разведкага йөри. Җиңү көнен Берлин тирәләрендәге Штейтен дигән шәһәрдә каршылый.

Озын юллардагы һәр адымда, походларда үткән һәр минутта егет йөрәгендә Ватанга һәм туган җирләргә әнә шул мәхәббәт ялкыны сүнмичә-сүрелмичә дөрли.

Ә хәзер ул икенче төр разведка остасы булырга тиеш: колхозны күтәрү чараларын һәм резервларын табарга! Алар, әлбәттә, бар. Тик «туфракның өске катламында» түгел, ә тирәндә яталар. Димәк, «казып чыгарырга» кирәк.

Шундыйларның берсе итеп Нурислам колхозда механик тегермән салдыра, шунда эшләргә иң тәҗрибәле механизатор Михаил Горбуновны куя. Тегермән янында аның белән бергә үк төзелгән яңа ашханә эшли башлый. Чөнки ак он тарттырырга тирә-як авыллардан, күрше Тәтеш һәм ул вакыттагы Тархан районнарыннан гына түгел, бәлки Ульяновск өлкәсеннән дә кышын-җәен берөзлексез килеп торалар. Тегермән беренче елны ук хуҗалыкка 38 мең сум табыш китерә.

Кадерле тиеннәрне шулай санау, аларны ишәйтү юлларын эзләү башлана һәм хуҗалыкны алып баруның төп законы буларак дәвам иттерелә.

## Кыш уңыш әзерли

Нурислам, гадәтенчә, иртән сәгать биштә торып, идарәгә килгәндә, бригадирларның күбесе анда иде инде. Кичтән бирелгән нарядларның ничек үтәлергә тиешлеге турында конкрет киңәшләшеп, аларга өстәмә күрсәтмәләр биргәннән соң, председатель фермаларга китте. Хәзер анда аеруча җаваплы чак (хәер, терлекчелектә ул ел әйләнә шулай инде): кышкы суыкларда да сыерларның сөте кимемәсен, симертүдәге мал-туар тиешенчә көрәйсен. Моның өчен кырыс контроль булдырып та, фермада эшләүчеләргә киңәш белән дә, конкрет оештыру чаралары күреп тә ярдәм итәргә кирәк.

Аннары — идарәдә киңәшмә. Шулай ук таңнан торып килгән партком секретаре Симунов, баш агроном Чашкин һәм бүтән берничә иптәш утыра.

Кыш уңыш әзерли дип тикмәгә әйтелми. Җирле ашламалар туплау, аларны дөрес саклау, кар тоту, чәчүлек орлыкларның сыйфатын даими тикшерү, механизаторларны һәм бүтән кадрларны укыту, техниканы ремонтлау — болар барысы да көн кадагы итеп сугылырга тиешле мәсьәләләр һәм мәшәкатьләр.

Арада тагын бер мөһиме: ярыш нәтиҗәлелегенең нигезе булган социалистик йөкләмәләрне җентекләп эшләү. Элегрәк колхозда башта хуҗалыкның бөтен коллективы, аннары бригадалар, фермалар үз йөкләмәләрен кабул итә иде. Аларны, гадәттә, колхозның һәм производство бүлекчәләренең җитәкче работниклары гына эшли, алар коллективларда киң тикшерелми иде. 1973 ел башыннан партком, колхоз идарәсе һәм профком индивидуаль йөкләмәләр әзерләүгә, аларны тикшерүгә игътибарны көчәйттеләр. Башта һәрбер терлекче, механизатор яки бүтән колхозчы үзенең шәхси план-йөкләмәсен эшләде һәм кабул итте, бер-берсе белән үзара социалистик ярыш договоры төзеде. Индивидуаль йөкләмәләр нигезендә бригадалар, фермалар һәм башка бүлекчәләрнең йөкләмәләре эшләнде. Аларның ярыш договорлары төзелү коллективлар җыелышларында тикшерелде һәм расланды. Шулай итеп, биредә һәркем һәм һәр коллектив ярыша һәм көч сынаша. Ярышның массовыйлыгы әнә шуннан гыйбарәт тә.

Бүген исә идарә, партком һәм профком, индивидуаль һәм коллектив йөкләмәләр җирлегендә гомум колхоз социалистик йөкләмәсен, күрше «Родина» колхозы белән ярыш шартларын һәм договорын эшләп утыра.

Халыкның зирәк әйтеме әнә шулай ди. Һәрбер хуҗалыкта моны, әлбәттә, онытмыйлар. Әмма язга яз туры килмәгән кебек үк, төрле колхозларда әлеге «Көз гамен уйлауда»да аерым үзгәлекләр була.

Кояш югарырак күтәрелеп, күңеллерәк елмая, шифалы җылысын юмартрак сибә барган саен, игенченең мәшәкатьләре, эштәге дәрте дә арта бара.

Мартның күңелләрне хуш итә торган якты, тын иртәләренең берсендә председатель, баш агроном һәм партком секретаре кырларда йөреп кайтырга киттеләр. Кояш нурында күзне чагылдырып торган ап-ак кырларда кар эри башлап, күгелҗем төс алган урыннар шактый күренә. «Боларның боз катламына әйләнүе мөмкин. Уҗым өчен бик хәтәр нәрсә. Язгы үсүгә уянгач, аны тончыктыра, черетә торган боз ул. Шундый урыннарга көл яки торф сиптерергә дигән нәтиҗә ясала.

Уҗым бодае басуына аеруча тукталдылар. Ничек икән моның кар «юрганы?» Чатнама суыкларда өшетмәде микән? Тукталуның хикмәте менә нәрсәдә. 1972 елның көзендә колхоз, тәҗрибә өчен һәм беренче тапкыр, 50 гектарга «Мироновская 808» сортлы бодай чәчкән иде. Ләкин, көзге яңгыр вакытында булмау сәбәпле, ул урыны-урыны белән генә, бик сирәк тишелеп чыккан. Кадыйровның бервакыт моны: «Менә минем баш түбәмдәге сирәгәйгән чәчләр кебек»,— дип көлдереп аңлатканы бар. Нишләргә? Ничек кышлап чыгар бу? Әгәр берни җыеп алалмасак, җир әрәм китте дигән сүз. Әллә көздән үк культивацияләп ташлыйкмы? Язын кабат эшкәрткәч, сабан культурасы өчен менә дигән басу булачак. Әмма сынап карыйсы да килә. Председатель партия райкомының беренче секретаре Сәлимуллин белән киңәшләшә:

— Без аңа тимәскә, сынап карарга уйлыйбыз. Сез ничек карыйсыз икән?

— «Гигант» аннан гына ярлыланмас әле, сынарга дисез икән, сынагыз!..

Яңалык кертү өчен шундый сынап караулар биредә әледән-әле үткәрелеп тора.

Колхозда иртә сабан культураларын чәчү алдыннан җирне ике тапкыр культивацияләү кагыйдә итеlә. Басу беренче тапкыр, дым каплау артыннан ук, 14—16 сантиметр тирәнлектә, ә икенче тапкыр — чәчү алдыннан, орлык күмдерү тирәнлегеннән 9—10 сантиметрга тирәнрәк культивацияләнә. Бу агротехник алым чүп үләннәрне яхшырак бетерә һәм уңышны һәр гектардан 1,5—2,5 центнерга, хәтта аннан да күбрәккә арттыра. Ике мәртәбә культивацияләү орлыкның кирәкле тирәнлеккә күмдерелүен дә ышанычлы итә.

Язгы кыр эшләре вакыты басуларда моторлар гүләве, орлык яки ягулык ташучы машиналарның тузан очыртып өзлексез йөреше, игенчеләрнең иртә таңнан алып кичке караңгыга кадәр аяк өстендә булулары белән, ыгы-зыгы килүләре белән, ничектер, фронт кырларын хәтерләтә кебек. Идарәдә, ягъни шул фронтның штабында — әледән-әле телефон шалтырый. Председатель шуны тыңларга һәм шуның аша тиешле күрсәтмәләр бирергә дә, кырда һәм фермаларда булырга да, кабинетында кешеләр кабул итәргә дә өлгерә. Бүлмәсендә өч телефон: берсе — районнан гадәти коммутатор телефоны, икенчесе — партия райкомыннан шунда турыдан-туры үткәрелгән телефон («СССР Верховный Советы депутаты булып сайлангач керттеләр»,— ди Нурислам). Мондый элемтә аңа райком бюросы члены буларак та бик кирәк. Өченче телефон — эчке АТС челтәренеке. Автомат телефон станциянең барлык производство объектларына (янгын депосыннан алып ку-

нак йортына кадәр) 80 ноктасы бар. Барча белгечләр, бригадирлар, ферма мөдирләренең өйләренә теләсәң кайчан шалтыратып була. Председатель: «Үзем йөри торган «газик»ка да радиотелефон кертерәм әле»,— дип хыяллана. Чөнки эштә оператив булырга кирәк. Бу инде — АСУга (идарә итүнең автоматик системасына) таба бер адым.



## Агымдагы көндәлек эшләр...

Председательнең эш көне көзге-кышкы айларда иртән сәгать биштә-алтыларда, ә язын-җәен исә аннан да иртәрәк — кояш чыгу белән бергә башлана. Участокларны карап чыкканнан соң, ул — идарәдә.

Менә экономист ярдәмчесе Валентина Землямерова килеп керде:

— Нурислам абый, миңа характеристика кирәк иде.

— Беләм, сеңелем. Хәзер язарлар.

Кыз чыгып киткәч, Нурислам әйтте:

— Сарык карачы булып эшли иде.— Колхоз хисабына Лаешка укырга җибәрдек, аена 45 сум түләп тордык. Бетереп кайтты. Әйбәт кенә эшли. Инде хәзер институтка керергә тели. Каршы килмәдек. Укысын. Без кадрларны үстерүгә биш куллап риза.

Телефон шалтырады.

— Кадыйров тыңлый. Биектаудан?.. Насос станциясе?.. Нинди? «СНП-75/1007». Машина җибәрергә? Аңа ЗИЛ кирәктер инде, ГАЗ гына ярамас...

Аннары бригадирлар җыелды. Инде Кадыйровның көнлек нарядлар язып куела торган, бик күп графаларга бүленгән калын журналы ачык. Заданиеләр бирү башлана. Киләге язып барылырга тиеш.

— Иртәгә карабодай һәм тары чәчүгә керешәбез. Тары орлыкларын суда чылатырга, юдырырга онытмагыз.

— Мин иртәгә керешә алмыйм,— ди икенче комплекслы бригада бригадиры Степанов. Нәрсәседер әзер түгел әле, күрәсең.

— Син,— ди председатель,— бишкә ярыл, әмма чәчүгә чыкмый калу мөмкин түгел! Аннары борчак, чөгендер шытымнарын тырмалауны башларга.

Менә, эшкәртү һәм карау өчен, чөгендер участокларын бүлеп бирү турында күрсәтмә:

— Партбюро һәм авыл советы вәкилләре белән бергә бригада советын җыегыз. Колхозчылар арасында тегеңәргә фәлән хәтле, ә миңа фәлән гектар бирәсез, дип, ризасызлык белдерүләргә юл куймыйк. Заготзерно «интеллигентларына» да участок бирергә кирәк.

Ул әле урыныннан торып баса, әле яңадан утыра. Кайчак кызыпдулап та алгалый, кемгәдер, нәрсәнедер бик кырыс, каты итеп тә әйткәли. Ә кайберәүләрне тавышын йомшартып нәсихәтли. Урыны белән шаяртып, көлдереп тә куя. Андый чакта гел чувашча сөйли торган гадәте бар (чуваш телен ул үзенең ана теледәй яхшы белә). Ләкин шунысы ачык: кемгәдер кызып, каты бәрелсә дә, кем беләндер мәзәк сөйләп шаяртса да, берәүнең дә аңа хәтере калмый, ул кырыс булганда — бик җитди тыңлап торалар, ә шаяртканда — үзе белән бергә рәхәтләнеп көләләр. Күрәсең, аны дөрес аңлавы бер дә кыен түгел. Димәк, авторитет ул — эш урыны, «башлык креслосы» түгел, ә шәхси үрнәгең, эшкә бирелгәнлегең, әхлакый җитлеккәнлегең, кешеләр белән мөнәсәбәттә гадел булуың белән яулана торган нәрсә.

Нурислам, «колхозлар берләшкәнче, бу хуҗалык территориясендә миңа хәтле 138 председатель эшләгән» дип шаян һәм кызыклы сан китергән башлык, «Гигант»та бер алмашсыз инде егерменче ел эшли. Симунов белән Чашкинның да колхоздагы хезмәт стажлары шул чама. Шунысын да әйтү урынлы: Нурислам Александр Чашкин белән тугы-

зынчы класска кадәр бер партада утырып чуваш мәктәбендә укыган, чөнки ул чакта бирелә татарча башлангыч мәктәп кенә була.

Колхоз тракторда һәм комбайнда инде унбишәр-егерме бишәр ел эшләүче Проворов, Сөләйманов, Кондратьев, Горбунов, Хөснетдинов, Терентьев, Кузьмин, Малышев кебек механизаторлары белән бик хаклы горурлана.

— Бездә бөтен бер династия саналган механизаторлар бар,— ди Нурислам.— Мәсәлән, комбайнчы Семен Вериялов. Хатыны Вера — аның ярдәмчесе. Әтисе — комбайнчы, бабасы һәм энеләре — комбайнчы...

Председатель андыйлар турында бирелеп, зур хөрмәт һәм ярату белән сөйли.

Бригадирлар белән сөйләшү дәвам итә.

— Сыерларга яшел арышны чабып, араннарына ташып ашатырга кирәк. «ЖБА-3,5»ургычлары белән.

— Куалап кертеп кенә ашатыйк, кишәрлекләп... Элек шулай эшли идек бит,— диде берсе.

— Һич ярамый! Искергән методка кире кайтмыйк. Сыерларның холкын беләсең. Алар, ашаудан бигрәк, бутап чыгалар. Яшел азыгыңны таптап, пычратып бетерә... Чабылган хәтлесен үлчәп, гектардан күпме яшел азык чыгуын чамалыйк.

Наряд бирү тәмамлангач, бүлмәдә башлыклар үзләре генә һәм шулар җөмләсендә баш зоотехник Хәбибуллин калды.

— Әйдә, энем, киңәшик-сөйләшик әле, савым сыерлар өчен яшел конвейерны син ни формадарак булдырырга ниятлисең?

Зәет куен кесәсеннән блокнот чыгарды, андагы язмаларга, саннарга карап, үз планнарын бәян итте. Киңәшләшкәч, савым сыерларга күпме яшел масса кирәклеге ачыкланды.

— Конвейерны тиешенчә гамәлгә ашыра алсак, сөт конвейеры — сөт чишмәсе дә саекмас,— диде Нурислам.— Башлыйк, оештырыйк, җитәклик, иптәшләр.

Кояш баерга күп калмаган иде инде. Юл уңае булганга, колхозның кунак йортына чаклы Нурислам белән бергә атладык. Юлда бөкрәю-бөгелүдән ияге җиргә тия язган, кулына ниндидер тимер-томырлар тотып вак-вак адымнар белән ару гына килүче бер бабай очрады.

— Нихәл, кәефләр ничек?—дип ягымлы эндәште аңа Нурислам.

— Безнеке билгеле инде, скуры — тегендә китәргә,— диде бабай, туктап бераз сулу алгач.

— Анда ашыкмыйк әле, бабакай, әле бер дә бирешкәнгә охшамыйсың.

— Кая инде ул, әтмә инде. Безнеке санаулы хәзер,— дип сөйләнә-сөйләнә атлавын дәвам итте карт.

— Фомин бабай ул безнең, авылда шулай дип йөртәләр,— диде Нурислам.— Үзе рус, хәзер татарча гына сөйләшә. Яшь чагында, гражданнар сугышы елларында, кайдадыр Карпат якларында Буденный, Ворошилов командалыгындагы гаскәрләрдә сугышып йөргән. Монда кайткач, гомере буена тимерче булып эшләгән, менә диген оста саналган. Әнә бит әле дә кулыннан тимер-томыр төшми. Үзе пенсиядә. Тик аны алырга беркайчан керми, өенә илтеп бирмәсәләр, айлар буе күренеп тә карамый. Колхоз түләүсез ашата үзен, йортын караша.

— «Кешегә калган көнең — таң атмаган төнең»,— дип яшәми, димәк.

Кунак йортына кердек. Анда безне пешекче һәм кунак йортын карачы Феня җиңги каршылады.

— Ай-яй, Феня, тазаргансың бу араларда!—диде Нурислам, сиздерми генә елмаеп.

— Авырыйм әле, көлмә,— диде тегесе уфтанулы итеп.
— Ни булган тагы?
— Белмим. Нәстәдер, кәеф начар. Каты авырып китмәсәм ярар ие.
— Баш катырма юкка. Кияүгә бирерлек әле син. Тик кызыңның бәби туен үткәрәсең бар.
— Анысы шулай шул,— дип көлеп куйды Феня үзе дә.

Кунак йорты кайчан керсәң дә чиста һәм пөхтә булыр. Затлыдан да затлы җиһазлар. Өстәлдә матур җәймә, чәчәкләр. Теләсәң — радио тыңла, газета-журнал укы. Феня җиңги һәм аның кызы Галя аш-суны тәмле һәм төрле-төрле итеп әзерлиләр. Бер булганнан барысы да була икән шул. Мондагы ашханәдә, килүче-китүчедән тыш, колхоз идарәсенә башка авыллардан килеп эшләүчеләр дә туклана. Самолеттан үсемлекләр тукландыручы очучыларга (алар кунак йортының бер бүлмәсендә тора) Феня җиңги яки Галя ашларны аларның эш урыннарына — кырга, аэродромга илтәләр...

## Уруга кадәр—мең эш, уру—бер эш

Узган елның җәе Апас, Тәтеш, Буа, Чүпрәле якларында авыл хуҗалыгы культураларыннан әйбәт уңыш үстерү өчен яхшы килде. Ләкин бу як игенчеләрнең бөртеклеләрдән һәм башка культуралардан мул уңыш җыеп алуларын бары тик яңгырларның вакытында явуына яки төрле стихияле бәла-казалар булмавына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Моны «Гигант» колхозы мисалында ачык күрсәтергә мөмкин. Яңгырлар һәр төштә бердәй диярлек яуды, ә шулай да, уңыш дигәнең, ни әйтсәң дә, төрле хуҗалыкларда төрлечә булды бит. Монда, димәк, көзге уңышны игенченең ел әйләнәсе буена куйган хезмәте хәл итә дияргә кирәк.

Биек булып дулкынланган арышлар, бармак юанлык тук башаклы бодайлар яшь баланы карагандай тәрбияләп үстерелә бит.

Шулай итеп, игеннәрне уруга кадәр башкарылганы — мең эш булса, уру үзе — бер эш. Ләкин игенченең бөтен тырышлыгына йомгак ясый торган, хәлиткеч эш ул. Шуның өчен дә «Гигант» колхозында уракка чыгуга фронтта зур штурмга хәзерләнгәндәй хәстәрлек күреләр. Моңа җентекләп төзелгән эш планнары, комбайннар һәм ургычларның төзеклеген һәм көйләнешен кат-кат тикшерү, комбайннар группаларына автомашиналарны иң оста йөрткән шоферларны беркетүләр, күчмә мастерскойның сугышчан хәзерлектә булуы кебек бик күп нәрсәләр кирә. Бригадирлар, белгечләр, сыйфат инспекторлары һәр басуда игеннәрнең өлгерүен көнләп түгел, ә сәгатьләп күзәттеләр. Чөнки уңышны югалтусыз җыеп алуның нигез кануннарыннан берсе — ура башлау моментын кулдан ычкындырмау. Бу көннәрдә Нурислам Кадыйров төн йокламады диярлек, бөтен игътибары белән әнә шул стартны уңышлы башлап җибәрү минутларын күзәтте. «Сине өйдә күреп тә булмый инде...» — дип, гадәттә зарланып та ала торган хатыны да андый вакытларда председательне борчымый торган була.

Өлгерә-җитлегә барган басуларга ургыч агрегатлары бер-бер артлы чыга торды. Механизаторлар беренче көннәрдән үк вакыт белән исәпләшмичә, кара таңнан торып, кичке эңгер-меңгергә кадәр батырларча эшләде. Алдынгы агрегатлар, мәсәлән, көненә норма буенча 10 гектар урынына 15 әр гектар борчак чапты .«ТАССРның атказанган механизаторы» исеменә лаек булган комбайнчы Кондратьев «ЖБА-3,5» ургы-

чы белән борчак чабуда үзен аеруча танытты. Коммунист Михаил Горбунов 20 елдан артык инде комбайнчы булып эшли. «Аның кебек комбайнчы Татарстанда юк»,— ди Нурислам. Шул җәйне ул 8212 центнер ашлык җыеп суктырды.

Нәтиҗәдә һәркемне сөендерерлек, игенче күңелендә үзенең тырыш хезмәте өчен горурлык хисе уятырлык йомгаклау финишына киленде: колхозның 6080 гектар мәйданында бөртеклеләрнең уртача уңышы гектардан 33 центнер булды. 3200 гектар сабан бодае исә 38 әр центнер бөртек бирде. «Харьковская 46» сортлы сабан бодаеның 80 гектарлы басуында һәр гектардан 48 әр центнер уңыш чыкты. Куанычлы рекорд димичә, нәрсә диярсең моны?! Сугышка кадәрге елларда гектардан 100 пот уңыш алу зур казаныш санала һәм җырларда җырлана иде... Гектардан 768 пот бит!

*
* *

Колхозда коммунистик хезмәт өчен хәрәкәт елдан-ел киң җәелә бара. Коммунистик хезмәт ударнигы исемен алу өчен 450 кеше ярыша. 182 кешегә бу мактаулы исем бирелде дә инде. Шунысы да гыйбрәтле: бу хәрәкәттә иптәшләрчә үзара ярдәмләшү, артта калучыларны алдынгылар дәрәҗәсенә кадәр күтәрү, алдынгылар тәҗрибәсен барысының да казанышы итү кебек әйбәт традиция туды. Мәсәлән, 2 нче комплекслы бригада узган елда басуларны туңга сөрүдә беркадәр артта калды. Аңа ярдәмгә 1 нче комплекслы бригада механизаторлары килде һәм эштә гомуми күтәрелешкә ирешелде. Яки менә икенче бер мисал. 6 нчы комплекслы бригадада шикәр чөгендерен казып алганда һич тә уйламаган-нитмәгән кыенлыклар туды. Ярдәмгә ярыш буенча аларның «көндәшләре» — 5 нче бригада механизаторлары килде. Колхоз үзе дә күршеләренә булыша. Бөртеклеләрнең тезәмнәрен җыеп суктыруда Кыят тәҗрибә-производство хуҗалыгында «Гигант»тан җиде комбайн эшләде.

Иптәшләрчә үзара булышуның кайберәүләргә үзе сайлап алган профессияне бик яхшы үзләштерергә һәм шул нигездә алдынгылар рәтенә чыгарга ярдәм итүе турында да мисаллар күп. Гөлфия Вәлитова мәктәп тәмамлаганнан соң ук фермага эшкә килде. Әлбәттә, кызның тиешле күнекмәләре юк иде әле. Башта ул шактый күп кыенлыклар кичерде, югалып калырдай булды. Шул чакны аңа ярдәмгә колхозның иң яхшы савымчысы, Хезмәт Кызыл Байрагы Ордены кавалеры Тәнзилә Рәхимҗанова килде. Хәзер Гөлфия — колхозның алдынгы савымчысы, аның портреты — Мактау тактасында. Комбайнда 25 ел эшләгән Кондратьев оста механизатор булырга яшь колхозчылардан 7 кешене өйрәтте.

Киң җәелеп киткән социалистик ярыш колхозда менә дигән хезмәт алдынгыларын тудыра. Коммунист Михаил Терентьев үзенең бишьеллык производство планын колхозда беренчеләрдән булып срогыннан алда, өч елда үтәде. Шушы вакыт эчендә ул «Т-40» тракторы белән, эталонлы сөрүгә күчереп исәпләгәндә, 5493 гектарлык эш башкарды — бу аның бөтен бишьеллык заданиесенә карата 120% тәшкил итә. Чөгендер игүчеләрдән Ольга Харитонова, Юлия Родионова һәм Александра Алексеева узган ел үз участокларының һәр гектарында 432—450 шәр центнер татлы тамыр үстерделәр.

Тәнзилә Рәхимҗанова ун елдан артык инде сыер сава. Узган ел ул бер сыердан уртача 3888 килограмм сөт сауды һәм, Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыгучы буларак, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Лидия Тайгина җитәкләгән ферма коллективы һәр йөз сыердан 123 әр бозау алып үстерде. Мөдир күкрәген

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бизи. Бозау караучы Зоя Никитина симертүдәге һәр яшь терлекнең авырлыгын тәүлеккә 670 шәр граммга арттырырга иреште.

Колхозның 27 хезмәт алдынгысы Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңүче значогы белән бүләкләнде. Почет грамоталары белән бүләкләнүчеләр дә аз түгел.

Бөртекле ашлык һәм игенчелекнең башка продуктларын җитештерүне арттыру буенча ярышта ирешкән уңышлары өчен колхоз үзе КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Кызыл Байрагы белән бүләкләнде. Хуҗалыкның 11 кешесенә хөкүмәт орденнары һәм медальләр бирелде. 1973 елның декабренда республика партия активы җыелышында КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Табеев, СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән, председатель Нурислам Кадыйровка Ленин ордены һәм Социалистик Хезмәт Героеның Алтын йолдызын тапшырды. Хәзер аның күкрәгендә өч Ленин ордены һәм берничә медаль.

Колхозда социалистик ярышның алгы сафларында коммунистлар бара, алар үзләренең шәхси үрнәкләре белән башкаларны да тырышып эшләүгә рухландыралар. Биредә партоешма 7 башлангыч оешмадан, 6 партгруппадан тора һәм 133 коммунистны берләштерә. Партком һәм аның секретаре Симунов авыл коммунистларының көчен, тырышлыгын, сәләтен производство бурычларын һәр вакыт арттырып һәм җиренә җиткереп үтәп баруга оста туплый. Коммунистларның күбесе — тармак җитәкчеләре, производство маяклары. 96 коммунистның турыдан-туры производствода эшләвен әйтү дә җитә.

Колхозның кешеләре дә, хуҗалык үзе дә әнә шулай нык һәм ышанычлы адымнар белән үргә менәләр, үсәләр.

Колхозның «Игенчелектә югары культура хуҗалыгы» дигән мактаулы исеме бар. Бу аңа инде дүртенче тапкыр бирелде.

## Лəбибə Ихсанова

# СƏРВƏРНЕҢ ТУГАН КӨНЕ



Сузылып киткəн туп-туры таш юл, Чепья юлы. Сул ягында урып-сугылган бодай басулары. Бер җирдə салам җыеп яталар. Кызу-кызу шуып барган салам җыю машиналарының кармавычлары бер күтəрелеп, бер төшеп тора. Кетер-кетер иткəн машина тавышы олы бер хайванның кыштырдатып салам чəйнəвен искə төшерə. Салам җыйгычлар артыннан ук, кара буразналар сузып, трактор үрмəли. Əллə сабан тəрəнендə, əллə дымлы буразна өстендə, өлкылдап, кояш нурлары чагылып китə. Уңда тəбəнəк тау тезмəлəре. Башларын яшел урман япкан усак, чыршы, чиклəвек куаклары. Мари урманнарының итəклəредер алар, мөгаен. Бирелəн Мари чиклəренə дə ерак калмый. Кешкəт, Чепья, Арбур авыллары...

Арбур — ул барасы авыл. Күпме йөрмəде ул шушы юллардан. Шул минутларда, шул сəгатьлəрдə күпме уйлар уйламады да, күпме планнар кормады. Балтач районы партия комитетының өченче секретаре Рəшидə Кариеваны нинди генə эшлəр, нинди генə йомышлар китермəде бу якларга. Əзмени секретарьның эше, халык белəн уртаклашасы киңəше. Колхозчы коммунистларның партия җыелышларында да катнашты ул. Мəктəплəргə барып укытучылар белəн дə киңəште, партия укуларын башлап җибəргəндə дə, терлекчелəр бəйрəмендə дə, яңа клуб ачу тантанасында да аның кирəге булды, хəтта берсендə Идел буе халыкларының җырларын өйрəнеп йөргəн венгр галимнəрен дə озата килде.

Кариева бүген дə юлда. Тик бу юлы җыелышлар җыярга да, кемнəргəдер ниндидер күрсəтмəлəр бирергə дə түгел, бүген ул кунак булып бара. Районның алдынгы терлекчесе, Хезмəт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, Ватан сугышы ветераны, унбер бала тəрбиялəп үстергəн Герой ана, коммунист Сəрвəр Гариpopованың чакырылган кунагы булып, аның илле еллык бəйрəмендə катнашырга килə.

Сəрвəр аны үзе килеп чакырды. Рəшидə күп мəсьəлə каралган һəм шактый озакка сузылган бюро утырышыннан чыгып, үзе эшли торган бүлмəгə узган гына иде. Биш-ун гына минут ялгыз калып, бераз тын аласы, бюрода сөйлəшенгəн сүзлəрне күңеленнəн үткəреп, фикерлəрен бер тəртипкə китерəсе килгəн иде. Артыннан ук иярeп дигəндəй, бүлмəсенə бер хатын керде. Керүен кыю керде үзе, рөхсəт-фəлəн дə көтеп тормастан, секретарьның каршына ук килеп утырды, əмма Кариеваның талчыккан зəңгəр күзлəренə карагач, уңайсызланып куйды. Вакытсызрак кердем, ахры, дигəн уй килде аның башына. Тик уйлаган эшеннəн чигенү гадəте юк иде бу хатынның, шуңа күрə генə сүзен башлыйсы итте.

— Рəшидə Əгълиулловна, Сез мине хəтерлəп тə бетерми торгансыздыр инде,— диде ул кояшта янган нəзек бармаклары белəн өстəл өстен сыпырып,— исегездəме, партия билетын алыштырган көнне, сез бик бəхетле ана дип əйткəн идегез...

Секретарь зəңгəр йон күлмəк өстеннəн кара костюм кигəн, костюмы өстеннəн төшереп, чəчəкле шəлъяулык бəйлəгəн юка гəүдəле, беленер-беленмəс кенə шадрасы булган чандыр йөзле бу хатынны таныр-танымас утыра иде. Җитмəсə тагын, ишектə тузгак чəчле бер егетнең башы күренеп хəтерен чуалтты.

— Рәшидә Әгълиулловна, тиз бушыйсызмы әле Сез? — диде егет. Секретарь җавап биреп өлгермәде:

— Юк, бушатмыйм әле мин аны, энем,— диде Сәрвәр, кырт борылып. Кергән минутындагы кыюлыгы кире кайткан иде аңа,— эшеңне үзең карый тор.

Шап итеп ишек ябылуга, Рәшидә көлеп җибәрде. Каршында утырган хатынны танып алган иде ул: менә характер! Сәрвәр бит. «Труд» колхозының сарык караучысы. Бер баруында колхоз председателе белән сөйләшеп торганы да исенә төште.

— Сәрвәр апаның авызы бир дип ачылган инде аның,— диде председатель, зарланасы килеп әйтте, әмма тавышында хатын өчен горурлану бар иде,— сәлам бир, өчөн бир, төгесен тап, моньюсын китер аңар.

— Үзенә дип сорыймы соң ул? — диде Рәшидә, аңламаганга салышып.

— Ферма өчен инде.

— Ә бүтәннәр алай түгелме?

— Алай ук бугазга басмыйлар.

— Кайсысына алданрак бирәсең соң?

— Ха, Сәрвәр апага бирми кара...

— Андый кешеләр белән ваемсыз яшәп булмый шул,— диде секретарь. Председатель дә аны җөпләде:

— Ярый әле, шундый тынгысыз кешеләр бар дөньяда.

Менә шушы тынгысыз хатын, артыннан ук тагылып дигәндәй килеп керде дә аның бүлмәсенә, каршына ук барып утырды. Ни йомыш китерде икән үзен?

— Тормышлар ничек соң, Сәрвәр?

— Таныды бит, һай, җаным! — диде хатын шатланып.— Урындыгын өстәлгә тагын да якынрак тарта төште һәм әле генә өзелеп калган сүзен дәвам итте.— Син мине бик бәхетле ана дип әйткән идең, Рәшидә Әгълиулловна. Дөрес әйткән идең. Менә шушы бәхетле Сәрвәрнең тормышын күреп китсен дип кунакка чакырырга килдем үзеңне. Илле яшем тула бит, туган көнемә балаларым җыела.

Илле ел...

Шаян һәм чая кыз булып үсте Сәрвәр. Мәктәпкә таба иң беренче булып кем йөгерә дисәң, чандыр гәүдәле шушы сары кыз булыр иде. Арбур тавының иң биек җиреннән кем шуа дисәң, тагын шул ук Сәрвәр. Малайлар белән кызып-кызып бәхәсләшүче дә, тиктормас теле аркасында алардан кыен ашаучы да ул иде. Андый чакларда еламый иде үзе, зарланмый иде. Вакытында җавабын бирергә тырышты. Эчкерсез бала күңелендә ачу торамыни. Әле генә авыз-борын салпайтып үпкәләшкән булалар, шунда ук чыр-чу килеп көлешә-көлешә мәктәбенә йөгерәләр, концертын өзерлиләр, спорт ярышлары оештыралар. Һәр җирдә, һәр вакытта Сәрвәрнең көмеш кыңгырау кебек яңгырап торган тавышы ишетелә. Күрше малае Мәлик белән генә тыныч яши ул. Йомшак табигатьле, уйга-хыялга бирелүчән зәңгәр күзле бу матур малай янында әллә ничек юашланып, сабырланып калган сыман була Сәрвәр.

Вакыт үтә. Ләкин акрын үтә. Тау астындагы нәни инеш тә бер, ашыкмый гына үтеп торган еллар да бер. Инеш суы да бит, акмаган да төсле үзе, һаман бер көе торган сыман. Еллар да шулай... Ә карасаң, Сәрвәр дә инде буй җиткереп килә икән бит. Хәзер аны биюче Сәрвәр диләр, ә Мәликне — гармунчы егет.

Нәкъ менә шул елларны йөгәнсез хыяллар биләп ала кызны. Аның күңеле әледән-әле Казанга, Мәгъсүм абыйсы янына омтыла. Полк мәктәбендә укытучы командир абыйсы бер җәйне, отпускага кайткач, Сәрвәрне дә шушы ерак шәһәргә үзе белән бергә кунакка алып киткән иде. Бармаган җире, күрмәгән нәрсәсе калмады кызның бу шәһәрдә. Зоопарктагы озын борынлы фил дә, кешеләрдән конфет теләнеп утыручы хәйләкәр маймыллар да, чын кеше тавышы белән сөйләшә торган кино да, шәһәрнең нәкъ уртасында диңгез кук җәелеп яткан Кабан күле дә исен китәрде аның. Аннан соң утлар, кичләрен шәһәр өстендә кабынган утлар калды исендә. Бу хәтле ут дөньясын Сәрвәрнең әле беркайчан да күргәне юк иде. Шуларның беразын гына Арбурга алып кайтып, мәктәп каршына гына булса да элеп куясы килде. Әмма чик бозучылар турында хикәяләр укып, шигырьләр ятлап, Щорс һәм Чапаевлар турында кинолар карап үскән Сәрвәрнең күңеленә казармадагы кызыларемеецлар тормышы күбрәк тәэсир итте. Аның да шулай сары каеш белән билен кысып буасы, пулеметчы Анка кебек, дошманнарга каршы көрәшәсе килде.

Сәрвәр генә белмәде ул чагында, сугыш сөремен сулар көннәр якын, бик якын иде инде. Менә Сәрвәр дә хыялында түгел, ә чынбарлыкта солдат булды, корал алып Ватан сагына басты.

Бөек Ватан сугышының икенче елы бара иде. Егетләр һәм ирләр барысы да дип әйтерлек фронтта. Бөтен эш, бар тормыш Сәрвәр һәм аның иптәшләре җилкәсендә. Сәрвәр инде комсомол комитеты секретаре. Оешма көннән-көн үсә, ныгый бара. Фронтка киткән егетләр урынына кызлар килә. Менә тагын сигез кыз, әле генә Ленин комсомолы сафына кабул ителгән сигез колхозчы. Сәрвәр аларны райкомол бюросына Чепьяга алып төшә. Бүген аларга комсомол билетлары тапшырачаклар.

Кара печать сугылган кайгылы хәбәрне Сәрвәргә бюрога керер алдыннан җиткерделәр. Үрле-кырлы биегән хәрефләргә карап тора-тора кызның күз алмалары уттай кыза башлады. Ни булды соң әле бу? Әле генә хаты килгән иде бит. Инде менә бу кәгазь... Мәгъсум Таҗиев батырларча... һәлак... батырларча...

Кайгы кәгазен тотып райкомол секретаре Ольга Волкова янына кергәндә кызның карары какшамас нык иде инде:

— Иртәгә Чепья районыннан фронтка озаталар. Шулар белән җибәр син мине. Яшь булсам да, яшьтәшләрем авылда калса да китим мин. Яраткан абыемның коралын алыйм.

Ул көнне районга килгән сигез кыз Арбурга Сәрвәрсез генә кайтты.

Ә Сәрвәр Мәскәүне дошман самолетларыннан саклаучы прожекторлар частена элгә. Солдат тормышының бөтен авырлыкларына түзә ул. Кара болыт булып килгән дошман самолетларын каршылаганда, тыныч йортларның җимерелеп төшүен, янып көлгә әйләнүен, коралдашларының рәхимсез үлемен күргәндә кичергән кайгыга, йөрәк әрнүенә түзә. Кайгы бәрабәренә дошманга карата нәфрәте арта Сәрвәрнең. Фронт сызыгы артында, дошман өере арасында калганда да, фашистларның котырынып бомбага тотулары вакытында да, позицияне дошманга бирмәс өчен бозлы кар суында утырганда да көч бирә аңа бу нәфрәт. Тылдан ярдәм көтеп салкын суда өч тәүлек утыралар алар. Шунда Сәрвәргә каты салкын тия, госпитальгә элгә.

Бу вакытлар инде бик еракта хәзер. Дәһшәтле сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыр көннәр йөрәк җәрәхәтендә каты җөй булып калды калуын. Вакыт-вакыт ул җәрәхәтләр әрнеп сызлый. Бигрәк тә балалар үсеп буй калкыта башлагач, күңелдәге борчулар арта икән. Еллар гына тыныч була күрсен. Аналарыбыз күргән хәсрәтне безгә күрергә язмасын. Ана хәсрәтен Сәрвәр үзе әни булгач бөтен тирәнлеге, олылыгы белән төшенде. Теге чакта, абыйсының үлем хәбәрен алгач, Сәрвәрнең күңелендә дошманнан үч алу кайгысы гына иде. Ул чакта әнисе кичерер дип уйлады. Үзе ана булгач исенә төшереп йөрәге сыкрана иде: райкомол бюросына төшкән сигез кыз Сәрвәрнең озын чәч толымнарын алып кайтып биргәч, бичара ана ничек чыдады икән? Бөек җиңүгә аналарыбызның кул көчләре генә түгел, барлык авырлыкларга да түзгән олы йөрәкләре дә ярдәм иткәндер, мөгаен.

...Яшьтән сыналган мәхәббәт белән кавышкан Мәлик белән Сәрвәрнең гаиләсе елдан-ел ишәя барды. Һәркайсы үз бәхете белән бере арты бере балалар туа торды. Ләкин алар тырыш хатынның кул-аягын бәйләмәделәр. Җыр-биюне яраткан, шаян холыклы, җор телле Сәрвәр элеккечә үк кеше арасында, элеккечә үк колхоз эшенең җаваплы участокларында. Менә ничә еллар инде ул районның алдынгы сарык караучылары белән ярыша. Тырыш хезмәте өчен аны хөкүмәтебез Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкли. Ә Мәлик гомере буе машина тирәсендә булды. Яшьтән үк тимер эшенә кулы ятты. Малайлары да үзенә охшап туды. Машина яраталар. Олы уллары Наилне машина докторы дисәң дә була. Техосмотрда мастер-наладчик булып эшли. Ватылганны-сүтелгәнне хәзер майлап, җайлап җибәрә. Икенче уллары Икрам — комбайнчы. Сигезенчене бетергән Әгъләменә хәтле комбайнер ярдәмчесе булып эшли. Абыйсы кебек комбайнчы булырга белеме генә җитеп бетми әле. Олылар киңәше белән ул механизаторлар мәктәбенә укырга керде. Төпчекләре Фәрит әле дүрттә генә. Бал чүлмәге тышыннан билгеле, дигәндәй, анысы да шул абыйларыннан калышмас, ахры. Өйгә кайтып керүләре була, әвәрә килеп, шулар янында йөри.

Тормыш иркен, абзар тулы мал-туар, ишегалдын тутырып кош-корт йөри. Унбер баланы үстереп инде җиргә иңә башлаган өй каршында, алма бакчасы эчендә, башын шифер белән япкан яңа бура утыра. Әнә шулай эш һәм көрәш белән үткән тормыш-

ның бер урынында туктап тын алырга, матур итеп бәйрәм ясарга зур хакы бар бу семьяның.

Килермен дип вәгъдә бирсә дә, секретарьны бик үк ышанып көтмәде Сәрвәр. Эш кешесе бит. Бер Сәрвәр генә кайгысымыни аның башында. Казаннан килеп төшүләре бар, җыелыш-фәләне булыр. Кайчагында барам дигән җирендә семьяңнан гына да чыгып китеп булмый. Ә секретарьның җаваплылыгында бөтен бер район. Рәхмәт әле шунысына — мәктәп завучын махсус чакырып әйтеп җибәргән: Сәрвәрнең бәйрәмен бик матурлап оештырыгыз, бик хөрмәтле кеше ул, аның тугыз баласы сезнең мәктәп ишеген ачып кергән, дип әйткән. Юк, бик үк ышанып көтмәде ул аны. Шулай да күңел төбендә әрсез өмет һаман-һаман үзен сиздереп торды.

Капка төпләренә райком машинасы килеп туктагач, Сәрвәр чиксез шатланды. Секретарьны ул үзләренең колхозларында, район җыелышларында күреп гадәтләнгән иде. Аның өстендә я йон, я кремплин костюм булыр иде. Ә бүген Рәшидә нәкъ бәйрәмчә киенгән. Инәдән-җептән төшкән зәңгәрсу күлмәктән, лаклы кара туфлилардан.

Сәрвәрнең бүген иң олы байлыгы — унбер баласы — унбер шатлыгы белән уртаклашасы килде. Рәхмәт инде балаларына, әти-әниләренең йөзенә кызыллык китермәделәр. Бүген алар барысы да бәйрәм табынында булырлар. Чиләбедәге кызлары Фәйрүзә белән Суфия гына кайта алмады. Еллары туры килмәгән инде. Әниләренең бәйрәменә алар күп итеп күчтәнәчләр һәм бүләкләр салганнар. Боздай күңелләрне дә эретерлек матур сүзләр белән рәхмәт хаты язганнар.

Райком секретаре үзе дә әни кеше, үзе дә бала җанлы. Килеп күрешкәч тә беренче сүз балалар хакында булды.

— Егетләр кайда соң әле? — диде ул, алма бакчасындагы өстәл артына килеп утыргач. Аның уенча, өйдә дә, ишегалдында да, хәтта шушы алмагач төпләрендә дә Сәрвәрнең балалары мәш килеп йөрергә тиеш иде. Ләкин әле Рәшидә аларның унберен түгел, берсен генә дә очратмады.

— Эштә әле, Рәшидә Әгълиулловна, улларым басуда, кызларым әнә өйдә, әбиләре белән аш-су карыйлар, — диде Сәрвәр, зур бер горурлык белән. — Кулдан киттеләр инде. Өлкәннәре Чиләбедә тора. Суфиясы почтада эшли, Фәйрүзәсе ясләдә тәрбияче. Заочно укый. Педагогия институтында. Санияbез кибетче. Анысы хисап эшен булдыра. Улларыбыз барысы да машина эшендә. Фәрдәвес белән Фәүзия кызларым укыйлар әле. Берсе алтынчыда, берсе дүртенчедә. Миләүшәм дә икенчегә күчте.

Сүз Миләүшәгә җиткәч, Сәрвәр иркенләбрәк сөйли башлады:

— Монысы — отличница. Бездә әле болай чат отличница юк иде. Безнекеләр руссчадан интектеләр. Миләүшәмне апалары янына Чиләбегә җибәргән идем, шунда руссчага өйрәнеп кайткан.

Сәрвәр тагын нидер әйтергә җыенган иде, бер ягына дүрт яшьлек Фәрите, икенче ягына алты яшьлек Фәридәсе килеп басты.

— Абый кайтты, — дип пышылдадылар алар, икесе дә чем кара күзләрен кунак ападан ала алмыйча.

— Кара инде бу өсләренңне, — дигән булды Сәрвәр, Фәритнең комга буялган чалбарын каккалап, — энеңнең битен юдырыр идең, Фәридә кызым.

Наилнең эштән кайтуы кич җитүе иде. Колхоз клубында тантана башланырга да күп калмый. Бу тантанада Рәшидә Кариева Сәрвәргә райкомның котлау һәм рәхмәт сүзләре язылган адресын тапшырачак. Адреста мондый сүзләр бар иде:

«Хөрмәтле Сәрвәр ханым!

Сез, тырыш хезмәтегез белән ил алдында хөрмәт казанган һәм хөкүмәтебезнең олы бүләгенә лаек булган райондашыбыз, бөтен гомерегез, тормышыгыз белән яшьләргә үрнәк булдыгыз. Ватан сугышының иң авыр елларында авыл комсомол оешмасын җитәкләдегез, аннары үзегез дә, корал алып, илне чит ил баскыннарыннан сакларга киттегез.

Сугыштан соңгы елларда Сез яңадан яшьләрнең җитәкчесе булдыгыз, колхозны аякка бастыруда күп көч куеп эшләдегез.

Сез берсеннән-берсе тырыш булган унбер баланың әнисе дә әле. Аларны тәрбияләүдә, илебезнең лаеклы гражданнары итеп үстерүдә бөтен көчегезне бирәсез.

Партиянең Балтач район комитеты Сезне, тырыш колхозчы һәм эшлекле коммунистны, илле еллык бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итә. Сезгә бетмәс сәламәтлек, бәхетле эш сәгатьләре, матур тормыш тели».

## Галим Шәйхиев

# БУА КАҺАРМАННАРЫ

## Дулкынлана чал Идел

*«Мокро-Савалеевка авылы крестьяннары Нефодий Андреев, Алексей Васильев һәм ялга җибәрелгән солдат Андрей Федорович Носов икмәк монополиясе турындагы законга көчле каршылык күрсәтәләр. 31 июльдә, авыл җыенында Андрей Носов хөкүмәткә ашлык бирүгә каршы пропаганда ясады, барлык икмәкне җәмәгать амбарларына салып куярга өндәде. Крестьяннар урган ашлыкны сугуны тоткарлыйлар.*

*Югарыда күрсәтелгән кешеләрнең каршылык күрсәтүләре хөкүмәт өчен куркыныч, шуңа күрә мондый коткы салучыларны, Вакытлы хөкүмәт боерыгы нигезендә, аңнарына кертергә кирәк.*

*Буа өязе азык-төлек управасы начальнигы*
*Г. Иванов*[1]*.*
*6 август, 1917 ел».*

Вакытлы хөкүмәт боерыгы. Аңа кем карый да, кем буйсына иде? Ул көннәрдә фронттан кайткан солдат сүзе Вакытлы хөкүмәт кәгазьләренә караганда халыкка көчлерәк тәэсир итте. Икмәк монополиясе крестьяннарның болай да ташып торган ачуын соңгы чиккә җиткерде. Бу — ирләрен үлемгә озаткан солдат хатыннарының, тәрбиячесез калган карт-карчыкларның, ятим балалары белән җыелып калган аналарның актык сыныкларын тартып алу иде. Ә бит сугыш сөреме бөтенләй орынмаган, бар хәсрәте кунак-кунак уйнаудан торган икенче полюс та бар. Ул — эре алпавытлар Головинский, Батанов, өяз җир управасы председателе Бонч-Осмоловский, тегермән хуҗалары Вәлитовлар, өяз чиновниклары һәм башкалар өере.

1917 елның 15 сентябрендә Сембер губернасы управасы комиссары Федор Головинский Петроградка, азык-төлек министрына менә нинди телеграмма җибәрде:

*«Сембер һәм аның гарнизоны икмәк белән ике көнлек кенә тәэмин ителгән. Ачуы кузгалган халыкны һәм гарнизонны тынычландыру өчен җир биләүче Шапроннан 42 мең пот арыш алырга рөхсәт итегез. Ул Сембердән 18 чакрымда гына яши.*

*Губкомиссар*
*Ф. Головинский*[2]*».*

---

[1] УДА. ф. 24. I тасвирлама. 18 эш.
[2] УДА. ф. 1470—2131. I тасвирлама. 4 эш.

42 мең пот! Ул кадәр икмәк 42 мең кешене ачлыктан вакытлыча коткарырга җитәр иде. Әмма бу телеграмманы җибәрүче Головинский да, аны алучы Вакытлы хөкүмәт министры да яхшы ният, нечкә күңеллелек белән эш итмәделәр. Курчак уены иде бу.

Тик халык министрдан телеграмма килгәнне көтеп тормады. Әле анда, әле монда алпавыт утарлары яна башлады. Солдат хатыннары амбарларны, кибетләрне ваттылар. Гарнизондагы солдатлар отделениесе, взводы, ротасы белән кача иде. Алар урынына яңа мобилизация үткәрелде. Буа өязе һәр атнада 300—500 солдат озата торды.

Күзге чәчү җиткәч, крестьян чуалышлары яңа көч белән кузгалды. Ивашевка, Ягодная, Утинка, Протопопов һәм башка авылларның крестьяннары алпавыт җирләрен үзара бүлеп чәчә башлады. Имениеләрдән атларны, чәчү инвентарен тартып алдылар. Авылларга җибәрелгән отрядлар халык ягына күчте.

Буа гарнизонында революцион рух үскәннән-үсә бара иде. Солдат депутатлары Советларына яңа сайлаулар вакытында эсер калдыклары төшеп калды. Өязнең Эшче, кретьян һәм солдат депутатлары Советына гарнизон солдатларыннан Ежов һәм Юркин, халык училищелары инспекторы Забродин, шәһәр думасыннан Шадрин кертелде.

## Өяз крестьяннарының I съезды

*«10 декабрьда власть Советлар кулына күчте. Работниклар җитми. Гарнизонда оештыру эше алып бару өчен көчләр кирәк».*

1917 елның 13 декабрендә партиянең Сембер губерна комитетыннан Үзәк Комитетка җибәрелгән бу телеграмма Ульяновск дәүләт архивында саклана. Аңа Е. Стасованың ике җавап телеграммасы бар. Үзәк Комитет губкомга тәҗрибәле большевик, 1913 елдан РСДРП(б) члены Иосиф Михайлович Варейкисны, ә өязләрдә эш алып бару өчен эшче һәм солдат агитаторларын җибәрә.

19 волостьны берләштергән Буа өязе ул чакта 284 авылдан һәм 40 хутордан тора. Анда 236 мең 648 кеше яши, аларга 249 мең 933 десятина җир мәйданы туры килә. 1914 елгы перепись мәгълүматлары күрсәткәнчә, халыкның 10 проценты гына укый-яза белә,ә хатын-кызлар арасында грамоталылар 1,98 процент кына. 29 процент халык җирсез, 42 проценты — бер десятинага кадәр генә җир биләүчеләр. Һәр хуҗалыкка уртача 6,40 десятина сөрүлек җир туры килсә дә, күпләр аннан файдалана алмыйлар. Барлык халыкның 0,12 процентын алып торган алпавытлар бер мең 700 десятина җир биләгән, бер десятиналы 42 процент халыкка да шул кадәр генә җир мәйданы туры килә.

Өяздә бер генә промышленность предприятиесе дә булмый. Эшчеләр юк. Бар кадәр һөнәрчеләр дә бер урында тормый, авылдан авылга күчеп йөри. Өяздә 1914 елга 950 такта яручы, 1448 балта остасы, 1019 тире иләүче, 466 итек басучы, 427 тегүче, 215 итекче, 195 тимерче, 1167 тегермәнче була. Төрле волость үзенең төрле һөнәрчеләре белән аерыла: Тимбай волосте — тегүчеләр, Мунчали — мунчала ясаучылар, Шамкино волосте — дегет кайнатучылар.

Большевик-агитаторларга менә шундый шартларда эшләргә, волостьларда крестьян съездларына әзерлек алып барырга туры килә. Урыннардагы контрреволюциячеләр — элекке управа хезмәткәрләре, төрле чиновниклар, алар коткысына бирелгән башка кайберәүләр, алпавытларның якыннары съездны учредительное собраниегә әйләндерү хәстәрлекләрен күрәләр. Хәер, төрле волостьта көчләр аермасы төрлечә була. Городище авылында губерна партия комитеты һәм Сов-

депы агитаторы Афанасий Иванович Чурбашкинны 4 көн подвалга ябып торалар. Ул качып котыла. Кече Чынлы волостеның крестьян Хәлим Сәгъдетдинов председательлегендәге крестьяннар съезды исә менә нинди резолюция кабул итә:

*«1. Безнең ирекле Россия Федератив Республикасында бөтен власть Солдат, крестьян һәм эшче депутатлары Советлары һәм аларның Халык Комиссарлары карамагында булырга тиеш дип таләп итәргә.*

*2. Солдат, крестьян һәм эшче депутатлары Советлары йөзендәге халык властена каршы корал күтәргән буржуазиягә кискен протест белдерергә.*

*3. Халык Комиссарлары чыгарган барлык декретларның тормышка ашырылуын таләп итәргә, ә аларга каршыларны Хәрби революцион трибунал судына бирергә.*

*4. Алпавыт Мотовилов җирләрен һәм аренда участокларын яздан ук крестьяннарга кайтаруны таләп итәргә.*

*5. Без мөселман милләтче провокаторларына протест белдерәбез. Без һәрберебез—татарлар, руслар, чувашлар—бертуганнар икәнлегебезне нык истә тотарга тиешбез.*

*6. «Өяз земствосына сайлаулар турында Положение» дигән Керенский законы буенча сайланган барлык эш башындагы кешеләрне алыштыруны таләп итәбез.*

*7. Безнең волостьның ачыгучы гражданнарына 100 пот икмәк биргән өчен Сембер губернасының халыкны азык белән тәэмин итү комиссариатына рәхмәт белдерергә. Большевик иптәшләрдән безнең дусларыбыз булуларын сорыйбыз. Долой буржуйлар!*

*Яшәсен халыклар туганлыгы!*

*Яшәсен басып алусыз һәм контрибуциясез солых!*

*Яшәсен Солдат, крестьян һәм эшче депутатлары Советлары һәм Халык Комиссарлары!*

*Бу протокол Буа шәһәрендә бара торган съезд делегатларына наказ булып хезмәт итсен* [1]*».*

Февраль башында шундый ук съездлар Шамкино, Шомыршы, Шыгырдан, Мунчали волостьларында да булып үтә. Контрреволюция көчле булган Городище, Уби, Рунга, Иске Суксу, Хомбусь-Батырево волостьларында Совет властен урнаштыру съездлары Крестьян депутатларының беренче өяз съездыннан соң, инде Буада власть Советлар кулына күчкәннән соң була.

Өяз крестьяннарының беренче съезды 1918 елның 15 февралендә большевик делегат Иван Кузьмич Скрипин председательлегендә ачыла. Президиумга Космовский, Карзанов, Солтанов, Розов, Хәмзин, Кочетков һәм башкалар сайлана. Беренче утырышта бәхәс бу органны съезд дипме яисә учредительное собрание дипме атау турында бара. Большевик делегатлар бердәмлеккә ирешү юлын эзлиләр. Скрипин, Космовский, Карзанов крестьяннар съездын яклап берничә чыгыш ясыйлар. Учредительное собрание яклылар утырган рәтләрдән:

— Долой!

— Фонарь баганасына асарга аларны!

— Россияне немецларга сатарга җыеналар, ышанмагыз аларга!— дигән тавышлар кузгала.

Көне буе да уртак фикергә килә алмагач, большевистик үзәк членнары Тимбай волосте делегаты Василий Талямановны Сембергә отряд

---

[1] «Известия Симбирск. Сов. Крестьянских, рабочих и солдатских депутатов». № 53.

сорарга җибәрәләр. Иртәгесен губерна башкарма комитетыннан Першин җитәкчелегендә 40 кешелек Кызыл Гвардия отряды килә. Съезд барган бинаны (хәзерге Советлар йорты) камап алган фетнәчеләр качалар. Крестьяннар җыелышы күпчелек тавыш белән съезд дип игълан ителә. Председательлек итүче Иван Кузьмич Скрипин съездга Сембер губернасы партия комитетының һәм Совдепның котлау телеграммасын укый һәм өязгә үзәктән 115 мең 440 сум акча, 4 вагон шикәр, 20 мең 460 аршын мануфактура, 152 пот сабын, 60 такта чәй җибәрелгәнлеген игълан итә. Делегатлар бу белдерүне кул чабулар, «ура!» тавышлары белән каршылыйлар. Бу хәбәр атмосфераны тиз үзгәртә. Советларның җир, солых, хезмәтчел халыкның хокук Декларациясе турында декретлары бертавыштан кабул ителә. Съезд 25 кеше составында Советларның өяз Башкарма Комитетын сайлый. И. К. Скрипин—председатель, И. С. Космовский—председатель урынбасары һәм финанс комиссары, Е. К. Карзанов һәм Вәлиев—председатель урынбасарлары, Солтанов секретарь итеп сайлана. Съезд биш көн дәвам итә.



Анда эчке эшләр, җир эшләре, халык хуҗалыгы, азык, финанс, хезмәт, халык мәгарифе, юстиция, хәрби, почта һәм телеграф халык комиссариатлары төзелә. Контрреволюцион элементлар җиңелүгә дучар ителәләр һәм съездны ташлап чыгалар.

Буада Совет власте урнаштырылуның беренче көннәренә туры килә торган түбәндәге боерыклар һәм телеграммалар тарихи кызыксыну тудыра.

*«6 март, 1918 ел. Буа өязенең атсыз крестьяннарына фронттан кайтарылган 2 мең 600 атны бирергә»* [1].

*
* *

*«10 март, 1918 ел. № 576. Өяз милициясе начальнигына. Буа Совдепы карары нигезендә, Буадагы Сысоев типографиясен кичекмәстән комиссариат карамагына учетка алырга кушам.*

*Эчке эшләр халык комиссары*
*Кочетков».*

*
* *

*«16 март, 1918 ел.*
*Буа өязе Эчке эшләр халык комиссариатына.*

*Хәбәр итәм: миңа буйсынучы милиция әгъзалары Совет власте — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы политик платформасында торалар.*

*Нагаткино милициясе*
*участковые Алексеев».*

*
* *

*«Циркуляр — 891. 1 апрель, 1918 ел.*
*Буа өязенең барлык волость Советларына.*

*Өязнең барлык волостьларында Советлар оештырылуга һәм үз функцияләрен үти башлауларына карамастан, миңа фактта инде бе-*

[1] «Известия Симбирск. Совета № 36».

*терелгән волость җир управалары исеменнән, алар штемпеле һәм печате белән эш кәгазьләре килү дәвам итә.*

*Кулланма итеп алырга һәм шуңа таянып эшләргә кушам: волостьта бернинди җир управалары юк, ә волость Советлары гына бар, учреждениеләр һәм кешеләр белән бөтен мөнәсәбәтләр Советлар исеменнән башкарылырга тиеш.*

*Буа өязе эчке эшләр халык комиссары Кочетков».*

Хәзерге Батыр, Шомыршы, Чүпрәле, Буа районнарын, Тәтеш һәм Цильна (Ульяновск өлкәсе) районнарының яртылашын биләп торган Буа өязендә Совет власте шулай нигезләнә. Әмма революцион көрәш дәвам итә әле.

## Өязнең беренче председателе

Солдат кайтты. Сугыш бетте, диделәр. Герман фронтында солдатларга гына түгел, атларга да демобилизация башланды. Сугышка алынган атларны авылларга — җилкә белән сука тартучы ярлыларга тараттылар. Солдат киемен крестьяннарның киндер күлмәгенә, патронташны йомшак билбауга алыштырып, иген игәргә, үзенчә көн итәргә, тыныч дөнья көтәргә кайтты ул авылына.

Ләкин болар бөтенесе дә уйда, хыялда гына калды. Чилим, Чокалы, Шамкино якларына революция сулышын алып кайткан солдат массалары бу караңгы почмакларда һаман да хакимлек итүче төрле управаларга, Вакытлы хөкүмәт комиссарларына башта ультиматум куйдылар, аннары бөтен өерләрен куып тарата башладылар. И. К. Скрипин солдат оешмасының җитәкче үзәгендә булды, башта Реввоенсовет председателе, аннары Шамкино волосте Советының башкарма комитеты председателе итеп сайланды.

1918 елның феврале. Буа өязе крестьяннарының беренче съезды. Скрипин — съезд председателе. Съезд җир управасын, Вакытлы хөкүмәт комиссарларын һәм учреждениеләрен туздырып ташлап, Крестьян, солдат һәм эшче депутатларының өяз Советын сайлый. Иван Кузьмин—Башкарма Комитет председателе.

Өяздәге бөтен власть Советлар кулына бер үк көнне күчмәде. Контрреволюция көчле булган Городище, Уби, Иске Суксу, Рунга, Тархан якларында Советка каршы бандалар күтәрелә. Городище динчеләре Совет хөкүмәтенең чиркәүне дәүләттән аеру турындагы декретына каршы манифестациягә чыгалар. Суксу ягы татарлары «Милли шура» — аерым мөселман дәүләте оештыру таләбен куя. Менә шул көннәрдә Скрипин, аның көрәштәшләре Космовский, Кочетков, Герасимов халык милициясе, Кызыл Гвардия отрядлары оештыру эше алып баралар. Волостьларда бер-бер артлы крестьяннар съездлары җыела. Авыллардагы старосталар ярлылар комитетлары белән алыштырыла. Болар бөтенесе дә аяусыз көрәш — сыйныфлар көрәше шартларында бара.

Беренче көннәреннән үк өяз Советы Башкарма Комитеты зур эш җәелдерә. Кулаклардан тартып алу юлы белән 121 мең пот ашлык туплана. Аның бер өлешен, кызыл олаулар белән, Курск, Мәскәү, Тула һ. б. шәһәрләр эшчеләренә озаталар. Алпавыт Тереховның, Бурундуковскийның мөлкәтенә һәм банктагы акчаларына арест салына, контрибуция тәртибендә 85 мең сум акча туплана.

Губерна Советына җибәрелгән отчетта шундый саннар да бар: «1918 елның 1 маена кадәр чорда солдат семьяларына, инвалидларга

һәм хезмәткәрләр профсоюзы членнарына 273 мең 600 сумлык 10 мең 206 паек бирелде. Ачлык кичерүчеләрдән 84 кеше эшкә урнаштырылды».

Урман хуҗалыгын оештыру, бәяләрне нормалаштыру, кооперация эше, тәҗрибә кырлары һәм җәмәгать агрономия хезмәте, эчүчелеккә каршы көрәш, юл төзелеше, авыл хуҗалыгы машиналары эшләү һәм ремонтлау — башкарма комитет утырышында шундый һәм шуңа охшашлы күп мәсьәләләр тикшерелә. Совет Буадагы профтехучилищеда сука тимерләре, сабаннар ясауны оештыра. Шул ук вакытта Кызыл Армиягә кадрлар әзерләү, ирекле отрядлар төзү, коралландыру эшләре дә алып барыла.

Советның беренче председателе И. К. Скрипин бөтенесендә дә башлап йөри, оештыра, юнәлеш бирә. Аның кесәсендә газета, кулында китап була. Председатель финанс эшләрен дә өйрәнә. «Кредит — латин сүзе, ышаныч күрсәтү, биреп тору мәгънәсендә. Дебитор — ул бурычлы кеше»,—дип яза Иван Кузьмич үзенең көндәлегендә. Анда художество әсәрләреннән алынган өзекләр дә бар. «Яктылыкка омтылыгыз, яктылыкта йөрегез, башкаларның юлын яктыртыгыз». «Һәртөрле ярсып китү, кычкырыну, ачу саклау, усаллык күрсәтү беркемгә дә киңәшче һәм юлдаш була алмый». «Данга бер генә юл — хезмәт кенә китерә».

Бу өзекләрдә Иван Кузьмичның халыкка хезмәт итү үрнәге чагыла. Ул һәр вакыт яктылыкка омтыла, кешеләрнең юлын яктырта. Буаны чехлар алганда өяз председателе партизан хәрәкәте оештыруда эшли. Аннары армиянең оператив штабы члены була. Конспиратив паспорт — крестьян Иван Нефедов исеменә бирелгән документ — белән акгвардиячеләр басып алган Буа өязе авылларында җыеннар үткәрә, агитация эше алып бара. 1919 елның 20 июленнән ул — Сембер губернасы азык комиссариатының хәрби вәкиле, аннары Кызыл Армияне тәэмин итү Баш идарәсенең военпреды.

Буа өязендәге беренче мәктәпләр, сәүдә кооперативлары, дәүләт учреждениеләре төзү, интеллигенция кадрлары әзерләү, халыкның акгвардиячеләргә каршы көрәшен оештыру — бөтенесе дә Иван Кузьмич Скрипин исеме белән тыгыз бәйләнгән. Ул Буада 1918 елның 20 февраленнән 1919 елның 20 июленә кадәр — ел ярым чамасы гына була. Ләкин башкарылган эшләре белән бу чор берничә дистә елга торырлык.

«Без бөтенебез дә сукадан һәм тырмадан килдек. Укымышлылардан түгелбез. Властьны алганда земский кассасында бирәчәктән башка берни дә юк иде. Безгә күчеп барган йортсыз-җирсезләрнең, солдат хатыннарының, ярлы крестьяннарның төркемнәре икмәк, акча сорап килде. Ул чакта учет эшен, язу-сызуны белүче интеллигентлар бик кирәк иде. Алар эштән баш тарттылар. Хәл шундый иде. Хезмәтчел халыкның бердәмлеге мөмкин булмаганны эшләде, юкны бар итте»,— дип яза үзенең истәлекләрендә Иван Кузьмич Скрипин.

Ульяновск крайны өйрәнү музеенда И. К. Скрипин исеменә бирелгән Кызыл гвардияче һәм Кызыл партизан таныклыгы бар. Гражданнар сугышы давыллары үтеп, инде беренче удар бишьеллыклар башлангач та Иван Кузьмич элекке гвардиядән аерылмый. Ул «Кызыл партизаннар һәм Кызыл гвардиячеләр землячествосы»ның бюро члены һәм җаваплы секретаре булып эшли, бу оешманың Самарада (хәзерге Куйбышев) уздырылган край конференциясендә катнаша.

Өяз Советы Башкарма Комитетының беренче председателе Иван Кузьмич Скрипинның Буада Совет властен ныгытуга куйган хезмәте югары бәягә лаек. Ул эшләгән урынга мемориаль такта куелса яисә шәһәрнең бер урамына аның исеме бирелсә, бу аның зур хезмәтенә хөрмәт булыр иде.

1918 елның май ахырында Буадан Сембергә ярлы крестьян ирекләреннән беренче отряды җибәрелә. 1 июньдә, Идел буена ябырылган баш күтәрүче чехларга отпор бирү өчен, губернаның бөтен өязләрендә коммунистик мобилизация башлана. Партиянең губерна комитеты үзенең гадәттән тыш утырышында барлык коммунистларны коралландыру мәсьәләсен куя. Сембердә, шулай ук Буа өязендә хәрби хәл кертелә.

Ул көннәрдә Буа өязенең хәрби-революцион штабы начальнигы һәм губерна штабы члены Иван Сергеевич Космовский да зур оештыру эше алып бара. Кызыл Армиягә яңа көчләр туплый, өйрәтә, яшь сугышчылар арасында политик тәрбия чаралары үткәрә. Космовскийга губкомны һәм губерна башкарма комитетын саклауны тапшыралар.

Вакыйгалар куера. Үзенең штаб-квартирасын Сембергә күчергән Көнчыгыш фронты командующие Муравьев шәһәрдәге коммунистик отрядларны тизрәк башка фронтларга күчерү чарасын күрә. Бу Идел буйлап килүче чехларга юл ачу өчен авантюра максатларында эшләнә. Тарихи материаллардан һәм тарих фәннәре кандидаты Б. Н. Чистов язмаларыннан күренгәнчә, Муравьев авантюрасын ачуда Космовскийның да роле зур. Ул Муравьевның отчетын тыңлаган губерна Советы утырышында катнаша. Күрше бүлмәләрдә Космовскийның комендантлык ротасы сугышчылары урнаша.

Муравьев «Метрополь» (хәзерге «Москва») гостиницасыннан ике сакчы отделение белән кадетлар корпусына — губком һәм губисполком урнашкан бинага килә. Урамда аны берничә бронемашина саклый. Командующийның уйлавынча, губком һәм губерна Советы членнары я Муравьев фикерен якларга, я кулга алынырга тиеш булалар. Ул инде, утырышка килгәнче үк, беренче командарм Тухачевскийны кулга алдыра. Ләкин бөтенесен дә алдан сизгән губерна Советы һәм Партия Комитеты фетнәне кабынып киткәнче үк бастыру чарасын күрә. Каршылык йөзеннән корал көче кулланган Муравьев утырыштан качканда атып үтерелә. Көнчыгыш фронтка яңа командующий — М. В. Фрунзе билгеләнә.

Әмма Муравьев хыянәте яшь Кызыл Армиягә авыр яра ясый. Чехлар бу вакытны Сембергә якынлашалар. Шәһәр камалыш хәлендә кала. Совет һәм партия учреждениеләре Алатырьга күчә. Космовский отряды, Буага килү юлын каплап, Киндяковка станциясен җиде көн буена үз кулында тота. Бары тик чигенергә приказ алгач кына ул, ротадагы исән калган сугышчыларны Мороз отрядына тапшырып, партия заданиесе белән, партизан отряды оештыру өчен Сура урманнарына китә.

1918 елның 4 августы. Буа чехлар кулына күчә. Алпавыт Блинов йорты подвалы һәм төрмә тоткыннар белән тула. Өяз Советы Башкарма Комитеты члены Кочетков, коточкыч җәзалар кичереп, акылдан яза. Активистлардан Долгов, Бровкин, Павлов, Розов, Копылов та ерткычларча җәзалауга дучар булалар. Аклар армиясенә авылларда мобилизация башлана. Менә шул көннәрдә Сура урманнарында Космовскийның 75 кешелек партизан отряды туплана. Константин Михайлович Зиновьев, Алексей Петрович Рубцов, Павел Сергеевич Денисов группалары Хмельницкий, Зимний, Раменский кордоннарына урнаша.

Партизаннар дошман тылына төнге налетлар ясыйлар, штабларына һөҗүм итәләр, җирле халык арасында аклар мобилизация-

сенә каршы агитация алып баралар. Партизан штабы Алатырьдагы регуляр армия белән элемтәгә керә һәм аннан алынган приказларны, чакыру кәгазьләрен авыллардагы ышанычлы кешеләр аша таратуны оештыра.

Акгвардиячеләр халыкны үз якларына тартыр өчен төрле уйдырмаларга баралар. Буа җир управасы вакытында хәрби начальник булып эшләгән акгвардияче офицер Зиновьев шундый телефонограмма җибәрә:

«Өяз Советы һәм кызыллар отряды казначействоны талап качканнар. Очраган берен тентегез, акчасын алып, үзен кыйнагыз, үтерегез яки талаучыларны Буага халык хөкеме ясау өчен китерегез».

Фактта исә казна акчасы таланмый. Бөтен документлары белән аны өяз Советы Башкарма Комитеты үзе белән Алатырьга күчерә. Шул турыда дереслекне халыкка партизан-агитаторлар җиткерәләр. Листовкада казначействоның Алатырьда булуы һәм акчасын алырга теләгән кешенең шунда килергә тиешлеге әйтелә. Бу, бердән, уйдырманы фаш итсә, икенчедән, андагы Кызыл Армия штабы килүчеләрне разведка максатларында да файдалана. Уби авылыннан Савельев дигән карт, аллага табынучы изге сыйфатында, кулына тәре алып юлга чыга. Аклар разъездларын читләтеп үтеп, ул отрядның беренче постына җитә. «Убида ике эскадрон солдат ялга туктады. Дүрт пулеметлары бар. Офицерлар эчә, типтерә. Солдатлары йорттан-йортка әйбер талап йөриләр. Казан белән араны өзмәкчеләр, тимер юл күперен шартлатмакчылар икән», дигән хәбәр китерә ул.

Сак көчәйтелә. Сура күпере төзек көе кала, задание белән килгән аклар отряды тар-мар ителә. Партизаннарның шундый ярдәмчеләре күп була.

Айбеси һәм Сойгино авыллары арасында партизаннар разъезды акларның бер отряды белән очраша. Дошман солдатлары атларын һәм мобилизация буенча көчләп җыйган крестьяннарны ташлап качалар. Разъезд Бичурго-Баишево авылын һөҗүм белән ала, больницадагы телефонны кулга төшерә. Скрипин үзенең язмасында Мунчәли белән түбәндәге сөйләшүне искә алып үтә:

«Баишево: Эшләр ничек бара?

Мунчәли: (телефонда ак офицер): Начар, туган. Татарва безгә хезмәт итәргә теләми. Урманга кача.

Баишево: Бездә тагын да начаррак.

Мунчәли: Кем белән сөйләшәм соң мин?

Баишево: Кавалерия разведкасы. Без Баишевода.

Мунчәли: Кызыл башлы бандитлар турында нинди мәгълүматлар бар?

Баишево: Котың чыгарлык. Меңләп штык, уннан артык пулемет. Алты пушкадан торган батарея. Буага һөҗүм итәләр, Тәтешкә чыкмакчылар икән».

Шул сүзләрдән соң сөйләшү өзелә. Офицер Буага хәбәр итә һәм, мобилизацияне ташлап, үзе дә шунда сыпырта.

Буага бер налет вакытында Космовский группасы чехлар штабын тар-мар итә. Андагы яшерен документларны, дислокация картасын кулга төшерә. Аны ашыгыч рәвештә Алатырьдагы регуляр Кызыл Армия штабына тапшырырга кирәк була. Бу операция — Космовский партизаннарының күп санлы батырлыклары арасында иң мөһиме. Чөнки кулга төшерелгән документлар Идел буендагы акгвардиячеләр һәм чехлар армиясенең санын гына түгел, бәлки кайда, ничек урнашуларын һәм хәрәкәт юнәлешләрен дә күрсәтәләр. Бу материаллар Кызыл Армиянең Көнчыгыш фронты штабына дошман армиясен бүлгәләп кыйнарга, кыю контрударлар хәзерләргә, Сембер-

не һәм Казанны ак бандитлардан тәмам чистартырга ярдәм итә. Партизаннар отряды аннары регуляр Кызыл Армия белән кушыла. Чехларга каршы генераль һөҗүм башлана.

## Комиссар Крепков

«Өяз комиссары Василий Крепков 1918 елның 9 сентябрендә акгвардиячеләр бандасына каршы көрәштә геройларча һәлак булды. Революция корбаннарына мәңгелек дан!» Батыр авылының туганнар каберлегендә шундый сүзләр чокып язылган таш тора. Һәр язны пионерлар бу кабер өстенә чәчәкләр утырталар, аның янында партиягә һәм халыкка турылыклы булырга ант итәләр...

Комиссар Крепковның мәңгелек батырлыгы турында халыкта күп легендалар йөри. Аларның кайсысы халык фантазиясе белән тудырылган, кайсысы булган хәл икәнен аеруы да читен. Хәер, 1918 елда Буа өязен басып алган чехларны калтыраткан партизаннар хәрәкәтенең кечкенә генә бер эпизоды да теләсә нинди фантазиядән өстенрәк.

Сентябрь башлары. Өяз шәһәре Буа белән элемтә өзелгән. Анда инде августтан бирле чехлар һәм ак бандалар котырына. Алатырьда — кызыллар. Алар Мәскәү — Казан арасындагы юлны үз кулларында тоталар. Сура урманнарында партизаннар берләшмәләре оешканлыгы турында хәбәрләр йөри. Батыр волостенда аклар да, кызыллар да юк. Ләкин барыбер тыныч түгел. Кулак, алпавыт малайлары прапорщик киемен алыштырганнар да яшерен агентлар булып алганнар. Халыкны восстаниегә өндиләр. Күптән инде Батырда җыен да булганы юк. Волость комитеты дружиначылар штабына әверелгән. Авылда постлар. Буа юлына көчәйтелгән каравыл куелган. Махсус задание буенча килгән өяз комиссары Василий Крепков добровольцлар отрядына кешеләр җыя. Үзәк мәйданда аларны корал белән эш итәргә өйрәтәләр.

Каршы як та йокламый. Исәк авылында атаман Жуков отряды тора. Җирле кулаклар — Нурулла, Николай Курмышлар аклар армиясенә вербовка үткәрәләр. Халык группаларга бүленгән. Кем алдыра?—Һәркемне шул сорау борчый. Кем алдыра, кем ягына чыгарга?

Бер үк көнне килеп чыккан ике вакыйгадан соң, өяз комиссары, конкрет карарга килеп, отделение командирларын үз янына җыеп алды.

— Беренче пакет Алатырьдан,— диде ул. — Оператив штаб чехларның һөҗүмгә әзерләнүен хәбәр итә. Аларны ике көнгә булса да Батыр янында тоткарлап торырга кирәк. Икенчесе — Рунгадан. Өяз комитеты инструкторы Васил Виковтан. Ул Жуков бандасының иртәгә таңнан безгә һөҗүм итәчәген яза...

Оперативкадан соң, кич белән, Крепков отрядны түгәрәк оборонага урнаштыра. 50 кеше, ике пулемет тачанкасы. Көч зур түгел, әмма егетләрнең берсе икегә торырлык. Дошманга булган нәфрәт, ерткычларча җәзалап үтерелгән иптәшләре, туганнары өчен үч алу хисе арттыра ул көчне.

Төн тыныч үтә. Икенче көнне дә ул-бу сизелми. Тик төш авышкач кына, Исәк авыл ягыннан акларның атлы разъездлары күренә.

Окоплар буйлап команда яңгырый:

— Әзерләнергә!

— Патроннарны саклап тотарга!

— Якынайгач кына ут ачарга!

Батыр янындагы бу сугыш, дошманның көче икеләтә артык булуга карамастан, ике көнгә сузыла. Икенче көнне дошман, яңа көчләр өстәп, тагын атакага ташлана. Уң флангта крепковчыларның 5 кешелек бер отделениесе генә кала. Пулеметларның берсе сафтан чыга. Икенчесенең пулеметчысы авыр яралана. Крепков, пулеметны алып, җил тегермәне төбенә урнаша һәм шуннан авылны өч яклап ураган дошманга ут яудыра башлый. Кызыл Армиянең махсус җибәрелгән отряды килеп җиткәнче, крепковчылар актык көчләре белән позицияне саклап калалар. Дошман, зур югалтулардан соң, чигенергә мәҗбүр була. Тик... сугышчылар үз командирларының пулеметны каплап ауган үле гәүдәсен генә табып алалар.

Буаны чехлардан азат итү өчен көрәш тарихына кереп калган Батыр янындагы сугыш әнә шулай тәмамлана. Кызыл Армия генераль һөҗүмгә күчә.



## Советлар йорты өстендә кызыл флаг

*«Чехларның Буа группировкасына каршы генераль һөҗүм турында.*

*Советларның Буа һәм Алатырь Башкарма Комитетларының берләштерелгән утырышы беркетмәсеннән. № 93, 2 сентябрь, 1918 ел.*

*Алатырь группасы гаскәрләре командующие Пеньевскийның «Фронттагы хәл турында» докладын тыңлаганнан соң, утырыш карар бирә:*

*1. Генераль һөҗүмне 10 сентябрьдә башлау турында командование планын расларга.*

*2. Һөҗүмгә җитәкчелек итү өчен Кустарников, Важдаев, Сабаев, Пеньевский һәм Скрипин составында оператив штаб оештырырга»*[1].

Ульяновск дәүләт архивындагы бу саргаеп беткән документ моннан 56 ел элек булган тарихи көннәрне күз алдына китереп бастыра. Ул көннәр контрреволюциянең һәм эсерларның Идел буендагы соңгы таянычын — чехословак корпусы фетнәсен бастыру, Совет властен яңадан торгызу белән характерлы.

9 сентябрь. Кызыл Армиянең Алатырь группасы командующие Пеньевский штабы. Оператив группа генераль һөҗүмгә күчүнең планын тикшерә. Ул өч юнәлештән башланырга тиеш. Батырдан Васил Виков отряды. Ембулаттан Космовскийның партизаннар отряды. Тимбайдан регуляр армиянең үзәк группасы. Һөҗүмне 10 сентябрьдән 11 сентябрьгә каршы төндә башларга. Партизаннарның Герасимов җитәкчелегендәге дозор отряды, Буага үтеп кереп, мобилизация буенча җыелган крестьян яшьләре арасында эш алып барырга, үзәктә акларга каршы восстание күтәрергә тиеш.

Отряд командирларына заданиеләр, маршрутлар һәм акларның дислокация планнары бирелә. Гаскәрләр соңгы һөҗүмнәр рубежына туплана.

Шушы операциядә катнашкан Александр Михайлович Саблуков болай дип сөйли: «Буаны чехлардан һәм ак бандалардан азат итү сугышы ике яклап алып барылды. Тылга үтеп кергән Герасимов отряды акларның үз лагеренда восстание күтәрде. Мобилизацияләнгән крестьяннар группасы-группасы белән кызыллар ягына чыгалар иде. Без алга барган саен, азат ителгән авыллардан яңа көчләр кушылды.

---

[1] УДА. Фонд 57а. Тасвирлама 2. Саклау берәмлеге 343.

Төп ядросы 75 укчыдан торган Космовский отряды Буага кергәндә инде 230 кешегә җитте...»

Өяз шәһәре Буага беренче булып Космовский җитәкчелегендәге партизаннар отряды керә. Сугышчылар, 11 сентябрь төнендә 70 километрлар юл үтеп, 12 сентябрьдә штурм белән шәһәрне алалар. Дошман таркау хәлдә Тәтеш ягына кача. Партизаннар 250 мылтык, 10 меңләп патрон, 12 пулемет тачанкасын кулга төшерәләр. Советлар йорты өстенә отрядның Кызыл байрагы эленә.

Өяз Советы Башкарма Комитеты Алатырьдан күчеп кайтканчыга кадәр властьны Революцион комитет үз кулына ала. Бу турыда Александр Михайлович Саблуков истәлекләрендә мондый юллар бар:

«Вакытлы революцион комитетта без өчәү — Космовский, Герасимов һәм мин идек. Беренче башлап комендантлык сәгате керттек, халыктан корал кабул итүне оештырдык. Ревком тыныч тормышка күчү, дәүләт учреждениеләренең эшенә катнашу һәм булышлык итү һ. б. буенча халыкка мөрәҗәгать итте. Вакытлы революцион комитет дүрт көн эшләде. Аннары бөтен властьны Крестьян, эшче һәм солдат депутатлары Советының өяз Башкарма Комитетына тапшырды».

Өяздә Совет власте урнаштыруда, аны эчке һәм тышкы дошманнардан саклап калуда исемнәре билгеле булган һәм әлегә билгесез йөзләгән каһарманнар катнашты. Өяз Советы Башкарма Комитеты члennarыннан Кочетков , Крепков, Павлов, Хәмзин, Долгов, Копылов, Карзанов бу изге юлда геройларча һәлак булдылар.

Буа өязе партия комитеты Колчакка каршы көрәштә үз сафларыннан 250 коммунистны җибәрде. Иреклеләр батальоны санитаркалары Александра Ефимова, Нина Утеева тиңдәшсез батырлык үрнәге күрсәттеләр һәм кеше бәхете өчен үзләрен корбан иттеләр. Өязнең революцион тарихында иң күренекле урынны алган легендар полководец Иван Сергеевич Космовский, үзенең кыска вакытлы тормышын мәңгелек данга күмеп, Урал далаларында башын куйды.

Бу язмаларга кергән каһарманнар авыр елларда, халык белән бергә, хаклык өчен, Совет власте өчен изге көрәшкә күтәрелделәр. Аларның данлы үткәне безнең бүгенге казанышларыбызны яуларга көч бирә. Ул көн геройларының образы менә шуңа күрә дә сүнмәс маяк булып балкый. И. С. Космовскийның геройларча һәлак булы уңае белән партиянең Сембер губерна комитеты һәм Советларның губерна Башкарма Комитеты органы «Заря» газетасы 1919 елның 31 августында болай дип язды: «Синең исемең тарихка керер, киләчәк буыннар синең бөек эшләрең турында укырлар да, синең гүзәл тормышыңны хөрмәт итәрләр, мәңге сүнмәс истәлегеңне буыннан буынга җиткерерләр...» Бу соңгы саубуллашу сүзләре үзләрен революция эше өчен корбан иткән барлык каһарманнар алдында изге ант булып яңгырый.

ооооооооооооо

Шәриф Рахманкулов

# ЗАҺИД ХӘБИБУЛЛИН



Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты композитор Заһид Хәбибуллинның иҗаты бай һәм күпкырлы. Ике балет, дистәдән артык сәхнә әсәре өчен махсус язылган музыкалар, инструменталь һәм вокаль әсәрләр авторы ул. Композитор тарафыннан иҗат ителгән җырларның гына саны да өч йөздән артып китә.

Социалистик культурага, халкыбызның музыка сәнгатен үстерүгә менә инде кырык ел буе армый-талмый хезмәт итүнең мул җимешләре бу. Һәм алар җентекле анализны, күләмле фәнни тикшеренүне таләп итә. Кечкенә очерк күләме, әлбәттә, аны сыйдыра алмый һәм без андый бурычны куймадык. Максат, яшьтән ата-анасын югалтып, урамда калган ятим баланың Совет власте шартларында тәрбияләнеп, күренекле сәнгать эшлеклесенә кадәр ничек үсүен күрсәтүдә.

## I

1919 ел башы. Оренбург шәһәреннән 240 чакрымнар чамасы ераклыкта, тау башында, Урал суы буена урнашкан Орск шәһәре.

Кышкы каты салкыннар. Халык ачлыктан интегә. Илдә тиф. Көнен көнгә ялгап яшәгән Вәли абзый гаиләсен дә бу афәт читләтеп узмый. Тугызынчы яшенә атлаган Заһидның бер атна эчендә башта әтисе, аннан әнисе дөнья куя. Салкын өйдә бер сынык икмәксез калган бала ятимнәр йортына килеп керә. Ачлык-хәерчелекнең ачысын татып өлгергән Заһид өчен балалар йортындагы тормыш гаҗәеп матур булып тоела.

Биредә ул беренче тапкыр музыка тавышын ишетә, беренче тапкыр рояль, скрипка, мандолина кебек уен коралларын күрә. Һәм монда ул ятимнәрнең иң якын абыйсы булган ягымлы, саф күңелле Мирхәйдәр Фәйзи белән очраша. Аның балалар йортына килеп укыган шигырьләре, сөйләгән әкиятләре, шәһәр китапханәсендә оештырылган әдәби-музыкаль кичәләр һәм, ниһаять, шул кичәләрдә тыңланган җыр-көйләр Заһидның киләчәгенә, музыка өйрәнүгә булган теләгенә юл ачып җибәрә.

Шушы балалар йортында Заһид музыка дәресләре ала башлый. Ишетелгән авазларны көйләтеп каратудан башланган дәресләр аша укытучы апасы акрынлап Заһидны музыканы тәшкил итүче авазлар һәм аларның исемнәре белән таныштыра. Алар җиде генә булсалар да, Заһид өчен дәресләр җиңел булмый. Әмма ул аларны хәтерләргә, күңеленә сеңдерергә тырыша. Берничә дәрестән соң бу авазларны фортепьяно клавишаларында таба да башлый.

Аннан соң Заһид нота билгеләре, аларны станга урнаштыру һәм шушы нота станына керү өчен кирәк булган скрипка һәм бас исемнәре белән аталган ачкычларга

да килеп житә. Дәресләр көннән-көн кыенлаша баралар. Бигрәк тә, төп нота билгеләреннән тыш, тагы аларның кардәш билгеләре, нота алдына куела торган «диез», «бемоль» дип йөртелүче нечкәлек белән калынлык атамалары, ачкычларга карап ноталарның исемнәре үзгәрүләре Заһидның башын чуалтып та җибәргәлиләр. Аларны озак үзләштерә алмый җәфаланган чаклары була. Хәтта вакыты-вакыты белән: «Аларны белү миңа нигә кирәк инде? Уйнарга гына өйрәтсә...»,— дип көрсенеп тә куйгалый ул.

Авыр булса да, Заһид сынатмады. Иптәшләре белән бергә буласы, туйганчы урамда уйныйсы килгән чакларда да ул үзен тыя белде һәм бар көчен үз алдына өйрәнүгә, күнегүләргә бирде.

Ихтыярының нык булуы һәм музыкага мәхәббәтенең көчлелеге Заһидны музыкадан аерылмаска, махсус уку йортына кереп укырга, музыкант булырга дигән карарга китерә.

Укырга! Ә кая барырга? Ул бит Орскидан башка тагын шәһәрләр барлыгын да әле күз алдына китерә алмый. Ләкин балалык тәвәккәллеге үзенекен итә, малай икмәкле шәһәр саналган Ташкентка юл тота.

Әмма балалык акылы белән генә җиңел уйланган бу сәяхәт Заһид өчен күңелсез тәмамлана. Ташкент базарларында эш эзләп йөргәндә аны караклар шайкасы үз элмәгенә элэктереп ала. Ләкин Заһид караклык юлына басудан баш тарта, төрле сәбәпләр белән читләшергә тырыша. Нәтиҗәдә, кирелеге, буйсынмавы өчен аңа самосуд ясала — сул кулының урта бармагына кадак кагалар.

Шушы фаҗигадән соң ул качып китә. Башта Оренбург шәһәрендә кагылып-сугылып йөргәннән соң, Актүбә шәһәренә килә һәм шәһәр үзәгендәрәк утырган бер чәйханәгә йомышчы малай булып эшкә урнаша.

Шушында ул үз хезмәте белән тапкан акчасына туйганчы икмәк ашый, сәләмәләнеп беткән өс-башын азрак рәткә кертә. Һәм биредә ул казакъ музыкантларының думбрада уйнауларын һәм чәйханәдәге ярым һәвәскәр, ярым профессиональ оркестр чыгышын сокланып тыңлый. Шушы оркестр составындагы бер латыш музыканты Заһидка музыка буенча башланган белемен дәвам иттерергә булыша.

Моңа чаклы ноталарны түгәрәк билгеләреннән генә гыйбарәт дип белгән Заһид алдына тагы да кыенрак, тагы да катлаулырак билгеләр килеп баса: бөтен нота, ярты, чирек һәм сигезле, уналтылы... ноталар, шуның өстенә аларның таякчыклары, койрыклары... Ул гынамы әле. Тагы такт дип аталган нота бүлемнәре һәм аларның счетметрлары, ноталарны тоташтыручы «лига» дип исемләнгән дугалар һәм башка бик күп төрле билгеләр. Заһидка алар кайчак өйрәнеп булмаслык читен һәм авыр нәрсә булып тоелсалар да, һәрбер яңа үзләштергән тавыш, яңа термин аның күңелен күтәрә, дәрт өсти иде. Һәм менә ул, ниһаять, ике-өч татар көен дә башкара алуга ирешә.

Чәйханә хуҗасы Заһидның бу һөнәрен үзенә табыш өчен файдалана. Шәһәр буйлап «Чәйханәдә скрипкачы татар малае уйнаячак» дигән хәбәр бик тиз таралып өлгерә.

Беркөнне хуҗа Заһидка:

— Бүген бик әйбәт итеп уйнарга тырыш, чәйханәгә Казан композиторы килә,— ди. — Әйбәт итеп уйнасаң, үзеңә чалбар алып бирермен, — дип тә өстәп куя.

Заһид каушап кала. Өйрәнчек малай өчен профессиональ музыкант алдында уйнау ансат эшмени? Шабыр тиргә батып беренче көйне уйнап бетерүгә, Казан музыканты Заһид янына килеп:

— Энем, сиңа укырга кирәк. Үзеңне көчләмә, уйнамавың яхшырак булыр. Казанга кил. Менә сиңа адрес. Үземне күр. Солтан абый Габәши дип сорарсың... — ди.

Хуҗага кунак ошамады. Бигрәк тә «уйнама» диюе аның ачуын чыгарды һәм Заһидка чалбар эләкмәде. Чалбарсыз калса кала, әмма шушы кичне Заһид Солтан абыйсы калдырган контрамарка белән Казаннан килгән артистлар концертына бару бәхетенә ирешә.

Беренче тапкыр ул профессиональ артистларны күрә, беренче тапкыр Казан артистлары тарафыннан бирелгән концерт тыңлый. Мәшһүр җырчы Газиз Әлмөхәммәтов башкаруындагы башкорт һәм татар халык көйләре, Солтан Габәшинең рояльдә уйнавы, «мандолина короле» дип даны таралган Исмәгыйл Һилаловның башкару

осталыклары Заһидта зур тәэсир калдыралар. Концерттан соң аның күңеле тагы да үсеп китә, музыкант булу теләге көчәя төшә. Хәзер ул фәкать Казанга китү, укырга керү турында гына уйлый башлый. 1926 елның август аенда, иң арзанлы билет алып, Заһид Казанга юл тота.



## II

Балалар йортына килеп кергәнче Заһид музыканың нәрсә икәнлеген дә белми иде. Дөрес, әти-әниләре исән чакта урамнарда некрутларның җырлап йөргәннәрен аның күргәне дә һәм ишеткәне дә булгалады. Ләкин ул аны җыр яки музыка дип түгел, ә солдатка китүче абый кешеләрнең елаулары дип кенә аңлый иде. Моңа чаклы аңа музыка турында хыялланырга да мөмкин түгел иде. Беренчедән, Вәли абый алла тарафыннан тыелган, мөселманнар өчен гөнаһ саналган музыкага, ихтимал, каршы булыр иде. Әле ризалыгын биргән тәкъдирдә дә, баласын укытырга һәм аңа нинди дә булса музыкаль инструмент алып бирергә байлыгы җитмәс иде.

Совет власте урнашу белән милли музыкабыз алдында торган каршылыклар, киртәләр дә көннән-көн җимерелә башлады. Колак ишетмәслек, күз күрмәслек аулак урыннарда гына шыңшыган музыка кораллары тулы хокук алды. Давыллы еллар һәвәскәрлеккә дә җанлылык кертә. Шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да «санаигъ нәфисә» хәрәкәтләре киң колач алды.

Заһид Казанга килгәндә, профессиональ сәнгатебез, шул җөмләдән музыкабыз, бөреләнеп чәчәк ата башлаган еллар иде.

Кыен заманда оешып, иске мохитның һәр авырлыгын үз җилкәсендә татыган «Сәйяр»га да 1926 елны егерме ел тула. Революциядән соң ул стационарга күчеп дәүләт карамагында эшли башлый. Шушы театр сәхнәсендә уйналган әсәрләргә музыка кертелә. Театрда Салих Сәйдәшев беренче профессиональ композитор һәм беренче татар дирижеры буларак танылa. Шушы театрыбызның тамаша залында беренче тапкыр татар көйләре симфоник оркестр башкаруында яңгырый.


Бөек Октябрь революциясенә ун ел тулган көнне Казан радиостудиясе үзенең дулкыннарын эфирга тарата башлый. Татар музыкасы, татар җыры илебезнең ерак почмакларына тарала. Студиядә В. И. Виноградов җитәкчелегендә симфоник оркестр оеша. Профессиональ башкаручы буларак мәйданга Асия Измайлова, Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләйманова, Сара Садыйкова, Ситдыйк Айдаров, Ярулла Чамаев, Зөһрә Байрашева, Любовь Юрусова кебек җырчылар белән Фәйзулла Туишев, Һилал Гомәров, Хәсән Гобәйдуллин, Заһид Зверев кебек музыкантлар күтәреләләр. Һәм Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев кебек үсеп килүче композиторларыбыз да күренә башлый.

Шушы ук елларда татар музыкасының беренче зур күләмле әсәре — «Сания» операсы да сәхнәгә менде.

Болар әлегә беренче тәҗрибәләр, башлангыч сукмаклар гына иде. Музыкабызның киләчәге турында да уйланылды. Нигезе салына башлаган музыка сәнгатебезгә кадрлар хәзерләү, моңа чаклы Казанда Шәрык консерваториясе төсендә яшәп килгән уку йорты нигезендә оештырылган һәм Римский-Корсаков шәкерте, олы музыкант, педагог Александр Александрович Литвинов җитәкчелегендәге Казан көнчыгыш музыка техникумына йөкләтелде. Бу техникумда дистәләрчә татар егетләре, татар кызлары тәрбияләнделәр. Җыйнап кына әйткәндә, шушы техникумда белем алган һәм алгы елларда югары музыка уку йортларында укыган көчләр белән татар совет музыкасы барлыкка килде, опера һәм балет театры туды, филармония оешты, җыр һәм бию ансамбле кебек зур художество коллективлары булдырылды.

Заһид Хәбибуллин да Казанга килгәч республикабызда бердәнбер музыка уку йорты саналган шушы техникумга керә һәм скрипка буенча А. А. Литвинов классына алына.

Бирерә Заһидка укуны яңабаштан башлап җибәрергә туры килде. Һәм ул укуга зур дәрт, зур теләк белән тотынды. Әмма беренче курсны тәмамлау алдыннан егеткә шик төшә. Укый алмаудан түгел, ә аны гарипләнгән бармагы борчый. Юк-юк та, күнегүләр вакытында бармак үзенең музыкант өчен яраксызлыгын сиздергәләп куя.



*Рәсемдә (сулдан уңга): композитор Александр Ключарев, композитор Заһид Хәбибуллин, шагыйрь Хәсән Туфан, актриса Шәхсәнем Әсфәндиярова, композитор Җәүдәт Фәйзи.*

Укучысының борчылуын Александр Александрович та сизә. Ул әледән-әле Заһидны тынычландырып килә һәм, озакка сузмый, каникул вакытында аны больницага алып бара. Врачлар белән сөйләшә, хирургик ярдәм кирәклеген аңлата. Һәм бармакка операция дә ясала.

Заһидның күңеле күтәрелеп китә. Киләчәккә булган ышанычы ныгый төшә. Укулар да, күнегүләр дә җиңeләеп киткән кебек була. Татар театры спектакльләрен карый, концертларга йөри башлый.

Менә ул уку алдынгыларыннан төзелгән оркестр составында уйнау бәхетенә дә ирешә. Югары уку йортларындагы студентлар өчен бирелгән концертларда да катнаша. Заһид өчен зур шатлык була. Тәҗрибәле профессиональ музыкантлар белән янәшә утырып уйнау укучы-музыкант өчен үзе бер мәктәп була. Опера коллективы тарафыннан куелган «Эшче» операсында уйнау яшь музыкантның үсешендә югарыга тагын бер баскыч булып истә кала. Татар, башкорт халкының музыкаль фольклорын җыюда зур хезмәт күрсәткән мәшһүр музыкант, композитор Антон Эйхенвальд дирижерлык иткән оркестр составында уйнау Заһид күңелендә онытылмаслык тәэсир калдыра. Ә инде бу олы маэстроның утызынчы елларда Казанда уйналган «Дала» операсы аңа көчле йогынты ясый. Композиторның башкорт һәм татар халык көйләреннән оста һәм иҗади файдалана алуы Заһидны илһамландырып җибәрә һәм иҗат теләкләре тудыра.

Заһидта иҗат сәләте бөреләнә башлый. Һәм ул халык көйләренә гади генә аранжировкалар ясап карый, импровизация белән мавыга.

Бу елларда илебездә «Күк күлмәклеләр» сәнгатенең тамыр җәйгән чагы иде. «Күк күлмәклеләр» иң әүвәл агитаторлар, ә аннан соң артистлар: декламаторлар, биючеләр, җырчылар, музыкантлар һәм гимнастлар булдылар. Искелекне, артталыкны, җимереклекне чыбыркыладылар, яңалыкны, производство алдынгыларын пропагандаладылар. Җыйнап кына әйткәндә, алар эчке һәм тышкы дошманнарны, кимчелекләрне фаш иттеләр, яңа мораль, яңа тормыш өчен көрәштеләр.

Аларның үз формалары бар иде. Ирләр кара күлмәк, кара галстук, соры костюм, кызлар — күк блуза, кара юбка, кызыл яулыктан чыгалар иде.

Завод-фабрика, предприятие-учреждениеләрдәге җыелышларның берсе дә «Күк күлмәклеләр» чыгышыннан башка үткәрелмәде. «Күк күлмәклеләр» өчен сәхнәнең кирәге булмады, алар кайда туры килсә, шунда: урамда, мәйданда, цехларда, хәтта тәбәнәгрәк түбә башларында да чыгыш ясыйлар иде.

Бүгенге күзлектән караганда, ул чыгышларның художество сыйфаты түбән булса да, алар үзләренең тоткан юлы, алларына куелган бурычлары белән яңа иделәр, алар пролетар сәнгать буларак партиягә, яшь совет иленә зур булышлык күрсәттеләр. Совет власте өчен көчле һәм тәэсирле агитация алып бардылар. Барлык яшьләрне хәрәкәткә китергән бу агымнан Заһид та читтә кала алмады. «Күк күлмәкләләр» концертларында ул аккомпаниатор-иллюстратор буларак катнаша. Һәм менә шушы пролетар сәнгать хәрәкәтенең гөрләп торган чагында ул үзенең беренче иҗат адымнарын ясап карый. «Күк күлмәкләләр» программасындагы кайбер номерлар аның музыкасы астында башкарылалар. Асылда ул музыкалар, мөстәкыйль әсәр булмыйча, фәкать сәхнәдә барган хәрәкәтләр өчен марш стилендә, югары пафос белән язылган кисәкләрдән генә гыйбарәт була. Ә соңга таба инде Заһид производствоны артка сөйрәүче ялкаулар, корткычлар, мещан типларын фаш иткән, вакытында көчле генә тәэсире булган, җиңел такмак төсендәге куплетлар да яза башлый.

Заһид Хәбибуллинның башлангыч иҗат юлы искелек белән яңалыкның бәрелешү елларына, сәнгать дөньясында төрле измнарның яшәгән вакытына туры килә. Ул елларның шаукымы татар музыкасына да кагыла.

Музыка яңалыкка юл яру елларында татар композиторларының музыкаль әсәрләре, нигездә, илебездә барган вакыйгаларга, аның бүгенгесенә һәм киләчәгенә аваздаш булып яңгырады.

Заһид Хәбибуллинның композитор буларак иҗади эшчәнлеге менә шушы катлаулы елларда башланды һәм аның беренче әсәрләре дә шушы елларда язылдылар. Сынау, тәҗрибә төсендәге бу беренче әсәрләрендә кимчелекләр дә булмады түгел. Кызыклы гына эзләнүләре булуга карамастан, кайберәүләре тирән эчтәлекле, мөстәкыйль әсәрләр югарылыгына күтәрелә алмады, төрле тавышларга нигезләнеп кенә язылдылар. Тәҗрибә дә, белем дә җитеп бетмәве әле үзен сиздерә иде. Әлбәттә, беренче тапкыр тәртә арасына кереп иҗат арбасын тигез юлдан тартып китү җиңел түгел. Әмма Заһид бу арбаны урыныннан кузгатты, аны тормыш юлыннан алып китәрлек сәләт тә, талант та барлыгын күрсәтте.

1932 елда Заһид техникумны тәмамлый. Башта Казан житен комбинаты каршындагы эшче-һәвәскәрләр театрына җибәрелә. Озак та үтми, профессиональ театрга күчерелә. Менә шушы «Эшче театры»нда аның иҗаты беркадәр камилләшә, ачыклана төшә. Театр коллективы тарафыннан уйналган «Кызыл байрак өчен көрәш», «Кояшлы цех», «Ударниклар», «Фабзавком» (барысы да Әсгать Мәҗит әсәрләре) кебек пьесаларга язылган музыкаль оформлениеләр сәхнәдәге вакыйгаларның пафосын бирүдә, геройларның характерларын ачуда уңышлы гына иҗат адымнары иделәр. Ә инде аның шул елларда «Ударниклар маршы», «Грузчиклар җыры», «Машиналар биюе», «Чүкеч тавышы», «Колхоз маршы» кебек индустрия, колхоз төзелеше, беренче бишьеллыклар пафосы белән рухланып язылган әсәрләре татар музыкасында хезмәт темасының яңгырашын көчәйттеләр.

Композитор буларак үзен таныта башласа да, бу беренче иҗат җимешләре Заһидны канәгатьләндермәде. Белемен ул тагы да тулыландырырга, тирәнәйтергә тиеш иде. Шул ният белән 1934 елны Заһид Мәскәүгә китә. Башта Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы рабфакның композиция бүлегенә икенче курска укырга урнаша. Бер елдан соң шул ук консерваториянең училищесына, ә тагы бер елдан яңа гына ачылган татар опера студиясенә күчеп, 1940 елга чаклы профессор Г. Литинский классында укый. Укуының беренче елларыннан ук иҗат эшен җәелдереп җибәрә. Ул труба өчен «Урманга, кырларга» исемле, кларнет өчен «Күңелле җыр», скрипка өчен «Фантазия» кебек пьесалар, инструменталь ансамбль өчен «Татар маршы»н яза. Болардан тыш Заһид Хәбибуллин, татар халык җыр иҗаты традицияләренә таянып, гади, ачык, матур көйләре һәм образлылыклары белән аерылып торган җырлар да иҗат итә.

Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган «Сагыну», «Җырым булсын бүләгем», «Колхоз кырлары», «Без яшь көчләр», «Батыр егеткә», «Хезмәткә» һ. б. лар — әнә шундыйлардан.

Гомумән, сугыш алды елларыннан алып аның иҗади йөзе киңәя төшә һәм ачыклана башлый. Заманның актуаль темаларына ул бу елларда иллегә якын җыр яза, ә 1940 елны скрипка һәм фортепьяно өчен язылган поэмасы Заһид Хәбибуллин иҗатының уңышлы үсә баруын раслаучы үрнәк булып тора.

## III

Заһид Хәбибуллинның иҗат эшчәнлеге күзгә күренеп үсә барганда, Бөек Ватан сугышы башлана. Композиторга башта кулына көрәк, лом тотып, көзге салкын көннәрдә каткан җирне актарырга, окоп казырга туры килә. Аннан соң солдат шинелен кия, хәрби техниканы өйрәнә.

Ләкин Заһидка сугыш кырына китәргә туры килми.

Ул Казанга кайтарыла һәм иҗат эшенә тотына. «Җиңеп кайт» (К. Нәҗми), «Партизан егет» (Н. Арсланов), халык сүзләренә язылган «Сугышчан егеткә» кебек халыкны изге көрәшкә рухландырган, сугышчан ритм, чакыру интонацияләре белән сугарылган патриотик җырлар туа.

Фашизм тар-мар ителгәннән соң Заһид Хәбибуллин зур иҗат күтәренкелеге белән яңа әсәрләр өстендә эшли. Композиторның бу еллардагы иҗаты иң әүвәл үзләренең актуальлекләре һәм тематик яктан төрле булулары белән аерылып торалар. Сугыш кырларында зур батырлыклар күрсәткән сугышчыларыбызга ул «Совет солдаты» җырын багышлый, тынычлык өчен көрәшкә чакырып «Яшәсен тынычлык» (Г. Насрый сүзләре), «Дүрт яран» (С. Хәким) җырларын яза, нефтьчеләребезгә «Баулылар» (Н. Арсланов), кыр батырларына «Сабанчы егетләр», «Комбайнчылар җыры», «Безнең басуда», «Сайра син, тургай», «Бригадир кыз Гөлниса» әсәрләрен бүләк итә. Ә аның «Партия турында җыр»ы (Ә. Ерикәй) республика конкурсында беренче премияне ала.

Заһид Хәбибуллинның Тукай сүзләренә язылган яңа җырлар циклы да шушы елларда барлыкка килә. Үзенең бер мәкаләсендә Хәбибуллин: «Тукайның һәр әсәре үзе музыканы тудыра. Бу аның шигырьләренең халыкчан, халык моңына бай булуыннан килә», — дигән иде. һәм бөек шагыйребезнең үлемсез мирасы белән рухланып, композитор Тукай поэтикасына тәңгәл килгән җырлар иҗат итә, Тукай сүзләренә ачык һәм матур яңгырашлы музыкаль образлар таба. Циклдагы «Туган тел», «Бишек җыры», «Иртә», «Карлыгач», «Пар ат», «Гали белән кәҗә» кебек җырларда җитезлек, тапкырлык, тормышка, хезмәткә мәхәббәт ачык гәүдәләнә. Ә «Җил», «Чишмә» кебек җырларда табигать матурлыгы чагыла.

Илленче еллардан алып З. Хәбибуллинның композиторлык эшчәнлеге киң колач алды. Татар дәүләт академия театры һәм республиканың башка театрлары спектакльләренә язылган музыкалар, бигрәк тә балет кебек зур күләмле әсәрләр өстендә эшләү елдан елга, әсәрдән әсәргә композиторның таланты ачыла баруын раслыйлар. Бу вакытта аның инде үзенчәлекле үз стиле формалашып җитә, иҗатының төп юнәлешләре билгеләнә, жанрлар буенча төрләнә.

1950 елда Заһид Хәбибуллин композитор Н. И. Пейко белән берлектә, татар музыка культурасы тарихында беренче булып, революция темасына багышланган балет иҗат итәләр. Бу — Кави Нәҗми романы буенча Ф. Гаскаров либреттосына язылган «Язгы җилләр» балеты. Балетта революция алды елларында татар һәм рус халкының героик көрәше сурәтләнә. Вакыйга Казанда бара һәм Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүе белән тәмамлана.

Балетның музыкасы гражданнар сугышы елларындагы татар һәм рус җыр фольклорына нигезләнеп һәм шәһәр татарлары җырларындагы интонацияләрдән оста файдаланып язылган, тыңлау өчен ягымлы, матур яңгырый. Гомумән, бу балет Заһид Хәбибуллин иҗатының җитдилеген, аның тирән эчтәлекле социаль темалар өстендә эшләргә сәләтле булуын күрсәтә.

1955 елда Заһид Хәбибуллин зур күләмле сәхнә әсәрен, Тукай поэзиясенә һәм татар халык әкиятләренә нигезләнеп язылган «Раушан» балетын тәмам итте (Г. Сәлимов либреттосы). Монда да композитор татар халкы музыкаль иҗаты традицияләренә таяна, аларны иҗади эшкәртә һәм социаль яңгыраш бирүгә ирешә. Язучы Җ. Тәрҗеманов «Татарстан яшьләре» газетасында басылган рецензиясендә әсәр хакында «Күңелнең иң нечкә җирләренә үтеп керерлек, тормышка дәрт бирерлек, уч төбе кызарганчы кул чабарга җәлеп итәрлек көйләр белән, онытылмаслык булып күңелгә сеңеп кала торган образлар белән иҗат ителгән спектакль», — дип язды. Ә «Социалистик Татарстан» газетасында музыка белгече М. Нигъмәтҗановны «киләчәк буынны, коммунистик иртәгәбездә яшәячәк балаларыбызны тәрбияләү өлкәсендә

зур хезмәт итәчәк һәм аларның эстетик зәвыкларын үстерүдә зур роль уйнаячак» әсәрләрдән «беренче карлыгач» дип бәяләде.

Татар музыка культурасы өлкәсендә хәзер халык әкиятләре, Г. Тукай поэзиясе белән рухланып язылган балетларның саны шактый үсеп бара. Менә алар: Ф. Яруллинның «Шүрәле»се, Н. Җиһановның «Зөһрә»се, Р. Гобәйдуллинның «Кисек баш»ы, Ә. Бакировның «Алтын тарак» исемле әсәре һәм, ниһаять, Заһид Хәбибуллинның «Раушан»ы.

«Раушан» балетының эчтәлеге үзеннән алда язылган балетларга охшый төшсә дә, «изге һәм явыз көчләрнең бәрелешен, яхшылыкның җиңү тантанасын» тасвирлауда тема кабатланса да, балет яңгырашы белән яңача кабул ителә. Балет музыкасындагы моңлылык, нәфислек һәм җылылык әсәрне тамашачы күңеленә якын итә.

Әйткәнебезчә, З. Хәбибуллинның бу еллардагы иҗаты республика театрлары сәхнәләрендә уйналган күп санлы спектакльләр белән дә бәйләнгән. Дөрес, бу жанрда ул иҗатының беренче елларында ук эшли башлаган иде. «Күк күлмәклеләр» дәверендә, соңрак «Эшче театры» һәм сугыш алды елларында күчмә театр сәхнәсендә уйналган «Шатлык җыры» (Г. Кутуй), «Эшче» (Ә. Мәҗит) спектакльләренә музыканы З. Хәбибуллин язган һәм алар үз вакытында җылы гына каршыланган иделәр. Ә инде илленче еллардан алып композиторның бу жанрдагы эшчәнлеге сизелерлек активлаша. Соңгы 15—20 ел эчендә Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйналган һәм уйналып килгән «Татар хатыны нилләр күрми» (Г. Ибраһимов), «Беренче театр» (Г. Камал), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш. Камал), «Якын дус» (Р. Ишморат), «Кыш нарат» (Г. Насрый) һәм республикабызның башка театрлары тарафыннан куелган «Күңел дәфтәре» (Г. Насрый) спектакльләренең музыкасы Заһид Хәбибуллинның иҗат җимешләре булды. Спектакль геройларының психологиясенә керү, характерны һәм заман колоритын музыкада бирү осталыгы әсәрдән әсәргә үсә бара. Сәхнә әсәрләренең эчтәлекләрен тулыландырып, алардагы вакыйгаларга органик үрелеп барулары, драматик төгәллекләре белән ул музыкалар мөстәкыйль хезмәт булып саналырга хаклылар.

Җыр жанрында Заһид Хәбибуллинның иҗаты бу елларда аеруча киң колач алды. Матбугатта басылган мәкаләләрдә Заһид Хәбибуллин язган җырларның саны 300 дән артып китүе күрсәтелә. Әлбәттә, шушы көнгәчә композитор әсәрләренең библиографик белешмәсе булмавы төгәл санны күрсәтүне беркадәр кыенлаштыра.

Мәгълүм ки, һәр җыр тексттан, сүздән башлана. Заһид Хәбибуллин сүз белән музыканың органик бәйләнешенә, аның бөтен бер әсәр булып берегүенә омтыла. Композитор үзенең музыкасы белән шагыйрь сүзләренең идея яңгырашын тулыландыра, көчәйтә һәм текстның «резонаторы» — көчәйткече югарылыгына күтәрелә.

«Җырны мин ике авторның күңел тавышы, йөрәктән чыккан иҗат җимеше дип таныйм, — ди Заһид Хәбибуллин, — шуңа күрә дә язылачак җырыма текст сайлаганда мине, композитор буларак, иң әүвәл авторына гына хас үзлекләргә ия булган, ихлас язылган һәм саф күңелдән иҗат ителгән шигырьләр кызыксындыра».

Композиторның текст буенча соавторлары кырыктан ашып китә. Алар арасында Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Һади Такташ кебек классик шагыйрьләр дә, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Фатих Кәрим, Гадел Кутуйлар белән бүгенге көндә иҗат итүче урта буын сүз осталары да һәм поэзиягә әле яңа гына аяк баскан яшь шагыйрьләр дә бар. Сибгат Хәким сүзләре белән әйткәндә, «Татар халкына искиткеч көйләр биргән. Заһид Хәбибуллин барлык татар шагыйрьләренең иң якын каләмдәш дусты».

Заһид Хәбибуллин җырларының тематикасы киң. Бу үзе композиторның халык белән бергә атлап баруын һәм аның иҗатының тормыш таләпләре белән сугарылганлыгын раслый.

Композиторның лирик җырлары да анык адресланган һәм җитди мәгънәгә ия булулары белән аерылып торалар. Мәсәлән, үзенең нәфислеге, сафлыгы белән тыңлаучыларны сокландырган, туган табигатебезнең матурлыгы белән бергә колхоз кырларының хезмәт батырлыкларын җырлаган «Бормалы су» (Н. Исәнбәт) һәм «Айлы төн», «Сиңа», «Эзләдем, бәгърем, сине», «Сөясеңме», (Ә. Ерикәй сүзләре) «Кечкенә Идел» (Ш. Маннур), «Казан кызы» (Н. Арсланов), «Иркәмә», «Зәңгәр» (Г. Насрый)

һ. б. бик күп җырлар Заһид Хәбибуллинга хас җылылык, самимилек белән иҗат ителгәннәр.

Заһид Хәбибуллин — шаян һәм күңелле җырлар остасы да. Алар ачык күңел белән дусларча шаяру булып та, адресатларына туры барып тия торган үткен такмаклар булып та яңгырыйлар. «Күк күлмәкләләр» өчен язылган «Ялкаулар турында җыр», скрипка өчен эшләнгән «Чикерткә», соңгы елларда иҗат ителгән «Мактанчык егет» (һ. Солтанов), «Яшәсен кияүләрем» (М. Хөсәен), «Нәсимә», «Күтәр күңелләремне» (Н. Арсланов), «Чибәр егет килсә» (халык сүзләре) һәм башка җырлар әнә шундыйлардан. Заһид Хәбибуллин пионерлар һәм мәктәп балаларына да берсеннән-берсе матур әсәрләр бүләк итте. «Пионерлар маршы» (Ә. Маликов), «Ана белән бала», «Чаңгычылар җыры», «Күңелле чыршы», «Әйлән-бәйлән», «Исәп-хисап» (Җ. Тәрҗеманов сүзләре), «Без үсәбез» (Б. Рәхмәт), «Күк күгәрчен» (Г. Насрый) җырларында балаларга хас җанлылык, җитезлек сизелеп тора.

Заһид Хәбибуллин күмәк башкару өчен дә шактый сандагы әсәрләр язды. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен әле соңгы ике елда гына да аның тарафыннан «Халыклар дуслыгы» һәм «Туй» исемнәре астында махсус ике зур программа эшләнде. Ә үзешчән коллективлар өчен язылган хор һәм бию музыкалары, аерым район алдынгыларына багышланган көйләрнең хәзер инде санын әйтүе дә кыен.

1968 елны Заһид Хәбибуллинның алты җыры Тукай исемендәге премиягә тәкъдим ителә. Аларның берсе — М. Җәлил сүзләренә язылган «Гөлләрем» җыры. Җыр исеме кебек үк гаҗәеп ягымлы, саф музыкаль телдә язылган әсәр. Алар арасында шулай ук «Солдат җыры» (К. Латыйп) кебек сугыш-тынычлык темасына багышланган патриотик әсәр дә, «Бормалы су» (Н. Исәнбәт) кебек лирик җыр да, сатирик планда язылган «Мактанчык егет» (һ. Солтанов) һәм «Казакъ кызы сөйгәнем» (Г. Сәгыйдуллин), «Безнең кардәшлек» (Г. Зәйнашева) исемле дуслык темасына багышланган җырлар да бар.

Бу җырлар һәрьяклап эшләнгән һәм композиторның иҗади йөзен билгеләүче югары сыйфатлы иҗат җимешләре итеп бәяләнделәр.

«Советская Татария»[1] газетасы композиторның дуслык темасына язылган җырларына карата: «халыклар дуслыгы һәм туганлыгы темасы аның музыкасында йолдыз булып яна», — дип язды. Шул ук газетада басылган икенче бер мәкаләдә бу җырларның яңалык алып килүләре һәм «татар сәнгатендә бөтенләй яңа сәхифә» ачулары»[2] турында әйтелә. Чыннан да, ул җырлардан саф күңеллелек, табигый юмор, эчкерсез дуслык хисләре бәркелеп тора.

Заһид Хәбибуллин үз иҗатында кешеләргә аеруча бер җылылык саклый, һәр яңалыкка шатлана, һәр уңыш өчен чиксез куана ала. Үзенең тыңлаучылары арасында З. Хәбибуллин бик еш була. Кыр эшләренең барышы да, нефтьчеләрнең казанышлары да, балаларның укулары да аны кызыксындырмый калмый. Заһид Хәбибуллинны «тимер юлыннан бик ерак булган авылларда да, Кама аръягы больницаларында, учак ягып утыручы көтүчеләр янында да... бик еш очратып була». Композиторның күпчелек җырлары менә шушы хезмәт кешеләре белән очрашу вакытларында туа.

Чыннан да, кайда гына булмасын, ул бөтен җирдә җыр калдыра. Нефтьчеләргә ул «Баулылар», «Лениногорск турында җыр»ын бүләк итә. Тымытык авылында тракторчылар һәм колхоз сыер савучыларыннан баянчылар ансамбле оештыра, аларга багышлап «Тымытык маршы»н яза, Балтач яшьләрен марш белән сәламли, кыр батырларының хезмәтләренә сокلануын «Игенче — ил терәге» җырында белдерә.

Композитор Актаныш, Баулы, Минзәлә, Саба һәм башка бик күп районнарның үзешчән коллективлары өчен тематик программалар хәзерләде, Арча районындагы гармунчылар ансамбленә махсус көйләр язды. Аның бу хезмәтләре СССР Культура министрлыгы һәм культура работниклары профсоюзы Үзәк Комитеты тарафыннан «Авыл культура шефлыгы отличнигы» исеме белән билгеләп үтелде. Республикабызның Мөслим районы аны үзенең почетлы гражданины итеп мәңгелек хөрмәт кенәгәсенә кертте. Шулай ук җирле һәм өлкә партия, совет оешмалары тарафыннан бирелгән дистәләрчә Мактау грамоталарында да Заһид Хәбибуллинның бу хезмәтенә зур

[1] «Советская Татария». Баш мәкалә. 1968 ел, 26 апрель.
[2] «Советская Татария», М. Нигъмәтҗанов. «Его песни поет народ», 1968 ел, 12 апрель.

бәя бирелә һәм композиторны совет авылы хезмәт ияләренең иң якын дусты итеп танулары әйтелә.

Заһид Хәбибуллин тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр арасында «ару» музыка дип аталган, ягъни текст белән бәйләнмәгән инструменталь әсәрләр дә бар. Мисалга аның трио, квартет, милли музыка кораллары, эстрада һәм симфоник оркестрлар өчен язылган әсәрләрен, аерым инструментлардан труба, гобой, кларнет өчен язылган пьесаларын һәм фортепьяно, скрипка өчен иҗат ителгән поэмаларны күрсәтә алабыз.

Шулай ук Заһид Хәбибуллин «Сарман», «Арча», «Уракчы кыз», «Су буйлап», «Су юлы», «Фазыл чишмәсе», «Сүнмәс дәрт», «Аккош» кебек дистәләрчә татар халык көйләрен үзенчәлекле эшкәртте.

«Сарман» көендә моңлылык арта төшкән, лирик буяулар баерак бирелгән, ә «Берсе алма, берсе хөрмә» җырында халык шаянлыгы һәм җанлылык өстәлгән, «Аппакай, алмакай» көе дуэт итеп кара-каршы җырлау өчен эшкәртелгән һәм музыкасында мәхәббәт хисләре үстерелеп бирелгән, ә «Арча» көенә композитор татар халкына якын булган тальян гармун тавышлары кертә...

Борынгы халык көйләрен композитор, алар барлыкка килгән дәвердәге яңгырашны төгәл саклап, ничек бар — шул көенчә нота кәгазенә генә күчерми. Ул аларны үз күз алдына китерә алганча, иҗади тирәнлектә ишетеп эшкәртә. Халык көйләрен ул үз иҗаты табышлары белән бизи, матурлый, хәзерге заман рухы белән сугара. Нәтиҗәдә халык җырларының тәэсире көчәя төшә.

Гомумән, Заһид Хәбибуллин әсәрләренең барысы да — балет, вокаль, инструменталь әсәрләр дә — халыкчанлык сыйфаты белән сугарылганнар. Мисалга бер генә җырны атау да җитә. Композиторның «Сагыну» җыры халык җырына шул кадәр якын ки, хәтта аны әле дә халык көе дип кабул итәләр. Шулай ук «Өчле» һәм «Бишле» дип аталган кызлар биюләре дә халыклашып киткән көйләр рәтендә йөриләр. Аның әсәрләренең күңел кылларын тибрәтә алырлык кодрәткә ия булуының сере дә әнә шул халыкчанлыкта. Шуңа күрә композиторның музыкасы тыңлаучыларга аңлаешлы, якын һәм кадерле. Композиторның алымы, стиль үзенчәлеге халык җырларыннан файдалана белүендә генә түгел, ә халык җырлары интонацияләреннән үсеп чыккан оригиналь әсәрләр тудыра алуында. Татар халкының гаҗәеп бай фольклорыннан тыш, Заһид Хәбибуллин рус революцион һәм совет халкының массовый җырларының интонацияләрен дә үзенә иҗат үрнәге итеп файдалана белә.

Заһид Хәбибуллин елдан елга, әсәрдән әсәргә техникасын үстерә һәм үзенең композиторлык почеркын ачыклый бара. Аның иҗади алымы үзенә бертөрле һәм үзенә генә хас аерымлыкка ирешә. Ләкин шулай да, бу иҗатның мөһим сыйфаты итеп, борынгы озын көйләргә, авыл җырлары тибындагы халык иҗаты чыганагына аеруча якын торуын күрсәтергә кирәк.

Музыка белгечләре Заһид Хәбибуллинның «билгеле булган композицион алымнарны, интонацияләрне, гармоник борылышларны үзенчә баета, аларны үзенчә эшли, яңадан «эретеп коя» һәм әсәрдән әсәргә югары уңышка ирешә» алуына басым ясыйлар. Һәм аны кыю художник дип атап, «иҗатының буеннан-буена һәрбер әсәрендә яңа саф һәм ачык тавышлар табуын, үзенә хас художество алымнарына һәм гадәттән тыш мул фантазиягә ия» булуын күрсәтәләр [1].

Заһид Хәбибуллин иҗатына хас икенче сыйфат — аның әсәрләрендәге гражданлык хисенең көчле булуында. Ул заманның иң үткен, иң әһәмиятле мәсьәләләрен тирән кичереп иҗат итә торган композитор. Аның әсәрләре уңышының төп сере дә — Ватан язмышы, халык тормышындагы зур вакыйгалар белән бергә үрелеп иҗат ителүендә, әсәрләренең заман сулышы белән сугарылган булуында.

Композиторның музыкаль палитрасы асылда ачыклыктан-аңлаешлыктан, оптимизмнан һәм дәртлелектән, шат күңеллелектән гыйбарәт. Аның күпчелек әсәрләрендә яз энергиясен, яшьлек көчен, туган илебез табигатенең гүзәллеген тоясың, халкыбызның үз тавышын ишетәсең. Бу исә әсәрләренең мелодик сулышы татар халык фольклорыннан, халыкның үз рухыннан килүен күрсәтә.

60 яшь тулып узуга карамастан, ул әле җиңел, хәрәкәтчән, ачык чырайлы, елмаю-

[1] «Музыкальная культура Советской Татарии», Москва, 1969 ел, 177 бит.

чан йөзле, саф күңелле һәм яшьлеккә хас җыйнак кеше. Бу сыйфатлары аның музыкасында да сизелә. Кешене яратуы, табигатькә соклана белүе, илен чын күңелдән сөю, халкының гореф-гадәтләрен ихтирам итүе гүзәл аһәңнәр булып аның музыкасына күчә, тыңлаучыга нык тәэсир иткән җырларында, күңелне сихерләгән инструменталь пьесаларында, зур күләмле музыкаль әсәрләрендә чагыла.

## IV

Заһид Хәбибуллин композитор булуыннан тыш, киң танылган башкаручы-музыкант та: ул талантлы профессиональ артист, солист-скрипач, пианист-аккомпаниатор.

Г. Тукай исемендәге филармония бригадалары, ансамбльләре составында ул республикабызның барлык районнарында да булды. Кыр батырлары алдында үзенең һәм каләмдәшләренең әсәрләрен, халык көйләрен башкарды һәм башкара. Илебезнең бик күп шәһәрләрендә бирелгән концертларда ул меңләгән хезмәт ияләре алдында татар совет музыкасын пропагандалый.

Үзенә генә хас алым, башкару осталыгына ия булган З. Хәбибуллин һәр концертта тамашачыларны сокландырмыйча, аларның җылы мәхәббәтләрен яуламыйча калмый, чөнки сәхнәдә башкарган әсәрләрен ул чын йөрәге белән, тирән кичереп уйный.

Сибгат Хәким үзенең бер язмасында татар композиторлары арасында Заһид Хәбибуллинның иң үзенчәлекле композитор булуына басым ясый да, аның уйнау осталыгына карата түбәндәге сүзләрне әйтә: ул уйнаганда «ашкынулы, ярсулы, хисләрдән тәмам шашынган бер шагыйрь кебек күз алдына баса. Илаһи рух уяна анда...»

Менә шушы «илаһи рух» аша Заһид һәр көйнең үзенә хас телен табарга, музыкадагы тирән серләрне йөрәге белән тоярга, милли рухта булган гармонияләрне, үзенчәлекле алымнарны тотып алырга тырыша. Һәм ул башкарган һәрбер көй тамашачыга барып җитә, аның күңелен әсир итә. Борынгы көйләр белән ул артта калган хаят трагедиясен күз алдына бастыра, халкыбызның тирән зарларын ишеттерә, ә инде бүгенге көн музыкасы белән хәзерге тормышыбызның матурлыгын, ямен, шатлыгын ачып бирә.

# «ТӘРБИЯТЕЛ ӘТФАЛЬ» ҺӘМ «АК ЮЛ» ЖУРНАЛЛАРЫНДА БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

1907 елның январь аенда мәдәни тарихыбызда урын алырлык күренекле вакыйга була. Татар балалары өчен Мәскәүдә беренче журнал — «Тәрбиятел әтфаль» («Балалар тәрбиясе») чыга башлый. 1905—07 елгы революция Россиядәге милли халыкларның культурага омтылышларын көчәйтеп җибәрә, бу елларда киләчәк кешесенең аңын, дөньяга карашын киңәйтүдә балалар әдәбиятының роле дә югары бәяләнә башлый. Җәмгыятьнең алдынгы көчләре аны иҗтимагый аң, нечкә хис, эстетик зәвык уяту һәм тәрбияләүнең куәтле чарасы итеп карыйлар. Татар балалар әдәбияты исә ул чорда яңару чоры таләпләрен канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә булмый, анда тормыштан аерылган дини схоластика, коры үгет-нәсихәтчелек өстенлек итә. Әдәби китаплар сан ягыннан да аз басыла.

Заман рухына җавап бирерлек яхшы әсәрләргә ихтыяҗ классикларыбыз Г. Тукайны, Ф. Әмирханны, соңрак Г. Ибраһимовны, М. Гафурины балалар әдәбиятына китерә. «Шура» журналында Дәрдмәнд кечкенәләргә атап гаҗәеп нәфис шигырьләр бастыра башлый. Әлеге сүз осталары балалар әдәбиятында югары художестволылык, реализм өчен көрәш ачалар. «Сабыйларыбызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә, вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен»[1],— ди Г. Тукай, балалар әдәбиятының нинди булырга тиешлеген образлы гәүдәләндереп.

«Тәрбиятел әтфаль» шушы әдәби бурычлар яктылыгында туа. Аның битләрендә чорына хас дини-мистик әйберләр байтак, әмма журнал нигездә яшь буынны дөньяви рухта яңача тәрбияләүне максат итеп ала. Журнал балалар әдәбиятын үстерүгә аеруча зур игътибар бирә, үзенең беренче санында ук: «Бармы бездә балалар әдәбияты?» дигән сорау куя, үзе үк: «Ул авыр хәлдә», дип җавап бирә.

Балалар өчен әдәби әсәрләр бастырганда, журнал реализмны алга сөрә. Аның җаваплы секретаре булып күренекле реалист Ф. Әмирхан торуын искә алсак, бу бик аңлашыла да. Бер иптәшенә язган хатыннан күренгәнчә, әдип һәр санны баштанаяк диярлек үзе эшләгән. Журналда Ф. Әмирхан дөньякүләм мәшһүр язучы Х. Андерсенның «Мәхәббәтсез үрдәк бәбкәсе», «Гөл агачы һәм әкәм-төкәм» исемле бүген дә сокланып укырлык әкиятләрен тәрҗемә итә. Н. Думавиның туган як табигатен җылы хисләр белән сурәтләгән пейзаж шигырьләре һәр санда диярлек чыгып килә. Моңарчы балалар әдәбиятында рәсемнең тәрбияви роленә илтифат ителмәсә, журнал иллюстрацияне балалар китабының аерылгысыз өлеше итеп саный һәм бу эшне башлап җибәрә. Шуннан соң балаларга багышланган әсәрләрне иллюстрацияләү гадәткә керә. Дини әдәбиятның «җир үгез мөгезе өстендә тора» дигән уйдырмаларына каршы, журнал үзенең битләрендә Җир шары, Ай, Кояш, йолдызлар турында башлангыч фәнни мәгълүматлар бирерлек әдәби парчалар, пейзаж миниатюралары урнаштыра. Киләчәктә мәдәниятле халыклар әдипләренең, татар язучыларының балаларга багышланган югары художестволы әсәрләрен басарга вәгъдә итә. Ләкин ул биш кенә сан чыгып кала, үзенең мәсләген тулысынча тормышка ашырырга өлгерми. Бу гаҗәп түгел. Журналның һәр саны цензура аркылы үтә. Ул елларда революция инде җиңелүгә таба бара, хөкүмәт демо-

[1] Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. 1956. Том 4. 72 бит.

кратик хокукларга яңадан һөҗүм башлый, журнал исә тоткан юнәлеше белән реакция, схоластикага аркылы төшеп, чынбарлык турында яңа кыю фикерләр әйтә.

«Тәрбиятел әтфаль» тукталса да, балалар өчен журнал кирәклеге көн тәртибеннән төшми. «Әльислах» газетасында, «Сөембикә», «Мәгариф» журналларында шул хакта өледән-әле сүзләр кузгатыла, нәшриятта басылган әсәрләрнең генә балаларны тәэмин итеп җиткермәве әйтелә. Ниһаять, 6 елдан соң, яңа революцион күтәрелеш елларында «Ак юл» журналы чыга башлый.[1]

«Ак юл» — «Тәрбиятел әтфаль» шикелле демократик эчтәлекле, алдынгы журнал. Ул капиталистик җәмгыятьтә бала бәхете өчен көрәшне үзенең төп лозунгысы итеп ала. Журналда эшләүчеләр сәнгать көченә ия булган реалистик әсәрләр генә яшь буынны заманның барышын дөрес аңларлык, үз бәхетен дауларлык көчле ихтыярлы кешеләр итеп тәрбияли алуын шактый ачык күзаллыйлар. Реализмга мөнәсәбәттә журналда чорының әдәби каршылыклары, заман тудырган яңалыклар көзгедәгедәй чагыла.

Дини дидактика тарафдарлары Вакыйф Җәлал, Зәки Вәлиди, Шәех Алкин кебекләр яшьләрне алла һәм пәйгамбәрләрнең ризалыгы өчен гыйбадәт кылырга чакыралар, әсәрләрендә дини бәйрәмнәрне күккә чөеп мактыйлар.

Алар балалардан тормышның кырыс хакыйкатен яшереп калдырырга тырышалар, яшь буынны язмышка буйсынучан пассив кешеләр итеп тәрбияләүгә этәрәләр, балалар әдәбиятында реализмны инкарь итәләр. Әсәрләрендә, ярлы һәм байны бертугандай тату яшәүчеләр итеп күрсәтеп, ялган буржуаз иллюзияләр тараталар. Төрле пәйгамбәрләрне, хан-ханзадә, гарәп илчеләрен, милли рухы кабарган батырларны, дин исеменнән барган сугышларны сурәтләүче дини-романтик характердагы хикәяләр, әкиятләр, шигырьләр дә журналда шактый очрый.

Тулаем алганда, «Ак юл»да реалистик тенденция өстенлек итә. Аның халык шагыйре Г. Тукайга олы мәхәббәт белән каравы да шул хакта сөйли. Шагыйрьнең туу һәм үлү көннәре журнал битләрендә киң күләмдә билгеләп үтелә, аның тормыш юлына, иҗатына багышланган зур мәкаләләр, истәлекләр басыла, рәсемнәре урнаштырыла.

Редакция сынлы сәнгать аша балаларда эстетик зәвык тәрбияләүгә нык игътибар иткән. Журналның техник оформлениесе Мәскәүдә эшләтеп кайтарыла торган булган. Нәфис, нечкә зәвык белән эшләнгән ул рәсемнәрдән бүгенге укучы да ләззәт алырлык.

Журнал үз чорының танылган әдипләрен җәлеп итә. Ф. Әмирханның «Ул үксез бала шул» хикәясе беренче шушында дөнья күрә. Журналда Н. Думави актив язышa. «Ак юл» Тукай мәктәбен үткән зур төркем яшьләрне — демократик карашлы укытучыларны, татарская учительская школа укучыларын, алдынгы шәкертләрне туплый. Журнал эшендә Шәһит Әхмәдиев, Садри Җәлал, Габдрахман Сәнгати, Хәлил Әбелхан, Гафур Гыйсмәти, Фәрит Ибраһимов, Гали Рәфикый, Лотфи Гадел, Рәхим Баязит, М. Әхмәр һ. б. якыннан торып катнашалар. Хәзер байтагының биографияләре дә билгеле булмаган бу яшь каләмнәр журналны өч ел буенча алып баралар. Араларыннан соңрак Зыя Ярмәки, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Сәгыйть Сүнчәләй, Нәкый Исәнбәт кебек танылган язучылар үсеп чыга. Совет балалар шагыйре Б. Рәхмәткә тәүге иҗади фатиханы «Ак юл» бирә. Язучы-галимнәребез Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин беренче әдәби сынауны әлеге журналда үтәләр. Әсәрләрен беренчесе — «Бикчәнтәй угылы», икенчесе — «Сәлмән» псевдонимы белән бастыралар. Г. Тукайдан соң балалар өчен иҗат итүчеләрнең күбесе шушында туплана.

Дөрес, бу яшь каләмнәрнең әсәрләре арасында әдәби яктан йомшак булганнары да, дини эчтәлеклеләре дә юк түгел, заман каршылыклары аларның иҗатларына эз салмый калмаган. Алар капиталистик җәмгыятьтә яшь буынның бәхетен социаль стройны үзгәртү юлы белән генә тәэмин итәргә мөмкин булуын аңлау югарылыгында тормыйлар әле. Иҗатларында иң әһәмиятлесе шул: бу яшьләр яңалыкны яклап, схоластикага, дини-дидактик тенденцияләргә каршы чыгалар, әдәбиятны хезмәт баласының реаль тормышына якынайту өчен тырышалар, сүз сәнгате, әдәби образлар аша гасырлар буе килгән артталыкка, наданлыкка, явызлыкка каршы көрәш ачалар.

Журналда реализм, табигый рәвештә, ул чорда көннең кадагында торган мәгърифәт һәм гуманизм таләпләре яктылыгында формалаша. Әсәрләрнең тематикасы, жанр байлыгы, әдәби алымнары шул идеяләрдән чыгып билгеләнә. Мәгърифәткә бәйле хәл-

[1] 1913—1916 еллар арасында ике атнага бер мәртәбә Казанда чыга. Редакторы һәм өештыручысы язучы, журналист, педагог Фәхрелислам Агиев.

дә, журналга мәктәп темасы килеп керә. Мәктәп ачылу, яңа уку елы башлану көннәре балалар өчен генә түгел, өлкәннәр өчен дә зур шатлык, бәйрәм итеп сурәтләнә. Уку йорты изге урын, бәхет йорты итеп күрсәтелә. Аны тасвирлаганда, әдипләр күңелне биләрлек нәфис сүзләр һәм тәгъбирләр эзлиләр. Мәсәлән, «яшел түбәле мәктәп ерактан нурланып күренә», «ямьле бакча эчендә утыра торган мәһабәт агач бина, ул бинаның тәрәзәләреннән ак нур балкыган төсле»; «әйдә, без мәктәпкә барыйк, нинди ямьле ул әнә» һ. б. Бу — балаларда укуга, белем алуга теләк уяту максатыннан чыгып шулай эшләнә, юкса, ул чордагы мәктәп-мәдрәсәләрнең күбесе җиргә сеңгән, юеш, кысан булуы һәркемгә мәгълүм.

Галим, белемле бала әдәбиятның уңай героена әйләнә, надан боларга капма-каршы куела.

**Күр галимне, ул килә кулга китабын кыстырып,**
**Ул галимгә юл бирәдер бар надан читтән торып.**[1]

Шундый эчтәлекле өндәүләр, шигырьләр «Ак юл»да еш очрый. Бу тема әсәрнең темасы итеп алына. (З. Ярмәки. «Мәктәп баласына»; Х. Әбелхан. «Яңа мәктәп ачылганда»; Ф. Ибраһимов. «Яңа мәктәп ачылган көн» һ. б.). Журналда мәгърифәт һәм гуманизм идеяләре коры үгет-нәсихәт әйберләреннән башлап, төрле сурәтләр, үзенчәлекле образлар ярдәмендә гәүдәләндерелүгә кадәр үсә.

З. Ярмәки, Н. Думави, С. Сүнчәләй, Г. Сөнгати шигырьләрендә, Ф. Агиев, Ш. Әхмәдиев, С. Җәлал, Г. Рәхим хикәяләрендә мәгърифәт һәм гуманизм төшенчәләренең эчтәлеге тирән, сурәт чаралары киң сыйдырышлы.

Мәсәлән, байтак шигырьләрдә белемле кешенең рухи байлыгы, күркәмлеге гүзәл табигать күренеше аркылы гәүдәләндерелә, бер-беренә шактый ерак торган бу ике нәрсә арасында өстән караганда сизүе дә кыен булган эчке чагыштыру үткәрелә.

З. Ярмәкинең пейзаж шигырьләре, шул исәптән җырларга күчкән «Ак каен», «Ялгыз каен»ы «Ак юл»да басыла. Шигырьләренең беришесендә пейзаж — мәгърифәт сурәтләмәсе. «Ялгыз каен»ы менә ниләр турында сөйли: яшь чагында ак каенның ботакларына сары сандугачлар кунып сайраган, яшел яфракларына, ак кәүсәләренә кешеләр сокланып караганнар. Сез дә, ди ул балаларга, китапларда язылган алтын сүзләрне өйрәнсәгез, яшь каендай гүзәл булырсыз.

Авторның «Иртә» шигыре дә пейзаж һәм мәгърифәт параллеле формасында язылган. Иртә ул иҗтиһадка тиң, ул безгә яктылык, тормыш китерә. Баланы да шагыйрь иртә таңнан үрнәк алырга өнди.

С. Сүнчәләйнең «Тау биекме?» шигырендә белем серләренә төшенү — гүя биек тау башына менү. Көчең, ихтыярың җитеп, шуны эшли алсаң, синең алдыңда киң дөньяның бөтен яме, байлыгы пәйдә була.

Икенче төр шигырьләрдә табигать — кешелеклелек сурәтләмәсе.

Галим һәм язучы Н. Исәнбәтнең журналдагы шигырьләре өйрәнчек тәҗрибәләре генә булса да, «Урманда», «Яз башы», «Теләнче бәхете» кебек күңелгә керен утыра торганнары юк түгел. Соңгысында, мәсәлән, явыз адәмнәр кагып-сугып рәнҗеткән хәерчене җылы кояш, ямьле җәй иркәли, күңелен күтәрә, табигатьтә кешеләрне аерып карау юк. Г. Сөнгатинең «Урманда», «Бакчада», «Бәхет таңы» шигырьләрендә дә табигать белән кеше аерылгысыз бәйләнештә бирелгән. «Бөтен җиһанда мәҗлес» исемлесендә яшел сәхрә шундый иркен, тормыштагы кысынкылыкка бөтенләй чит. Хәлсез хәерче карт тик шул сәхрәдә генә җанына тынычлык таба, табигать гүзәллегенә сокланганда, аның рухи бай күңеле ачылып китә.

Биредә шуны әйтеп үтәргә кирәк: шагыйрьләр журналда күбрәк табигатьнең күңелгә аеруча хуш килә торган җылы, йомшак чакларына: яз, җәй айларына мөрәҗәгать итәләр, ул шигырьләрдә эпитетлар да җылылык тойгысын бирерлек итеп сайлана. Аларда караңгылык, күңелсезлек, төн юк. Буяуларның да күңелдә күтәренке хисләр уята торганнары алына. Бу хәл язучыларның гуманистик карашлары белән бәйле. Бер яктан, табигать белемле кеше сурәтләмәсе итеп алынса, икенче яктан, язучылар сыйнфый җәмгыятьтә көндәлек тормыштан табу кыен булган рәхәтлекне, гаделлекне шунда күрәләр. Табигатьнең кешене иркәли торган рәхимле чагы ыгы-зыгылы, шау-шулы мәрхәмәт-

---

[1] Н. Исәнбәт. «Галим», «Ак юл», 1915, № 1, 15 бит.

сез чынбарлыкка контраст куела, пейзаж гаделлекне гәүдәләндерүче символга әйләнә, үзенең матурлыгыннан бигрәк, иҗтимагый ягы белән ялтырап чыга.

Журналда мәгърифәт һәм гуманизм идеяләре, әле сөйләгәннәрдән тыш, тагын күп төрле чагылышларын таба.

XX йөз башында яшьләргә белем алу, бәхеткә ирешү өчен шартлар юк иде. Октябрь революциясе генә моның ишекләрен киң итеп ачты. Яшь буын исә гомер-гомергә бәхет турында хыялланып килде. Ш. Әхмәдиев, Ф. Агиев, Г. Рәхим балаларның шушы хыялларын чагылдыру өчен халык арасында йөри торган фантастик образлардан файдаланалар, хикәяләрендә хыялый һәм реалистик вакыйгалар бергә үреләә. «Без сукыр Ильясны һаман да күрә алмый идек» исемле хикәясендә Ф. Агиев халыкта изгелек сурәтләмәсе булып киң таралган хөзер Ильясны традицион мәгънәсендә ала. Хикәядә ярлы гаиләнең ишле балалары никадәр авыр яшәмәсеннәр, өметсезлеккә бирелмиләр. Хикәянең тәэсир көче дә ярлы балаларының әкиятләрдә генә мөмкин булган яхшылык, мул тормыш турындагы беркатлы өметләрен һәр деталенә кадәр тәфсилләп сурәтләүдә, сабый гына хыялланырга мөмкин булган гаҗәеп фантастик дөньяның бер күренешен иҗат итүендә. Кечкенә геройлар киләчәкне матур итеп күз алдына китерәләр, нинди дер бер мәрхәмәтле сукыр Ильяс килер дә аларны бөлгенлектән тартып алыр төсле тоела.

Г. Рәхимнең «Елан мөгезе» хикәясендә тылсымлы әкиятләрдә генә очрый торган елан патшасы образы — геройны да, сюжетны да хәрәкәткә китерүче төп чара. Авыл малае Габдрахманның эчке дөньясы, киләчәк турындагы уйлары, омтылышлары шул хыялый образга мөнәсәбәттә ачыла. Г. Рәхим чынбарлыкны бала күзлегеннән чыгып күрә белә. Малайның күзаллавынча, шул сихри, ап-ак елан патшасының мөгезен табып алсаң, бәхет, имеш, кулыңа үзеннән-үзе килеп керә. Ш. Әхмәдиевнең «Канатлы тай» хикәясендәге фантастик образ — канатлы тай да крестьян баласының бәхет турындагы хыялын гәүдәләндерә. Хикәяләрдә фантастик вакыйгаларга реалистик мәгънә бирелә. Балаларның көткәне сукыр Ильяс та килми. Габдрахман да елан мөгезен тапмый, авыл малаеның да күңел төбәп көтеп алган тае, ул теләгәнчә, канатлы булып чыкмый, сабан туйларындагы ат ярышларында беренче килеп, аны шөһрәткә күмми. Бәхет еракта гы өмет кенә булып кала. Сыйнфый җәмгыятьтә идеал белән чынбарлык арасында тәңгәллек юк, төп фаҗига әнә шунда. Хикәяләрдә бу гаделсезлеккә карата ризасызлык сизелеп тора. Хезмәт иясе баласы бәхетле булырга тиеш, аның моңа тулы хокукы бар. Биредә авторларның гуманистик карашлары шул рәвешчә чагыла.

Язмышка, дингә буйсынучан кешеләр хөзерләү ниятеннән чыгып, руханилар гомергомергә яшь буынны төрле юк-бар нәрсәләр: җеннәр, пәриләр, су анасы, албасты, йорт иясе, аждаһа һ. б. белән куркытып, дини йолалар белән агулап килделәр. Мәгърифәтчелекнең бер күренеше буларак, яшь буынны рухи яктан гарипләндерүче хорафатларга, зарарлы йолаларга каршы көрәш журналда даими төс ала. Бу тема ике планда яктыртыла. Язучыларның беришесе әсәрләрендә иске хорафатларга каршы чыга башлаган бала образлары иҗат итәләр. Аларда яңалык чаткылары искелек белән каршылыкка керә. Ф. Агиевның «Гармонь» хикәясе иске карашлы ата белән баласы арасындагы рухи конфликтка нигезләнгән. Хикәядә башка берәү дә түгел, нәкъ менә мулла малае гармонь уйнарга өйрәнергә тели. Мулла урамда уен коралларын ватып-җимереп йөри, малае исә аңардан яшереп акча җыя һәм гармонь сатып ала. Ф. Агиев яңалыкның җиңәчәгенә сизелерлек ишарә ясый. Хикәя гармонь моңы белән тулы, аның тавышы, мулла тыюга карамастан, кичләрен авылның төрле почмакларыннан ишетелеп тора. Г. Рәфикыйның «Үрдәкләр эзләгәндә» исемле хикәясендә җен-пәриләрнең уйдырма гына булуы хакында үз күзәтүләреннән чыгып нәтиҗә ясый башлаган бала образы җанлана. «Төнлә җен була торган булса, көндез дә берәр җирдә күренер иде ул», — дип фикер йөртә бу бала.

Икенче төр хикәяләрдә юк-бар ышануларның, зарарлы хорафатларның яшь буынны ничек итеп рухи яктан гарипләндерүе ачыла, иске мәдрәсәләрдәге тәрбия эшенең тормыш алдында көчсезлеге, реаль булмавы күрсәтелә. Мәсәлән, Ш. Әхмәдиевнең «Ай алдады» хикәясендә нәкъ менә иске мәдрәсә шәкерте төп герой итеп алынган. Дини әкиятләр белән тәрбияләнгән баланың эчке дөньясының мескенләгән, караш даирәсенең тарлыгын хикәяче оста ачып салган. Ш. Әхмәдиев моңа сюжетны киеренке итеп төзү, геройны гадәттән тыш хәлгә кую юлы белән ирешә.

Жен-пәри, албасты, шүрәле кебек мифик образлар кайбер әсәрләрдә, мәсәлән, С. Рахманколый хикәяләрендә халык арасында йөри торган әкият сюжетларына дөньяви эчтәлек бирү, ул сюжетларны яңача аңлату юлы белән дә фаш ителә. Болар исә журналда атеистик тәрбия элементларының да урын алуы турында сөйлиләр.

«Ак юл»да ятимлек мәсьәләсе махсус проблема дәрәҗәсенә күтәрелеп, чорның бер фаҗигале күренеше итеп сурәтләнә, журналның байтак саннары шушы теманы яктырткан шигырьләр белән ачыла. Капиталистик эксплуатациянең көчәя баруы шартларында производствода кечкенәләр хезмәтен куллану киңәя бара, көчләре җитәр-җитмәс килеш сабыйларны ялчылыкка, «малайлыкка» бирү типик күренешкә әйләнә. «Ак юл» империалистик сугыш елларында чыгып килә, сугыш исә күп санлы балаларны урамга ташлый, ә хөкүмәт бу турыда бер төрле дә кайгыртучанлык күрсәтми. Язучылар тирән борчылу белән җәмәгатьчелек игътибарын шушы социаль фаҗигага юнәлдерергә тырышалар. Тәрбиячесез калган карт һәм карчыклар, ятим балалар әсәрләрнең уңай геройлары итеп сурәтләнәләр. «Безнең кан кардәшләребез булган ятимнәр күңелләре ярсыган, күзләре яшь белән тулган килеш урам чатларында, былчырак эчендә боегып, теләнеп йөргәндә, мин бәйрәм көнне дә шатлана алмыйм», [1] — дип яза Ф. Агиев «Мин шатлана алмыйм» исемле публицистик мәкаләсендә.

Ф. Әмирхан «Ул үксез бала шул» хикәясендә ятимнең эчке матурлыгын чагылдыруга игътибарын юнәлтә. Урам балалары арасында күпме сәләтле киләчәк кешеләре бар, тиешле игътибар, тәрбия җитешмәү нәтиҗәсендә алар иҗтимагый тормыштан тибәрелеп читтә калалар, яисә һәлакәткә дучар ителәләр, ди автор.

Хикәядә байлык һәм ярлылык контрасты көчле бирелгән. Бер якта — аякларына үкчәле итекләр кигән, эшсезлектән нишләргә белми кызык эзләп йөргән бай малайлары. Икенче якта — ярлы, ятим Нури. Үксез дип кимсетүләренә карамастан, ул җебеп, басылып калмый, уен вакытларында бай малайларын җиңеп чыга, тапкыр һәм зирәк булуы белән аларның ачуын кабарта. З. Ярмәкинең «И ятим», «Ятим зары» шигырьләрендә дә кешенең кешелек дәрәҗәсе белән урам баласының хәле капма-каршы куела. С. Җәлал «Аерылышу» хикәясендә империалистик сугыш елларындагы ятимнәрнең ачы фаҗигасен сурәтли. М. Әхмәрнең «Вахит бабай» хикәясендә ятимнең үз хәленнән ризасызлыгы чагыла. Вахит бабай курай уйнаганда агачларның шаулаудан тынып, кешеләрнең барган җирләреннән туктап калулары, курай тавышының үзәк өзгеч моңы тикмәгә түгел. Ятим карт ул моңга үзенең бөтен эчке рәнҗүләрен, кайгы-хәсрәтләрен, кимсетелү хисләрен салган. Шуның аша карт гаделсезлекне, тигезсезлекне гаепли сыман.

Гомумән, журнал көндәлек вак-төяк, ыгы-зыгыны сурәтләүгә караганда, тормышның иҗтимагый мәсьәләләренә күбрәк урын бирә, яңару чоры сулышы аңа шактый тирән үтеп керә. Әсәрләрдә яңалык белән искелек конфликты, артталыкка, дини йолаларга, зарарлы хорафатларга каршы көрәш, белемле, укымышлы кеше образларын идеаллаштыру, хезмәт иясе баласына теләктәшлек, аны уңай герой дәрәҗәсенә күтәрү, байлык һәм ярлылык контрасты үзәк урынны алып тора.

«Ак юл»ның балалар өчен халыкчан әдәби телне үстерүдәге эшчәнлеге дә зур. Әле язма телебездә күпчелеккә аңлашылмый торган гарәп-фарсы сүзләре киң урын биләп торган бер вакытта редакция беренче санда ук «журнал саф татар телендә булачак» дип белдерде һәм бу сүзенә ахыргача турылыклы булып калды. «Март ае керү белән көннәр җылына. Кояшның нурларына көч кергән кебек сизелә. Кыш буена җиргә каплап яткан карлар инде тавышсыз-тынсыз гына эреп, су була башладылары» [2],— менә шундый һәркемгә аңлаешлы җиңел телдә язылган әсәрләр өстенлек итә.

Г. Тукайга кадәр балаларга багышланган күп әсәрләрнең теле коры, образсыз, төче үгет-нәсихәт лексиконына корылган иде. Шагыйрь балалар әдәбиятына образлы сөйләм, яңа сурәтләр алып килде, аны халык иҗатына, аеруча җыр-әкиятләргә хас метафоралар, эпитетлар, чагыштырулар, сынландырулар белән баетты. Журнал авторлары бу яңа традицияне күтәреп алалар, иҗатларында фольклор белән бәйләнешне үстереп килеләр. Хикәяләрдә әкияткә тартымлылык — фантастик һәм реалистик вакыйгаларның бергә үрелеп килүе тотрыклы күренешкә әйләнә. Шүрәле, су анасы,

[1] «Ак юл». 1913. № 14. 11 бит.
[2] Г. Рәфикый. «Аякка чеби чыкты», «Ак юл». 1915. № 8. 126 бит.

канатлы тай, елан мөгезе, алтын кош кебек әкият образлары аша дөньяви мәсьәләләр чагылдырыла. Шигырьләр нигездә җыр һәм такмак үлчәмендә языла. Аларда җырлардан килә торган биек тау, алсу шәфәкъ, алтындай игеннәр, салкын чишмә, сары сандугач, күбәләк, моңсу таң, пакь күңел, нурлы йөз, моңлы тургай, ялгыз каен, көмеш тавыш кебек традицион образлар һәм эпитетлар киң кулланыла.

**Бер яшәрү сизгән кебек бөтен кырлар**
**Таңның көмеш нурларында иркәләнә.**
**Изге бәхет таңы дигән аваз белән**
**Сайраулардан колакка бер җыр бәрелә [1].**

*(Г. Сөнгати. «Бәхет таңы».)*

Бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу эпитетлар һәм образлар таушалган сыман. XX йөз башы татар балалар әдәбияты өчен алар әле яңа була.

«Ак юл» балалар әдәбиятын жанр ягыннан баетуга күп көч куя. Балалар драматургиясен тудыру юнәлешендә башлангыч тәҗрибәләр ясала. Диалог формасындагы әдәби парчалар күренгәли. Мирхәйдәр Фәйзи 1915 елда рус балалар язучысы Клавдия Лукашевичның «Чәчәкләр арасында», «Эшләп тапты», «Корым тазартучы» исемле пьесаларын тәрҗемә итә. Әмма ул пьесаларда драманың җаны булырга тиешле динамика, хәрәкәт, конфликт юк. Эчтәлекләре белән дә ярлыларга ярдәм итәргә әзер торучы нечкә күңелле бай балаларын мактауга гына кайтып калалар. Моңа өстәп тагын Ш. Әхмәдиевнең Лев Толстойга ияреп «Байлык хакында», «Үкенү» исемле пьесалар язуын күрсәтергә мөмкин. Ләкин Октябрьга кадәр балалар драматургиясе, гомумән алганда, формалашмый кала әле.

Проза һәм лирик поэзиянең исә журналда балалар әдәбиятының үсешен чагылдырырлык ныклы традициясе булдырыла. Прозаның төпле нигезен Ш. Әхмәдиев, С. Җәлал, Ф. Агиев, Г. Рәхим, Г. Рәфикый, Р. Баязит хикәяләре сала. Бу жанр кыска хикәя җирлегендә үсә. Роман, повесть кануннарына җавап бирерлек күләмле әсәрләр анда очрамый диярлек. З. Ярмәки, С. Сүнчәләй, Н. Думави, Н. Исәнбәт, Г. Сөнгати пейзаж лирикасы юнәлешендә уңышлы гына эзләнүләр алып баралар. Реалистик поэманың башлангычы булган сюжетлы шигырьләр иҗат итүгә омтылыш ясала. З. Ярмәкинең «Сабан туенда», «Атлар белән куна барганда», С. Сүнчәләйнең «Балыкчы карт», Г. Сөнгатинең «Урманда» шигырьләренең сюжеты реалистик сурәт чараларыннан үсеп чыга, лирик геройның кичерешләрен сурәтләүдән бигрәк аларда вакыйгаларны хикәя итү өстенлек ала. Журналда иң киң яктыртылганы — әкият. «Шүрәле» һәм «Үги кыз» әкиятләренең төрле вариантлары барлыкка килә. Ш. Әхмәдиевнең, Г. Рәхимнең, Ф. Агиевның, Ф. Сәйфи-Казанлының хезмәт иясе вәкилләрен уңай геройлар итеп алган әкиятләре халыктан килә торган сюжет-композиция төзү алымнарын тирәнтен үзләштереп, мавыктыргыч итеп язылулары белән аерылып торалар.

Л. Гадел, И. Бикмулов, Х. Мәүлюдов фәнни әдәби жанр өстендә эшлиләр. «Караны кем түкте?», «Бер кәгазь кисәгенең башыннан үткәннәре», «Киңәю һәм кысылу», «Күк дөньясы», «Җил нидән була?», «Су бөртекләре» һ. б. әсәрләрдә физик күренешләр һәм аларны китереп чыгарган сәбәпләр публицистик стильгә салып, я төрле әдәби образлар ярдәмендә аңлатылалар.

Журналда мәсәл жанрын З. Ярмәки җитәкли. Язучылар нәсер жанры өстендә каләм көчләрен сынап карыйлар. (С. Җәлал. «Яз»; Л. Гадел. «Томан күтәрелде».) Ф. Агиевның байтак публицистик мәкаләләре дөнья күрә. Хайваннар, кош-кортлар турындагы анималистик әдәбият та шактый урын ала.

«Ак юл» турында сөйләгәндә, әдәби бәйләнешләрне читләтеп үтеп булмый. Журнал башка халыкларның әдәби тәҗрибәләренә җитди игътибар бирә. Бу үзеннән-үзе аңлашыла. Язучыларны рус һәм Европа классик мирасының тормыш һәм халык белән тыгыз бәйләнгән булуы җәлеп итә, анда алар үзләренең мәгърифәтчелек һәм гуманистик теләк-омтылышларына җавап табалар. Әдәби бәйләнешләр татар балалар язучыларына милли чикләнгәнлектән чыгуда ярдәм итә. Әсәрләрне файдалану журналда нигездә ике төрле — ияреп язу, тәрҗемә юлы белән бара. Бер очракта әсәр

[1] «Ак юл», 1915, № 7, 1 бит.

оригиналдагыча татарчага күчерелә, икенчесендә әсәрнең кайсы автордан икәне дә әйтелми, вакыйга татар җирлегендә итеп күрсәтелә, геройларның исемнәре дә алыштырыла, персонажларга үз милләтебезнең рухын бирергә тырышыла.

Октябрь революциясеннән соң, утызынчы елларга таба ияреп язу, яки авторын да әйтмичә текстны бөтенләй үзгәртеп куюлар тәнкыйть астына алына. Оригиналның төп үзенчәлекләрен саклап тәрҗемә итү принцибы яклана. Татар балалар әдәбиятының формалашу чоры — XX йөз башларында исә тегесе дә, бусы да уңай күренеш була.

Шундый бер дәверне XVIII йөздә рус балалар әдәбияты да кичерә. Күренекле рус мәгърифәтчесе Н. И. Новиков «Детское чтение для сердца и разума» (1785—1789) исемле балалар журналы чыгара. Журналда Көнбатыш Европа әдәбиятыннан үрнәкләр күп. Төп нөсхәдәге исем, фамилияләрне русныкы белән алыштыру, вакыйгаларның урынын Россиягә күчерү, текстны үзгәртү, кыскарту һәм өстәүләр, әсәргә рус колориты бирү Новиков журналында да еш очрый.

«Детское чтение» белән «Тәрбиятел әтфаль»нең күп кенә бүлекләре (хайваннар, мәгъдәннәр, үләннәр, чәчәкләр, кошларга багышланган мәкаләләр, фән яңалыклары, күренекле кешеләрнең тормыш юлы, чит ил хәлләре, уеннар, табышмаклар һ. б.) туры килә. Мәгърифәтчелек идеаллары яктылыгында туулары, яшь буынны дөньяви рухта күп яклы тәрбияләүне максат итеп куюлары белән бу журналлар бер-берсенә шактый якын торалар.

Журналда татар балалар язучылары дөньякүләм танылган әдипләргә мөрәҗәгать итәләр. Пушкин, Толстой, Бунин, данияле Андерсен, инглиз әдипләре Р. Киплинг, О. Уайльд, француз язучысы В. Гюго һ. б. авторларның әсәрләреннән тәрҗемәләр еш басылып тора. Болардан тыш авторы күрсәтелмәгән, сюжеты я русчадан, я инглизчәдән, я казакъчадан, төрекчәдән алынды диелгән дистәләрчә әсәрләр урнаштырыла.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: татар балалар журналлары гасырлар буе килгән торгынлыкка, наданлыкка каршы көрәшнең бер нәтиҗәсе буларак туалар. Алар заманның алдынгы карашларын, мәгърифәт һәм гуманизм байрагын югары күтәрәләр.

«Тәрбиятел әтфаль», бигрәк тә «Ак юл» балалар әдәбияты үсешендә зур роль уйныйлар, яңадан-яңа язучыларның әдәбиятка килүе өчен мәйданны киңәйтәләр, үз чорының яшь укучыларын бай әдәбият материалында тәрбиялиләр. М. Җәлил инде үсеп үзе шагыйрь булгач, «Ак юл»ны җылы хисләр белән искә ала. «Кечкенә иптәшләр» журналының редакторы итеп билгеләнгәч, аның сыйфатын күтәрү максаты белән «Ак юл»ның талантлы авторларына хатлар җибәрә. Г. Рәхимгә җибәргәнендә мондый юллар бар: «Кечкенә иптәшләр» «Ак юл»ның сабакларына нык тукталырга тиеш. Ә аны бизәүчеләрнең, билгеле, берсе — Сез. Безнең хәзерге җәмәгатьчелегебездә тагы да зуррак роль уйнаган «Кечкенә иптәшләр»гә үзегезнең хезмәтегезне кызганмассыз, дип ышанам»[1].

«Ак юл» нәшриятта чыккан балалар әдәбиятын пропагандалау өлкәсендә дә эш алып бара, үзенең аерым саннарына өстәп бушлай китаплар бүләк итә. Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәясе беренче тапкыр «Ак юл»ның бүләк китабы булып дөнья күрә. Журнал балалар китабының библиографиясен булдырырга омтылышлар ясый.

«Ак юл» журналының тормыш күренешләрен әдәби детальләр, пейзаж тасвирлары, геройларның эш һәм хәрәкәтләре аркылы ачкан әйбәт әсәрләре совет балалар әдәбиятына традиция булып күчәләр. Октябрь революциясеннән соң алардан берничә мәртәбә серияләр бастырылып чыгарыла. «Балалар күңеле» (1917), «Балаларга ирекле уку» (1921), «Күчмә уку китабы» (1922). Бу җыентыклар ул вакытта мәктәпләрдә дәрестән тыш уку өчен файдаланылалар.

«Тәрбиятел әтфаль», «Ак юл» чәчкән орлыклар мул шытым бирде. Совет власте елларында балалар матбугаты чәчәк атты, үз үсешенең яңа дәверен башлады. Әле яшәү яки үлем өчен киеренке көрәш барган алмашыну көннәрендә (1917 елның мартыннан) «Балалар дөньясы» журналы чыга башлый. «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы», «Пионер каләме», «Ялкын» журналлары — барысы да балаларга Октябрь бүләкләре. Татар балалары үзләренә багышланган беренче газетаны да («Яшь ленинчы») Совет власте елларында алдылар.

**Ф. ИБРАҺИМОВА.**

---

[1] «Совет мәктәбе», 1966, № 2, 8 бит, Р. Гайнанов, М. Җәлилнең журналистик эшчәнлеге.

**Шәрәф Әхмәдуллин**

# СУРӘТЛЕ ФИКЕР

Яшь авторга редакциядән хат килеп төшә: «Шигырегезне газетада файдалана алмадык. Аның әдәби эшләнеше начар, сурәтле фикере юк».

Автор мондый хөкемне көтмәгән икән. Ул, ризасызлык белдереп, редакция белән бәхәскә керә, үз файдасына дәлилләр китерә башлый:

— Шигырьнең рифмалары бармы? — ди ул һәм шунда ук җавап та бирә:

— Бар.

— Ритм дөрес сакланганмы?

— Сакланган. Шулай булгач, әдәби эшләнеше начар дияргә нигез каламы соң? Аннары «сурәтле фикер» дигәне дә юк сүз бугай. Нишләп сурәтле фикер булмасын ди?.. Хәер, тукта әле, нәрсә соң ул сурәтле фикер?..

Менә шушы рәвешчә фикер йөртү башлап шигырь язучылар арасында еш очрый. Һәм моңа гаҗәпләнеп тә булмый. Чөнки әдәбият мәйданына омтылучы яшьләрдә шигырьнең табигате, максаты, бурычлары кебек мәсьәләләр хакында кирәкле белем җитәрлек булып бетми. Шуңа күрә дә яшь авторлар белән шигырь язуга бәйле мәсьәләләр буенча әңгәмә башлау урынсыз эш булмас дип уйлыйм.

Шигырь ни өчен языла? Әңгәмәне шундый сорау белән башлап җибәрәсе килә. Мәгълүм ки, шигырь укучыга йогынты ясау максатыннан чыгып языла. Бурыч шул: шигырь укучыга эстетик ләззәт бирсен, кешедәге матурлык хисен хәрәкәткә китерсен, ул хисне үстерсен, камилләштерсен. Алай гына да түгел, шигырьдә бәян ителгән вакыйга, күренеш, хис укучыны тетрәтсен, алга әйдәсен, матурлыкка чакырсын. Шигырь менә шуның өчен языла.

Сүз дә юк, бу — бик зур һәм катлаулы бурыч. Укучыны тетрәтү, аны алга әйдәү өчен шигырь чын мәгънәсендә сәнгать әсәре булырга тиеш. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, башлап язучыларның шигырьләре гадәттә андый югарылыкта булмый. Алар язган шигырьләрдә рифма була, ритм була, аннары... коры информация була. Билгеле, бу сыйфатлар гына тезмәне сәнгать фактына әйләндерә алмый.

Шигырьне нәрсә шигырь итә? Аны нәрсә сәнгать әсәре итә соң? Барыннан да элек, образлы, сурәтле фикер. Нәкъ менә сурәтле фикер аша шагыйрь чынбарлыкны танып белә, аны бәяли, хөкем итә. Мәгълүм ки, Габдулла Тукайның «Ишан»[1] исемле мәшһүр парчасы бар. Аңарда ишан үтергеч каты тәнкыйть утына тотыла. Ләкин моны бөек шагыйрь «ишан болай, ишан тегеләй» дип хәбәр итү юлы белән эшләми. Парчада андый коры, шәрә фикер юк. Киресенчә, аңардан укучы алдына ишан сурәте килеп баса:

**Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган;**
**Кибән чалма кибәк башта: ишан булган, имеш,**
**хайван!**

[1] Г. Тукай, Әсәрләр, 1955, Том 2, 52 бит.

һәм менә шулай сурәтләнгән ишан үзенә-үзе хөкем укый, үзеннән-үзе биздерә. Кешедәге матурлык хисләре аны кабул итми, кире кага. Чөнки сурәт — шыксыз, килбәтсез. Бу инде коры фикер йөртү түгел, бу — сурәтле фикер.

Тагын бер мисал. Монысы бүгенге татар совет поэзиясеннән: Ренат Харисовның «Өянке» шигыре:

**Өскә үсмәсен әле дип,**
**Баш ботагымны киссәң, —**
**Мин бит як-якка үсәм!..**

**Киңлеккә китмәсен диеп,**
**Ян-якларымны киссәң, —**
**Мин куелыкка үсәм!..**

**Куелыкка үсмәсен дип,**
**Ябалдашымны киссәң, —**
**Мин тамыр якка үсәм!..**

**Бәгъренә чабыймчы диеп,**
**Казып тамырыма төшсәң, —**
**Каберең өстендә үсәм!..**

Тормыш, яшәү — үлемсез! Бу шигырьнең идея эчтәлеген кыскача шулай билгеләргә мөмкин. Ләкин шигырьдәге әлеге идея турыдан-туры кычкырып, маңгайга бәреп тормый. Шагыйрь аны күз алдына китерерлек, хис итәрлек конкрет күренеш аша тәгъбир итә. Мәгълүм бер күренешне сурәтләү ярдәмендә автор укучыда явыз көч барыбер бетәр, җиңелер, ә тормыш — үлемсез дигән ышаныч уята. Бу инде коры, абстракт фикер түгел, бу — сурәтле фикер, образлы фикер. Нәкъ менә шушы фикер югарыда китерелгән юлларны шигъри сөйләмгә, шигырьнең үзен исә сәнгать фактына әйләндергән чараларның берсе булып тора.

Инде килеп, мондый сорау куйыйк: бу шигырьдә сурәтле фикергә ничек ирешелә соң? Барыннан да элек, өянке сүзен туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану юлы белән.

Өянке — гади бер агач. Бу — аның туры мәгънәсе. Өянке — тормыш, яшәү символы; өянке — кеше, аның әрсезлеге, тырышлыгы, эшчәнлеге... Болары — аның күчерелмә мәгънәләре. Шигырьдә автор өянке сүзенең менә шушы ике төрле мәгънәсе белән эш итә.

**Өскә үсмәсен әле дип,**
**Баш ботагымны киссәң, —**
**Мин бит як-якка үсәм!..**

Бу — агачның чынбарлыктагы табигый халәте. Әйе, аның башын киссәң, ул як-якка үсә, ян-якларын киссәң, куелыкка үсә... Ләкин агачның шушы табигый халәте ассоциация буенча укучыны икенче планга күчерә. Ул инде, өянкегә карап, гомумән кешенең әрсезлеге, яшәү, үлемсезлек кебек мәсьәләләр турында уйлана башлый. Һәм шулай итеп өянке, үзенең туры мәгънәсе белән бер рәттән, икенче мәгънәне ала. Өянке тормышның үлемсезлеген гәүдәләндергән конкрет образга әйләнә. Шулай сурәтле фикер туа.

Әлбәттә, фикер сурәтлелегенә төрле шагыйрь төрле юл белән ирешә. Әле генә карап үткән шигырьдә бу максатка автор сүзнең күчерелмә мәгънәсен ачу, шуннан файдалану юлы белән килә.

Венгр халкының сөекле шагыйре Шандор Петефиның «Җитәр»[1] исемле шигырендә исә сурәтле фикер бөтенләй башка юл белән тудырыла. Биредә сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләренә корылган тоташ метафора алымы юк. Киресенчә, шигырьнең һәр юлы үзенең туры мәгънәсендә яңгырый:

[1] Шандор Петефи, Җитәр, М. Садри тәрҗемәсе, «Социалистик Татарстан» газетасы, 1973 ел, 7 январь.

**Солдат булып сафка басыйк!**
**Кем дә курчак булмасын!**
**Флейта күп тынычландырды,**
**Инде быргы уйнасын!.**

Буйдан-буйга публицистик пафос белән сугарылган бу шигырьнең беренче юлларыннан ук кеше рухының конкрет халәте ачылып китә. Шигырьне уку дәвамында безнең алга яшь көрәшче — патриот образы килеп баса:

. . . . . . . . . .
**Уйнау белән җиз быргылар**
**Өндәп көрәш таңына,**
**Без җиңәрбез, коендырып**
**Дошманны үз канына.**
**Әйдә, баш күтәр, туган җир,**
**Яңгырасын даннарың,**
**Көрәшчеләр ирек өчен**
**Кызганмаслар җаннарын...**

Безнең алда — дошман өстенә ташланырга әзер торган көрәшче образы. Аның рухи халәте — иң киеренке ноктада, хисләре — кайнар, һәр сүзеннән чаң тавышы ишетелә. Ул әйди, чакыра. Нәкъ менә шушы ялкынлы чакыру, утлы фикер әлеге шигырьне образлы итә, аны сәнгать фактына әйләндерә.

Сурәтле фикер тудыруның юллары бик күп. Аларның барысын да күздән кичерү мөмкин дә түгел. Шулай да тагын бер мисал белән танышу кирәк булыр шикелле. Шагыйрь Нури Арслановның «Илһам»[1] исемле шигырен укучылар хәтерлидер. Сүз анда илһам кебек иң абстракт төшенчә хакында бара. Ләкин шагыйрь беренче юллардан ук аны күз алдына китерерлек конкрет сурәткә әйләндерә алган:

**Нишлисең син, илһам дигән тинтәк,**
**Мине үртәп шулай итәмсең:**
**Шаян килен кебек, алларымнан**
**Итәк кенә болгап үтәсең!!**
**Дәртем дә бар әле, көчем дә бар**
**Билләреңнән кысып кочарлык.**
**Җилкән итеп җиләс итәкләрен,**
**Дулкыннарда тибрәр, очарлык.**
**Форсатыңны җилгә җибәрмә син —**
**Кала күрмә кысыр, тол булып.**
**Әйдә чыңла, чыңла бар тавышыңа,**
**Җырларыма алтын кыл булып.**

Моңа ирешү өчен, ул төгәл һәм урынлы чагыштырулар, реаль тормышка нигезләнгән ачык мәгънәле метафоралар кулланган. Шагыйрьнең бөтен коралы — әнә шулар.

Әйтергә кирәк, сурәтле фикер ни дәрәҗәдә тирән, әһәмиятле һәм актуаль булса, шигырьнең тәэсир итү көче дә шул кадәр зур һәм дәвамлы була. Киресенчә, сай фикер, уйланып җитмәгән идея-эстетик караш, кагыйдә буларак, вак, кыйммәте аз булган мәсьәләләр белән мавыгуга китерә.

Хәлбуки, партиябез иҗат кешеләрен сәнгатьнең идея-эстетик кыйммәтен тагын да югарырак баскычка күтәрү өчен даими көрәш алып барырга чакыра. Әсәрләрнең идея-эстетик кыйммәтен күтәрү исә, барыннан да элек, эчтәлектән башлана. Әдәби әсәрнең эчтәлеге тормыш хакыйкатен ачуга юнәлдерелгән булырга тиеш. Ләкин шуны истән чыгармаска кирәк: тормыш хакыйкате дигән нәрсә бар, сәнгать хакыйкате бар. Болар бер-берләренә тәңгәл килеп тормыйлар. Дөрес, сәнгать хакыйкате тормыш хакыйкатенә нигезләнә, ләкин аның белән генә чикләнеп калмый. Мәсьәләнең тагын

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1971 ел, 9 сан, 16 бит.

бер ягын истән чыгармаска кирәк, факт дөреслеген тәгъбир итү белән чикләнеп калганда, социалистик реализм методына бары тик тормышны анық үз формасында сурәтли торган әсәрләрне генә танырга, ә инде шартлы алымнар кулланып язылганнарын танымаска туры килер иде. Болай эш итүне марксистик-ленинчыл эстетика кире кага. Чөнки сәнгать хакыйкате ул — фәлсәфи-эстетик категория. Ул, барыннан да элек, күренешнең асылын ачуга бәйләнешле дөреслекне эченә ала. Шулай ук ул күренешнең фәлсәфи-этик мәгънә дөреслеген ачып бирүне һәм, ниһаять, күренешне идея-эстетик яктан чыгып бәяләүне эченә ала. Сәнгать дөреслеген тирән һәм тәэсирле итеп ачып бирү өчен, шагыйрь чынбарлыктагы күренешләрне хәрәкәттә, агышта, каршылыклылык хәлендә сурәтләргә тиеш. Нәкъ менә каршылык, аны ачу һәм хәл итү әдәби әсәргә, шул җөмләдән шигырьгә дә, сәнгать хакыйкатен тирән итеп күрсәтергә ярдәм итә.

Шигырьнең идея-эстетик яңгырашын көчәйтү — катлаулы һәм күпкырлы мәсьәлә. Ләкин аны һәрьяклап ачу теләгән бер якка куеп, биредә яшьләр игътибарын эмоциональ тәенләнешле шигырьләргә юнәлтеп үтү зарурирак булыр. Чөнки эстетик камиллеккә ирешү юлында андый шигырьләр күренекле урын алып тора. Бу төр шигырьләрне беренче булып ачкан һәм аларга нигезле аңлатма биргән кеше профессор Хатип Госман булды. Эмоциональ тәенләнешле шигырьне ул шигъриятебез мәйданында «яңа казаныш»[1] дип бәяләде. Галимнең эмоциональ тәенләнешле шигырь турында, аның эстетик вазифасы турында әйткән фикерләре яшь авторлар өчен аерата гыйбрәтле: «Бу чаранық,— ди ул,— бик көчле бер сыйфаты — шигырьнең барлык өлешләрен үз тирәсенә шактый кискен кырыслык белән җыеп алуында. Әйтерсең ул магнитлы үзәк: шигырьнең бөтен эмоциональ куәте аңа төбәлгән, аңа бәйләнгән. Яки, тупасрак димәсәләр, шигырьнең кендеге, кучәре дияргә мөмкин. Шигырь текстына ул тик аның үзенә бәйләнгән юлларын гына кабул итә, бәйләнмәгәнен кире кага, төшереп калдыра»[2].

Бүгенге көндә мондый шигырьләрне Муса Җәлил, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Нури Арсланов кебек өлкән буын шагыйрьләр иҗатында гына түгел, бәлки урта һәм яшь буын шагыйрьләр иҗатында да күпләп табарга мөмкин. Шунысы да бәхәссез: эмоциональ тәенләнешле шигырьләр бер татар шигърият дөньясына гына хас күренеш түгел. Алар тугандаш әдәбият вәкилләре иҗатында да тулы гражданлык хокукы белән файдаланалар.

Тугандаш әзербәйҗан шагыйре Искәндәр Ахундовның «Әзербәйҗаным» исемле шигыре — моңа ачык дәлил. Бу шигырьдә эмоциональ үзәкне рефрен тәшкил итә.

**Хәтта мине кулсыз**
**калдырсыннар,**
**Сукыр һәм дә чукрак**
**итсеннәр,**
**Йөрәк белән тоеп һәм ишетеп**
**Мин кайтырмын сиңа —**
**белсеннәр,**
**Горурлыгым —**
**Туган ягым,**
**Туган йортым,**
**Туган җирем,**
**Туган Әзербәйҗаным![3]**

Шигырьнең бөтен хис ташкыны менә шушы рефренга омтыла, аны яңгырата һәм раслый. Нәтиҗәдә шигырь бермә-бер камилләшә, үзенең тәэсир итү көчен арттыра.

Билгеле, шигырьнең һәр күзәнәге: ритмы да, рифмасы да, композициясе дә камил булырга тиеш. Чөнки боларның барысы да шигъри эчтәлекнең яшәү формасын тәшкил итәләр. Алыйк ритмны. Аны шигъри сөйләмнең цементы дияргә була.

---

[1] Хатип Госман. Эмоциональ тәенләнешле шигырь. «Казан утлары» журналы, 1972 ел, 4 сан, 135 бит.
[2] Шунда ук, 137 бит.
[3] Искәндәр Ахундов. «Әзербәйҗаным». Э. Синеголов тәрҗемәсе. «Социалистик Татарстан» газетасы, 1972 ел, 3 декабрь.

**Яшь гомерем, зәңгәр чәчәк,**
**Узар димәгән идем...**

Халык җырыннан алынган бу юлларны коеп куйганнар диярсең. Алар ничек җиңел, ничек шома укыла! Ә бит моның хикмәте ритмда. Нәкъ менә ритм шигырь агышына әнә шундый сокландыргыч төзеклек, шомалык бирә. Ул бозылдымы, шигырь шунда ук аксый, чатанлый башлый. Матурлык югала, төзеклек бетә.

Ирекле шигырьдә исә ритм тагын да зуррак вазифа үти. Ул биредә шигъри сөйләмне гади сөйләмгә, чәчмәгә әйләнеп китүдән саклап тора.

**Азмы кирәк**
**яшәү өчен —**
**ышаныч,**
**көч,**
**ихтыяр,**
**дәрт!** [1].

Бу юлларны нәрсә чәчмәдән аера, нәрсә аларга оешканлык, ныклык, шигъри куәт бирә? Билгеле, ритм, аннары интонация.

Яки менә бу юлларны алыйк:

**Бездән —**
**көн дә кешелекклелек,**
**ныклык,**
**сафлык,**
**фидакарьлек!**
**Бездән —**
**көн дә янып сөю,**
**тугры сүз,**
**җылылык,**
**нур!**

Биредә дә шул ук күренеш: охшаш конструкцияләр кабатланалар. Сөйләмдә ритм туа, оешканлык, төзеклек, ныклык туа.

Мәгълүм ки, шигырь — билгеле бер калыпка салынган сөйләм. Әлбәттә, һәрбер калыпка салынган сөйләм үз-үзеннән, ягъни калыплы булганы өчен генә сәнгать фактына әйләнми. Чын мәгънәсендә шигъри сөйләм тусын өчен, ул үзенең калыплы булуын сиздермәслек дәрәҗәдә табигый, шома һәм камил яңгырарга тиеш. Кабат югарыда китерелгән мисалга мөрәҗәгать итик:

**Яшь гомерем, зәңгәр чәчәк,**
**Узар димәгән идем...**

Бу — калыплы сөйләм. Ә менә аның шундый сөйләм булуын укучы сизми дә диярлек. Хикмәт шунда, калыплы булса да, сөйләм — табигый, шома һәм камил. Шул ук вакытта рифма, ритм өчен сүзләрне «колагыннан» тартып-сузып китерү дә юк. Киресенчә, бар сүз үз урынында, барысы килгән, җитешле.

Өлкән шагыйрьләребез иҗатында без нәкъ менә шундый камиллекне очратабыз. Түбәндәге юлларны Хәсән Туфан язган:

**Кил әле, кил,**
**Кочыйм үзеңне бер,**
**И кадерлем, и асыл Җирем! —**
**Кочагыма минем сыймасаң да,**
**Йөрәгемә сыясың минем...** [2]

Болары — Сибгат Хәкимнеке:

**Сугышта һөҗүмдә белдем:**
**Тылың нык булсын икән,**

---

[1] Р. Фәйзуллин. Гадиләргә гимн. Казан. 1971 ел. 7 бит.
[2] Х. Туфан. Давыллы еллар лирикасы. Казан, 1970. 299 бит.

**Шигырьдә тылың — тарихың,**
**Телең нык булсын икән**[1].

**Гайҗан бабай сөйли, һаман сөйли...**
**Чәе суына, — аны сизми ул;**
**Куанычы эченә сыймаганга,**
**Һаман сөйли, һаман сөйли ул...**[2]

Болары инде Шәйхи Маннур иҗат иткән мәшһүр Гайҗан бабай турындагы әсәрдән.

Үзен шигърияткә багышларга карар иткән һәр яшь каләм иҗат эшчәнлегендә әнә шундый камиллеккә омтылырга тиеш. Чөнки шигырь техникасында камиллеккә ирешми торып, сәнгатьчә өлгергән әсәр тудырырга мөмкин түгел. Ләкин бу — беренче шарт кына әле. Иң әһәмиятлесе шул: чын шагыйрь булу өчен, югары культурага ия булу кирәк, кешелек дөньясының иң камил фикер хәзинәсе — марксизм-ленинизм тәгълиматы белән тирән коралланy кирәк. Өстәвенә, иҗат кешесе гомер буена яшьлеккә хас пакь, саф хис кайнарлыгын югалтмаска тиеш.

Онытмыйк: шагыйрьләр борын-борын заманнардан бирле фәннең, философиянең, сәнгать белеменең алдынгы сафында атлаганнар. Гомәр Хәйям, барыннан да элек, бөек шагыйрь. Ләкин шул ук вакытта ул — зур математик, зирәк философ. Шагыйрь Имадетдин Нәсими Кавказ, Урта Азия халыкларының тарихын, культурасын белгән; мөселман, христиан диннәренең асылын өйрәнгән; математиканы, астрономияне, анатомияне, хокук фәннәрен белгән. Философия исә аның иң мавыктыргыч шөгыле саналган. Өстәвенә, И. Нәсими өч телдә — әзербәйҗан, фарсы, гарәп телләрендә шигырь язган.

Болары — ерак үткәндәге шагыйрьләр. Ә менә Гете, Шиллер. Аннары Тукай. Хәер, шагыйрьне шагыйрь иткән сыйфатларны болай гына барлап чыгарга мөмкин түгел. Безнең көннәрнең таләбе исә тагын да зуррак, тагын да катлаулырак. Шул таләпләр югарылыгында торып иҗат итү — шагыйрьнең иң мөкатдәс бурычы. Шигърият мәйданына атлаучы яшь каләмнәр бу хакыйкатьне һич кенә дә истән чыгарырга тиеш түгелләр.

---

[1] «Казан утлары» журналы. 1973 ел. 2 сан.
[2] Ш. Маннур. Күңел йомгагы. Икенче китап. Казан. 1971 ел, 11 бит.

# АРАДАН БЕР ҺӘЙКӘЛ

Хәрби темага, аерым алганда, Бөек Ватан сугышына кагылышлы әсәрләр бездә шактый күп язылды. Алар арасында романнары да, повесть һәм хикәяләре дә, истәлекләре дә бар. Сугыш темасына караган әсәрләр һаман языла тора һәм, күрәсең, киләчәктә дә күп язылыр. Шуңа күрә, Әдип Маликовның «Яшьлек утравым»[1] повесте хакында ни дә булса әйтер алдыннан, сугыш темасына язылган әсәрләргә карата кайбер уйлануларым, күзәтүләрем белән дә уртаклашасым килә.

Сугышның фәлсәфәсен аңлап, беренче чиратта, кешенең рухи дөньясына мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләрне укыганыбыз бар. Кеше дигән затны самолетлар һәм танклар гүләве, автоматлар тырылдавы, снаряд һәм бомбалар шартлавына күмеп, аның эчке дөньясын, эчке халәтен бөтенләй онытып, тулысы белән диярлек баталь сценаларга, сугыш маҗараларына корылган, детективка тартым әсәрләрне, кинофильмнарны да байтак күрдек. Мондый әсәрләрдә геройлары күп булса да, нигездә алар барысы да төссезләр, шуңа карамастан, үзләре тагын коеп куйган батырлар. Куркуны, үлем дигән нәрсәне бар дип тә белмиләр. Вакытында андый әсәрләрнең язылуы бәлки котылгысыз да булгандыр. Ләкин инде хәзер, сугыш беткәнгә утыз ел тулып килгән көннәрдә, шундыйрак әсәрләрнең һаман басыла торуы эчне пошыра. Бу очракта мин нигездә Совет Армиясе көненә, Җиңү көненә, Ватан сугышы башланган көнгә һәм башка истәлекле даталарга төбәп, сугышны үзләре күрмәгән, анда катнашмаган кешеләр тарафыннан кемнеңдер сөйләвенә яисә аерым документларга таянып язылган һәм газета-журнал битләрендә басылып килгән кайбер әдәби әсәрләрне, очеркларны күздә тотам. Алар ясалма булулары, авторларның укучыларны шаккатырырга тырышулары, ялган пафослары белән ачуны китерәләр, күңелне рәнҗетәләр.

Бәхеткә каршы, безнең хәрби темага багышланган әдәбиятыбызны алар билгеләми. Аны, рус әдәбиятындагы Алексей Толстой, Александр Твардовский, Леонид Леонов, Михаил Шолохов, Константин Симонов, Борис Полевой әсәрләре белән бәрәттән, үзебезнең «Сиваш»лар, «Газинур»лар, «Тупчы Ваһап»лар, «Өзелгән кыл»лар, «Йөзек кашы», «Җимерелгән бастион»нар кебек, сугышның үзен бер генә минутка да онытмаган хәлдә, беренче чиратта кешенең эчке дөньясына үтеп, сугыш мәйданына аның рухи байлыгын чыгарып, шуңа таянып язылган күренекле әсәрләр, Сибгат Хәким, Афзал Шамов, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Атилла Расихларның сугыш хикәяләре, сугыш истәлекләре билгели. Болардан тыш та әйбәт, тормышчан әсәрләр бар, монда мин беренче булып хәтергә төшкәннәрен генә атадым.

Узган сугышта безгә бик тә мәкерле, бик тә көчле, бөтен Европаның сугыш потенциалын үзенә туплаган дошманга каршы торырга туры килде. Сүз дә юк, мондый дошманга каршы торуы кыен булды. Кыен вакытларда безгә туган илебезгә булган чиксез мәхәббәт ярдәм итте. Һәр сугышчының эче тулы нәфрәт, моң-сагыш иде. Солдатлар белән бергә «Саратский яшел гармуннар», Пушкин, Лермонтов, Тукай һәм Такташларның солдат капчыгында йөр-

[1] Ә. Маликов. Яшьлек утравым. Казан, 1974 ел.

гән әсәрләре дә сугышты, чак кына буш ара булган саен окопларда, блиндажларда, привалларда бергә җыелып җырлана һәм тыңлана торган, күңелләргә сеңгән, граммофон тәлинкәләренә язылган «Сагыну», «Салкын чишмә», «Карурман», «Тәфтиләү» көйләре дә бульшты. Кыскасы, дошманның ут һәм корычына каршы һәр милләтнең, һәр халыкның Совет власте шартларында үткән бөтен тормышы, шул тормыштан чумырган рухи байлыгы ярдәмгә килде. Нәкъ менә шушы хәзинә безне көчле итте. Ниһаять, җиңүгә китерде. Сугыш кырында кемнең үз-үзен ничек тотуы, гражданин буларак үзен ничек күрсәтүе соңгы чиктә әнә шуларга бәйле.

Сугыш ул — халыклар тормышында иң зур сынау. Монда бөтен илнең барлык материаль һәм рухи ресурслары хәрәкәткә килә. Вакыйгасын да, баш әйләндергеч маҗараларын да уйлап чыгарасы түгел, барысы да үзендә, барысы да күз алдында. Тик күңел күзең үткен булсын да йөгерек фикерең булсын, образлы итеп уйлый, сурәтли генә бел. Шуңа күрә Бөек Ватан сугышы кебек зур, җаваплы темага язылган әсәрләрдә дөреслек, табигыйлек, фәлсәфи тирәнлек, күрәсең, теләсә нинди башка әсәрләргә караганда да күбрәк булырга тиештер. Әлеге әсәрләрне совет халкының фидакарьлегенә, батырлыгына, якты идеалларыбыз өчен шәһит киткән якташларыбызга, миллионнарча ватандашларыбызга бер һәйкәл дип карарга кирәк. Шуңа күрә алар дөрес коелган, яшьләребез сокланырлык, авыр сынау вакытларында үрнәк һәм өлге итеп алырлык мәһабәт булырга тиеш. Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» повестен укыганда мин әнә шулар турында да уйландым.

Бу повесть турында мин бары бер генә сүз әйтер идем: әйбәт әсәр! Повестьта бернинди уйдырма урыннар да, ялган пафос та юк. Барысы да дөрес, барысы да чамасын белеп сурәтләнгән. «Яшьлек утравым» — билгеле дәрәҗәдә документаль әсәр. Сурәтләнгән вакыйгаларда катнашучыларның күбесе исән. Алар сиңа нине дә булса күпертергә яисә шомартырга, урынлы-урынсыз мутланырга ирек бирмәячәкләр. Бар булган материалың — нигездә үзең күргәннәр, син һәм синең белән бер үк юлдан атлаган дусларыңның, иптәшләреңнең кичерешләре. Менә шулардан кеше мавыгып укырлык та, образлы да итеп әсәр язып кара. Моның өчен осталык та, тәҗрибә дә кирәк. Әдип Маликов бу әсәре белән үзендә әнә шул сыйфатларның булуын ышандырырлык итеп күрсәтте.

Повесть бик гади, бик табигый башлана. Көннәрдән бер көнне, истә-төштә югында, Әхнәф Мәүлитовка телеграмма килеп төшә. «Көньяк Сахалинны һәм Куриль атауларын япон империалистларыннан азат итүгә егерме биш ел тула. Сезне, хөрмәтле Әхнәф Галимович, шул сугышларда катнашучы буларак, олы бәйрәм белән тәбрик итәбез, тормышыгызда иминлек һәм корычтай сәламәтлек телибез», дип, юбилейга чакырып язганнар.

Үзе сугышып йөргән, яшьлеге узган җирләрне кайсы гына солдатның яңадан бер барып күрәсе килмәс! Китә солдат Әхнәф. Аңа ияреп син дә китәсең. Китми хәлең юк, чөнки әсәр гадилеге белән ияртә, баштан ук үзенә ышаныч уята.

...Ниһаять, Әхнәф белән бергә Сахалинга килеп төшәсең. Элекке солдатны купшы гына гостиницага илтәләр. Инде автор сүзләре: «Мондый гостиницаларда, белүемчә, югары чиндагы хәрбиләр: полковник ишеләр, генераллар тукталучан була. Мин, армиядә сеңеп калган гадәт буенча, үземне һаман рядовой яки сержант итеп хис итәм. Рядовой булып йөргән чакларым хәтердә ныграк саклана. Янымнан кызыл лампаслы генерал узганда йөрәгем әле хәзер дә уч төбенә кучәрдәй була. Минем өчен бик үк кулай гостиница булып чыкмас, ахры...»

Инде менә солдат вакытлары искә төшкәндә йөрәкләре әле хәзер дә уч төбенә күчәргә торган егетләрнең армиягә чыгып киткән чакларына күз салыйк:

«Без утырган вагон караңгыда паровоз белән «чәкеште».

— Көнбатышка, егетләр, җылы якка!

Сөенергә иртә иде әле. Чуен тәлинкәләр чәкешкәннән соң, безне бер сәгатькә якын урыннан-урынга тәгәрәтеп йөрттеләр. Ахыр чиктә, очы-кырые күренмәгән эшелонның урта бер төшенә кыстырып куйдылар... Күңелдәге нечкә кыллар чыңлап өзелгәндәй итте. Шул китү китү булды».

Туган ил белән аерылышу моменты

әнә ничек гади дә, хисле дә итеп бирелгән. «Шул киту киту булды». Күп сөйләп торуның кирәге дә калмаган, барысын да, барысын да аңлата торган җөмлә бу.

Менә тагын, солдатның стройда йөрергә, честь бирергә өйрәнгән вакыттагы кичерешләре: «Әниләр безне солдат тәртибенә тугач та өйрәтә башлаганнар. Аяклар төз булсын, куллар һавада буталмасын өчен кысып биләүгә биләгәннәр. Дөньяга туры карасын дип, башыбызны мендәргә җайлап, турылап салганнар. Биләүдән ычкынуга, без бу кагыйдәләрне оныткан̣быз. Кызык бит, тәпи йөреп киткәннән бирле җиргә ничек басарга белмичә йөргәнбез... Әле аның тагын (честь бирүнең — Г. Ш.) кырык төрле вак детальләре бар. Менә шуларның берсе килмәсә, Батраков (отделение командиры — Г. Ш.) сине зырылдатып борып җибәрә... Батраков мине бер вакытны җиде мәртәбә рәттән борып җибәрде. Һәр куылу йөрәгемә ук булып кадала... Бик нервыма тигәч, сигезенчесендә кире әйләнеп килмәдем, үз хаҗәтем белән бүтән якка йөгердем...»

Йөгерүен йөгерә дә бит солдат, ләкин командир янына кире килмичә барыбер булдыра алмый. Әнә шулай җәза артыннан җәза, наряд артыннан нарядлар китә. Ниһаять, солдат шундый бер нәтиҗәгә, әйтергә кирәк, бик кыйммәтле, безнең армиябезнең нигезен тәшкил иткән нәтиҗәгә килә. Автор үзе моны кызыклы, гыйбрәтле генә итеп сөйләп бирә:

«Мин һаман бер нәрсә турында уйланам: буйсынырга теләмәгән яшь тайны Миңнулланың (Миңнулла авторның якташы — Г. Ш.) әтисе өянкегә бәйләп ярган. Күрәсең, башкача мөмкинлеге булмаган. Шул көнгә калмас өчен, үз кытыгыңны үзең качыру яхшырак түгелме?

Армия өянкесе нык. Хәтәр давылларга, гарасатларга каршы торган, тамырларын гасырлар төбенә җибәргән өянке ул. Аны какшата алмыйсың...»

Бу инде солдатның чын солдат булып җитлегә баруы. Бу инде аның хәрби дисциплинага аңлы рәвештә буйсына белүе, командирлар әмерен Ватан әмере итеп кабул итә алу дәрәҗәсенә күтәрелүе. Солдатның әнә шулай әкренләп җитлегү моментларын я юморга төреп, я булмаса күңелгә ятышлы буяулар сайлап, тыйнак кына бизәп күрсәтә алуы белән дә кирәкле әсәр бу.

Аннан китә көн аралаш диярлек кырык-илле чакрымлы походлар, танкка каршы чокырлар казу, урман кисүләр, атналар буена чишенмичә йоклаулар, көненә әллә ничә тапкыр була торган тревогалар... Көнбатышта дәһшәтле сугыш бара. Көнчыгышта да ул менә-менә кабынырга тора. Мондагы дошманның да мәкерлеге немец фашистларыныкыннан ким түгел. Вакыты белән кәрәк-лом тотарлык, аягын атларлык хәле калмаса да, солдат үз бурычын үти, уфтанмый-сыктанмый. Чөнки Ватанның әмере шундый. Ватан газиз. Бу тема әсәрнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузылган.

Автор солдатларның сабыр гына сагына белүләрен, туган илләреннән килгән хатларны укып юануларын, кышкы салкыннарда, юеш землянкаларда бала чак хатирәләре, туган як моңнары белән җылынуларын, кайчандыр әллә ни исләре китмичә, бары тик шома һәм кызыклы итеп язылулары белән генә истә калган китаплардан, үз тирәләрендә, илдә һәм бөтен дөньяда барган вакыйгалардан хәзер сулышларын, элек үз авылы, үз шәһәре белән генә чикләнгән офыкларын киңәйтерлек җим эзләүләрен, тирән мәгънә табуларын, нинди генә очракта да рухи байлыкка омтылуларын, ата-бабалар мирасы, туган туфрак, туган ил, Ватан дигән төшенчәләрнең ни икәнен чынлап торып аңлый баруларын дөрес һәм калку итеп тасвирлый.

Инде әйтелгәнчә, документаль әсәрнең мөмкинлекләре шактый чикле. Шуңа карамастан, Әдип Маликов истәлектәге төп геройларны образ дәрәҗәсенә күтәрә алган. Чын тәрбияче сыйфатларына ия булган кадровый офицер — взвод командиры лейтенант Орлов, беренче карашка төксе, корырак булып күренгән, ләкин асылда ышанычлы иптәш, әйбәт командир сержант Батраков, сугыштан соңгы бөтен гомерен һәлак булган солдатларының каберен эзләүгә багышлаган полк командиры Сабит Жумакаев, «эшләпәсе, зур кабак өстенә менеп утырган песи баласы шикелле, баш өстендә генә тора» торган музей экскурсоводы, соңыннан фәннәр кандидаты Алексей Рыжиков, авторның як-

ташы, отделение абруе дигәндә үлеп китүче, үтә дә самими, сабыр, шул ук вакытта кыю һәм тапкыр, һәр нәрсәгә юмор аша карый белүче авыл баласы Миңнулла Миңлекәев — һәркайсы тулы канлы, якты һәм кешелекле образлар булып күңелдә калалар.

Әсәрнең теле җыйнак, мамыклы, юморга бай. Автор турыдан-туры үзенә кагылышлы, үзенә бәйле вакыйгаларны да тыйнак кына итеп, юмор белән сурәтли белә. Язучы өчен бу бик кыйммәтле сыйфат, бу инде киң күңеллелек, олы җанлылык галәмәте. Әдип Маликов чагыштыруларны, гомумән, сурәтләү чараларын җиренә җиткереп, тәмен белеп куллана.

Япон самурайларына каршы сугыш атна-ун көндә тәмамланды. Ләкин шул вакыт эчендә дә без анда меңнәрчә һәм меңнәрчә кеше югалттык. Каты булды бу сугыш. Безнең гаскәрләргә табигый киртәләр, климат шартлары да баштанаяк коралланган дошман кебек үк каршылык күрсәтте. Сахалин һәм Маньчжурия сазлыкларында батып, ком чүлләрендә сусап, алҗып үлгән солдатларыбыз тагын күпме! Әмма шунысы бар, әлеге сугыш Көнбатышта дүрт ел буена дәвам иткән, халыкны инде тәмам алҗыткан, җелегенә төшкән сугыш тәмамланып, җиңү тантанасы белән кинәнеп яшәгән бервакытта башланды. Илебезнең үзегеннән читтә, иң ерак чигендә барганлыктан, шуның өстенә тагын тиз дә тәмамлануы белән, ул ничектер игътибар үзәгеннән читтәрәк калып торды шикелле. Бу вакыйгаларга багышланган әсәрләр рус әдәбиятында да шактый вакытлар үткәч кенә күренгәли башлады. Безнең татар әдәбиятында исә алар әле шушы көнгә кадәр юк дәрәҗәсендә аз. Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» повесте әнә шул бушлыкны шактый киметүе белән дә әһәмиятле. Әлеге әсәр биш-алты ел буена японнарның һөҗүмен көтеп, дөресрәге, аларның юлын бикләп торган гаскәрләребезнең искиткеч кыен шартларда да, бернигә карамыйча, сугышчан сәләтләрен туктаусыз үстерә баруларын, инде вакыты җиткәч, алларына куелган бурычны намус белән башкарып чыгуларын калку итеп, дөреслеккә хыянәт итмичә сурәтләп бирә алган. Миңа, шул вакыйгаларда катнашкан кешегә, бу нәрсәләр ачыграк күренә дип әйтсәм дә ялгышмам төсле. Кыскасы, Әдип Маликов укучыларыбызга әле моңарчы таныш булмаган яисә аз таныш булган хәлләрне, вакыйгаларны ачты. Мин исә аның шагыйрь дә булуы өстенә лирикуйчан, шәп прозаик та икәнлеген ачтым.

**ГАБДУЛЛА ШӘРӘФЕТДИНОВ.**

# «ЭПИК ЖАНРЛАР»

Әдәбият белгече Фәрит Хатиповның яңа китабы шулай дип атала[1]. Исеменнән үк күренүенчә, үзенең бу хезмәтендә автор художестволы прозаның төп жанрларын яктыртуны максат итеп куйган. Китапта эпик жанрларның бәләкәй формалары — новелла, хикәя һәм күләмлеләре — повесть, романның эчке табигате билгеләнә, аларның төп үзенчәлекләре ачыклана.

Ләкин башта ук шуны әйтергә кирәк: Ф. Хатипов бөтен бу эпик жанрларны тулы һәм җентекле тикшерүне бурыч итеп куймый, ә төп максат «аеруча типик күренешләргә характеристика бирү булганга», автор бу жанрларның иң характерлы сыйфатларына күбрәк тукталa. Димәк, аның алдында торган бурычлар таррак.

Безнеңчә, бу китап, беренче чиратта, университет һәм педагогия институтларының тел һәм әдәбият факультетлары таләпләрен исәпкә алып язылган.

Хезмәтенең кереш бүлегендә Ф. Хатипов сәнгатьнең тармаклану принципларын аңлата, аның үзенчәлекле бер тармагы булган матур әдәбиятның төрләренә (эпос, лирика, драма) һәм аларның үзара мөнәсәбәтләренә кыскача характеристика бирә. Бу бүлек, әлбәттә, бик кыска, ләкин автор монда алда сүз алып барылачак темасы

[1] Фәрит Хатипов. Эпик жанрлар. Казан, 1973 ел.

өчен кирәк булган күренешләргә генә туктала.

Эпик жанрларның төп сыйфатларын билгеләүгә күчүдән элек, китапта башта халык иҗаты жанры булган мәзәк җентекле тикшерелә. Авторның бик дөрес билгеләвенчә, «аның тирән тамырлары язма әдәбият жанры новелла белән шактый тыгыз үрелешкән». Бу фикер мәзәкне анализлаганда да һәм ары таба новелла жанрына характеристика биргәндә дә нигезле дәлилләр белән аңлатыла.

Аерым бүлекләрдә Ф. Хатипов, әйткәнебезчә, новелла һәм хикәя, повесть һәм роман жанрларының иң мөһим үзенчәлекләрен күрсәтә. Бөтен бу жанрларны тикшерүне ул аларның барлыкка килү, туу тарихын сөйләүдән, новелла, повесть, роман терминнарының мәгънәләрен аңлатудан башлый, жанрларның үсеш юлларын күрсәтә. Барлык очракларда да автор көнчыгыш һәм көнбатыш илләре, рус, татар, башкорт әдәбиятлары мисалларына мөрәҗәгать итә, төрле чагыштырулар үткәрә. Аның шулай бай материалга таянып эш итүе, безнеңчә, китапның фәнни кыйммәтен арттыра.

Эпик жанрларның хәзерге үсеш мәсьәләләрен караганда, Ф. Хатипов соңгы елларда матбугат битләрендә барган төрле бәхәсләрне дә читләтеп үтми, үзе дә бәхәскә керә һәм һәрбер мәсьәләдә үз фикерен әйтергә тырыша.

Барлык жанрларны тикшергәндә дә алар арасындагы уртак сыйфатлар һәм аерымлыклар күрсәтелә, һәрбер жанр эчтәлек һәм форма бердәмлеге җәһәтеннән чыгып карала, төпле дәлилләргә нигезләнеп, аерым нәтиҗәләр ясала.

Автор хикәя, повесть, роман жанрларына, аларның төп сыйфатларыннан чыгып, үзенең билгеләмәләрен бирә.

Жанрларның үзенчәлекләрен теоретик күзәтүдән соң, Ф. Хатипов аларның һәрберсенә мисал итеп конкрет бер әсәрне алып тикшерә. Китапта Ф. Хөснинең «Тромбон һәм кыз» хикәясе, Г. Ахуновның «Чиләвек төше» повесте һәм И. Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясе тулы килеш анализлана.

Бу исә теоретик фикерләрне укучыга җиткерергә, ныклап аңлатырга мөмкинлек бирә. Чөнки күп очракта бер әсәр аша да аерым жанрны, әдәбияттагы агымны, хәтта бер чорны мәгълүм дәрәҗәдә күз алдына китереп була. Аннан соң аерым әсәрләрне конкрет анализлауның студент яки укытучы өчен практик ярдәме, эш процессында китергән файдасы да шиксез.

Тик шунысы бар: билгеле булуынча, эпик жанрлар бер-берсеннән күләмнәре буенча нык аерылалар. Әйтик, новелла яки хикәя — кыска, ә повесть, роман зур күләмле булулары белән характерлы. Шушы яктан гына караганда да, хезмәтнең бүлекләре арасында күләм җәһәтеннән үзара нисбәт, безнеңчә, исәпкә алынырга тиеш булгандыр.

Ф. Хатипов мәзәкне дә, новелла һәм хикәя жанрларын да бик җентекләп тикшерә, аерым конкрет әсәрләрне анализлаганда да бәләкәй жанрларга игътибарны күп бүлә. Әлбәттә, мәзәк жанрын җентекләбрәк тикшерергә, безнеңчә, бөтен нигезләр бар, чөнки ул (автор моны үзе дә билгели) әле әдәбиятта аз өйрәнелгән.

Тик аерым бүлекләрдә күләмгә игътибар бирмәү повесть һәм роман жанрларына азрак урын калдыра. Бәлки китапта очерк һәм мәсәл жанрларына да тукталырга кирәк булгандыр.

Ф. Хатипов — югары уку йортларында күп еллар эшләп килгән педагог, әдәбият галиме. Аның «Эпик жанрлар» дигән китабы әнә шул эш тәҗрибәсеннән чыгып язылган. Күләме ягыннан зур булмаган бу хезмәт эпик жанрларга, бер урынга туплап, тулы гына характеристика бирүе, аларның төп сыйфат һәм үзенчәлекләрен нигезле аңлата алуы белән әһәмиятле. Һәм ул, беренче чиратта, студентларга һәм әдәбият укытучыларына «Әдәбият гыйлеменә кереш» курсын һәм әдәбият тарихын өйрәнгәндә файдалы кулланма булачак. Чөнки әдәби әсәрләрнең аерым жанрларын конкрет әсәрләргә нигезләнеп җентекле анализлаган хезмәтләр бик кирәк.

**И. ВӘЛИТОВ.**

# КИТАП УКЫГАНДА...

Яктылык спекторы төп җиде төстән тора: зәңгәр, яшел, сары... Элегрәк рәссамнар үз иҗатларында күбрәк шушы конкрет җиде төс белән генә эш иткәннәр. Әмма вакыт үтү белән гаҗәеп дәрәҗәдәге бай дөньяны чагылдыру өчен бу төсләр генә җитми башлаган, һәм рәссамнар буяуларны бер-берсенә кушып яңа төсләр (төсмерләр) тудырганнар. Шигърияттә дә шулай. Коры риторикага корылып, гади хикәяләү стиле белән язылган, кәфия-вәзенгә төренгән, прозага тартым шигырьләр урынына тирән образлылыкка нигезләнгән яңа формалы әсәрләр туа. Төрле алымнар куллану, кыю эзләнүләр уңышлы нәтиҗәләргә китерә. Ниһаять, шигърияттә интеллектуаль агым да көчәеп китә.

60 нчы еллар татар поэзиясендә бер төркем яшьләр шул агымга кушылдылар. Болар арасында Рөстәм Мингалимов та бар иде. Хәзер инде аның татар әдәбиятында үз мәйданы, үз хезмәте күренә. Беренче әйберләре белән үк үзен өметле, үзенчәлекле шагыйрь итеп күрсәткән Р. Мингалимовның быел тагы бер китабы дөнья күрде. Ул «Күз карасы» дип исемләнгән. Соңгы елларда язылган әсәрләреннән төзелгән бу яңа җыентык шагыйрьнең оригиналь тавышлы булуын, татар шигъриятенә үзенчә яңа матурлык алып килүен чагылдыра.

Бер үк күренешне төрлечә тасвирлап була. Әмма иң төгәл, иң тәэсир итә торган вариантны табу шагыйрьнең күңел күзе белән күрә белүеннән, үзенчә образлы фикерләү осталыгыннан тора. Ә образлы фикерләү ассоциатив тою белән тыгыз бәйләнгән. Бер карасаң, игътибарга лаек була алмаслык нәрсә, кечкенә генә деталь шагыйрьдә әллә нинди тойгылар уята, аңа илһам бирә. Р. Мингалимовның үз сүзләре белән әйтсәк:

> Тамчы күрсәм дә
> тошәсең исемә.
> Диңгез күрсәм дә
> киләсең уема: —
> Дөньяда иң яшел,
> иң йомшак,
> синең яр.
>
> (Касады елга.)

Нәтиҗәдә, кечкенә генә бер авыл елгасы шагыйрь күңеле аша зур диңгезләр рәтенә баса, шулай сәнгать әсәре барлыкка килә. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, ассоциатив тойгыга корылган әсәрләр укучының аң-белеменә, эстетик зәвыкларына карап төрлечә кабул ителә икән, бер дә гаҗәп түгел. «Тамчы күрсәм дә...» Кемдер шушы тамчыларда күз яшьләре күрер, кемдер аларны кояшта ялтыраган чыкка тиңләр, кемдер... Шагыйрь күзенә күренгән әйбер белән мондый хәл дә була.

> Күрегез:
> учымнан
> Күбәлек өстенә
> очырам.
> Шигырем белән
> ак күгәрчен итеп
> очырам
> ак Кремльне.
>
> (Ак Кремль.)

Шушы юлларны укыгач, бер төрле укучы аптырап калуы һәм шагыйрьне гаепләве мөмкин. Ләкин тәнкыйть итәргә ашыкмыйк әле. Кискен нәтиҗәләр ясаганчы шагыйрьнең әлеге образлы фикерләү мантыйгын, үзенчәлеген кабул итәргә тырышып карыйк. Әгәр дә шуңа төшенсәң, шигырьләр су агымы кебек шигърият киңлегенә үзләре алып кереп китәрләр. Һәм син моңарчы сизмәгән матур-матур бизәкләр, мәгънәви төсмерләр күрерсең, тойгылар, образлар артында тормыш фәлсәфәсен табарсың.

Үзенчә образлы күрә белү яңа сурәтләү чараларын сорый; охшатым (сравнение), читләтем (аллегория), күчмә (метонимия), арттырымнарның (гиперболалар) оригиналь булуын таләп итә: «кояш көйрәде», «кара алтын» төсле кара толымнары иңнәреннән Иделемә ташып тора...», «зур күзләре — Татарстан күзләре бит...» һ. б. Боларның, беренче карашка, сәеррәк тоелулары да бар. Моңа бер дә гаҗәпләнергә кирәк түгел. Халыкның сөйләм теленнән бер генә мисал китерик: әче яшькелт тавыш (белән кычкырды) диләр. Без моңа бит шаккатмыйбыз, чөнки күнеккәнбез. Ә уйлап карасаң, халык тавышта төс һәм тәм күрә алган! Ярый әле, бу сүзләрне халык әйткән, әгәр дә моны яшь язучы язса, кайберәүләрнең тел бозуда гаепләнүләрен көт тә тор...

Бездә кайчакта игътибарны эчтәлеккә юнәлдереп, шигырьнең бүтән якларына тиешле дәрәҗәдә илтифат итмиләр. Ә бит коры фикер генә әйтү өчен мәкаләләр, фәнни хезмәтләр язып була. Аннары сәнгатьнең үзенә күрә бер могҗиза булуын онытмыйк, матурлык кануннарына буйсынуын искә алыйк. Аның сихри көче дә шунда.

Әйтәсе фикер тәэсир аша иңдерелсен, шигырь акылга йөрәк аша үтсен. Кемдер әйтмешли, «күңеле каткан» кешенең дә эчендәге бозлары күз яшьләренә әйләнсен. Моңа ирешү өчен акыл белән хиснең органик берлектә булуы шарт. Р. Мингалимовның күп кенә шигырьләре моңа мисал була ала.

Син каршымда горур кыя булма,
Булма нәни чишмә яктысы...
Ерактагы зәңгәр офыгым бул,
Тормыш таным синдә яктырсын.

(Ерактагы зәңгәр офыгым бул.)

Яки менә яңгырлы бер төн турындагы юллар:

Күргәнем юк иде мондый төнне,—
Төн дисәң дә бүген төн мени!
Су төбендә яткан шәһәр төсле
Казан бүген яңгыр төбендә...

Бу китапта традицион шигырьләр белән беррәттән, ирекле стильдә язылганнары да байтак. Безнең әдәбиятта ак шигырь үзенә юл яра башлаган чорда, тәнкыйтьчеләр арасында төрле фикерләр булып алды. Күпләр аның татар шигъриятендә урын алуын шик астына куйдылар. Инде исә, ул шактый тамыр җәйгәч тә, ара-тирә икеләнүле сүзләр ишетелгәләп куя: менә ирекле шигырь язучылар шаулап йөрделәр-йөрделәр дә, хәзер инде бөтенесе дә барыбер шул ук иске традицион калыпка кайтып баралар. Димәк, бу форма безгә хас түгел...

Дөньядагы һәр нәрсә үзгәреш кичергәндәй, әдәбият та туктаусыз үсеш хәлендә. Аерым алганда, шигырь дә бер калыпта гына тора алмый. Эчтәлек иске формага сыеша алмау нәтиҗәсендә яңа форма туарга мәҗбүр була. Һәм ул форма эчтәлек таләпләреннән үзеннән-үзе килеп чыга. Ахыргы чиктә, ирекле форманың барлыкка килүе иҗат шартларының артуы, шигъриятнең баюы турында сөйләмимени?

Хәер, Р. Мингалимовның һәм башка шагыйрьләрнең ирекле формада язылган шигырьләренең сан ягыннан кимүе хак. Әмма бу аларның элеккеге карашларыннан баш тартулары түгел, киресенчә, сан ягын киметеп, сыйфат ягын үстерүдән киләдер. Эзләнүләр дәвам итә. Р. Мингалимов ирекле форманы тирән эчтәлекле, зур күләмле әйберләргә дә кыю рәвештә алып керә. Моны В. И. Ленинның 100 еллыгына багышланган «Минем дәүләтем» дигән поэмада күзәтергә мөмкин. Шушы ук алымны ул Чаллыдагы гигант төзелеш турындагы «Күз карасы» дигән яңа әсәрендә дә киң файдаланган.

Поэмаларда ирекле һәм традицион форма бер-берсен тулыландырып, тыгыз үрелеп бара. Әмма Р. Мингалимовка һәм бүтән шагыйрьләргә дә ирешкән уңышлар белән генә чикләнмичә, яңа эзләнүләргә омтылу һич комачауламас иде.

Бездә яшьләрдән берәрсен мактаганда ул инде формалашкан шагыйрь диләр. Ә бәлки бу сүзләр аңа мактау булып яңгырамыйдыр? Бәлки шагыйрьнең бары гражданин булып җитлегүе турында гына сөйләргә кирәктер? Әгәр дә инде кем дә булса берәү шагыйрь булып формалашкан дибез икән, димәк, ул максатка ирешкән, тауга менеп җиткән һәм хәзер әкренләп төшәсе генә калган дигән сүз түгелме соң? Бу аның эзләнүсез, янусыз, бер төстәге, монотон шигырьләр чыгарып, мыштым гына, Пегас артыннан өстерәлүе булмыймы? Сорауларны болай артык кискен төстә куюыбызның нигезе бар. Чөнки андый шагыйрьләр дә бездә җитәрлек бит. Болардан бернинди яңалык көтеп булмый инде. Алар нинди генә актуаль темага язмасыннар, һәр әсәре бер үк шигырьнең икенче вариантын гына хәтерләтә. Шуңа күрә эзләнүчән, яңалыкны аңларга тырышучан, сәнгатьне изге эшкә санап, матурлык һәм вөҗдан кануннарына буйсынып эшләүче шагыйрьләрдән генә чын әсәр өмет итеп була. Яшьләр «формалашырга» бик ашыкмасыннар иде. Форманың эчтәлек һәм тема таләбеннән чыгып тууы хәерлерәк бит. Ә бу гаҗәеп кызык һәм катлаулы дөнья темаларга никадәр бай! Нинди генә күренешләр шагыйрь күңелен җәлеп итми.

Табигатьне алыйк: кешене сафландыра, чистарта, кешелек сыйфатларын үстерә торган табигать күренешләре китаптагы байтак шигырьләргә тема биргән. Ләкин шагыйрь зәңгәр күккә үрелеп үскән ботакларны гына түгел, ә шул ботакларга бик нык охшаган җир астындагы тамырларны да күрә. Шагыйрь күңеле күк кебек киң. Җирдәге үзгәрешләр бөтен матурлыгы, каршылыклары белән аның йөрәгендә кайтавазын таба. Ул тормышны битараф күзәтүче генә булып кала алмый, үз мөнәсәбәтен белдереп, һәр нәрсәдә актив катнаша. Менә ул, Р. Мингалимов Чаллы нигезенә җыр сала:

Милләтләрдән монда кем генә юк!
Хезмәт көне тора яңгырап.
Яңа Чаллы!
Синең нигезеңә
Татар җыры салып калдырам.

(Күз карасы.)

Киләчәгебез бүген яулана. Киләчәгебез яшьләр кулында. Шагыйрь аларга мөрәҗәгать итә:

Өйрәнәбез!
Кадерлеләрем,
киләчәкнең күп өлеше

өйрәнүдә хәл ителә,
Бүген хәл ителә,
шушында, хәзер!

(Күз карасы.)

Туган як темасы да бу җыентыкта зур урын алган:

Хатадырмы, юкмы —
Һич сөйләмим көлеп:
Миңа Татарстан —
җир үзәге кебек...

Бу юлларны туган җирен чын күңелдән, ихлас яраткан шагыйрь генә яза ала. Әмма аның яратуы тар территориаль рамкалар белән генә чикләнми:

Мин дөньяны сөйдем,
Дөнья торсын белеп:
Ул да Татарстанның
Бер өлеше кебек!

Шагыйрь хәятнең төрлелегенә һәм шул төрлелеге белән кызык булуына мәдхия җырлый:

Яшик әле сокланышып,
Сокланырга күпме төс бар:
Күпме иллэр, төрле милләт —
Нинди келәм, матур, чуар!
Түм-түгәрәк җир шарыбыз
Чәчәк тулы болын кебек,—
Бер чәчәген югалтсак та,
Зур хатабыз булыр кебек.

Чынлап та, ярый әле, бу дөньяда төрле төсләр бар, төрле авазлар бар. Ярый әле, без сандугач, тургай, хәтта күке тавышыннан мәхрүм түгел. Яшь кызга охшаган каен нәфислеге, су буенда үскән тал зифалыгы, мәһабәт имәннең горур ныклыгы белән соклана алабыз! Дөньяви гармония тудырган бер авазны, төсне югалту — зур югалту, саклый алмау — мәңге гафу ителми торган җинаять булыр иде.

Р. Мингалимов олыларга адресланган бу китапка балалар өчен язылган шигырьләрен дә керткән. Һәм бик дөрес эшләгән. Күпме сафлык, самимилек аларда! Бу шигырьләрне укыгач, яланбаш, тузаннар туздырып, балачак илена чабасы килә...

Менә бер кызчык кичкенә генә зәңгәр чиләген, «узучылар иркен сулап басып эчсеннәр дип», инеш буенда калдыра. Иртәгесен килсә, узучылар элеккечә суны ятып эчә. Кыз аптырашта кала:

Мин бит сезгә чиләгемне
Калдырдым кичә?!.
Нигә инде, узучылар,
Шулай иттегез?
Минем зәңгәр чиләгемне
Кая илттегез?

(Узучылар.)

Без дә шулай беркатлы түгел идекме? Дөнья белән шулай танышa башламадыкмы? Ләкин шулай да «түбәтәйгә утырып күктә йөзгән» малайның матур сыйфатларын хәзергегә кадәр саклый алдыкмы? Үзебезнең җирдә яшәвебез белән «Бәхетле исем»дәге кыз сыман кешеләргә шатлык китерәбезме?

Дәү абыйларга, апаларга мондый шигырьләрне укыганда бала чак иленә әйләнеп кайту бер дә зарарлы булмас.

Кыскасы, Рөстәм Мингалимовның «Күз карасы» — әдәбият сөючеләр өчен әйбәт бүләк булыр. Алар аның актив, тулы канлы, бүгенге көннең актуаль проблемаларын тирән аңлап, киләчәкне кайгыртып яшәүче лирик каһарманы белән бергәләп шатланыр-кайгырырлар.

Шунысы гына күңелне борчый, ул да булса елдан-елга үсеп килгән шагыйрьнең китабы саен тиражы кимүе. Җыентыкның бары ике мең данә белән чыгуы күпме укучыны кызыклы шагыйрь белән танышудан мәхрүм итә.

**РӨСТӘМ ФӘЙЗУЛЛИН.**

# КИҢ КОЛАЧЛЫ ГАЛИМ

Күренекле тел белгече, тәнкыйтьче һәм педагог, татар тел белемендә беренче фән докторы профессор Латыйф Җәләйнең тууына шушы елның 17 ноябрендә 80 ел тулды.

Аның биографиясе өлкән буын татар совет интеллигенциясе үткән юлдан берни белән дә аерылмый. 1894 елны Самара губернасы Иске Кызылсу авылының ярлы крестьян семьясында туган Латыйф Җәләйнең бала чак һәм яшьлек еллары байларда «малайлыкта», кышын караңгы мәдрәсәдә, ә җәйләрен, укыр, тамак туйдырыр өчен, авыр кара эш эшләп, ялчылыкта, ярым ач-ялангач тормышта уза. Унсигез яшеннән ул авыл мәктәбендә укытучылык итә башлый.

Ачы тормыш мәктәбен яшьли үткән, солдат окопларында империалистик сугышның гаделсезлеген үз җилкәсендә татыган татар егетенең күзләрен большевиклар ача. 1917 елны ул туган авылына кайта һәм тормышын үзе кебек изелгәннәргә азатлык бирүче большевиклар партиясе белән бәйли.

Партия аны элекке укытучы буларак халыкны агарту өлкәсенә юнәлтә. Революциянең беренче көннәреннән алып ул авыл мәктәбендә укытучы, балалар йортында мөдир, совет-партия мәктәпләрендә, педагогия техникумнарында һәм Самара авыл хуҗалыгы институтында татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак меңәрләгән милли кадрлар — яшь укытучылар, совет һәм партия хезмәткәрләре тәрбияләүгә күп көч куя. Һәр вакыт эзләнүчән табигатьле педагог милли мәктәпләрдә укыту методикасын камилләштерү турында уйлана, аерым фәннәрне укыту ысуллары турында методик журналларда, җыентыкларда мәкаләләр белән чыга.

Л. Җәләйнең педагог-методист буларак иҗат эшчәнлеге край мәгариф бүлеге инспекторы булып эшләү дәверендә аеруча активлаша. 1929 елны Самарада ул үзенең беренче китабын — беренче баскыч мәктәпләрдә атеистик тәрбия мәсьәләләренә багышланган методик кулланма бастыра, зурлар мәктәпләре өчен «Ничек эшләргә», «Уку китабы», «Туган тел», «Урта Идел» һ. б. дәреслекләр яза. 8 нче класс өчен ул төзегән «Әдәбият», «Әдәбияттан хрестоматия» дәреслекләре илленче еллар башына кадәр бер генә татар баласының да кулыннан төшми.

1933 елны ул белемен күтәрү өчен Казанга, педагогия институты каршындагы аспирантурага укырга килә һәм, аны уңышлы тәмамлап, чирек гасыр буена башта Казан педагогия институтында, ә 1944 елдан Казан университетында яңа курслар — татар диалектологиясе, әдәби тел тарихы, тарихи грамматика фәннәрен алып бара, югары мәктәпләр өчен программалар төзи, төрле кулланмалар хәзерли. Аның турыдан-туры катнашлыгы белән шушы вакыт эчендә меңәрләгән югары белемле милли кадрлар тәрбияләнә, йөзәрләгән укытучылар, төрле курсларда аның лекцияләрен тыңлап, белемнәрен арттыралар. Бер үк вакытта ул яшь галимнәр тәрбияләүгә дә көчен кызганмый. Хәзерге көндә татар тел белемен әйдәп баручы фән докторлары һәм кандидатларының күпчелеге — Латыйф ага Җәләй мәктәбен үткән галимнәр.

Фәннең яңа тармагын ачу бәхете бик сирәк галимнәр өлешенә тия. Латыйф ага Җәләй исә татар тел белеменең өч тармагына нигез салган киң колачлы галим.

Аспирантурада укыган елларында ук ул борынгы һәм хәзерге әдәбиятны, иске язма ядкарьләрне тирәнтен өйрәнеп, татар теленең бик борынгыдан алып хәзерге көнгә кадәр үсеш тарихын күзаллаган зур хезмәт яза. «Татар теле тарихына караган кайбер материаллар» дип тыйнак кына исемләнсә дә, тарихи синтаксиска нигез салган бу хезмәте өчен 1942 елның декабрендә Мәскәү университетының Гыйльми советы Л. Җәләйне ул елларда сирәк галимнәр генә ия булган филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә лаеклы таба.

Сугыштан соңгы елларда ул, туктаусыз эзләнүләр алып барып, «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар» (Казан, 1954), «Татар теленең тарихи морфологиясе» кебек монографияләр иҗат итә. Югары уку йортларында озак еллар буена тарихи грамматика курсы хезмәтен үтәгән бу өч әсәр, аның төрле журналларда һәм җыентыкларда басылган аерым мәкаләләре белән берлектә, татар теленең тарихын киң күләмдә күз алдына китерергә ярдәм итә һәм бу өлкәдә киләчәк тикшеренүләргә ныклы нигез булып тора.

Латыйф Җәләй утызынчы еллар ахырыннан башлап (бигрәк тә 1939 елны Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшләргә күчкәч) ел саен Татарстанның төрле районнарына һәм күрше өлкәләргә халыкның җирле сөйләмен өйрәнү өчен диалектологик экспедицияләргә чыга, махсус сораулыклар, программалар төзи. Күпьеллык эзләнүләр нәтиҗәсендә, 1947 елны ул «Татар диалектологиясе» дәреслеген бастырып чыгара, соңрак «Татар теленең урта диалекты» исемле монографик хезмәтен тәмамлый.

Татар диалектларын өйрәнүче галимнәр Л. Җәләйгә кадәр дә күп була. Әмма татар диалектологиясен аерым күзәтүләрдән фән дәрәҗәсенә күтәргән, татар диалектларына беренче мәртәбә дөрес классификация биреп, һәр җирле сөйләш үзенчәлеген кардәш яки күрше телләр һәм борынгы язма истәлекләр белән чагыштырып, җентекле тасвирлаган һәм татар әдәби теленең нигезендә кайсы диалект ятуын ачыклаган галимнең исеме Латыйф Җәләй иде. Татар галименең исемен гомум тюркология күләмендә таныткан бу хезмәте өчен аңа 1954 елны фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе бирелә. Тиздән ул Казан дәүләт университетының профессоры итеп сайлана.

Киң җәмәгатьчелеккә Латыйф ага күренекле телче-галим сыйфатында гына түгел, матур әдәбияттә әдәби осталык мәсьәләләрен күтәреп чыккан гаять принципиаль, үтроле» (1940) исемле беренче мәкаләләрендә үк ул атаклы сүз осталары иҗатының кен телле тәнкыйтьче буларак та билгеле. «Киң җәймәдәге таплар» (1934), «Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең аерымланган кисәкләре» (1935), «Сиваш» (1938), «Тукай телендә фигыльләр» (1938), «Татар художество әдәбияты телен баетуда Ш. Камалның үзенчәлекле якларын ачарга тырыша, тормышчан, җанлы образлар, онытылмас характерлар тудыру өчен, кайсы тел-сәнгать чарасы куллану уңышлы булу-булмавын конкрет мисаллар өстендә күрсәтә.

Соңгы елларда язылган «Совет чоры татар матур әдәбияты теленә бер күзәтү» (1951), «Тукай поэзиясенең кайбер синтаксик үзенчәлекләре» (1954), «Язучылар телен өйрәнү принциплары» (1960), «Әдәби тел һәм матур әдәбият теле» (1964) һ. б. мәкаләләрендә Л. Җәләй язучыларның тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү принципларын ачыклый. Аның җиңел кулы белән татар тел белемендә яңа тармак — матур әдәбият теле фәненең беренче нигез ташлары салына.

Ярты гасырлык иҗат дәверендә (ул 1966 елның 1 августында үлде) профессор Латыйф Җәләй тел белеменең аз өйрәнелгән тармакларын тикшерүгә, бәхәсле мәсьәләләрен (бигрәк тә хәзерге әдәби тел грамматикасы, әдәби тел тарихы, орфография, сөйләм культурасы) хәл итүгә зур өлеш кертте. «Татар теленең орфоэпик нигезләре» (1953) хезмәтендә әдәби әйтелеш нормаларын татар тел белеме тарихында беренче булып конкрет системага салды, татар филологиясендә киң колачлы галим буларак тирән эз калдырды.

**ИСКӘНДӘР АБДУЛЛИН.**

# АТАКЛЫ ГАРМУНЧЫ-МУЗЫКАНТ

Мәшһүр гармунчы-музыкант, Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевның тууына январьда 90 ел тула.

Фәйзулла Туишев хезмәт халкының традицион уен коралы — гармунда уйнау осталыгын чын сәнгать биеклегенә күтәргән гармунчы буларак дан казанды. Гармунны ул халык сәнгате чикләреннән профессиональ сәнгать киңлекләренә алып чыкты. Гармун тавышларының кабатланмас яңгырашларын тапкан, үз стилен, мәктәбен тудырган бу музыкантның уйнавы үзенә күрә бер дөнья, гүзәллек дөньясы иде. Чын музыка, чын сәнгать бер вакытта да эзсез югалмаган кебек, күп тармаклы татар музыка сәнгатендә дә Фәйзулла Туишев салган эз бетмәде, матур бер традиция булып



*Рәсемдә: Фәйзулла Туишев үзенең гармуннары белән.*

үсеп китте, Фәйзи Биккенин, Гали Җәмлиханов, Гани Вәлиев, Рокыя Ибраһимова һәм дистәләрчә башка талантлы яшь гармунчы-музыкантлар иҗатында чәчәк атты. Татар музыкасында Фәйзулла Туишевның урыны әнә шулар белән билгеләнә дә.

Фәйзулла Туишев Мәләкәс шәһәрендә батрак Кәбирнең ярлы һәм ишле семьясында туа, авыр бала чакның ачы җимешләрен татып үсә. Кечкенә чагыннан ук күңеленә кереп утырган музыкага, гармунга мәхәббәте аның өчен бу тормышта бердәнбер якты нур була.

Томана атасыннан кыен ашаулары да, дин әһелләренең каргышы да малайны гармун белән саташу «чиреннән» биздерә алмый. Шуннан соңгы елларда, инде иҗатының чәчәк ата башлаган чорында да, Фәйзулла Туишевка үзенең гармуннарын һәм музыканы динчеләрнең, хәтта официаль власть органнарының да һөҗүмнәреннән яклап көрәш алып барырга туры килде. Дингә хилаф дип игълан ителгән «гөнаһ иясе» гармунны ул «идән астыннан» яктыга, халык алдына, киң Россиянең шәһәр һәм авыллары сәхнәләренә алып менде. Бу үзе үк зур батырлык, чын бер каһарманлык иде.

Революция алды елларында, аеруча Петербургта яшәгән чорда, Ф. Туишев үзенең концерт эшчәнлеген киң колач белән җәеп җибәрә. Нигездә татар музыканты булып саналса да, бу вакытта ул рус һәм башка халыкларның көйләрен дә гаҗәеп зур осталык белән башкара.

Бөек Октябрь Ф. Туишевны чын мәгънәсендә халык артисты итте, аның алдында моңарчы күрелмәгән офыкларны ачып җибәрде. Миллионлаган хезмәт ияләре аның гармуннарын үзләренең күңел сердәшләре буларак кабул иттеләр.

1929 елны Татарстан җәмәгатьчелеге Фәйзулла Туишевның иҗади һәм концерт эшчәнлегенең 25 еллыгын билгеләп үтте, юбилярга Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирелде. Гомеренең соңгы көннәренәчә Фәйзулла ага үзенең гармуннарыннан аерылмады. Аның илленче елларда магнитофон тасмасына язылып алынган көйләрен без хәзер дә зур ләззәтләнү белән тыңлыйбыз.

Фәйзулла Туишевның башкару осталыгы тирән һәм гыйбрәтле. Көйне иҗат иткән халык белән гүя янәшә басып, ул җыр иҗатының дәвамын күрсәтә, аны яңа аһәңнәр белән баета. Аның тылсымлы гармуннарының телләреннән көйләр гүя яңарып һәм сафланып, үзенә бер гайрәт алып чыгалар, тагын да хәрәкәтчәнрәк, омтылышлырак яңгырый башлыйлар. Алар безгә көйләребезнең гүзәллеген ачарга һәм аңларга ярдәм итәләр.

**РИМ ШИРИЯЗДАНОВ.**

## Шәүкәт Галиев

### «Курыкма, тимим!»

Малай урманга кергән,
Каршында куян күргән.
Куянкай дер-дер килгән:
«Инде нишләтер...» дигән.
Ә малай бара биргән:
«Күрергә килдем, дигән,
Курыкма, тимим!» дигән.,

Малай эчкәрәк кергән,
Каршында тиен күргән.
Тиенкәй дер-дер килгән:
«Инде нишләтер...» дигән.
Ә малай бара биргән:
«Күрергә килдем, дигән,
Курыкма, тимим» дигән.

Аю авылга килгән,
Анда малайны күргән.
Малай да дер-дер килгән:
«Инде нишләтер...» дигән.
Ә аю бара биргән:
«Курыкма, тимим, дигән,
Шәфкатьле баланы мин
Күрергә килдем!» дигән.

### Керәшәләр

Югары да менәләр,
Түбәнгә дә төшәләр,
Әйләнә керәшәләр...
Әллә ни серләшәләр?
Мин беләм, керәшәләр
Миңа ни сөйләшәләр:
— Ярый инде ояга
Еланнар кермәсәләр...
— Еланнар кермәсәләр,

Оланнар менмәсәләр...
— Әгәр елан кергәнне
Оланнар белмәсәләр?!
— Еланнар тешләр инде!
— Оланнар нишләр инде?!
Ярдагы керәшәләр
Борчылып сөйләшәләр.

## Дөмбәскә

Болын тулы дөмбәскәләр —
Дөмбәскә дә дөмбәскә!
Дөмбәскәдән дөмбәскәгә
Ник сикереп йөрмәскә!

Син сикерә беләсеңме?
Сикерә дә белмәскә!
Үчекләмәс лә, көлмәс лә,
Егылсак та дөмбәскә...

Тәкәрлеккә, чү, тимәскә,
Ул тирәгә кермәскә!
Тәкәрлеккә тигәннәрне
Син, дөмбәскә, дөмбәслә!

## Күбәләк

Бер генә көн яши күбәләк!
Бер генә көн яши күбәләк...
Алай диеп тормый күбәләк,
Аның өчен дөнья түгәрәк!
Күпме болыннарга төште ул,
Күпме чәчәкләргә күчте ул,
Татлы ширбәтләрен эчте ул,
Матурлыкны татып үсте ул.

Мәңге очар кебек очты ул.
Шул гомердә Идел кичте ул!

## Бала белән бәбкә

— Печеньене дә
Капмаган була,
Кыстата бигрәк!

— Яшел чирәмдә
Ви-ви-ви-ви-ви-
Витамин күбрәк!

## Чисталыкны тикшерү

Бер малай өзеп
Чәчәкне исни,
Ис китеп әйтә:
— Ай-һай, хуш исле!

Чәчәк тә аның
Борынын исни.
Бу бәя белән
Һич тә килешми...

## Кеше урман кисә...

Алдан-арттан кисә,
Уңнан-сулдан кисә,
Кисә, һаман кисә,
Бигрәк яман кисә,
Кеше урман кисә.

Эшләр кайнап тора,
Балта уйнап тора!

Ә кәккүк кычкыра,
Моңаеп кычкыра —
Урман бетә, дип,
Ниләр көтә, дип...

Кеше тыңлап тора,
Кеше сорап тора:
— Күпме яшәрмен,
Кәккүк, санап кара?

Кәккүк болай дип
Әйткән шул чакны:
— Яшәрсең урман
Яшәгән чаклы...

Балта туктап тора,
Кеше уйлап тора...

## Әллә бер тырышасы?

— Нигәдер бу арада
Тастымал тиз карала.
Ни булган бу сөлгегә,
Җир шикелле гел генә!
Биш бармак та ун бармак,
Бүтәнен булмый аңлап,
Колаклардыр, күзләрдер,
Тагын нинди эзләрдер...

Әнием хәйран кала,
Сөлгене чөйдән ала
Һәм җебетергә сала.
Күп итеп сабын сөртә,
Чиста суда йөздертә,
Җиләс җилдә киптерә,
Тирләп тә пешеп бетә,
Яңадан ап-ак итә.

Күрмимме, күреп торам,
Сизмимме, сизеп торам,
Әллә бер тырышасы,
Әнигә булышасы —
Сабынлап юынасы?

## Әлфия хикәясе

Әлфия Миннуллинага

Әни эшкә чыгып киткәч,
Икәү калдык өйдә без.
Апа әйтә:
— Тукта әле,
Тик торабыз нигә без?

Гаҗәпләндерик әнине,
Китәрик әле исен,
Берәр эшен эшләп куйыйк,
«Ай-һай, кызларым!» дисен.

Урын-җирләрне карыйбыз —
Урын-җирләр җыелган.
Савыт-сабаны карыйбыз —
Савыт-саба юылган.

Бөтенесен эшләп киткән,
Безгә эш тә калмаган.
Идән дә ялтырап тора...
— Әйдә, юыйк яңадан!

Ни булса да тигез тиеш,
Моны яхшы беләбез —
Юыласы идәнне дә
Өлешләргә бүләбез.

Акбур алды да апаем
Сызды-куйды идәнне.
— Карап бул, — дим, күрмисеңме
Миңа әзрәк тигәнне!

Төкереклэп ышкый-ышкый
Ул сызыкны бозабыз,
Түр яккарак авыштырып,
Яңабаштан сызабыз.

Анда — шкаф, монда — диван...
Килдек без шундый уйга:
Юмыйсы төш тигез тисен —
Буләргә кирәк буйга!

Ак, зәңгәр акбурлар беткәч,
Шәмәхәсен алабыз.
Шулай сыза-боза торгач,
Бөтенләй буталабыз.

Бер заман идән дә, без дә —
Нәкъ салават күпере...
Булеп тә бетергән идек,
Әни дә кайтып керде.

Чыннан да, бик исе китте,
Бик гаҗәпләнде инде,
Чыннан да, безгә карап ул:
— Ай-һай, кызларым... — диде.

Ваннага кертеп бастырды,
Өскә җылы су койды.
Безне дә һәм идәнне дә
Булмичә генә юды...

## Өйрәндем мин Вовача

Вова гел русча сөйли,
Вова татарча белми.
Нәп-нәни мәэмае да
Көйләнгән үз җаена,
Капка астыннан керә,
«Вов-ва! Вов-ва!» дип өрә.

Вовача мин белмимен,
Баһауча мин сөйлимен.
Мәэмаем шуңа күрә
Минемчә генә белә,
«Баһ-һау! Баһ-һау!» дип өрә.

Вова белән очраштык,
Вова белән дуслаштык.
Мәэмайлар да очрашты,
Мәэмайлар да дуслашты!

Вова сөйли үзенчә,
Мин сөйлимен үземчә.
Әйтеп-әйтеп карыйбыз,
Аңлый гына алмыйбыз...
Белми йөргәч ишләргә,
Ярдәм итте ишарә,
Булышты дус-ишләр дә.
Бергә йөгерә торгач,
Кеше көлдерә торгач,
Өйрәндем мин Вовача.

Ничек әле моңача
Белмәгәнмен мин русча?!
Йөри торгач тирәмдә,
Маэмаем да өйрәнгән.
Тыңлап карадым юри,
Ике дә уйлап бирми,
«Вов-ва! Вов-ва!» дип йөри!

## Аю кебек

Чыгам да шугалакка,
Карыйм мин тирә-якка,
Бүтәннәр сыман мин дә
Шуып китәрмен кебек,
Куып җитәрмен кебек,
Узып китәрмен кебек!
Бассам тимераякка,
Һаман агач аяк ла...
Белмәгәчтен, нишлисең,
Монда мәзәк кеше син.
Аякларның икесе
Ике тарафка китә,
Мине бик кызык итә —
Чайкалам да торамын,
Лырк итеп утырамын...
Ай-һай, каты икән боз!
Дуслар үтә выж да выж,
Җитмәсә, үчеклиләр:
— Уңышлар ничек? — диләр, —
Әллә инде юри син
Аю кебек йөрисең!

Һай, рәхмәт төшкереләр,
Исемә төшерделәр —
Циркка барасым бар,
Аюлар карыйсым бар!
Циркта да тамаша:
Шугалакта лабаса
Аюлар уттай йөри,
Аюлар уктай йөри —
Тимераякта йөри!
Ничекләр көйләнгәннәр,
Ничекләр өйрәнгәннәр?!

Кызыгып карап тордым,
Уйланып та утырдым,
Оялып та утырдым,
Шул көннән соң ныклабрак
Күнегергә тотындым.
Максатым: өйрәнергә
Аю кебек йөрергә!

# КИНДЗЮЛИС[1] КИЛӘ ДӘ ӘЙТӘ...

## Костюм теккәндә

— Шундый яхшы һәм затлы материалдан бик начар костюм тегәсез бит?!

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Начар материалдан да тегеп карадык, костюмы барыбер шундый булды.

## Үзгәрми

— Безнең ашханәбездә быел биш директор, өч пешекче һәм ике калькулятор алмашынды.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Аның каравы, менюның бер дә үзгәргәне юк.

## Таксистка сорау

Статистика белән бик кызыксынып шөгыльләнүче берәү таксисттан сорый икән:

— Сезгә бик күп төрле профессия кешеләрен машинада йөртергә туры килә. Әйтегез әле, нинди пассажирлар күбрәк эләгә?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Безгә утырганнары күбрәк исерекләр була.

## Әллә өйдә дә йоклыйсызмы?

— Нишләп тагын эшкә соңардыгыз?—дип сорый директор үзенең бер хезмәткәреннән.

— Гафу итегез, йоклап калганмын.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Әллә сез өйдә дә йоклыйсызмы?

---

[1] Киндзюлис — хәзерге литва сатирик әдәбиятының зирәк һәм тапкыр мәзәкчесе, «Шлуота» журналы хезмәткәрләренең коллектив иҗатында әдәби герой.

## Һава хәле

— Минемчә, бүген һава нәкъ кичә синоптиклар әйткәнчә булды бугай.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Әллә сез прогнозлар бюросы ялгышмый дип беләсезме?

## Директор турында

— Сезнең директорыгыз, минемчә, бик яхшы кешедер?

— Зарланып булмый.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Зарланып кара—шул ук минутта эштән куачак.

## Эшкә алу

— Сез төнге каравылчы булып эшләргә телисез, алайса? — дип сорый директор.

— Әйе,—ди бер әби.

— Бик шәп булыр иде дә бит, ләкин сез бик карт инде.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Төнлә бит аның картлыгы беркемгә дә күренмәячәк.

## Кайда очрашырлар?

Арифметика дәресендә укучыларга мәсьәлә чишәргә кушыла.

— Шәһәрнең ике читеннән үзәккә таба ике йөк машинасы каршы-каршы юнәлештә килә. Берсенең тизлеге—сәгатенә 90, икенчесенеке—100 километр. Машиналар кай төштә очрашыр?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Автоинспекциядә очрашачаклар.

## Приемныйда сөйләшү

— Әйтә алмассызмы, иптәш, бу оешманың башлыгы бүген буш микән?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Әйе, буш ул хәзер. Кичә эшеннән алдылар.

## Эш урынын эзлә

— Кайларга гына китеп югалды икән лә минем балакаем? Шалтыратмаган җирем калмады: ресторанын да, милициясен дә, айныткычын да айкадым... инде тагын каян эзлим икән дип башларым ката...

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Ә син аның эшләгән урынына шалтыратып кара!..

## Ишеттермә

— Беркайчан да кешегә кусәк кутәрмә син, чөнки кайберәүләр тәнкыйть сүзен ишетмәс өчен хәтта чукрак булып кылана беләләр, ә берәүләрнең исә...
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Сине ишетүләре мөмкин.



## Ярыйсы вариант

— Сез бары тик минем мәетем аша гына бу газета бусагасын уза аласыз.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Шәп вариант бит бу, ә?!

## «Тавышланмагыз!»

Студентлар троллейбуста бик каты кычкырып-шаулап сөйләшәләр икән.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Тавышланмагыз! Монда сезгә лекция укымыйлар ич.

## Бердәнбер чара

— Бәлки сез чәч агармасын өчен нинди дә булса чара беләсездер?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Пеләш булырга кирәк!

## Этикет

— Нәрсә ул этикет?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Авызың ябык килеш исни белү дигән нәмәстә ул.

## Тыңлар өчен түгел...

— Музыка белән шөгыльләнергә улыгызны ник болай көчләп кушасыз. Аның тыңлау сәләте юк,—ди музыка мәктәбе укытучысы малайның әнисенә.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Ә ул бит музыканы тыңларга җыенмый да: без аның уйный белүен телибез.

## Ялдан кайткач

Ялдан кайткач, бер клубның художество җитәкчесе директорга рапорт бирергә ашыга:
— Карагыз нинди күңелле, клубыбыз тулы эшче бит!
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Әйе шул: алар клуб ремонтлыйлар.

## Соң түгел

Дәрескә соңга калып килгән бер укучыны пешекли укытучы.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Укырга бер вакытта да соң түгел.

## Курыкмагыз

Бер композитор чибәр дамаларга эч серен сөйли:
— Гениаль булу—ул үзе бер чир...
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Ә сез үзегез моңардан бер дә курыкмагыз, чөнки, һичшиксез, таза күренәсез.

## Ис китәрү

Берәүнең туган көненә барышлый кунаклар: «Хуҗаның исен нәрсә белән китәрик?» — дип киңәшәләр.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Бер шешә дә аракы алмыйча барыгыз.

## Иң яхшы вакыт

Бер кафеда ике кеше сөйләшеп утыра:
— Минем иң яраткан вакытым нәкъ менә шул үзе инде.
— Ә ник алай?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Чөнки бу вакыт—эшкә кире барырга инде соң, ә өйгә кайтырга әле иртә чак.

## Бәхетнең сере

Ике күрше ханым үзләренең хәл-әхвәлләре турында гәпләшә:
— Кичә безнең малай дүртенче каттан җиргә мәтәлде, әмма бер җиренә дә һич нинди зыян килмәгән.
— Чынлап та шулаймы?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Чөнки сез яңа йортта торасыз, ә төзүчеләр аны салып бетергәч дүртенче каткача өелгән чүп-чар калдырып киттеләр.

## Каян белсен

Йорт идарәсе башлыгы кабинетына каты йөгерүдән тыннары кысылган бер кеше килеп керә:
— Яңгыр ява башласа, минем бүлмәмне су баса. Бу хәл тагын күпме дәвам итәр икән?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Моны белергә метеоролог түгел ич ул.

## Ник автор юк?

— Автор! Автор! Сәхнәгә автор чыксын!—дип кабатлый тамаша залы, яңа спектакль карагач. Әмма пьеса авторы күренми.

Шул чакны Киндзюлис чыга да әйтә:

— Борчылмагыз, тамашачы иптәшләр. Пьесаны төзәткәндә анда авторның бер генә сүзе дә калмады.



## Автомат булырга теләү

Бер фабриканың ике эшчесе сөйләшә:

— Минем автомат буласым килә.

— Ник?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Чөнки аның күп вакыты эшсез уза, ә акчаны барыбер ала...

## Интригалы әсәр

Бер театрда яңа пьеса укыганнан соң, артистлар бик кызып бәхәсләшә башлыйлар.

— Бу әсәрдә бернинди интрига юк!—ди берәү.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Интрига дигәнегез рольләр бүлешә башлагач килеп чыгачак...

## Ник кермибез?

Бер төркем туристлар белән бергә Киндзюлис Вильнюс шәһәренә килә.

— Менә хәзер без бу каладагы иң борынгы сыраханә яныннан узабыз,—ди экскурсия йөртүче белгеч.

Шул чакны аның янына Киндзюлис килә дә сорый:

— Ә ни өчен узабыз гына?..

## Черек бау

Бау ныкмы икән дип сынарга теләп, ике өлкән агай аны икесе ике баштан тартып бик тиз өзәләр. Егылган урыннарыннан торгач, куанычлары эчләренә сыймый: янәсе, аларда да көч бар икән әле!

Шул чакта Киндзюлис килә дә әйтә:

— Черек бау өздегез бит сез.

## Кайсы җиңелрәк?

— Укуы һәм тәнкыйть итүе бик җиңел ул, ә менә үзең язып кара син китапны!—ди язучы бер тәнкыйтьчегә.

— Язуы һәм укуы җиңел, ә син менә тәнкыйтьләп кара!—дип каршы төшә тегесе.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Язуы һәм тәнкыйтьләве җиңел, менә сез, коллегалар, китапны укып карасагыз иде...

## Кайчы белән...

Хатынының пальтосын чистарткач, бер ир бик зур мактау ишетә:

— Инде дә әйбәт булган бит бу, тапларын ничек бетерә алдың шул хәтле яхшы итеп?—ди хатыны.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Кайчы белән эш итте бугай.

## Ата белән бала

Нәни бала әтисенә сорау бирә: «Сөйләшергә инде өйрәнгән кеше тагын нәрсә белергә тиеш була?»

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Дәшми тора белергә кирәк.

## Синнән кем чыгар?

Нәни бала урамда уйный. Әнкәсе аны өйгә чакыра, әмма тыңлата алмый.

— Үскәч синнән кем чыгар икән, балакай?—дип ачулана ана.

Шул чакны аның янына Киндзюлис килә дә сорый:

— Официант булыр бу,—менә дигән шәп һөнәр бит, ә?

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПЛЕНУМЫ

Совет язучыларының беренче Бөтенсоюз съезды булуга 40 ел тулу уңае белән 3—4 сентябрьдә Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында СССР Язучылар союзы правлениесе пленумы булды. Пленумда катнашучылар В. В. Гришин, К. Т. Мазуров, М. А. Суслов, П. Н. Демичев иптәшләрне алкышлап каршыладылар.

Пленумны кереш сүз белән СССР Язучылар союзының беренче секретаре Г. М. Марков ачты. СССР Язучылар союзы правлениесе секретаре Социалистик Хезмәт Герое Н. С. Тихонов доклад белән чыкты.

Пленумда Татарстан язучыларыннан Г. Ахунов, З. Нури, Г. Бәширов, М. Әмир һәм Х. Туфан катнашты.

## КамАЗда СЕМИНАРЛАР

Республикабыз иҗат интеллигенциясенең КПСС өлкә комитеты каршында даими эшләп килүче семинарының нәүбәттәге занятиесе сентябрь урталарында Чаллыда үткәрелде. Анда катнашкан күп санлы язучылар, композиторлар, рәссамнар, артистлар КамАЗдагы төзелеш объектларында булдылар, төзүчеләр белән очрашулар уздырдылар.

Язучылар алты төркемгә бүленгәннәр иде. Беренче ике төркемдәге тәҗрибәле әдипләр КамАЗдагы «Ләйсән» һәм «Орфей» әдәби түгәрәкләрендә булып, жирле авторлардан Х. Хөснуллин, Ә. Гайнуллин, Р. Юнусов, Р. Гыйззәтуллин, Е. Кувайцев, Н. Кандудина, Н. Олешков, В. Сушко, Н. Чапкино әсәрләрен тикшерделәр, яшь каләмнәргә матур-матур киңәшләрен бирделәр.

Г. Минский, М. Хәбибуллин, М. Әмир һәм В. Нуруллин җитәкчелек иткән башка төркемнәрдәге язучылар тулай торакларда очрашулар уздырдылар, үзләренең әсәрләре буенча үткәрелгән әдәби конференцияләрдә катнаштылар.

## БЕЗНЕҢ КУНАКЛАР

Июль аенда Казанга Эстония коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының культура бүлеге мөдире урынбасары язучы Анте Саар килде. Монда ул Бөек Ватан сугышы елларында эстон хәрби часте оешкан урыннар белән танышты, яңа әсәре өчен материал туплады.

*
* *

Чувашстан китап нәшрияты Татарстанда яшәүче чуваш һәм татар шагыйрьләренең шигырьләрен туплап, чуваш телендә «Хузан» («Казан») дигән альманах чыгарырга жыена. Чабаксардан килгән шагыйрь Михаил Сэниль, әнә шул альманахка керәчәк шигырьләрне тәрҗемә итү өчен сайлап алганнан соң, башкалабызның культура яңалыклары белән танышты.

*
* *

Мәскәү шагыйре тәрҗемәче Александр Говоров татар әдипләренең балалар өчен язылган шигъри үрнәкләре белән танышты. Киләчәктә ул аларны русчага тәрҗемә итәчәк.

*
* *

Яңа уку елы башланыр алдыннан Казан дәүләт университетында Польша студентлары өчен татар әдәбияты һәм сәнгатенә багышланган кичә үткәрелде. Кичәдә шагыйрь Г. Рәхим татар әдәбиятының бүгенге торышы турында сөйләде. Кунаклар шагыйрьләребездән Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, М. Зарецкий, филология фәннәре кандидаты Ф. Сафиуллина чыгышларын зур кызыксыну белән тыңладылар, яшь рәссамнарыбыз Э. Зарипов һәм Н. Әльменов картиналарын, рәсемнәрен яратып карадылар.

*
* *

В. И. Ленин образы илебездәге барлык иҗат көчләрен даими кызыксындырып тора. Күптән түгел генә Әзербайҗан язучысы Бәйрәм Гасанов та бөек юлбашчы эзләреннән Казанга килгән иде. Казанда ул Ленин булган урыннар белән танышып йөрде. Казан дәүләт университетында, Ленин музеенда һәм башка урыннарда булды. Аның теләге — юлбашчы турында яңа әсәр язу.

## ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

Август аенда Коми АССРда совет әдәбияты көннәре булып узды. Рус һәм илебездәге башка халыкларның әдипләре катнашында уздырылган бу әдәби бәйрәмгә Татарстан язучылары оешмасыннан Г. Ахунов барды.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ОТЧЕТЫ

29 августта язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булып узды. Анда коммунист-язучы, «Батыр егет», «Хикәяләр», «Сусыз дәрья» исемле китапларның авторы Габдулла Шәрәфинең иҗат отчеты куелды. Әдипнең иҗаты турында Татарстан язучылар союзы председателе Г. Ахунов доклад ясады. Фикер алышуларда катнашкан Б. Камалов, Д. Зөбәерова, А. Хәсәнова һ. б. иптәшләр, Г. Шәрәфи әсәрләренә уңай бәя биреп, киләчәктә аңа тагын да активрак иҗат итәргә кирәклеген әйттеләр.

## УТЫЗ ИМӘНИГӘ БАГЫШЛАП

Шушы елның 1 августында күренекле татар шагыйре һәм галиме Утыз Имәнинең тууына 220 ел тулды. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының чираттагы утырышы әнә шул датага багышланып уздырылды. Утырышта Утыз Имәнинең тормышы, иҗат юлы һәм аның әдәби мирасын өйрәнүнең бүгенге торышы турында институтның фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов доклад ясады. Докладтан соң фикер алышуларда филология фәннәре докторы Г. Халит, филология фәннәре кандидатлары Ш. Абилов, Б. Гыйззәт һ. б.лар катнашты. Алар Утыз Имәнинең татар әдәбияты тарихында әһәмиятле урын алып торуын билгеләп үттеләр, шагыйрьнең 225 еллык юбилеена аның әсәрләрен аерым җыентык итеп бастырып чыгарырга кирәклеген әйттеләр.

## ИЛҺАМЫБЫЗ — ИГЕНЧЕГӘ

Татар язучылар союзы менә берничә ел рәттән инде урып-җыю эшләренең барышын матбугатта яктырту буенча махсус бригада төзи. Быел әнә шул бригада составына кергән язучылардан Н. Дәүли Питрәч, Б. Камалов Чүпрәле, Х. Сарьян Куйбышев, Ф. Шәфигуллин Арча, С. Шакир Актаныш, Т. Камалиев Әгерҗе районнарында булдылар һәм алдынгы игенчеләребез турында очерк-мәкаләләр яздылар.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Минзәлә татар дәүләт драма театры үзенең яңа сезонын Габделхәй Сабитов әсәре буенча эшләнгән «Гарасат» исемле спектакль белән башлап җибәрде. Лена елгасы буендагы 1912 елгы тарихи вакыйгаларны чагылдыруга багышланган бу спектакльне Минзәлә, Чаллы, Түбән Кама, Зәй һәм нефть районнары тамашачылары яратып карадылар.

## ТЕАТР—НӘНИЛӘРГӘ

Казан дәүләт курчак театры быел кырыгынчы сезонын уздырды. Ул башка сезоннардан үзенең кызыклы спектакльләре, уңышлы гастрольләре белән аерылып торды. Гастрольләр Дагстанда, Киевта, Башкортстанда, Пермь өлкәсендә барды. Нәни тамашачылар Е. Чеповецкийның «Әй, бу Мыцык», П. Амосова һәм Е. Петрованың «Атаклы үрдәк баласы Тим маҗаралары» исемле әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр карадылар. Республикабызның Сарман, Актаныш, Минзәлә һәм башка районнарында Н. Фәттахның «Энҗеле үрдәк», Т. Миңнуллинның «Азат» пьесалары нигезендә эшләнгән спектакльләр күрсәтелде.

## АРТИСТ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

«Советская Россия» газетасы үзенең 1974 елгы 199-санында редакция хәбәрчесенең РСФСР һәм ТАССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров белән әңгәмәсен урнаштырды.

— Театр ул алкышлар һәм чәчәкләр генә түгел,— ди чирек гасыр буена меңнәрчә тапкырлар сәхнәгә чыгып, йөзгә якын рольдә уйнаган талантлы артист,— сәнгать ифрат киеренке эш. Минем үземә заманыбызның уңай герое образын тудыру аеруча ошый. Мин һәр вакыт шул юнәлештә эзләнергә тырышам.

## ФӘННИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР РАЙОННАРДА

Татарстан Дәүләт музееның бер төркем хезмәткәрләре җәйге айларда Лаеш, Балык бистәсе, Чистай, Чаллы районнарында булып кайттылар. Алар үзләре белән бергә, авылларда күргәзмәләр оештыру өчен, Дәүләт музееның сирәк әйберләр фондыннан кызыклы экспонатлар алганнар иде. Музейның фәнни работниклары Р. Трофимова, Ф. Нуретдинов, Л. Дмитриева, Н. Белова, И. Хөсәенов һ. б.лар «Ленин һәм Татарстан», «Ленин Казанда», «КамАЗ — бишьеллыкның бөек төзелеше», «Герой-шагыйрь Муса Җәлил» дигән темаларга лекцияләр укыдылар.

## ҺӘВӘСКӘР РӘССАМНАР

Бүгенге көндә безнең республикабызда 1500 дән артык үзешчән рәссам иҗат эше белән шөгыльләнә. Алар Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз күләмендә уздырыла торган күргәзмәләрдә катнашалар. 1973 елның ноябрендә Мәскәүдә булып үткән шундый күргәзмәдә якташларыбыз беренчелекне яулап алдылар. Анда катнашуга лаек дип табылган 48 әсәрнең 11 е Мәскәү халык иҗаты музеена тәкъдим ителде, 10 үзешчән рәссамга бүләкләр, 20 әсәргә беренче дәрәҗә дипломнар тапшырылды. Казанда һәм республикабыз районнарында яшь рәссамнар иҗатына багышланган күргәзмәләр уздыру матур традициягә әйләнеп бара. Быел җәй шундый күргәзмәләрнең берсе Мөслим культура йортында оештырылды. Экспозициягә йөздән артык картина куелган иде. Татарстанның гүзәл табигатен оста чагылдырган пейзажлар, рәсемнәр, ку-

ренекле игенчеләрнең, терлекчеләрнең, интеллигенция вәкилләренең портретлары бик күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итте. Күргәзмәдә инженер В. Кочунов, укытучы А. Свергузин, Арча районы агрономы А. Фомин, Әлмәттән Ф. Моркович иҗатларына аеруча югары бәя бирелде.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Тугандаш чуваш халкы татар язучыларының әсәрләрен яратып укый, аларның иҗаты белән һәр вакыт кызыксынып тора. Шушы олы ихтирамга җавап йөзеннән татар язучылары үзләре дә чуваш укучылары белән әледән-әле очрашып торалар. Сентябрь башларында Б. Камалов, Р. Гатауллин, Р. Әхмәтҗанов, К. Латыйпов һ. б. лар составындагы бер төркем язучылар Чувашстанның Батыр районында булдылар. Укучыларны яңа хикәяләре, шигырьләре белән таныштырдылар.

*

* *

Шагыйрьләрдән Г. Латыйп, Н. Дәүли, драматург Р. Ишморатова, прозаик Г. Шәрәфи, яшь шагыйрь М. Галиев һәм Татарстанның халык артисты Ә. Яһудин Питрәч районы авылларында колхозчылар һәм мәктәп балалары белән очраштылар.

*

* *

Өлкән драматург Р. Ишморат моннан 45 еллар элек Зеленодольск якларында колхозлар оештырып йөргән. Быел җәй шул районның Ленин, Ильич, Киров, Тукай, Вахитов исемендәге, «Искра» һәм «Совет» колхозларында булып, игенчеләр белән очрашты. Аның белән бергә барган М. Әгъләмов, Р. Ишморатова тыңлаучыларга шигырь һәм хикәяләрен укыдылар, очрашуларда ТАССРның атказанган артисткасы Җ. Сәләхова, үзешчән композитор З. Гыйбадуллин да катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Август аенда Лениногорск шәһәрендәге әдәбият берләшмәсе членнары җыелышы булды. Лениногорск шәһәренең яшь әдипләре зур күләмле проза әсәрләре язу өстендә эшлиләр. Нефтьче инженер Хәким Хәйруллин «Ургыл» исемле роман тәгәлләде. Җәмит Рәхимов «Өлешемә тигән көмешем» повестен һәм Түмән нефтен чыгаруда катнашучы якташларыбызга багышланган «Гасыр могҗизасы» исемле очерклар җыентыгын Татарстан китап нәшриятына тапшырды. Альберт Хәсәнов, Әсрар Галиев замандашларыбыз турындагы яңа хикәяләре һәм очерклары тупланган җыентыкларын әзерләп, язучыларның Әлмәт бүлегенә китерделәр.

Шәһәрнең әдәби берләшмәсе август аендагы утырышын шушы яшь каләмнәр иҗатына багышлады. Бу утырышта язучы Шамил Бикчурин үзенең иҗат тәҗрибәсе белән уртаклашты. Татарстан язучылар союзы Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Әдип Маликов, СССР язучыларының I Бөтенсоюз съезды ачылуга 40 ел тулуга бәйләп, татар совет әдәбияты ирешкән уңышлар турында сөйләде, республикабызның нефть районнарында яшәүче әдипләрнең иҗатларына тукталып үтте.

Яшь язучыларның иҗатларына багышланган җыелыш шулай ук Азнакай нефтьчеләр поселогында да уздырылды. Җыелышта Ә. Маликов, М. Хәсәнов һәм әдәбият берләшмәсе членнары чыгып сөйләделәр.

*

* *

Әлмәт язучылары узган айларда да күп кенә урыннарда укучылар белән очраштылар. Драматург Сәет Кәлметов, мәсәлән, районның Фрунзе исемендәге колхоз ындыр табагында һәм механизаторлар алдында чыгыш ясады. Язучы Рафаил Төхфәтуллин «Әлмәтбурнефть» идарәсе тарафыннан оештырылган «Бораулау осталары» көнендә катнашты. Шагыйрә Клара Булатова Түмән өлкәсендә булып, анда уздырылган әдәбият атналыгында катнашучылар белән бергә, моторлар заводы эшчеләре алдында шигырьләрен укыды, Түбән Варта һәм Мигион нефтьчеләр поселокларында яшәүче нефтьче якташларыбыз белән очрашты.

*

* *

Урып-җыю башланган көннәрдә Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты һәм район культура бүлеге белән берлектә, район колхозларында һәм совхозларында әдәбият атналыгы үткәрде. Елховой, Мәмәт, Кичучат, Салкын Алан, Кәләй авылларында язучылар механизаторлар, агитаторлар, китапханә хезмәткәрләре белән очраштылар. Кичен клубларда әдәби чыгышлар булды. Ә. Маликов, Г. Афзал, С. Сөләйманова, С. Кәлметов, К. Булатова игенчеләргә багышланган әсәрләрен укыдылар. Язучыларның автографлары белән китаплар сатылды.

*

* *

Нефтьчеләр көне уңае белән, Казан радиосыннан Әлмәт язучыларының чыгышлары оештырылды. Ә. Маликов, Г. Афзал, С. Сөләйманова һәм К. Булатова хезмәт кешеләренә, нефтьчеләргә багышлап иҗат ителгән яңа шигырьләрен укыдылар.

Татарстан радиосыннан шулай ук Азнакай әдәбият берләшмәсе членнары чыгышы да булды.

Тапшыруны язучы Мәхмүт Хәсәнов алып барды.

## ГДР ФИЛЬМНАРЫ ФЕСТИВАЛЕ

25 сентябрьдә Казанга телевидение һәм радио, кино работниклары Союзы вице-президенты режиссер Гюнтер Райш житәкчелегендәге ГДР кинематографистлары делегациясе килде. Делегация составында режиссер Ирис Гуснер, кинодраматург Курт Беликс, актер Джекки Шварц, актриса Микаэло Крайслер, режиссер Готфрид Кольдитц, актриса Эвелин Опочински иптәшләр бар иде.

Шул ук көнне СССР Кинематографистлары союзы секретаре Алексей Баталов житәкчелегендәге Совет киносы эшлеклеләре группасы да килде. Группа составында Ия Саввина, Тамара Кокова, Михаил Ножкин кебек күренекле актерлар, СССР Кинематографистлар союзының халыкара элемтәләр комиссиясе председателе урынбасары Леонид Булдаков, СССР Кинематографистлар союзының Идел буе бүлеге секретаре Вера Плотникова бар иде.

Татарстан башкаласының җәмәгатьчелек вәкилләре кунакларны жылы кабул итте. Аларны КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, партиянең Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, ТАССР Министрлар Советының кинофикация идарәсе начальнигы В. Н. Макаров һәм башка иптәшләр каршылады.

«Татарстан» кинотеатрында ГДР фильмнары фестивален ачу тантанасы булды. Кунаклар Чаллыда, Түбән Камада автогигант төзүчеләр һәм нефтехимия комбинаты коллективы белән очраштылар, үзләренең яңа хезмәтләрен күрсәттеләр. Бер үк вакытта фестиваль барышында хезмәт ияләре яңа совет фильмнары белән таныштылар. ГДР фильмнары фестивале 29 сентябрьгә кадәр дәвам итте.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Минзәлә дәүләт драма театры артисткасы *Ания Гарифулла кызы Фаттахова*га *Татарстан АССРның атказанган артисткасы* дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Музыка сәнгатен пропагандалау өлкәсендә күп еллар буе нәтиҗәле эшләве өчен Казан телевидение студиясенең өлкән редакторы *Фәүзия Габдрахман кызы Бурнашева*га *Татарстан АССРның атказанган культура работнигы* дигән мактаулы исем бирелде.

## ЖУРНАЛИСТЛАР СӘЯХӘТТӘ

21 сентябрьдә Татарстанның газета-журнал редакцияләре, радио, телевидение, китап нәшрияты журналистлары республикабызның Куйбышев районында булдылар. Татарстан журналистлар союзы тарафыннан оештырылган бу сәяхәттә катнашучыларны КПССның Куйбышев район комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының район Советы житәкчеләре каршылады. Алар районның үсеш перспективалары турында сөйләделәр, шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныштырдылар.

Шул ук көнне журналистлар Болгар заповеднигында булдылар, тарихи истәлекләрне карадылар.

## ПЕРМЬЛЕЛӘР ЯНЫНДА

Җырчы һәм композитор Мәсгут Имашев Пермь һәвәскәрләре белән күптәннән бирле тыгыз бәйләнештә тора. Кайчандыр ул биредә Свердлов исемендәге культура сараеның татар үзешчән көчләренә житәкчелек иткән. Моннан ике ай ярым чамасы элек М. Имашев укытучыларның белемен күтәрү институтына килгән тамашачылар алдында чыгыш ясады. Ул музыка һәм заман, хәзерге көйләр һәм профессиональ сәнгать турында мавыктыргыч итеп сөйләде. Соңыннан куелган концертта аның үз әсәрләре дә башкарылды.

## НӘФИС СҮЗ КИЧӘСЕ

Казандагы М. Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркы нәфис сүз остасы, Татарстанның Халык артисты Әзәл Яһудин иҗатына багышланган кичә үткәрде. Бу кичә «Яшәү рәхәт, яшәү күңелле» дип исемләнгән иде. Артист рус һәм татар язучыларының юмористик шигырьләрен, хикәяләрен укып, тамашачыларның тирән ихтирамын казанды.

# 1974 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

**КПСС өлкә комитетында һәм ТАССР Министрлар Советында. 1974 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен бирү турында. № 6.**

**1973 елда «Казан утлары» журналы бүләген алган авторлар. № 1.**

## ПРОЗА

**Г. Ахунов. Ардуан батыр.** Повесть. **№ 1, № 2.**
**Г. Бакиров. Балалар дөньясы.** Парчалар. **№ 4.**
**Ә. Баянов. Тау ягы повесте.** Повесть. **№ 9.**
**А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар.** Повесть. **№ 8.**
**Т. Гыйниятуллин. Солдат үлеме.** Хикәя. **№ 10.**
**Д. Зөбәерова. Кыр чәчәге.** Повесть. **№ 12.**
**Р. Исаев. Үрнәкле кияү.** Хикәя. **№ 11.**
**Х. Камалов. Һәркемнең гомере бер генә.** Роман. **№ 3, № 4, № 5.**
**Ә. Камалов. Олы Әкбәрнең кече Әсгаре.** Хикәя. **№ 6.**
**Р. Кутуй. Яңгыр шавы.** Хикәя. **№ 11.**
**А. Мифтахетдинов. Хан-Гәрәйнең сәер көннәре.** Хикәя. **№ 11.**
**Ф. Мостафин. Кенәриле Галимҗан.** Хикәя. **№ 8.**
**К. Мәргән. Солдат хаты.** Хикәя. **№ 3.**
**М. Насыйбуллин. Телсез шаһитләр.** Повесть **№ 4.**
**В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң...** Повесть. **№ 2, № 3.**
**Ү. Саттаров. Кызым хикәяләре.** Хикәя. **№ 1.**
**Ү. Саттаров. Айлы төндә.** Хикәя. **№ 6.**
**И. Туктар. Җөмләләр. № 4, № 11.**
**Р. Төхфәтуллин. Акбүз ат.** Повесть. **№ 1.**
**Н. Хәмиди. Фәүзия кияүгә чыга.** Хикәя. **№ 1.**
**Хәким Хәйруллин. Ургыл.** Роман. **№ 10, № 11, № 12.**
**Ф. Хөсни. Алтын эзләүчеләр.** Повесть. **№ 6.**
**С. Шәрипов. Сөлек.** Хикәя. **№ 7.**
**М. Юныс. Тозлы җил.** Повесть. **№ 7, № 8.**

## ПОЭЗИЯ

**Ш. Анак. Тыйнак табын.** Шигырьләр. **№ 12.**
**Н. Арсланов. Мин тауларга карыйм.** Шигырьләр. **№ 6.**
**К. Булатова. Ана җыры.** Шигырьләр. **№ 11.**
**Г. Афзал. Салават батыр.** Шигырьләр. **№ 1.**
**Г. Афзал. Китаплар язмышы.** Шигырьләр. **№ 9.**
**Р. Вәлиев. Туган як.** Шигырьләр. **№ 2.**
**Ф. Галиева. Урамнар була бормалы.** Шигырьләр. **№ 3.**
**М. Галиев. Пискарев каберлегендә.** Шигырь. **№ 6.**
**Ш. Галиев. Сигезьюллыклар.** Шигырьләр. **№ 8.**
**Р. Гәрәй. Җайлашмыйбыз.** Шигырьләр. **№ 2.**
**Р. Гәрәй. Васыятен дә әйтеп калдырмаган.** Шигырьләр. **№ 12.**
**Ә. Давыдов. Галәмнәргә хатлар язу.** Шигырьләр. **№ 10.**

С. Кудаш. Атлыйм әле. Шигырьләр. № 10.
Р. Кутуй. Мамык оча! Шигырьләр. № 11.
Н. Мадьяров. Ник тынычлык бетми урнашып ла! Шигырьләр. № 10.
Ш. Маннапов. Китә чын Кеше дөньядан... Шигырь. № 11.
Ш. Маннур. Гомер белән гомер арасы. Поэма. № 12.
Р. Мингалимов. Җитди итеп әйтәм. Шигырьләр. № 1.
Р. Мингалимов. Игенче егеткә. Шигырьләр. № 10.
Р. Миңнуллин. Таулар. Шигырьләр. № 7.
Э. Мөэминова. Туган илем минем. Шигырьләр. № 5.
З. Нури. Май ае балладасы. Шигырьләр. № 6.
М. Румянцева. Чал чәчләр турында баллада. № 3.
Г. Рәхим. Бу дөньяда. Шигырьләр. № 6.
Г. Садә. Тимерче. Шигырьләр. № 1.
Ф. Сафин. Ташчы. Шигырьләр. № 7.
К. Сибгатуллин. Кибәнче карт. Баллада. № 10.
Ә. Синеголов. Таулар иле. Шигырьләр. № 3.
Д. Сирай. Авыл поэмасы. Поэма. № 2.
С. Сөләйманова. Эңгер төшеп килгән кышкы көннең. Шигырьләр. № 1.
М. Сөндекле. Көндәлек дәфтәреннән. Шигырьләр. № 9.
Р. Солнцев. Ул чакта. Шигырьләр. № 11.
Х. Туфан. Багышлаулар дәфтәреннән. Шигырьләр. № 5.
Х. Туфан. Багышлаулар дәфтәреннән. Шигырьләр. № 7.
Е. Уткин. Кырда күксел томан... Шигырьләр. № 11.
Р. Фәйзуллин. Бу беренче пароходлар. Шигырьләр. № 4.
Р. Харис. Мәхәббәт сукмагы. Шигырьләр. № 8.
С. Хәким. Дәверләр капкасы. Поэма. № 5.
Ф. Чанышева. Бер төенчек идең. Шигырь. № 1.
М. Шабаев. Ялта аһәңнәре. Шигырьләр. № 3.
Л. Шакирҗанова. Үземә кайтып төштем. Шигырьләр. № 3.
Ф. Шәфигуллин. Җидегән. Шигырьләр. № 7.
Ф. Яруллин. Яңгыр. Шигырьләр. № 4.
Ф. Яруллин. Экраннарда Павел Корчагин. Шигырьләр. № 11.
Роберт Әхмәтҗанов. Тормыш арбасы. Шигырьләр. № 7.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Х. Вахит. Мәхәббәтең чын булса. Пьеса. № 9.

## ДӨНЬЯ КЛАССИКЛАРЫННАН ТӘРҖЕМӘЛӘР

Пабло Неруда. Мин сиңа эндәшәм. Шигырьләр. № 7.
Имадетдин Нәсими газәлләре. № 3.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Ә. Атнабаев. Горурлык. Шигырьләр. № 6.
Ш. Биккол. Фаҗигадән туган дүрт җыр. Шигырьләр. № 5.
Б. Исхаков. Тукай. Шигырьләр. № 12.
Г. Рамазанов. Райнис. Шигырьләр. № 12.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Х. Гайнетдинов. Май яңгыры. Шигырьләр. № 4.
Я. Игәнәй. Сөрелгән җир ята күпереп... Шигырьләр. № 11
Н. Кәримова. Дусларым-иптәшләрем. Парчалар. № 1.

**Р. Низамиев.** Ил кайгысы — минем кайгым. Шигырьләр. № 11.
**Г. Шәмсетдинов.** Көз. Шигырьләр. № 11.
**Н. Әхмәдиев.** Йөз чишмәнең суын эчеп... Шигырь. № 11.

## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Х. Халиков.** Җәйге яңгыр. Шигырьләр. № 2.
**Ш. Галиев.** Бакчада бәхәс. Шигырьләр. № 3.
**Ш. Галиев.** «Курыкма, тимим!» Шигырьләр. № 12.
«Яшь ленинчы» бездә кунакта. Шигырьләр. № 8.

## ОЧЕРКЛАР ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

**И. Алексеев.** Олы юлга чыкканда. № 3.
**Д. Вәлиев.** Җамалиевлар династиясе. № 1.
**Ә. Гайнуллин.** Ашкынулы булсаң... № 2.
**М. Зарипов.** Тавык кошмы, түгелме! № 9.
**Д. Зөбәерова.** Әманәт. № 1.
**Л. Ихсанова.** Сәрвәрнең туган көне. № 12.
КамАЗ елъязмасы № 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12.
**Э. Касыймов.** Күршем Габделхәй буровоенда. № 11.
**М. Маликова.** Күлләр үзәге Самотлор. № 5.
**Ә. Маликов.** Язмышлар. № 7.
**Т. Миңнуллин.** Тау башында бардыр бер район. № 8.
**Ф. Насыйров.** Бәйрәм алдыннан. № 6.
**К. Рәхим.** Табигать белән очрашканда. № 1.
**Ш. Садыйков.** Председатель. № 12.
**Ш. Хамматов.** Матбугатта катнашу — язучының иҗтимагый вазифасы. № 11.
**М. Ханнанов.** Син кем, Саматов!.. № 8.
**Р. Хисмәтуллин.** Бәйрәм белән, дуслар! № 11.
**Ф. Хәбибуллин.** Ышанып атлыйбыз. № 7.
**М. Хөснимәрдәнов.** Сиңа тартыла күңел. № 8.
**М. Хөснимәрдәнов.** Күңелең керсез булса. № 10.
**Г. Шәйхиев.** Буа каһарманнары. № 12.

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

**И. Беляев.** Солдат төймәсе. № 9.
**М. Зәкиев.** Ай һәм йолдыз яктысында. № 1.
**С. Сөләйманова.** Әс-сәлями, Суфият! № 5, 6.
**А. Хәсәнова.** Япония... нинди ул! № 4.

## ӘДӘБИ МИРАС

**Т. Гыйззәт.** Чордашлар, каләмдәшләр. № 4.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**А. Айнетдинов.** Батырлар эзеннән. № 2.
**И. Ахунҗанов.** Шигърият юллары чатында. № 7.
**М. Вәлиев.** Безгә ак болыт булырга язмаган шул... № 6.
**Т. Галиуллин.** Буыннар һәм язмышлар. № 5.
**В. Гончаров.** Фронтташ дустым. № 2.
**И. Илялова.** Академия театры сәхнәсендә — татар классикасы. № 8.

Р. Мостафин. Яңа теманы үзләштерү юлында. № 1.
З. Нури. Яшьләргә — яшел урам. № 3.
Х. Сарьян. «Алай да була!» — булмасын. № 2.
Ф. Хатипов. Җаваплылык. № 4.
А. Шапиро. Сәхнәдә бүгенге көн темасы. № 4.
Л. Юдкевич. Татарстанда яшәүче рус язучылары иҗаты. № 5.
А. Әхмәдуллин. Заман героен эзләү юлында. № 4.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Г. Ахунов. Татар совет прозасының офыклары. № 10.
Н. Дәүли. Халык алдында җаваплы эш. № 10.
Т. Журавлев. Уңышлар һәм бурычлар. № 10.
Л. Ихсанова. Матурлык һәм батырлык дөньясында. № 10.
С. Михалков. Халыкчан әдәбият, тормышчан әдәбият. № 10.
Т. Миңнуллин. Шатлыклар һәм борчулар. № 10.
Ф. Миңнуллин. Тәнкыйтьнең төп бурычлары. № 10.
Р. Мостафин. Әдәби тәнкыйтьнең уңышлары һәм бурычлары. № 10.
З. Нури. Заман белән бергә. № 10.
Татарстан язучыларының VIII съезды резолюциясе. № 10.
Р. Фәйзуллин. Югары идеяле поэзия өчен. № 10.
С. Хәким. Җаваплылык хисе. № 10.
И. Юзеев. Тукай, Җәлилләр биеклегенә. № 10.

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Х. Курбатов. Иректе шигырь. № 7.
Р. Мостафин. Үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат. № 8.
Ф. Мусин. Реализм юлыннан. № 11.
Ә. Мәхмүдов. Муса Җәлилнең тәнкыйть эшчәнлеге. № 8.
Н. Хисамов. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының халыкта яшәеше. № 9.
С. Шәйдуллин. Хикмәт инкарь итүдә генәме! № 5.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ү. Гыймадиев. «Чикерткә» — татар телендә беренче сатирик журнал. № 2.
Ф. Ибраһимова. «Тәрбиятел этфаль» һәм «Ак юл» журналларында балалар әдәбияты. № 12.
Ф. Махиянов. Колхозчы шагыйрь Г. Насыйров. № 2.
Х. Миңнегулов. Әхмәд Үргәнҗи һәм аның ике чордашы. № 7.
М. Мөлеков. «Галиябану» ничек язылган... № 8.
С. Рәимова. Г. Ибраһимовның бер хикәясе турында. № 5.
С. Хафизов. Онытылган бер әсәр турында. № 5.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. Абдуллин. Дини тәгълиматка һәм суфичылыкка каршы. № 2.
Я. Абдуллин. Иҗтимагый яңарышны яклап. № 10.
Ф. Кадыйрова. Сәнгатькә багышланган гомер. № 7.
Г. Казанский. Тәрҗемәи хәлем. № 7.
Ә. Кәримуллин. Татар типографияләре тарихыннан. № 9.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

**И. Абдуллин. Әдәби тел тарихы һәм бүгенге көн. № 6.**
**С. Алишев. Татарстандагы авыл исемнәре. № 1.**
**И. Ахунҗанов, В. Зеленков. Паустовскийның гуманизмы. № 5.**
**И. Вәлитов. «Эпик жанрлар». № 12.**
**М. Галиев. Җилкәннәр бирешмәс әле. № 4.**
**М. Галиев. Гомернең июне. № 9.**
**Н. Гамбәров. Гөрләвекләр яз алып килә. № 7.**
**Ә. Дәминов. Учак урыннары. № 4.**
**А. Литвин. Кызыллар һәм аклар. № 7.**
**Т. Миңнуллин. Тәнкыйтьчеләр өлгергәнче. № 3.**
**Р. Нәфиков, М. Мөлеков. Үткән гасырларга сәяхәт. № 6.**
**Р. Салихов. Тыйнак геройлар. № 11.**
**Х. Сарьян. Кыскалык — әдәби осталыкның бер шарты. № 3.**
**Ф. Сафиуллина. Язучының тел осталыгы һәм тәрҗемә. № 9.**
**Р. Фәйзуллин. Китап укыганда. № 12.**
**Ф. Урманчеев. Фикер гармониясе. № 8.**
**Ф. Хатипов. «Канатланыр чак»ның яңа варианты. № 8.**
**Ф. Хатипов. Тарихыбызның поэтик сәхифәсе. № 1.**
**Ф. Хатипов. Керәшче геройны яклап. № 2.**
**Ф. Хатипов. Р. Төхфәтуллин повестьлары. № 11.**
**Г. Шәрәфетдинов. Арадан бер һәйкәл. № 12.**
**Р. Ширияздановы. Сибелә чәчәк җилләр искәндә. № 5.**

## БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Р. Галявин. Олылар да яратып укырлык. № 8.**
**Р. Мостафин. Былбыл Хәбир чишмәсе. № 2.**
**Н. Мәҗитова. Шәрыкны өйрәнү буенча яңа хезмәт. № 2.**

## СӘНГАТЬ

**М. Глухов. Эзләнүләр җимеше. № 7.**
**М. Зарипов. Биеклекләр. № 8.**
**Ә. Рәшитов, Г. Шәрәфетдинов. Сөйкемле сөяге бар. № 6.**
**Ш. Рахманкулов. Заһид Хәбибуллин. № 12.**
**З. Шаһиморатов. Нөнәгәр кызы. № 11.**

## ЛЕНИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦ-ФАШИСТ ИЛБАСАРЛАРЫН ТАР-МАР ИТҮГӘ 30 ЕЛ

**Ленинград өчен сугышларда. № 2.**

## ИСТӘЛЕКЛӘР

**Л. Бадыйкшан. Ерак диңгездә. № 5.**
**Г. Кайбицкая. Ильяс Әүхәдиев — музыкант. № 7.**
**Ф. Камалова. Халыкчан моңнар. № 7.**
**Г. Минский. Дустым турында. № 3.**
**А. Шамов. Бер китапның тарихы. № 11.**

ӘДӘБИ БӘЙРӘМНӘР

Р. Төхфәтуллинга 50 яшь. № 1.

Шәриф Камалның тууына 90 ел

Г. Кашшаф. Иҗат портретына штрихлар. № 2.
Юбилярларны котлыйбыз! № 2.

Самат Шакирга 50 яшь

Һаман да тынгысыз. № 4.

Х. Ярмигә 70 яшь

И. Надиров. Татар совет фольклористикасының аксакалы. № 5.

Ә. Мөэминовага 50 яшь. № 5.

М. Сөндеклегә 70 яшь

С. Сафуанов. Күңелендә — ике халык моңы. № 9.

А. С. Пушкинның тууына 175 ел

А. С. Пушкин. Шигырьләр. № 9.

Сәйфи Кудашка 80 яшь

С. Хәким. Олылык. № 10.

Нур Гайсинга 60 яшь. № 11.

Шәйхи Маннурга 70 яшь

З. Рәмиев. «Яши алмыйм шул мин янмыйча». № 12.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

И. Абдуллин. Киң колачлы галим. № 12.
Ф. Вәлиева. Профессор Мөхетдин Корбангалиев. № 1.
Р. Ширияздaнов. Атаклы гармунчы-музыкант. № 12.
Фәрит Яруллин. № 1.
Камил Якубовның тууына 80 ел. № 5.
«Ялкын» журналына 50 ел. № 5.

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНӘ 250 ЕЛ

А. Әхмәдуллин. Олы фән юлында. № 5.

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Л. Мәхсүмова. Татар-үзбәк әдәби мөнәсәбәтләре. № 6.

## ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Ф. Сафиуллина. Тел байлыгы — халыкта. № 4.**

## ӘДӘБИ КОНСУЛЬТАЦИЯ

**Ш. Әхмәдуллин. Сурәтле фикер. № 12.**

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

**Г. Әпсәләмов. Кояш тотылганда табылган хәзинә. № 2, 3, 4.**

## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

**Г. Рамазанов. Үкендермәс мине үткән гомерем. № 2.**

## УКУЧЫ ТРИБУНАСЫ

**Ш. Әхмәдуллин. Киләчәкне уйлап. № 1.**

## МАТБУГАТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Анкета битләреннән. № 3.**

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Е. Гортинский. Арктикага сәяхәт. № 7.**
**М. Елизарова. Пушкин Казанда. № 11.**
**Г. Саттаров. Исемнәр-атамалар сөйли: болгар-татар авыллары. № 11.**
**С. Червонная. Яшь рәссам. № 6.**
**Л. Шәйдуллина. Ислам динендә изге хатыннар культы. № 6.**

## «ЧАЯН» БҮЛЕГЕ

**Киндзюлис килә дә әйтә...** Мәзәкләр. **№ 12.**
**Ш. Рахманкулов. Габрово мәзәкләре. № 6.**
**Пудэш Патян хикмәтләре. № 11.**
**Татарстан язучыларының стена газетасы «Тынгысыз каләм» бездә кунакта. № 5.**


## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ РӘССАМНАР ИҖАТЫНДА


**Укучылар сүзе. № 6, № 10.**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.**
**Таныш булыйк. № 2.**
**Н. Җиһанов музыкасы. С. Хәким сүзләре. Өзелгәнсең сиреньнән. № 3.**
**А. Монасыйпов музыкасы. Г. Зәйнашева сүзләре. Могҗиза. № 12.**

# МОГҖИЗА

АЛМАЗ МОНАСЫЙПОВ музыкасы. ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА сүзләре.






Иртә торсам, күңел нидер
көтә, сизә,
Булыр кебек бер могҗиза,
бер могҗиза!

Кушымта: Сокланудан ярсу йөрәк
ничек түзә!!
Бу дөнья үзе бер могҗиза,
бер могҗиза!

Су буенда берәү җырлый,
үзәкне өзә.
Моңлы җырлар бер могҗиза,
бер могҗиза!

Кушымта.

Гашыйкларга бәхет теләп,
язлар уза.
Мәхәббәт ул бер могҗиза,
бер могҗиза!

Кушымта: Сокланудан ярсу йөрәк
ничек түзә!!
Бу дөнья үзе бер могҗиза
бер могҗиза

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

1975 ел өчен газета-журналларга язылу айлары үтеп бара.

Сез инде «Казан утлары» журналы өчен алдагы елга язылгансыздыр дип өметләнәбез.

Кайбер сәбәпләр белән әлегә кадәр язылырга өлгермәгән булсагыз, Сез моны якын көннәрдә эшли аласыз.

«Казан утлары» журналына, яңа ел башлангач та, елның теләсә кайсы аеннан башлап язылырга мөмкин.

Яңа елда журналыбызның беренче саны Мәхмүт Хәсәновның **«Хәдичә»** исемле әсәре белән башлана. Нури Арсланов, Сәҗидә Сөләйманова, Хәкимҗан Халиков шигырьләрен дә шушы саннан укырсыз.

1975 елда Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 30 ел тула. Шул уңай белән «Казан утлары» журналы, беренче саннан башлап, «Бөек җиңүгә 30 ел» дигән рубрика ача һәм анда һәр сан саен очерклар, истәлекләр, документлар, фотосәсемнәр һ. б. күп төрле материаллар урнаштырачак.

Республикабыз тормышына багышланган рецензияләр һ. б. күп төрле материаллар да Сездә зур кызыксыну уятыр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА